ISSN 0206—4189

казан утлары

9.2003

КАЗАН ШӘҺӘРЕНӘ—1000 ЕЛ

Болак елгасы

Болак елгасының Г. Камал театры бинасы ягыннан күренеше

Үткәнебез һәм бүгенгебез. Бер үк ноктадан бер гасыр аерма белән төшерелгән фоторәсемнәр.

Хаҗи Абдулла Дубин коллекциясеннән.

Казан утлары
Qazan utları

2003

9

(971)

ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:

Татарстан хөкүмәте,
Татарстан Язучылар берлеге,
редакциянең хезмәт коллективы

БАШ МӨХӘРРИР

Равил Фәйзуллин

ИДАРӘ:

Харрас Әюпов
Зилә Вәлиева
Мөдәррис Вәлиев
Фоат Галимуллин
Тәлгат Галиуллин
Миркасыйм Госманов
Алмаз Гыймадиев
(җаваплы сәркатип)
Флүс Латыйфи
(баш мөхәррир урынбасары)
Мирза Мәхмүтов
Туфан Миңнуллин
Хатип Миңнегулов
Гәрәй Рәхим
Факил Сафин
Ренат Харис
Зиннур Хөснияр
Розалина Шаһиева

Мөхәррирләр: **Мансур Вәли, Наис Гамбәр, Рәдиф Гаташ, Марат Закир, Камил Кәримов, Марс Шабаев.**

Гамәли хезмәткәрләр: **Гөлзадә Бәйрәмова, Лилия Гатауллина, Флера Сабирова, Тәслимә Сибгатуллина, Альбина Сибгатуллина, Тәгъзимә Шиһабиева.**
Исәп-хисап бүлеге: **Асия Рәхимова** (баш бухгалтер), **Эльвира Камалова.**

420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.
Баш мөхәррир — 92-38-60.
Баш мөхәррир урынбасары — 92-36-49.
Җаваплы сәркатип һәм компьютер үзәге — 43-56-12.
Бүлекләр: шигърият, фән, сәнгать — 92-38-61,
чәчмә әсәрләр, хатлар, әдәби тәнкыйть — 92-39-63,
гамәли хезмәткәрләр — 92-39-65.
Исәп-хисап бүлеге — 92-93-16.
Факс — (8432) 43-56-12.
E-mail: kazanutlari@telebit.ru.

КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

Бу санда

ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

Ркаил ЗӘЙДУЛЛА. Сәер сөю сурәте. *Шигырьләр* 5
Камил КӘРИМОВ. Сакау күке. *Роман (Ахыры)* 9
Флера ГЫЙЗЗӘТУЛЛИНА. Милли моң. *Шигырьләр* 84
Флүс ЛАТЫЙФИ. Себер хикәяте. *Хикәя* 87
Бикә РӘХИМОВА. Болгарыма барам әле... *Шигырьләр* 95
Рафис КОРБАН. Бишек җыры. *Шигырьләр* 99

ӘДӘБИ МИРАС

Флора ӘХМӘТОВА-УРМАНЧЕ. Документларның да үз язмышлары 102
ИДЕГӘЙ. Татар халык дастаны 106

ПУБЛИЦИСТИКА

Нурулла ГАРИФ. Авылым кайтавазы 136

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Суфиян ПОВАРИСОВ. Акыл һәм хис дулкыны *(Роберт Миңнуллин публицистикасына бер караш)* 140
Рөстәм ЗАРИПОВ. Кашка тәкәме, кәҗә тәкәсеме? 145

ФӘН

Дөррия РАМАЗАНОВА. Ишәле авылы җырлары турында 148

ТАРИХ

Раиф МӘРДАНОВ, Ирек ҺАДИЕВ. Әгерҗе төбәге тарихы 159

СӘНГАТЬ

Дания ГЫЙМРАНОВА. Түгәрәк дөнья уртасында 175

КОРЪӘН ТАТАР ТЕЛЕНДӘ

48–Фәтех (Жиңү) сүрәсе 183

ЮМОР-САТИРА

Резеда ШӘРИПОВА. Шул кирәк аларга! 189
"Казан утлары" архивыннан 186
Язучылар берлегенең яңа әгъзалары 188
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан 190

В НАШЕМ НОМЕРЕ:

Журнал чыгадит один раз в месяц

"Проза и поэзия": роман К. КАРИМОВА "Картавая кукушка" (окончание); рассказ Ф. ЛАТЫФИ "Сибирская быль"; стихи Р. ЗАЙДУЛЛЫ, Ф. ГИЗЗАТУЛЛИНОЙ, Б. РАХИМОВОЙ, Р. КУРБАН.
"Литературное наследие": Одна из версий тат. нар. эпоса "Идегей" (с предисловием Ф. Ахметовой-Урманче.)
"Публицистика": Н. ГАРИФ. "Зов родной деревни".
"Литературная критика": статьи С. ПОВАРИСОВА о публицистике Р. Миннуллина и Р. ЗАРИПОВА о рассказах в журнале "Казан утлары".
"Наука": Д. РАМАЗАНОВА. "Песни деревни Ишале".
"История": статья Р. МАРДАНОВА, И.ХАДИЕВА "История Агрызского края".
"Искусство": статья Д. ГИМРАНОВОЙ об артисте театра им. Г. Камала А. Хафизове.
Коран на татарском языке.
"Юмор-сатира": юмористический рассказ Р. ШАРИПОВОЙ.
Из архива журнала.
Новые члены союза писателей.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: работа художников Р. МИННЕБАЕВА И В. ШАЙХУТДИНОВА "Великий шелковый путь"; писатель Ф. Зиятдинов.

IN OUR ISSUE:

The magazin edits monthly

"Prose and poetry": K. KARIMOV'S novel "Cuckoo, which speak with a burr" *(ending)*, F. LATIFY'S story "Siberian fact"; the verses of R.ZAYDULLA, F. GIZZATULLINA, B. RAKHIMOVA, R. KURBAN.
"Literary legacy": Version of Tatar national epos "Idegey" (with F. AKHMETOVA-URMANCHE'S preface).
"Publicism": N.GARIF "Summons of native village".
"Literary criticism": S. PAVARISOV'S articles about publicism of R. Minnullin and R.ZARIPOV about stories in "Kazan utlary" magazin.
"Scince" D. RAMAZANOVA "Songs of Ishale village".
"History": article of R. MARDANOV, I. HADIEV "History of Agriz land".
"Art": D. GIMRANOVA'S article about artist of G. Kamal theatre A. Khafizov.
Koran in Tatar language.
Humour and satire: R. SHARIPOVA'S humorous story.
New member of writers Union.
From magazin archives.
The diary of social and cultural life.
On our covers: work of artists R. Minnebayev and B. Shayhutdinov "The Great silk way", writer F. Ziatdinov.

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кулъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 19-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

Журнал редакциянең компьютер үзәгендә жыелды һәм битләргә салынды.
Басарга кул куелды 21.08.2003 ел. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70X108$^{1}/_{16}$.
Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8). Тиражы 7031 . Заказ Я—575
Журнал Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән.
Теркәлү таныклыгы № 7.

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 2003 ел.

Ркаил Зәйдулла

СӘЕР СӨЮ СУРӘТЕ

Түрклəр

Да, скифы мы.
А. Блок.

Түрклəр без!—
Кысан бу дөньяга
Тудырган да безне Ашина,
Җилдергəнбез җитез тулпарларда
Җилләр, зилзиләләр каршына.

Түрклəр без!—
Күзебез дə хəтта
Ук төзəргə диеп уелган.
Офыкларда югалабыз, чыгып
Тормыш дигəн затсыз уеннан.

Түрклəр без!—
Дөм караңгы төндə
Дала бүресенең юлдашы.
Таш диварлар кыса хəзер җанны,
Ерагая Күлтəгин ташы.

Түрклəр без!—
Хəтер корбаннары:
Күзне йомып тып-тын тор гына,
Йөз меңнəрчə кылыч күтəрелə,
Һəм төмəннəр яуга ыргыла.

Ркаил ЗӘЙДУЛЛА (*1962*)–шагыйрь, прозаик, драматург; *"Кояшлы кызлəр", "Урыс кышын озату", "Ил" һ.б. китаплар авторы. Казанда яши.*

Түрклəр без!—
Аларның да əле
Иң чыдамы икəн лəбаса!—
Татар атын авыр аркан белəн
Өстерибез гасырлар аша.
Түрклəр без!—
Кеше арбасында...
Күлдан төште күптəн дилбегə.
Сиздермичə əрнеп күз ташлыйбыз
Дөнья дигəн атның биленə.

Түрклəр без!—
Урман җəяүлесе
Адымнарын тыеп атласын!—
Арган җайдак камчы сабы белəн
Кага яңа гасыр капкасын.

Күргəзмə

Хəрəкəттə туктап калган сылу:
Мизгел булып үтəр гасырлар,
Мөлдерəтеп күзен тукымада,
Рəссамыннан бер көн җан сорар.

Тими микəн сөт тəненə аның
Ул төннəрнең шыксыз салкыны?
Һəрбер тыннан, һəрбер ишарəдəн
Күləгəлəр куя кымшанып.

Татар кызын—шул мəңгелек ярны—
Яратып ул судан, утлардан,
Кайсы яудан йолып алган икəн,
Кайсы золымнардан коткарган?

Бүтəн телдə сокланалар аңа,
Үзгə күзлəр бирə бəясен.
Татар кызы кан тамырын түгел,
Телебезне хəзер бəйлəсен.

Туктап калган əнə хəрəкəттə.
Мизгел булып үтəр гасырлар.
Мөлдерəтеп күзен рəссамына,
Кайсы телдə сылу җан сорар?

Чəчеп ташлар безне Ахырзаман,
Йə җил белəн килеп, йə силдə...
Урманченың җаны иңəр кызга,
Дəвам кирəк булгач нəселгə.

Килəчəккə хат

Сəлам, Такташ!
Бүген офыкларда
эзлəгəндə синең чалымны,
агарды да шəфəкъ,
тагын миннəн
сəмави нур читкə агылды.

Күк иңлəргə яратылган җаның
моңсуланып аска күз атты,—
күмə карлар синең канап-канап
җирдə өстерəлгəн канатны.

Илаһи бер моңга төренгəнсең
бу кыршауның теге ягында,—
монда исə сине сыткан чорның
капкалары иңрəп ябыла.

Карлар күмə безнең эзлəрне дə,—
башка җырлар монда.
Кошлар да,
гел бүтəнчə канат җилпи-җилпи,
җəяү күченəлəр кышларга.

Агарды ул шәфәкъ,
сәмави нур
тагын миннән читкә агылды,
шулай да мин ерак офыкларда
эзлим синең таныш чалымны.

Канатларым җирдә өстерәлә,
шигырьгә дә чыктылар ясин.
Томан эчендәге киләчәктә
үз яныңнан урын калдыр син...

Мәһди өне

Иссен ул җил, чү, димәгез,
көннәр дә булсын явымлы,—
Гөберчәк басуларына
алып китсен сыктавымны.

Анда әле элеккечә
колыннар уйнап җылына...
Үксүләрем яусын иде
кипшенеп яткан болынга.

Күке һаман гомер саный,
үзәкне өзә лә өне.
Урманнар йотсын үзенә
күңелләрдәге әрнүне.

Кеше китә, җыры кала—
иясен җуйган җырлар да
сагыну булып сибелсен
"төлке уйнаган ор"ларга.

Иссен ул җил, кубарылсын
кемнәрнең ниләр кылганы,—
Шул җил белән йөзен каплар
даланың көмеш кылганы.

Алып китсен үкенечне
еракка.
Дала ул—табиб.
Безнең язмышлар сыярлык
бүтәнчә җир кайдан табыйк?

Уйнасын анда, кузгатыр
борынгы учак көлен дә...
Мәһдиләрнең өне булып
сеңәр гасыр төпкеленә.

Өмет

Кулын чәбәкләп йолдыз сикерә,—
тезләнеп эзен эзлим үзәннән.
Өзелгән җаннар сиздерми генә
сүземне көтә...
Мин тик бүзәрәм.

Бүзәрәм—офык читендә болыт,
сискәнеп җилдә, кымшанган төсле.
Серле үткелгә очар алдыннан
безгә бу төштә туктап үтешле.

Чыклы үләнгә чума бер чибәр,
кочагы кемгә диеп ачылган?—
Ябышып калам җиләк чеменә,
пакуслар монда балга манчылган.

Ябышып калам—ызан сизелми:
үкенеч белән өмет арасы.—
Офыкка кадәр пакуслар буйлап
сабый йөгерә...
сабый...
нарасый...

Җәйрәп ята анда арыш кыры,
Тартып тора әллә нинди сер...
Ник керәсе килә арасына?—
Күмеләсе килә, күрәсең...

Сары сихер йотты аны бүген,
Кая илтәр инде юллары?
Сагыш кына калды аунап җирдә,
Һәм сак кына тирбәлде арыш.

Дүртъюллыклар

Юатса да теге мөһер
"Бар да уза" дип юкса,
Дошманның йөзенә төкер,
Аузың тулы кан булса.

Чия чәчәге—тажында
Өч бал кортын тирбәтте.
Язгы һавага саркылды
Сәер сөю сурәте.

Куабыз ла, әй куабыз дөньяны,
Кышкы урманда куган күк куянны.
Кул изи, ашыктыра еллар аша,
Һәм әҗәл, кочак җәеп, якынлаша.

Таралса да таңда мәҗрух аңым,
Үз-үземә борылып карадым:
Көзге яңгыр кебек пычрандым мин,
Төнге кояш сыман каралдым.

Китапларны ташлап, башны тышка суздым
Пәрәвезләр сарган иске чоланнан.
Анда исә чык тамчылары җемелди,
Ә хыяллар күз яшенә чыланган.

Кичер, язмыш: юл читенә тукталдым ич!
Һичбер кемне бу бәйгедә узмадым.
Максат!— диеп күпме аксак—юллар саба,
Ә мин—тыңлыйм йөрәгемнең сызлавын.

Соңгы шигырь төсле саркып көздән
Күк йөзендә сыңар болыт йөзә...
Кулын изи, үзәкләрне өзә...
Ул да әмма эреп бетәр тиздән.

Камил Кәримов

САКАУ КУКЕ

РОМАН

Син кем дә—мин кем?

Сакал Шәйхи чакыртты дигәнгә бик исе китмәде әле Нотфулланың. Юл төсенә кергән чыбыркысын дүрт божралап өйалдындагы чөйгә элгәндә: "Эткә шулпа бир әле, көтүдә көне буе ашамады. Малайлар кайда?.. Кызлар тагын качтымы?" дип, ашыкмыйча гына өйдәге хәлләрне сорашты. Көне буе кояш астында торгач тавыклар башын тыкмасын дип, иске куна тактасы капланган лөгәндәге җылы суда быкырдап бит-кулын юды.

—Алып чык яшел күлмәкне, чалбары белән,—диде ул мәйданга кия торганнарын соратып,—эш буенча чакыртса кирәк. Зампред итәм дигән сүзе барые.

—И, Нотфулла, шашма инде! Ниткән зампред ди ул! Писерме, нәчәлник малаемы син, укымышың бармы?

—Кичке мәктәпне бетерермен дә дәлше китәрмен. Укырга дигәндә мина куш. Гомер буе чыбыркы сөйрәп йөрергә Низаммы әллә мин?

—Укырсың әнә,—диде Нәфисә, бит алмасындагы шәфәкъ нурын куертып,—сигезенчегә узганмын әле менә.

—Вәт, әнәңне... Итит-митит! Бала имезгән килеш ниткән узу ди ул тагы?

—Суң нишләтим инде, миннән торамы? Ходай кушкач...

—Ярар,—диде Нотфулла, бәхәсләшерлек вакыты юклыкка ишарәләп кул селтәгәч,—Герой ана исемен тикмәгә генә бирмәгәннәрдер, организмында дуңгыз каны бардыр синең...

Үзе сайлаган председательнең ин беренче соравы ук гарьләндерде Нотфулланы. Сабантуйга йөгергән малай-шалай шикелле, бәйрәмчә киенеп, конторга ашкынганы өчен үз-үзен битәрләде ул.

—Халык дөресен сөйлиме синең хакта?!—дип башлады Сакал Шәйхи.

Ахыры. Башы 7-8 саннарда.

Аның йөзендә елмаю, күзләрендә хәйләкәрлек чалымнары калмаган. Ачудан нуры сүнгән, кашлары тырпайган.

—Белмим, дежурный Газизән нинди гайбәтләр жыеп кайткандыр?

—Чулак Газизә монда ни причем. Әле генә урта звено житәкчеләре белән киңәшмә үткәрдем. Гөж киләләр. Сүз куешкандай барысы да бер балык башын чәйниләр. Син Мөлековны идарәгә баш итеп куярга йөрисең икән.

Шәйхи әңгәмәдәшенең ялт кына акланырга тотынмаслыгын яхшы белә. Жавап көткән арада урнашкан тынлыкны артык күтәрә алмады, киңәшмәдән жыелып калган исне жилләтер өчен дүрт тәрәзәнең дә өлгеләрен ачты.

—Дөресме шул?—диде Шәйхи, жавапны ашыктырырга теләп.

—Дөп-дөрес.

—Күнел өчен генә булса да хет, ялганлар идең.

—Дөп-дөрес. Допрос алуың ошамый. Шуна әйтерем кыска. Элегрәк син сүзне сургучлыны ачып башлый идең. Саранлашасың хәзер. Түрә булуың житте. Колхоз рәисенең кәнәфие ике сайлау арасына гына түзә, әрләп кал.

—Син...—Шәйхинең авыз тутырып сүгенергә исәбе бар иде, мәктәп ягындагы тәрәзәнең ачык икәнлеген абайлап, тыелып калды...—Син бит минем көрәштәш кешем.

—Ә урта звеноңда Тажи кешеләре. Аларны тарантаслы атка Тажи утыртты. Димәк, кәнәфиең тирәли дошман тулы.

—Бөтенесен кырып-себереп алыштырам, иртәгә үк.

—Бик мөмкин. Ну, мине алыштыра алмыйсың. Авылда көтүче табуы кыен хәзер. Рәхмәт үзенә—уртага кертмәгәнең өчен рәхмәт.

Нотфулланың "рәхмәтеннән" Сакал Шәйхи сөрхәнтәй кәҗә куып эченә кату чыккан көтүче кебек хәрәкәтсез калды. Нидер исенә төштеме, аягөсте капылт кына берәр яна план корып өлгердеме—аңламассың.

—Нәкъ менә шуның өчен чакырткан идем мин сине бүген. Дәүләт заданиеләрен үтәве кыен. Ит, сөт, йомыркага план арта, ә хуҗалыклардан жыю кимегәннән кими. Өй борынча йомырка жыеп йөргәнче зурдан кубып тавык фермасы ачарга булдык.

—Ну, мина көтү чираты белән өй саен тавык жыярга кушасыңмы?

—Казан инкубаторыннан ике мең чеби кайтарырга сөйләшенгән. Иртәгәдән Сыер күленә барасың. Андагы ферманы бушатасың. Малларны пилорам каршындагы яңа коровникка күчерәбез.

—Сыерларны ияләшкән жирдән күчереп йөрткәнче, яңа коровникны гына тавыклар фермасы итәргәдер бәлки?

—Киңәшмәдә андый сүз булды. Мин каршы. Беренчедән, Сыер күле ерак, янгырлы-бураннлы көннәрдә савымчыларны техника белән озатып йөрисе. Икенчедән, тавык фермасы авыл уртасында калса—исенә чыдап булмас, диделәр...—Һәм Шәйхи яшел сукно тарттырылган өстәлнең биек тартмасына тыгылды.—Никтер рәхмәтең йөзенә чыкмады. Ризалашмасаң, әнә, куян фермасын ал. Сукыр Кәримне тавыкларга күчерәбез.

—Дүртаяклы хайваннардан болай да гарык. Ике аяклылары ничегрәк микән?

—Сайлаулар житкәч күрербез инде нәтиҗәсен.

—Тавык халкы мингерәү, анысын беләбез. Ну ашаткан кешесен таный, кулга бик тиз ияләшә.—Нотфулла тамак төбенә кылчык утырган кешедәй: "хыр-хыр-хыр..." дип куйды. Бу аның гадәттәгечә, көләсе килмәгәндә, әмма көләргә кирәк чакта үзенчә пырхылдавы иде.

Өстәл тартмасыннан кулына ияреп чыккан савыт мәктәпнең химия кабинетыннан соратып алынган бүксәле колба иде. Шәйхи, сургучлы шешәне мәктәп савытына бушатып, каеш бөке белән томалап куярга өйрәнде.

—Мәктәбем истәлеге,—диде ул мактанып, һәм өстәлдәге чем-кара

телефонның трубкасын алды: "Алло, почта, молзаводны тоташтыр... Алло, Сәрвиназ, кабымлык алып кил әле. Ашханәдә күренеп йөри алмыйм, икәү без монда..."

Сәрвиназның ашханәгә кереп Шәйхи өчен ризык алып килүе яңалык түгел. Нотфулланы уйландырганы башка нәрсә: "Физкультура укытучысы чагында пыяла колба белән мәктәптә нишләде икән бу?.."

Өеннән чыгып киткәненә өч сәгать тә үтмәде, көтүче Нотфулла жиде бала анасы Нәфисә янына мөдир булып кайтып керде. Өйдәгеләргә хәлне аңлатып биргәч тә бәйрәм кәчтүнен салмады ул, чыбыркыны уртанчы малаена тоттырды. Һавадагы тавыкларга ышанып, гаиләне ашсыз калдыру килешмәс. Бер чыбыркы ун кешенең тамагын туйдыра алганда, мөдирлек вәсвәсәсенең заялыгы сизелмәс, ашказаны зыян күрмәс. Әгәренки тавык фермасын аякка бастырып булса, ул чагында чыбыркыга калган малае көзгә укуын дәвам итәр. Нәфисә белән олы улына кетәклек тирәсендә эш табылыр.

Сыер күле авылдан читтә, Казан юлына борылган калын комлыкта. Киртә белән әйләндереп алынган утарның бер ягы нарат урманына терәлгән, икенче ягында кукуруз басуы. Читтән килгән кешегә бәлки сәер тоелыр, әмма, Питрәч юлына чыкканда, югары урман эчендәге ком өстендә тагын бер күл кала—Печмән күле. Бу ике күлне ничек ком йотмыйдыр, анысы төбәкнең табышмагы. Күз-колактан читтә булгач, авылның карт-корысы бу ике күл хакында төрле куркыныч имеш-мимешләр сөйли. Ләкин, бишек чыбылдыгыннан телеп алынган марля тотып килгәч, кәрәкәле жылы күлдә "Төпсез. Упкынлы. Аждаһа төшкән. Су анасы бар," дигән янаулар онытыла.

Күрше Күн авылыннан яңа укытучы килгән. Ул өй борынча йөреп, класска язып китте. Фазыл белән Мәгъсүм шул сөенечтән Сыер күленә жыена башлады. Нәфисәнең эремчек саркытырга тота торган марлясын йомарлап чалбар кесәсенә тутыргач, повидло чиләген эләктереп, тере кәрәкәләр алып кайтырга дип, йөгерделәр.

Сыерлар жәйләүгә күчкәч, утар тирәсе кипкән. Ферма эченә ат белән ком ташыйлар. Ике балта остасы шифер түбә астындагы бәпкәлекләргә нарат сиртмәләрдән тезмә жәя. Ике абзый сыерлардан бушаган араталарга баскыч-баскыч итеп куначалар тезә. Озын-озын көрпә тагараклары ясар өчен шомартылган тар такталар китертелгән. Мәгъсүмнең әтисе тавык фермасы мөдире түгел, күбрәк һаман шул көтүчегә охшаган әле, тегене куа, моны ашыктыра, анысына сүгенә—чыбыркысы гына юк.

Малайлар кайнар күл астына килеп керде.

—Безне бүген мәктәптән килеп яңа укытучы язып алды,—дип башланган жөмләсе белән мактанып өлгермәде Мәгъсүм, аны әтисе бүлдерде:

—Әйбәт булган, менә зур үскәнсез. Барыгыз әле ферма эчендәге комны таратыгыз. Таптый-таптый жәегез, чебиләр абынырлык булмасын. Кесәгездәге марляны чиләккә салып, әнә кадакка элеп торыгыз. Кояш күтәрелсен, күл жылынсын әле бераз, кәрәкәләрегез беркая да качмас!

Тавык арифметикасы

Бөркәүле машинага төяп кырык әржә чеби алып кайттылар. Юаш Нотфулланың бөтен гаиләсе, хәтта Актырнак та шунда иде. Өйдә кош-корт үстереп сиксән яшьлек кайнана белән карт киленгә әверелгән Нәфисә ике мең чебине аякка бастырганчы күпме чиләнәсе барын белә. Монда чеби анасының канат астын алыштырырлык күл жылысы кирәк. Ә бу инде бары тик хатын-кыз эше генә. Нәфисә Динәне дәштерде. Чебиләрне арата саен тигезләп таратырга, асылмалы лампочка нурына жыелсыннар өчен жим сибәргә, инкубатордан жибәрелгән калай ялгашларга чыпчык тезеннән генә су салырга, юлдан ук хәлсезләнеп кайтканнарына авыздан сөт эчерергә кирәк иде. Соңгысына Фазыл белән Мәгъсүм дә

өйрәнеп китте, дерелдәп торган кош баласы иреннәренне кытыклап сөт эчкәндә күнел сөенә, тузганак чаклы гына җан иясе синең якын дустына әверелә, сөт эчкәч уч төбең белән аның йөрәк тибешен тоясың һәм кошчык: "Мине иптәшләрем арасына жибәр!" дигәндәй, тыпырчына башлый.

Шул көннән башлап Актырнакны да көтүгә чыгармадылар, дилбегә озынлыгы чылбыр белән капка төбенә кадаклап куйдылар. Жәй житте исә, көтү куып, кышын урамда адәм типкесендә йөреп әрсезләнгән эткә картайган көнендә тыныч эш таптылар. Дөрес, иртә-кич, авыл очында чыбыркы шартлатучыларга сискәнеп, колакларын торгыза ул, йоклап калган эшем кешеседәй киртә капкага ыргыла, ләкин, аның сөенече муен каешын тартып торган чылбыр озынлыгы гына. Ул янадан кадакланган урынына килеп ята.

Чебиләр үскән арада ферма әйләнәсен тимер чыбыктан үрелгән челтәр белән урап куйдылар. Нәфисә белән Динә ашату белән шөгыльләнсә, Нотфулла җәй буе печән чабып ферма тезмәсенә җәйде, теге кырык әрҗәне шунда меңгезеп, оялар ясады, түбә эченә сөяп юкә себеркеләре киптерде. Һәм чебиләрнең тизрәк үскәнен көтте. Сакал Шәйхи дә көтте, ашыктырды һәм ярдәм итте. Сәрвиназга әчегән сөтләрне дунгыз фермасына жибәрүне тыйды, эремчек ясап көн саен тавыкларга илтергә кушты. Бер ат жигүчене махсус беркетеп, амбардан капчык-капчык бодай ташытты. Тажи вакытында тугыз центнердан ары уңыш күрсәтмәгән гектарлар бу елны унөч центнер икмәк бирде. Сайлау жыелышында Шәйхигә авыр сүз әйтеп кара хәзер!

"Чебешне көз көне саныйлар" дигән мәкальне Юаш Нотфулла чыгаргандыр. Жәй башындагы кырык әрҗә чебинең югалганнарын үлгәнгә санап, яшь әтәчләрен иткә тапшыргач, тезмәдәге ояларга керердәй бер мең чамасы тавык үсте. Чамасы дип әйтми хәл юк, Питрәчнең заготконтора вәкиле белән Шәйхинең бухгалтеры килеп, яшь тавыкларның баш санын алмакчылар иде. Районда монарчы тавык үрчетү тәжрибәсе булмагач, санау эшен беренче тапкыр нидән башларга микән, дип, вәкил теш щеткасы сыман тырпайган мыегын кашып шактый торды. Иртәчәрәк килеп, куначадан төшкәнче санап чыкмакчылар иде. Ләкин, ферма эченә кеше кергәч, ашарга китерү дип аңладылармы, очып-очып килеп вәкил белән бухгалтерны сырып алдылар, аяк астындагылары кулга сикерә, өсте-өстенә өелә. Атласаң таптарга кирәк, тик кенә басып торсаң чукып үтерәләр... Китте ыгы-зыгы, арата кырмыска оясына әверелде. Санарга тиешле кешеләр аякларын комлы боламыктан шудырып-шудырып атлап көчкә чыгып котылдылар... Ике канатлы капканы аз гына ачып, иртәнге жимгә чыгасы "титибашларны" урам ягыннан санап торырга уйладылар. Тагын унга хәтле життеләр микән... Начальство әйткәч, ярыктан берәм-берәм генә чыгасы урынга, бу мингерәүләр урамдагы көрпә тагаракларында бодай барлыгын сизеп, давыл булып ябырылды. Капканың ике канаты ике якка каерылды. Тавык давылы куллары белән битләрен каплап жиргә чүгәләгән бухгалтер белән вәкил өстеннән очты.

Заготконтора вәкилен белмим, каян китереп куйганнардыр, әмма Шәйхинең бухгалтеры авыл мужигы иде: "Кояш баегач тавык күзле жан ияләре берәм-берәм оясына кайта, санап өлгерербез",—диде. Тавык та кош шул. Кош—димәк, романтик, хыялый, моңлы... Әгәр кеше үзенә ризык итәр өчен аларны борынгыдан кулга ияләштермәгән булса, әлеге мең тавык та бәлки авылга терәлеп үскән куе урманда иректә яшәр иде. Жәйге аяз кичләрдә алар куначаны онытып Сыер күле тирәсендә чебен-черки, чикерткә тоталар, койма читенә ияләшкән кәлтә еланнарын куалар, борынгыча бер калыпка салып, сузып-сузып жырлыйлар... Син аларның фермага борылып йокларга кайтырга теләгәннәрен көтеп кара... Төркем-төркем булып капкадан керәләр дә: "И-и-и, ашыгыбрак кайтканбыз, куначада беркем дә юк әле..." дип, кире чыгып качалар. Кушу-алу уены ясап бухгалтер белән вәкилнең женнәре котыра, күчтәнәчкә дигән йомыркаларны да онытып, караңгыга калганчы авылга ашыгалар.

Тавык исәбен алу район күләмендәге хафага әвереләсе иде, котылу чарасын сигез яшьлек Фазыл әйтеп бирде:

—Аларны буярга кирәк...

—Вәйт, малай актыгы,—дип бот чабып куйды Нотфулла,—атаң мәрхүм башлары бар үзеңдә...

Күршенекеләр белән буталмасын өчен, Динә ел саен тавыкларның сыртына язу карасы сылап чыга иде. Кош-корт яңгыр астына чыкмый, тамгалары кышка чаклы саклана, Фазыл әнә шуны исенә төшерде.

Бер савыт түбә буявын ике чиләккә салып, вәкил белән бухгалтерга тоттырдылар. Көрпә тагарагына тезелгән кошларның сыртына пумала тидереп бер, ике, дип саныйлар да ун булгач, исәп дәфтәренә теркиләр, ашаган чакта тавыкны буяу түгел, койрыгын киссәң дә исе китми. Ярты көн тырыша торгач, ап-ак кошларның күбесе кызыл кикрикле, яшел сыртлы булды. Ә сүз тыңламас-тиктормасларын Фазыл белән Мәгъсүм пумала күтәреп куып йөрделәр. Тавык халкын беләсез инде, бер үҗәтләнсә—малайлар түгел, әтәч тә куып тота алмый. Тамгасызларны аерым санадылар...

Фазыл уку башланган көннәрне һич онытмас. Чөнки сентябрьдә ферма тавыклары йомырка сала башлады. Дүрт дәрес бетүгә, малайлар өйгә кереп сумкаларын ыргыталар да Сыер күленә йөгерәләр. Өйләдән соң, Динә белән Нәфисә кырык әрҗәдән заготконтора өчен план җыя башлый. Ләкин, иң кызыгы Фазыл белән Мәгъсүмгә... Тезмәнең чит-читенә сөяп куйган юкә себеркеләр артында, тавыклар үзләре урлап ясаган ояларда, бишәр-алтышар йомырка балкып ята. Малайларның сөенүен күрсәң—гүя мажаралар арасыннан хәзинә эзлиләр.

—Әни, монда жидәү! Әни, менә тагын... Әни!

Алты чиләк йомырканы колхоз складына тапшырып, боерык кәгазен кулга алгач, көнлек эш бетә. Чылбырлы Актырнакка кыр каравылчысы иптәшкә кала.

Ике күрше гаилә арасында тормыш жанланып, балалары көрәеп, тавык карау сөендерә башлаган иде. Колхоз эше дә гөрли, өйдәге мәшәкатьләргә дә кул житә. Идарә утырышларына килгәч, Нотфулланы аягүрә бастырып мактыйлар. Балалар тук, өсләре бөтен, шөкерана кылып яшисе иде кана.

Яшәсен!..

Нотфулланың кичке мәктәпкә укырга килүен ишеткәч, Шәйхи тагын мәктәп директоры Марат Мөлековны идарәгә чакыртты. Идарә конторы зират коймасына терәп салынган өч буралы йортка яңа гына күчкән иде. Дежурный Газизә, бисмилласын кабатлап: "Марат хәзер килә!"—дип әйтеп өлгермәде, Мөлеков ишектән килеп тә керде.

—Син нәрсә, кичке мәктәп белән ашыгасың? Колхозда көзге эшләр төгәлләнмәгән ич әле.—Кырдан салам тарттырасы бар, тунга сөрүләр бетмәгән,—диде Шәйхи, Мөлековны каршы алышка, аннан соң кул биреп күрешергә булды.—Нихәл, пнимаете так.

Директор: "Әйбәт әле..." диярга дә онытты.

—Ел саен октябрьнең бересеннән эшли башлый инде ул.

—Күп килгәннәрме?

—Ну, жәмгысы алтмышка якын.

—Жыен икеле-берле, күчми калган тинтәкбашлар инде, пнимаете так... Бүкәнне укыттың ни дә, укытмадың ни аны.

—Ул бүкәннәрне читтән жыймадык инде, үзебезнең колхозныкылар. Гомуми белем бирү мәжбүриләнде. Күбесе көндезге укуны гаилә хәленнән чыгып ташлаган. Кичкегә ялынып дигәндәй чакырабыз.

—Ә Нотфулла пнимаете так, нишләп йөри? Ана кырык яшь бит инде.

—Кичке мәктәп кешенең яшен сорамый, пенсионерларга да ярый. Ә Нотфуллага килсәк—ул класска керү белән: "Мин Тажи өчен укыйм!"—диде.

—Бар!—диде председатель, мәктәп директорын куып чыгаргандай кул селтәп. Ул Мөлековның жаваплариннан бигрәк, аның "Шәйхетдин Исламович!"—дип мөрәҗәгать итмәвенә хурланды.

Уйлансаң уйланырлык нәрсә Шәйхи өчен—"Юаш" кушаматын тикмәгә генә такмаганнар Нотфуллага. Халык гел киресен әйтеп үрти. Югары очта ярты урамлы нәсел "Чегән" кушаматы йөртә—ни өчен диген—сап-сары чәчле,шадра йөзле булган өчен. Армиягә алынмасаң—син "Әписәр", урамда жырлап йөрсән—"Карга". Шәйхинең үзенең дә нәселдән килгән кушаматы—"сакал", ата-бабалары ягыннан кайсын гына алма—мыек чыга, ә сакаллары үсми. Юаш Нотфулланың да ишеккә сыймастай юанайганын көтмәскә... Башы йомры, теле шома, үзенә дигәндә йөгерергә иренми. Урта мәктәпне дә тәмамлар, авыл хуҗалыгы техникумына да барып житәр, кичкегә йөрергә иренмәгәнне, читтән торып укуга чыдар. Белеме арткан саен теле үсәр!..

Колхоз отчет-сайлау жыелышына әзерләнде. Газизә өйдән-өйгә кереп, халык исеменнән әйтеп йөрде: "Кеше мактый,—дип башланган сүзе шигырь кебек ятланган.—Аллага шөкер, бер ел эчендә яңа правление салдырды, искесен медпункт итеп калдыра. Тавык фермасын күр—йомырка сату планын үти башладылар. Тугыз центнердан ары уңыш бирмәгән кырлардан, гомердә булмаганны, унөч центнер икмәк жыеп алдык. Ходайның рәхмәте яусын. Тажидан колхозыбыз егылып калганые, Шәйхи торгызды. Үткән көннәр кире кайта күрмәсен инде..."

Элеккеге председательне оныттырырга теләде Шәйхи. Жәй уртасында укытучыларга утын китертте. Сугыш елларында тол калган ялгызак әбиләр өчен мәчет янына картлар йорты салдырды. Көл, тимер-томыр жыюда алга чыккан пионерларны, туфраксадагы Ленин эзләрен күрергә, Кокушкино авылындагы музей-йортка жибәрде. Укуларын өзеп, бәрәңге сутыенда ун көн буе чиләнгән балаларга өч кило шикәр алырлык акча өләште. Уңыш амбарга кереп беткәнне дә көтмичә, бер хезмәт көненә алты йөз илле граммнан икмәк бүлеп бирде. Нотфулла белән Нәфисә янында тавык караучы булып йөргән өчен Динәләр капка төбенә егерме пот ашлык китереп аударылар... Мөлековка әйтеп тормыйча гына сельпога акча күчерде һәм ятим балаларны идарәгә чакыртып, бушлай кием-салым белән сөендерде. Фазылга быел сыек көрән төстәге бушлат эләкте. Киләсе елга кирза итек бирәчәкләр ди. Бирмәделәр генә...

Озак еллар эшләгән Тажинын әле һаман райкомда үз кешеләре бар, ул Шәйхинең беренче хисап жыелышын Октябрь бәйрәме алдыннан үткәрергә дигән карар чыгарттырды. Башка хуҗалык житәкчеләре чатырчабып бәйрәмгә әзерләнгәндә, Шәйхи мәшәкать өстәп хисап доклады язып утырырга тиеш. Жыелышны күчерттерсәң—районга каршы килү кебегрәк, әгәр инде совет халкының иң зур бәйрәмен тиешенчә үткәрә алмасаң—персональ эшең обком утырышына барып житәчәк. Һәр ике очракта да Шәйхи өчен хурлык.

Вакыт әрәм итмәс өчен, ул райком карарының хат белән килеп житкәнен көтеп тормады, телефоннан белешкәч, шул минутта ук, мәктәп директоры Мөлеков янына керде.

Озын тәнәфес вакыты иде. Ике катлы агач мәктәп штормга эләккән корабны хәтерләтә, балалар дулкын булып класстан класска күченә, үзләренчә кабинет алыштыра. Спортзалда октябрятлар вожатыйны уртага алган, алар өчен жыр укытучысы мандолина уйнап тора. Замазка сыланган тәрәзәләрнең берсен ачып, мәктәп бакчасына төшкән уенсыз малайлар миләш сыдыра. Аскы коридор белән өскесе бергә кушылгандай йөгереш бара. "Исәнмесез, абый?"—дип, күрешергә тиешле узган елгы малайлар, узган елгы физкультура укытучысын танымагандай, бәрелеп-бәрелеп китәләр.

Мәктәптә директорның аерым кабинеты юк, Мөлеков укытучылар бүлмәсенең түренә бер өстәл куеп кына утыра. "Бу яңа председатель тагын нинди эш кушар икән безгә?"—дигәндәй, элеккеге коллегалар шым булды.

Хәлләрен сораштырган атлы кыланып, аларның дәрескә кереп киткәннәрен көтәргә туры килде. Мөлеков үзе тарихтан укыта, ләкин директорның дәрескә соңга калып керүе укучылар өчен сөенеч кенә иде.

—Исәнмесез, Марат Әбдүлрәсүлевич?—дип, элеккегечә ягымлы итеп эндәште ул, хәтта икәүдән-икәү генә калган уңайдан, кочаклашып та күреште.

—Әллә спортзалыңны сагындыңмы?—диде директор, Сакал Шәйхинең кинәт йомшарып сөйләшүенә аптырап.

—Кире кайтуымны теләмисездер ич?

—Дөресен генә әйткәндә—теләмим! Әгәр укытучы мәктәпне бер ташлап китә алган икән, димәк, ул педагог буларак ышанычлы кеше түгел.

—Ләкин сезнең дә авылда өй салырга уегыз юк, димәк, китәргә телисез?

Мөлеков стенадагы Ленин портретына карап җавап эзләде.

—Әгәр партия кушса—бик мөмкин! Мине педагогия институтына өлкән укытучы итеп гел чакыралар.

—Һәм сез шундый перспективадан баш тартасызмы?

—Шәйхи, энем, "сез" дип сөйләшүеңнең тел төбен аңламыйм. Гадәттә, мин үзем яңа түрәләргә һәм икейөзле кешеләргә генә "сез" димен. Бу очракта...

—Ярар инде, Марат абый, үпкәләмә! Минем киредән мәктәпкә кайтуымны теләмисең икән—ярдәм ит. Пнимаете, так...

—Менә монысы—үзебезчә ичмасам! Балалар ярдәме кирәкме? Бушлай хезмәт, ягъни мәсәлән...

—Балалар укысын. Карлар яугач көл җыярлар... Син миңа отчет җыелышы өчен чыгыш язып бир.

—Гыйльми конференциягә фәнни доклад язып ятам. Аспирантураны бетергәч тыныч кына эшләргә ирек бирмиләр икән... Ә синең читтән торып булса да укырга исәбең юкмы?

—Колхоз җитәкчесе читтән торып укый алмый.

—Ничек инде?—дип аптырап калды Мөлеков.

—Язгы сессияне тапшырырга ирек бирмиләр. Язгы чәчү вакытында, бөтен эшеңне ташлап, бер айга ничек китәсең ди?—Шәйхи, сүзнең артык читкә тайпылуын өнәмичә, тагын туп-туры сөйләмгә күчте:—Докладыңны тарих китабы кебек итеп яз, йәме! Озын һәм минем турыда булсын...

Мөлековның ризалашуы Шәйхинең кәефен күтәрде... Карасана—моның күзе бөтенләй кысык түгел икән. Себердә шуна күрә яши алмагандыр ул. Ялыныч белән килгән кешегә ярдәмчел үзе, андыйларны халык ярата һәм иярә... Юк шул, Марат Әбдрәсүлевич, отчет җыелышы үткәнче халык мине генә яратырга тиеш. Һәм син, доклад язарга ризалашып, үзеңне күләгәдә калдырдың...

Ул көнне клубның кичке уеннар үткәрелә торган ягында алты үлчәүле сәүдә оештырылды. Райпо сатучылары билле прәннек, ысланган балык, ширбәт эчле кәгазьсез конфет, хәлвә, уналты тәңкәлек такта чәй, клиндер, таракан жимеше, ат һәм кит итеннән томаланган консервалар алып килде. Шунда ук ике чиләкле самавыр җырлап утыра.

Хисап җыелышы алдынгыларга тантаналы төстә бүләкләр өләшүдән башланып китте. Барысын да Шәйхи шәхсән үзе тапшырды, партоешма секретаре исемлекне укып чакыра торды. Бик үк алдынгы булып җитмәгәннәр өчен әз-мәз акчалата премия куелды. Ведомость белән акча кассирша кулында, җыелыш беткәч клуб мөдире бүлмәсендә өләшенәчәк...

Колхозчылар алдында хисап тотар минут җиткәч, Шәйхи бер кулына тарих китабы калынлыгы докладны күтәрде, ә икенче кулына бер дәфтәр бите тотты.

—Иптәшләр, ел буена бергәләшеп ниләр эшләгәнебез турында ишетәсегез килсә, менә шушы докладны укып чыгам. Әгәр инде, пнимаете

так, киләчәккә карата планнарымны белергә теләсәгез, менә бу кәгазь битендәге жөмләләрне санап чыгам.

"Доклад кирәкми, сүздән туйган, вәгъдәләреңне әйт!"—дип, премия алырга ашыккан кешеләрнең фикерләре янгырагач, тавышка куясы гына калды.

...Авылга тагын ике кибет салдырабыз...

...Тау башында төзелеп беткән яңа правление бинасы якындагы бишьеллыкта егерме алты урынлы участок больницасы булып калачак...

...Вак буалар жәй уртасында кибә, инешнең Казан юлы өстендә ике йөз мең кубометрлы су саклагычы корырга проект төзеттек...

...Салам түбәле иске өйләрне бетерү буенча идарә карары бар. Кулыннан килгәннәргә техника белән ярдәм итәрбез, хәленнән килмәгәннәргә колхоз хисабына ун еллык ссуда бүлеп бирербез...

...Киләсе елга уныш күләмен унжиде центнерга житкерергә!..

Йөкләмәләрнең ахыры күтәренке сүзләр белән бетте:

"Яшәсен Бөек Октябрь Социалистик революциясенең 41 еллыгы!"

Көчле алкышлардан соң жылынган куллар, Шәйхине егерме жиде елга житәрлек дәрт белән кабат сайлап куйды...

Аның исеме "Әй"...

Авыл кышка әзерләнде.

Язгы сулар идән астына төшмәсен өчен өй тирәли казыла торган ерганакларны тирәнәйтеп, урам ягындагы базларны томалап, абзар коймасы белән кәрниз арасындагы ярыкларга абага тутырып, туфраксаларга балчык өстәп, яңа өйләрдә икенче кат тәрәзәләр куеп, искеләрендә рам араларын сылап, халык үзеннән-үзе әкрен генә кышка кереп бара иде. Өлкәннәрнең төрле ырымнарга карап, гел раштуа суыкларыннан гына торган кырыс кыш вәгъдә итүе елдан-елга кабатланса да, авыл әзерлек чараларын киметми, кар яуганчы ук итекләр бастыра, озын балтырлы йон оеклар бәйли, затлы шәлләр өчен Ырымбур кәжәләреннән таралган мамык эрли.

Дәресләр беткәч, югары сыйныф укучылары мәктәп лапасында утын яра, балтасыз калганнары кул алмашып, пүләннәрне әрдәнәгә өя.

Фазыл белән Мәгъсүм мәктәп мичләренә утын кисәрдәй сыйныфка житмәгәннәр әле. Аларны өйдә көтәләр. Әтиле кешенең малае укудан кайткач сыер асты жыештыра, башакка салам турый... Ә Фазыл әнисенә нигез салыша. Әтиләре, сугыштан алып кайткан жәрәхәтләрен төзәтеп бетерә алмыйча, теге дөньяга ашыгып китеп барды. Динә, вакытлычага ярап торыр, дип, келәт бурасыннан күтәрелгән иске өйдә утырып калды. Тавыклар менеп актара торгач, жәй буена чокырланган түбә саламына янаны өстәмичә кыш чыгарлык түгел. Житмәсә, өйнең бүрәнәләре куышланып, мүкләре череп беткән, көнгә ике кат мич яксаң да жылысы тормый. Наратлар ылыс койгач, Динә балаларын житәкләп, урманга китә. Урманны тырмалап жыйган ике сарба[1] ыры[2] өйне тышкы яктан киртәләп төреп алырга житә, тәрәзәләрнең өске өлгесе генә томаланмыйча кала. Өй эче карангыланса да, жил үтми, жылы югалмый. Бәлки, инде киләсе елларга нигез өеп торасы булмас, Шәйхи салам түбәле өйләрне бетерәбез дип, жыелыш алдында вәгъдә бирде.

Динә сәнәк белән ыры чөя, Фазыл аны таптап тора. Киртәне үстереп менә торгач, өстәмә "нигез" кәрнизгә килеп терәлә, авыр гәүдәле зурлар өчен бик тә жайсыз саналган әлеге эш, Фазыл кебекләргә уенга әверелә.

Бакчаның "плугарь" ягын өяргә дип ыры ташыганда әллә каян гына Мәгъсүм килеп басты. Анын да Фазыл белән бергә ыры өстендә ауныйсы килә иде. Нотфулла малаеның уйнарга чыгуы иртәрәк тоелды Динәгә.

---

[1] Сарба—ылыс ташый торган әржәле арба (диал.)

[2] Ыры—коелган ылыс (диал.)

—Ник эштән качып йөрисең?

—Әти малайларны өйдән куып чыгарды.

—Ачуын китергәнсеңдер әле.

—Жук. Әнине Питрәчкә апкитәргә дип ат жигәләр.

—Ниткән сүз сөйлисең, кичкырын районга чыгалармыни?—диде дә, сәнәгенә элгән ырыны кире куеп, нәрсәнедер исенә төшергәндәй итте һәм Нәфисәләргә йөгерде.

Малайлар үзләре генә калгач кинәнделәр уйнап: чүмәлә өстеннән мәтәлчек атындылар, тәгәрәделәр, күмелделәр. Кыш буе ямь-яшел булып урман төсен саклап торган ылыслар, жәй уртасыннан саргаешып коела да, урманга түшәлә. Ул өй түренә урман ямен алып кайткан, анда чәер исе, кояш төсе, сары энәләр өеме дисәң дә—кадамый, муен арасына кереп кытыклый, учына кыссаң йомшак үләнгә әверелеп кала. Мәгъсүмнәр ыры ташымый, аларның өе нык.

Динә кергәндә жигүле ат инде капкадан чыгу уңаена борылган. Арбадагы түшәкнең баш асты турысын күтәртеп куйганнар. Нәфисәне олы кызы белән Нотфулла ике ягыннан култыклап алып чыктылар, ул юка боз өстен кичкән ихтыярсыз адәм кебек, аяк очларына басып кына атлый—гәүдәсенең авырлыгы үзендә түгел. Күршегә килен булып төшкәннән бирле иң якын дустына әверелгән Динәне күргәч, Нәфисәнең ап-ак чырае бит алмасы турыннан бер мизгелгә кызарып алды. Нотфулла капканы ачкан мәлдә, Динә түшәккә сеңгән Нәфисәнең колагына иелде.

—Кай арада аяктан егылдың соң син? Әле бая гына эштә идек ич!

Нәфисә дәшмәде, аскы иренен тешләп торуыннан шәйләп кенә жан ачысы барлыгын тоеп була иде.

—Егылдың мәллә?

Ниһаять, Динә эшнең нидә икәнлеген төшенгәндәй, пышылдавын көчәйтте!

—Әллә, Ходаем, кул уйнаттынмы?! Биш айлык корсаккамы!..

Нәфисә, ике кулы белән йөзен каплап, кинәт елап жибәргәч, күнеленә килгән шик-шөһбәнең чынбарлык икәненә ышанды Динә.

Баскыч төбенең биш басмасында сиксән яшьлек әби канаты астына кереп елап калган дүрт кыз бала, әниләре кием алыштырганда урамга куылган өч малай, төнге сәгать икедә ятим каласыларын белмиләр иде әле.

Нотфулланың аты тәүлек буе тугарылмады.

Вазифасы буенча фельдшер-акушерка дип аталса да, авыл врачы әлеге очракта ярдәм итә алмады һәм район больницасына атап язылган юллама чынлыкта исә, Нәфисәнең гафу ителмәслек ялгышына хөкем карары иде.

Чана жигәргә иртә, арба жигәргә жайсыз чак. Атны бераз куаласаң арба түмгәктән-түмгәккә сикереп, Нәфисәнең кан сауган гәүдәсен вата. Район белән авыл арасын сигез чакрымлы урман каплап тора.

Нотфулла соңгы тапкырында шушы юлдан жиде баласын төяп район сабан туена алып барган иде... Кайткан чакта бәйрәмдә уйнап-көлеп, сыйланып алжыган балалар арба төбендәге чыптага тәгәрәшеп йокыга китте, атны агачка бәйләп, әти белән әнинең жиләк аланына кереп чыкканнарын да сизмәделәр. Нәфисәнең күлмәк итәгенә жиләк сытылып беткән иде, йокы чүлмәкләрен арбадан бушатканда кожан бөркәнеп йөрде ул.

Ә хәзер зәнгәр күлмәге канга батты. Ястык өстендә яткан килеш, күлмәк төсендәге күк йөзендә арбага иярген сынар болытка карап бара. Нарат урманы жиләк аланнары белән киребә йөгерә, Нәфисәдән кача. Батыр ананың ут янып торган бит алмалары сүнгән, күзләре нурсыз, жиде баланың керен юа-юа юылып беткән куллары тагын да агарып, корсак өстендә кушйозакланып калган.

Мәрхүмәнең ястык өстендәге гәүдәсен капкадан алып кергәндә, икенче көннең кояшы кичке якка авышкан иде инде. Жигүле ат инләп йөрерлек иркен ишегалды күрше-күләң белән тулды. Кичә генә көндез,

сөснә-сөснә яшәп йөргән Нәфисәнең бүген вафатына ышанмады халык.

Кеше тудыруның бер генә дөрес ысулы бар... Ә жан кыю—миллион төрле...

Адәм баласы туганда ук канга батып туа. Гадәттә, әти кеше аны күрми. Тәненә яра төшсә, ирләр ныграк каушый. Хатын-кыз кан коюдан курыкмый, балигъ булган көннән башлап күнегә ул ана... Хатын-кыз хирурглар да каты бәгырьләрәк. Операция ясаганда ир хирургка авыруны кызгану хисе комачаулый. Йөкле хатыннар ир гинекологка ныграк ышана... Малайлар үскәндә уенчык машиналары ватыла-жимерелә, ә кыз баланың кеше сурәтендәге курчаклары туза, өзгәләнә, ыргытыла...

Хатын-кыз—тудыручы, ир кеше—кабер казучы...

Нотфулла тавык фермасында бөтен гаиләне туендырырлык эш тапкач, Нәфисә аның нужа камытын жиңеләйтергә теләде, тапканнарын исән-сау үстерсәк, бик житкән дип, сигезенче көмәненнән котылырга булды. Күршекүләп белән киңәшләшеп тормады, кирегә үгетләячәкләрен белә иде. Осталыгы белән тирә-юнь авылларга даны таралган Олы Елга карчыгының да биш айлык йөккә кул күтәрмәслеге билгеле, гөнаһысыннан курыкмаса да законнан куркыр... Һәм Нәфисә үз жанына үзе кул сузды.

Дустының кырыгын үткәргәнче, тавыклар фермасында Динә берүзе йөреп торды. Колхоздан нәрәт белән көн саен яңа кеше кушалар иде кушуын. Ләкин, алар бер генә көнгә яллангаңнарын бик тиз аңлап, артык өшәнмичә булыштылар, төп эш барыбер Динә өстенә өелде.

Мәктәптән соң, Мәгъсүм Фазылга иярмәскә тырыша, тавыклар янында кызык тапмый ул хәзер. Буш вакыт барында ике ятим урамның ике ягында аерым-аерым уйнады... Берсенең әтисе юк, икенчесенең—әнисе... Фазыл Мәгъсүмне ничек юатырга кирәклеген белми, менә мин тумышымнан ятим үсәм ич әле, жыламыйм, дип әйткәли иде... Ә Мәгъсүм, анын саен: "Әти кешенең нәрсәгә кирәге бар аның, әни булсыныс хәзер!"—дип капка төбендәге чирәмлектә тәгәри-тәгәри елый... Инде ул турыда сүз чыгармаска тырыша Фазыл.

Балдызлары ягыннан сазамыклары-толлары юк иде Нотфулланың... Өчкә жидене кушсаң ун була, ике тол кавышса уң була дип, Динәнең колагына да пышылдамады түгел... Ләкин, күрше хатыны Нәфисәнең үлемендә Нотфулланы гына гаепләде. Һәм ана булган нәфрәт, әнисез калган жиде баланы кызганудан көчлерәк иде.

Жиде кашыкны бер тирәдә тотар өчен Нәфисәнең сиксән яшьлек кайнанасы мәчет урамындагы берәүгә үзе яучы булып китте. Ятимнәрнең иң олысына унбиш яшь, ашарга пешерү, керләр юу дисәң, кулыннан килә. Хужалык тирәсендәге эшләргә малайларның көче житәр иде. Ләкин, гаиләне саклар өчен әти кешегә ул гына житми шул... Сиксән яшьлек яучыбыз сазамык Айжамалның ризалыгын алып кайткач, Нотфулланың нурсыз өенә сүрән генә булса да яктылык өстәлде. Үги анага төпчек кыздан гайресе "әни" дип дәшә алмады. Нотфулла күпме үгетләсә, кыйнаса да, балалар өчен аның исеме "Әй!" булып кына калды.

Айжамалның яңа кушаматы Динәнең дә теленә керде. Тавыклар фермасында Нәфисә урынын хәзер шушы—чегән хатыннарына охшаган "Әй" алыштырды. "Әй, бодай сип әле... Әй, аяк астындагы кош тизәкләрен кырып себер әле",—дип аралаша торгач, яшь хатын үзенең яңа исеменә ияләнде. Тик Динә ана ияләнә алмады, эшләгәндә жаны өшеде, елаганда бәгыре катты...

«Зимагур баеп кайткан...»

1959 елның мартында Сакал Шәйхи районга барып сәер йөкләмә алып кайтты... Чирәм жирләрне үзләштерү программасы биш ел буе дәвам итеп, ниһаять, ахыргы этабына житте дигәндә, авылның биш гаиләсен Урал ягына жибәрергә кушалар.

Анда, кырык миллион гектар кыргый җирне кулга ияләштердек дип, күрше Күн авылыннан киткән гаиләләр чирәмлектән качып кайта башлады, ә монда Сакал Шәйхи, Ырымбур далаларына җибәрер өчен, Нотфулланы үгетләп маташа. "Юаш" ризалашса, калган дүрт гаиләне үгетләү берни тормый.

Нотфулланы ул Айҗамалы белән бергә чакырттырды. Үксез гаиләдә ярты ел яшәп караган үги ананың карт кайнана күзеннән, күрше-күләп сүзеннән котылыр өчен жиде баланы иярtep Себергә олагырга риза дигән сүзен ишеткән иде ул.

Шәйхи ашыктырып үгетләмәде. Иркенләп хәл-әхвәл сорашты. Бәйнә-бәйнә зарланасын белеп, гаилә арасындагы борчуларны күбрәк Айҗамалдан сорашты... Тавык фермасы хакында ләм-мим, сүз чыгармады, чөнки, Нәфисә исеме телгә керсә әңгәмә әрләшүгә күчәргә мөмкин иде... Нотфулланың утыны күп икән, ә менә мал-туары бала-чага кулына калгач, печәнне урык-сурык тотканнар—яз чыгарга житмәс кебек, ди. Балаларын берәм-берәм телгә алганда Шәйхи кул астындагы зур кәгазьгә теркәп торды... Аннан соң, ил күләмендәге мөһим вакыйгаларга күчте, кая карама зур төзелешләр бара, кеше кулы житми... Иң мөһиме—икмәк. Чирәм җирләрне иген мәйданына әйләндерү Совет халкын икмәкле итәр, егерме беренче елгы ачлык кабатланмас... Кыскасы, гаилән белән Урал елгасы итәгендәге яңа колхозларга күчеп китсән—уңарсың... Юл чыгымнарын без түлибез. Гаиләнне өч ел асрарга житәрлек пособие бирелә—колхоз кассасыннан бүген үк кереп ал. Моннан биш ел элек киткәннәр палаткаларда, вагоннарда яшәгән, ә сезне аерым өйләр көтеп тора. Әзергә—бәзер, рәхәтләнеп эшлә, акча җый, баеп кайт... Унбиш процент "уральский" өстәмә түләүне дә исәплә. Ике малаең трактордa, хатының белән олы кызың—сыер сауса, син терлек симертүдә—учти, анда пнимаете так, хезмәт көне дигән система юк, айныкын айга акчалата түлиләр...

Сакал Шәйхи кире чигенмәслек итеп байлык юрап сайрады, ә Нотфулла ахыры матур бетәчәк әкият итеп тыңлады да тыңлады, сораулар бирмәде, каршы дәшмәде. Нәфисә кайгысыннан күндәм иде ул...

Башка вакытта сыный карарга җае килмәгәнме, председатель бүлмәсенә кергәч кенә күреп алды Айҗамал, Юаш Нотфулласына кырык яшеннән чал ингән, чәч түбәсендәге аркылы буразнасы тирәнәеп, аны ике башлы иткән, чигә сакалы төбеннән чыккан буй-буй җыерчыклары иягенә чаклы төшкән, мангае карт өянке кайрысы шикелле каушакланган, зәңгәр күзләре сурәтендә вак-вак кан тамырлары чатнаган...

Озак уйларлык вакыт калмаган, язгы чәчүләр башланганчы барып урнашырга кирәк иде. Исемлектәге калган дүрт гаиләне Нотфулла үзе үгетләп йөрде. Аның ышандыра белү сәләте хакында артык җәелеп аңлатасы юк.

Шәйхинең партия бурычларына ышыкланып уйланылган мәсләге көн кебек ачык—Ырымбурга жибәреләсе биш гаилә барысы да Таҗины алып ташлауда катнашкан дуслар иде. Ә дуслар белән көрәшү җинел түгел. Нотфуллаларны ераккарак олактырмыйча, Сакал Шәйхи тынычлап утыра алмас, отчет-сайлау жыелышы саен мажара көтеп яшәргә тиеш иде.

Язгы ташуга әзерләнеп, Мишә аша салынган агач күперне сүтә башлаганнар иде. Ялланган гаиләләрне, боз йомшарганчы дип, иртән иртүк трактор чанасына төяделәр. Озата килүчеләр арасында биш гаиләнең нәсел тамыры, участковый Архипов һәм гыйбрәт итеп сөйләгәндә белеп сөйләр өчен дип, аерылышу галәмәтен үз күзләре белән күрергә теләгән авылдашлар бар. Директор Мөлеков китүчеләр арасындагы дистәгә якын мәктәп баласын кызганып торучы укытучылар төркеме арасында иде. Нотфулла белән кочаклашып хушлашкан арада алар янына Шәйхи килеп басты. Ул гадәттәгечә, райкомга ашыккан кыяфәт чыгарып, тиз генә саубуллашырга теләгән иде. Ләкин, Нотфулла аның кулын жибәрмичә кысып тотты, ә үзе Мөлеков белән сөйләште:

—Менә, күр, бу Сакалсыз Шәйхине без синең белән йомырка кабыгыннан үзебез чыгардык. Ә ул—кәккүк баласы шикелле төрткәләп, безнең ише кычыткан чыпчыгы чебиләрен туган ояларыннан куып чыгарды. Хәзер чират сина инде, Марат Әбдрәсүлович, Себергә озатырмы, өтөрмәгә утыртырмы?.. Ну мин, баеп кайткач, иманын алам әле моның, балалар гына аякка бассын!..

Һәм Нотфулла, председательдән ычкынган кулына кар йомарлап алып, трактор тәрәзәсенә ыргытты:

—Киттек!

Мәгъсүм, трактор кузгалып киткәч чанадан сикереп төште. Озатып калучылар арасында елап калган Фазылны кочаклап алды.

—Әти исән булса, без дә сезнең белән китә идек, баеп кайткач, минем ишеләрне танымассың да инде...

Мәгъсүм җавап урынына, Фазылны кар өстенә төртеп екты һәм тракторны куып китешли артка борылып кычкырып калды:

—Син мине сагынма! Юкса юлыбыз уңмас!..

Песиләр дә адаша

Казан-Куйбышев поездына тагыласы өч вагон Чирәм җир күтәрергә ялланган гаиләләр өчен махсус эшелон рәвешендә бирелгән булып чыкты. Татарстанның ераграк районнарыннан килүчеләр язгы бураннар аркасында озак җыелды. Ничә көн көтәргә икәнлекне белүче юк. Тупиктагы вагоннарда дүрт көн буе яшәргә туры киләчәк дип алдан әйтүче табылса, ярты халык түземлеген җуеп, бәлки кире өйләренә йөгергән булыр иде. Ә болай: "Ташкент поездына кушасылар... Юдинога чаклы мотовоз илтеп куя... Куйбышевка безнең өчен өстәмә поезд бирәләр..."—дия-дия "вербованный"ларны тимер юл тирәсеннән җибәрмичә өстәмә хәбәрләр белән юмалап тоттылар. Нотфулланың колхоз базарына барып май-каймак сатучы авылдашлары белән саубуллашып килергә исәбе бар иде, җибәрмәделәр. Колхоз идарәсендә төзелгән килешү кәгазе Партия өлкә комитетыннан беркетелгән уполномоченный кулында иде, аның сүзеннән чыкмадылар.

Нотфулланың, тавык фермасына йомырка эчәргә ияләнгән песиләрне капчыкка тутырып адаштырганы бар. "Печмән күле"нә илтте—югалмадылар, капчыкны "Шиһап чүннигенә" китереп бушатты—тагын кайттылар. Карурман читеннән карабодай ташучы "ЗИС" әрҗәсенә утыртып, "жәһәннәм"гә илтеп ташлагач, бер атнага югалып торганнар иде. Ләкин, озак көттермәделәр, берсе-бер югалмыйча, тагын да симереп, тавыклар фермасын сагынып кайтып җиттеләр.

Ул Казан күздән югалгач кына исенә килгәндәй булды. Күр әле син, Сакал Шәйхине, үзенә председатель кәнәфие алып биргән тынгысыз ирләрдән берьюлы котылды—төркеме белән калай капчыкка тутырып, Урал елгасының аръягына адаштырды... Вокзал тирәсендәге йончулардан соң, билгесезлеккә тәмам ияләшкән авылдашларның биштәр өстендә изрәгән чырайларын күргән саен уяулыгы артты Нотфулланың. Туган якта йокыга китеп, чит жирләрдә уянасы балалары алдында үзен гаепле дә, жаваплы да итеп тойды ул. Һәм юлда үткән ике тәүлек буе керфек какмады. Тәрәзәгә маңгаен терәп һәр вокзал исемен, һәр елга күперен, юллар чатын дәфтәргә төшереп барды, картадагы тамгалар белән чагыштырды. Ягылмаган вагонда жылыга кинәнмәгән халык, кул астындагы бөтен киемне иненә элде, төенчекләрдән чыгарып төренде. Айжамал бик еш саташып уянды, өнендә уйлаганы төшендә күргәне дә бер борчу—Нотфулла тукталышларның берсендә урамга чыгар да югалыр, жиде үги бала итәгенә тезелеп калыр кебек тоелды ана. Уянган чакларында мамык шәлгә уралган кара тутлы Айжамал, ирене өстендәге коңгырт минен сикертеп, Нотфулланы әрли: "Нәрсә дип тәрәзә ялап барасын инде, жанашым, кеше йоклаганда ял ит!.." Нотфулла, утырган

килеш мәрткә киткән ил агаедай, ишетмәмешкә сабыша.

Дамбар станциясендә аларны арба таккан тракторларга күчереп утыртгылар. Көнозын барганнан соң, ниһаять: "Килеп життек!" дигән җылы сүз ишетелде. Ырмаулы такталардан җыелган тиңдәш өйләрне бер сызыкка тезеп, дүрт урам иткәннәр. Монда Чирәм җирләргә илле алтынчы елларда ук күчеп килгән гаиләләр яшәгән. Сөрү җирләренә якынрак булсын өчен елга-сулардан йөз чакрым читкә салынган бу ясалма авыл бердәнбер артезиан коеның санаулы суы белән генә туена, шуна күрә өй түрендә бакчалар юк, агачлар үсми. Буш өйләр, төзүчеләрдән калганча, бер-берсенә охшаган, кәрниз почмагына сугылган номерыңны онытсаң—чит гаилә өстенә килеп керәсеңне көт тә тор! Чирәм җирләрне Мәгъсүм капка төбенә хәтфәдәй түшәлгән бәпкә үләне дип күз алдына китерә иде. Ә монда—офык әйләнәсе чиксез дала, өй тирәләре яланаяк басып булмастай дөя чәнечкесе. Кулга ияләштерәсе җир көрәк күрмәгән кара туфрак—узган елгы типчак, кылган, әрем ише әрсез үләннәр язга чыккач каракура болынына әверелгән.

Далада көннәр гел бер төрле. Әйләнә-тирәдәге мохит стенага эленгән сагышлы рәсем кебек. Бары тик ел фасыллары алышынганда гына җирдәге төсләр үзгәрә. Яңгырлар яуганда кыр эшләре туктап бераз ял бирә. Ә инде кыш көннәренең эчпошыргыч төннәре, утсыз өйләре, мәрхәмәтсез җилләре әтиләрне эчүгә сабыштыра, балаларны азындыра, әниләрне елата һәм өч елга ялланган гаиләләрне качып китәрлек хәлгә төшерә.

Фазыл сигезенчедә укыганда әйләнеп кайткан иде инде алар. Тик Нотфулланыкылар гына күренмәде. Туган авылга кайтып, яңадан үги ана исеме күтәрәсе килмәде Айжамалның. Монда ул гаилә хуҗасы, яңа көн туды исә алай ит, болай нит, дип Нәфисәдән калган карт кайнана тыкшынмый. Иярә килгән балаларга өстәп үзе дә икене алып кайтты. Карынында үскәннәре аның өчен "Әни!" дип өзелеп тора. Ләкин, үгиләрнең "Әй"ләре дә колакка якын. Авылдашлар кайтып киткәннән бирле аңа Айжамал дип дәшкән кеше юк. Нотфулла—Никита, Айжамал—Аня, Мәүлия—Маша, Мәгъсүм—Яша хәзер.

Исемсез авылдан алар Орск якларына күчеп киттеләр. Тора-бара Нотфулла Казакъстанның Ырымбур белән чиктәш Уральск шәһәре тирәсеннән Жаеклы, урманлы һәм исемле авылны белешеп кайтты... Ләкин, Уральск якларына да күнеле ятмады. Күчмә тормышка ияләнгән—дүңгәләк гаилә тагын кузгалды. Сайлана торгач, Ташлы районының Ранняя дип теркәлгән саласына килеп төпләнделәр. Айжамал каршы дәшмәде, ияреп тик йөрде. Нотфулланың күчә-күчә юньле урын таба алмавы үзенчә Шәлегә охшаган авылны эзләве иде.

Ранняя авылын Мәгъсүм янына бәхет эзләп килгән Фазыл да яраткан иде. Урал яры, урман ышыгы, күлләр шәплеге, киек-җәнлекләр күплеге, кыш көне килеп урырдай печәннәре гашыйк иткән иде Фазылны. Хәмдияне алып киләсе дә яшисе иде кана... Ләкин, бу өмет Хәмдия урланган көнне үк чәлпәрәмә килде...

Ә Нотфулла Ранняя авылында берүзе калганчы яшәде. Трактор чанасына төялеп, Чирәм җирләргә алгысынып чыгып киткәннән соң, кырык ел үткәч кенә, ул Айжамалны урыс зиратына җирләп, тугыз баланы тугыз якка таратып, инде бүтән кайгы сыймас язмышын йомгаклап, туган авылына кайтып егылды.

Боларын язып торма...

Мәгъсүмнең Яна ел белән котлап җибәргән открыткасы кышкы каникулның өченче көнендә генә килеп житте. Шул тиклем ерак араларны үтеп тә бөгәрләнмәгән, әйтерсең лә Шәленең хат ташучысы, өеннән алып кына, үзе язып тоттырган. Котлау сүзләре һәм Нотфулла гаиләсенең яңа адресы өстенә өч урыннан почта мөһере сугылган. Икенче

ягында әкияти рәсем: йолдызлы күк йөзендә жигүле өч ат оча, түрле чанада кызыл тунлы яшь егет—ак бүрегенә "1961" дип язылган, култык астына өстәл чыршысы кыстырган, жирнең ясалма иярчене елмаеп юл бирә... Открытканы өй эчендәгеләр кулдан-кулга йөртеп карады. Нинаять, Динә өстәлгә бер конверт куйды.

—Дәфтәр бите жыртып бирегез,—диде ул, өч укучыга берьюлы дәшеп. Өч кушбит жыелгач, кара савыты белән ручка сорап алды.

Балаларга бу хәл бик кызык тоелды. Башлангыч белеме булмаган абый-апаларны кичке мәктәпкә жыеп, латин имласы белән уку-язуны янарта башлаганнар иде. Кырыктан узган Динә, Мөлеков сүзен олылап, ярты ел чамасы укырга йөреп карады. Колхозлашу елларында укып азапланган грамотаны хәйран искә төшерә башлаган иде. Ләкин, белем алу—ул жиләк вакыты кебегрәк икән. Кыш житкәч тубал күтәреп урманга керүдән ни файда... Өч баланың укыганы да житкән. Кич белән аларның үзләрен генә калдырып йөрү килешмәс. Болай да ятимлектә үсеп, ялгызлыктан туйганнардыр инде... Калын китапларны укырга йөрәге житмәсә дә сыздый-быздыйга кулыннан килә Динәнең. Ләкин, анын хат язарга теләве балалар өчен көтелмәган яналык иде.

—Гомергә бер хат язып бирергә иренәсез инде,—диде әни кеше, лампочканың матчадагы кадакка уралган шнурын озынайтып.

—Мин клубка соңга калам,—диде кызы.

—Мине әби көтә торгандыр,—диде олы улы, юлның клуб аркылы үткәнен искәрмичә генә.—Әнә, Фазыл язып бирсен, маржа кызлары белән хат алышырга бик ярата.

Хатның баш өлеше: "Исәнме Нотфулла, Айжамал һәм балалар?"—дигәне генә латин хәрефләре белән язылды. Калганын Фазыл дәвам итте. Әнисе әйтеп торды...

"...Үзебез һаман шул иске өйдә яшәп ятабыз. Кышлар суык бездә, көнгә ике тапкыр мичкә ягабыз.

Әбиегез исән әле. Аны күрше Миниса карый..."

Фазыл каләмен кара савытына манган арада Динә язылган кадәр хатка күз салып ала, хата белән язмый микән, ди.

"Ферма тавыклары кырылып бетте. Сыер күлендә гараж хәзер. Колхоз куяннарының исәннәрен мәктәпкә бирделәр.

Мәктәп дигәннән, Мөлековны эшеннән алдылар. Унынчы классны бетергән йөз бала урыс теленнән язма эш буенча имтихан тапшыра алмады. Көзгә калдырганнарые, анда да өч кенә кызның эше үткән. Син аларны беләсең: берсе—Тажи кызы, берсе—Сәрвиназ кызы, өченчесе—урыс теле укытучысы Бәйрәмгалинең сеңлесе иде. Калганнары катыргы ала алмады. Инде минем олы малаем янадан унынчы класста укып йөри..."

—Әни,—дип бүленде Фазыл,—абыйлар күчми калды дип кенә язым әле, алай кыскарак була.

—Тутырып языйк, улым, бер абыең гына күчми калган икән дип уйлар. Алар бит анда йөздән артык бала! Аннан соң, мәктәпне тәмамлаган елны күчми калу дип язсаң тагын аңламаслар. Нотфулла абыең Юаш булса да төпченергә ярата.

—Мин барыбер аңламыйм. Дүрткә-бишкә генә укыган абый нишләп имтихан бирә алмады икән ул?

—Хатны ни өчен язабыз дип уйлыйсың? Мөлековны эштән алганнарын белсен. Сәбәбен үзе чамалар... Кулың армаса яз әйдә...

"...Бәйрәмгали бөтен язма эшләргә "икеле" куйган, күчерергә ирек бирмәгән, әллә нинди хаталар эзләп тапкан. Мөлеков балаларны яклап маташкан, тыңламаганнар. Бөтен ил алдында хурга калдык..."—диген улым, йәме!

—Ашыгып әйтмә әни, юкса хата китә.

—Төн озын. Иртәгә укырга барасың юк. Мондый суыкта колхоз эше

дә качмас. Яз әйдә...

"Яңа акчаларга ияләнеп булмый, бик вакландык. Ун тәнкәлек шикәрне бер сумга алабыз. Базарда бәрәңгенең килосы ун тиен, бигрәк хур иттеләр, саткан акчаң кесә төбенә төшеп җитми. Онытта язганмын. Мәктәптә яңа директор хәзер. Читтән китерделәр. Әллә, Зиннәт шунда..."

—Наил Зиннәтович ул. Озын чәчле, кечкенә буйлы, бик усал абый. Линейкага тезеп әрләвен күрсәң... Марат абый алтыные ул.

—Боларын язып торма, улым. Читтән килгән кешеләрне барыбер белмәс Нотфулла. И-и, самый главныен онытып торам икән, яз әле, яз.

"Сакал Шәйхи Бәйрәмгалине парткомга куйды—секретарь итеп. Кабат сәләм белән—Динә..."

Хатны кем язганын Мәгъсүм аңласын өчен, Фазыл җәяләр эченә үз исемен өстәп куйды.

—Әни, художниклар килгәнне язмадык инде.

—Анысы икенче хатка калсын.

Хаталар китмәде микән, дип, язганнарны бер кат укып чыккач, Фазыл көрсенеп куйды.

—Әни, Сакал Шәйхине мин ялгыш Шакал дип язганмын, бозам инде.

—Калсын, улым, тимә, Нотфулла абыең көлә-көлә укыр.

Ырымбур белән ике арада ярты елга бер булса да хатлар йөреп торды. Нотфулла ягыннан гаилә яңалыклары гына килә, чөнки, аларның нинди тормышта, нинди жирдә яшәвен күз алдына китерү мөмкин түгел, авыллары, күрше-күлән, дус-ишләрен дә белүче юк. Шуңа күрә, хатлары гел бер төрле: Мәгъсүм көтүдә, абыйлары трактордa, Нотфулла үгез симертә. Айжамал сыер сава, олы кыз бозау карый, кечкенәләре өй тирәсендә.

Фазылдан килгән хатлар кулдан кулга йөреп, кат-кат укылып, таушалып бетә. Алардагы вакыйгалар Нотфулланың күз алдында калган авыл сурәтен яңарта, үзгәрешләр кертә, андагы кешеләрнең исемнәрен искә төшереп тора.

Еллар үткән саен, Фазылга хат язардай адреслар да артты. Абыйсы, армиягә киткән жиреннән, Каспий диңгезе тирәсен яратып, хезмәт елы беткәч, яңадан китеп барды... Апасын үзбәк егете Караком чүлендәге "жәннәт"кә алып китте.

Фазылның хатлары төрле тарафларга кыйбла тотса да, эчтәлекләре бер булды. Сирәк-мирәк бер хат яза да шуны күчереп өч адреска жибәрә... Хатларның сирәклеге язарга иренүдән түгел, ә яңалыклар житмәүдән генә. Елдан-елга саркып кына жыела ул яңалыклар...

Кукурузлы рәсемнәр

Көн саен яңа көн туа торыр. Ләкин, һәр яңа көн авыл тормышы өчен яңалык алып килми. Көндәлек гадәти вакыйгалар кеше теленә керми. Өйдән-өйгә, урамнан-урамга, авылдан-авылга житкереп сөйләр өчен яңалыкның йә мәзәге, йә фажигасе, йә гаебе, йә әһәмиятле мәгънәсе булырга тиеш. Авыл жирендә яңалык ясаучыларның берсе—колхоз рәисе.

1963 елның җәендә, "Кубань" автобусына төялеп, авылга кунаклар килеп төште.

Шәһәр якын булгач, кунакларның өзелгәне юк әлбәттә, өч йөз илле тамашачы сыйрдай клуб барлыгын белгәч, атна саен артистлар сагынып килеп тора, районара семинарлар үткәрер өчен колхозның ашханәсе жайлы. Тере балык, карбыз, алма сатучылар, кырык тартмачылар, Саба көмешчеләре, күрше-тирәнең Балык Бистәсе, Лаеш кебек районнарында янгыннан ярлы калган хәер сорашучыларың берсе дә дүрт мең ярым кешеле авылның олы юлына тузан кунарга ирек бирми... Ләкин, автобустан коелган кунаклар үзенчә сәерләр иде. Аркаларындагы биштәрләре шәһәрчә ыспайлыкларына килешеп тора, кыска жиңле күлмәкләре, аксыл чалбарлары бөгәрләнмәгән,

яна сандалыйларына тузан кунып өлгермәгән, башларында кин кырыйлы салам эшләпә. Араларында хатын-кызлар затыннан берәү дә юк. Кулларында әкәмәт әйберләр... Чемодан дисәң—юка, куна тактасы дисәң—калын, аяксыз өстәл дисәң дилбегә кисәгеннән кагылган тоткасы бар.

Авыл үзәгенә якынайган саен, кунакларга иярген малайлар төркеме зурая барды. Каникулга дип тугарылган мәктәп баласы мажара эзләп су буйларында, ватык трактор тирәсендә, иске фермаларда уйнаса-уйнар, әмма мәктәп янына якын бармас. Анда уен бетә, укулар сагындырмаган әле. Кибет тавын күтәрелгәч, юл икегә аерыла. Кунаклар кая борылыр—идарәгәме, мәктәпкәме, дип аптырап торганда, малайларның үзләреннән сорадылар: "Колхоз правлениесе бу яктамы?"

Малайларга жан керде, шөкер, болар яна укытучылар түгел икән... Сакал Шәйхидән сөенче алырга дип кунаклардан алгарак чыгып йөгерделәр.

Шәһәрдән чыккачы ук телефоннан киңәшеп өлгергәннәр, ахрысы, Шәйхи гомердә булмаганны, көн уртасында эш бүлмәсен саклап утыра. Ялтыравык "Победа"сы кояшта кибенә.

Председатель сөенечен тыя алмастай тавышы белән малайларга йомыш өләшә:

—Менә бу абыеңнар, пнимаете так, художниклар, авыл кешеләренең рәсемнәрен ясарга килгәннәр... Син,—диде ул кул астына эләккән беренче "йомышчыга",—менә бу абыеңны жанкай Габделхәйләргә озатып куй... Син... дунгыз көтүчесе Галимулла абзаннын кайда торганын беләсеңме? Белсән—давай шунда. Жиһанша малае янына кайсыгыз бара?.. Ә син,—диде ул Фазылга төртеп,—Мәрфуга апаңнарга!

—Нишләп Мәрфуга апага, ә нишләп безгә түгел. Минем әни дә матур, ясасыннар рәсемен...

Рәссамнар көлешеп куйды. Ә Шәйхинең чырае кинәт икегә бүленде сыман: бер бите кунакларга кушылып елмаерга теләде, ә икенче янагы ачудан тартышып куйды.

—Бөтен малайлар да "ярар!" дип торганда, пнимаете так, нишләп син генә киресен сөйләп торасыңдыр?! Хәерченең теле әче диләр!.. Мәрфуга апаң Хезмәт герое, алдынгы сыер савучы. Ә синең әнкәң төрле эштә эшләүче гади колхозчы гына! Бар, теленә салынма! Художник абыең юлдан килгән, карыны ачкандыр, тизрәк озатып куй.

Фазылга иярген чандыр рәссамны Сакал Шәйхи аркасыннан сөеп калды.

—Энем, син бу көчекнең өрүенә игътибар итмә. Нәселләре-күршеләре белән шундыерак алар.

Чандыр рәссам ашыгып атламады, Фазылны сөйләндереп калырга теләде, ахрысы.

—Председательгә үпкәләдеңме, ник дәшмисең?

—Шәйхи абыйга үпкәләргә ярамый. Безнең әле өй салып чыгасы бар... Ә безнең өй рәсемгә ясарга матур, түбәбездә алабута үсә, күрмичә калсак—тавыклар менеп актара, черек саламны яраталар алар. Сәке астында ояда утырган каз, урамда минем тавышны ишетсә, куыш бүрәнәдән башын тыгып кычкыра.

Чандыр рәссам Фазылны тыңлый-тыңлый алга чыгып барды, әйтерсең лә ул, Батыр Мәрфуга янына малайны үзе озата бара. бактың исә, сөйләгәннәрен тыңлаганда йөзенә чыккан кызгану хисен сиздермәс өчен шулай итә иде ул. Ә Фазыл сөйли дә сөйли.

—Абый, сез үзегез Казаннанмы?

—Әйе, агайне.

—Мин дә үскәч Казанга китәм. Анда утын-печән ташымыйлар. Көз житкән саен өйләргә ыры белән нигез өясе дә юк, кайнар торбалар жылыта. Суны да чишмәдән ташымыйлар—кухнядагы өстәл артыннан гына үрелеп аласы... Минем апай үзбәк егете белән хат алыша, анда гел жәй икән, утыннын һич кирәге юк, ди. Жәен-кышын жиләк-жимеш үсеп ята.

—Арттырасың инде, Фазыл, кыш көне үсми торгандыр...

—Ник үсмәсен! Колхоз базарында үзбәкләр җәен-кышын өрек сата—каян килә соң ул?

—Сезнең авыл да җәен-кышын бәрәңге ашый. Кар астыннан чүпләмисездер ич?

—Чүплибез... Гаилә башына гектарлап бүлеп бирәләр ул колхоз бәрәңгесен. Безнең әти булмагач эш озаккарак сузыла. Күчләрдән төяп жибәргәндә карлар яуган була... Ярый, әнә ул Мәрфуганың өе. Мин шушында гына калам, курыкмагыз, этләре юк.

—Ә син, агайне ник шүрләдең?

—Минме?! Һе... просто якын барасым килми... Безнең авылда хезмәт батырларын бик өнәп бетермиләр.

—Көнләшәләрме?

—Өенә кергәч күрерсең әле... Нәрсәсеннән көнләшәсең инде аның?!.

Фазыл чандыр рәссам белән саубуллашу сүзен кыскарак тотып, тагын идарә янына йөгерде. Аның уенча, әле Казан кунаклары таралып бетмәгән һәм ул аларның берәрсен һичшиксез үзләренә алып кайтачак, әнисенең рәсемен ясаттырачак иде. Ләкин, Шәйхи эшне кызу тоткан, рәссамнар инде исемнәре мактау тактасына күчкән алдынгыларга, хәллерәк гаиләләргә, яңарак өйләләргә өләшенгән иде.

Язгы сессияләрнең берсендә Шәйхинең урыны рәссамнар союзы идарәсе председателе Харис Якупов белән янәшә туры килде.

Алдан килгән депутатлар арткы рәттән җайлырак урынны сайлап ала, соңга калганнары иң алга—обком секретаренең күз алдына килеп утырырга мәҗбүр була.

Сессиядә каралган жиде мәсьәләнең иң мөһиме—икенчесе иде. Днепропетровск шәһәренең Кукуруза Институты Идел буе районнарында чәкән өлгерерлек кукуруз үстерү өчен салкынга чыдам сорт эзләп тапкан. Хәзер исә, ул сортны тиз арада Татарстан кырларына жәелдерергә кирәк иде.

...Сөекле халкына нинди ризык ашатырга кирәген Патшалар үзләре белә. Украин егете—"Кукуруз Патша"ның тозлы суда пешкән чәкән яратуы бер дә гажәп түгел. Ләкин, ул җыелыш саен, кукурузны бөтен Совет халкы яратырга тиеш, дип кычкырды.

Бөтен кырларны кукуруз басты, силосы—сыерларга, чәкәне—халыкка. Арыш ипие белән бодай күмәчләре артта калган илләргә китә, ә безгә, сап-сары кукуруз каравае! Кайнар килеш кулыңа эләксә ашап өлгерәсең, өлгермәсәң уалып төшә. Ярмасыннан ботка пешә, крахмалыннан кесәл болгаталар, мәлтүзеннән конфет ясыйлар... Халык үзе кукуруз үстерә, үзе көлә: "Әле дә ярый Кукуруз Патша борчак яратмаган, бөтен Советлар Союзы чалбар төбеннән кикереп йөрер иде",—ди.

Әле дә ярый банан яратмаган...

Казанга килгәч Хрущевны чәк-чәк белән каршы алганнар. Ә ул, йола нигъмәтен умырып капкан да: "Кукуруза штоли?"—дип бик сөенгән имеш ди.

Кукуруздан Шәленең дунгызларына да өлеш тиде. Алар өчен Казанның крахмал заводыннан әчегән мәлтүз ташыдылар. Мичкәле машина белән алып кайтып, янгыннан саклану өчен жиргә күмелгән су чаннарына бушаттылар. Ә Галимулла әлеге кукуруз балын ат арбасына салынган калай мичкә белән дунгызлар улагына ташып торды. Ай эчендә чучкалары Галимуллага гашыйк булды: арба көпчәгенең шыгырдавын ишетүгә үк утар коймасыннан сикереп чыгардай булып ашкыналар, колгага сапланган казан чиләге белән үрелеп улакка мәлтүз сосканда кулларын үбәләр. Галимулла аларга карап уйлап-уйлап тора да, тагын бер уйлап куя: "Нәрсәсен яраталар икән шул чаклы?" Улак ялагач чырайлары Сакал Шәйхинеке төсле кызарып чыга түгелме? Мичкә тирәсендә чебеннәр генә түгел, карабодай басуына барышлый, юлларыннан язып, бал кортлары да саташып йөри икән, димәк, пүчтәк

нәрсә түгел... Галимулла имән бармагын мәлтүзгә манып ялап карады—үзе хуш исле, әчкелтем, сыек повидло кебек ябышкак баллы... Бәй, чүпрә генә өстисе мона, су да кушып торасы юк!

Дүрт чиләкле сөт бидонын калай түбә астындагы кызуга ничек күтәреп менгәндер Галимулла, анысын өйдәгеләр күрми калды... Ә ике атнадан бер төркем ирнен Галимулла чормасында җырлашып утыруын бөтен урам ишетте... Кукуруз балының даны бөтен авылга чорма җыры булып таралды. Ун тонналы чаннар төн чыкканчы коргаксыды. Крахмал заводыннан кайтып килүче сөт машинасын урман эченә алып кереп бидоннарга саудылар. Дунгызларның тагын Галимулладан күңеле бизде. Участковый Архипов катышкач кына мәлтүз ташуны вакытлыча туктатып тордылар... Менә сиңа кукуруз!..

Харис Якупов белән сөйләшеп утырганда: "Безнең авылда атлы казак күмелерлек кукурузлар үсә!"—дип мактанудан башланган сүз рәссамнарның зур төркемен Шәлегә ижади кунакка чакыру белән тәмамланды.

Мактаулы кукуруз өчен "Карповка" дип аталган җитмеш гектарлы мәйдан бирелгән. Анда аны тәрәзә төбендәге тамчылы гөл кебек сокланып һәм иркәләп үстерәләр—мактаныр өчен. Быел кыш буе мәктәп ишегалдына җыелган табигый ашламаларның бөтенесен китереп чәчтеләр. Әле һәр балага өеннән иллешәр кило тирес алып килергә дигән йөкләмә биреләсе иде, җыеп торырга ышык урын тапмадылар.

Зур авылның үз кыенлыклары бар. Өй саен икешәр-өчәр машина утын, кыш чыгарлык печән әзерләргә кирәк. Өч бригадага бүленгән авылдан һәркөн иртән алты көтү чыгып китә. Колхозның сигез фермалы сыерларын да җәйләүгә куып чыгарсаң, хужалыклар өчен печән чабарлык болыннар калмый. Кулында транспорт булган гаиләләр җәһәннәмдәге сазлыктан кычыткан ура, карурманнан юкә себеркесе җыя, күрше колхоз чигеннән сорамыйча гына клевер төяп кышка житәрлек азык әзерли. Фазыл кебек арбасызлар печән урынына буразнадан чүп үләннәр йолкып ташый. Ике куллап үлән йолкый-йолкый, аның чәнти бармакларына үлән яшеле йога һәм ул беренче уку чиреге тәмамланганда гына юылып бетә. Арбасызлар ябырылгач жил тегермәне янындагы басулар тиз чистара, чүп-үлән авылдан ерагая... Фазыл бер көпчәкле тачкасын комлы юлдан сөйрәп Карповка басуына юнәлә, ана көянтә тоткан апасы да иярә.

Ах, ул кукуруз арасындагы үләннең шәплеге! Кукуруз бераз күтәрелгәч, рәт араларын эшкәртергә трактор керми, эт эчәгесе, сөтле билчән, тал үләне, кәлшә, ак чәчәк кебек вак хайван яратырдай чүп үләннәр котырып үсә.

Биек кукуруз арасында шунысы рәхәт—кояш өтәләми. Озын җиңле күлмәк кисәң үткер кырлы аскы яфраклары кискәләми. Бер буразна башыннан утарга тотынасың, култыклап-култыклап тезә барасың, шул эздән кире чыкканда җыеп алып чыгасың.

Фазыл тачкага таптый-таптый төяп, бау белән бастырыклап куя. Апасы—үзенә җыйганны колач житмәстәй ике көлтә итеп, чиләк баулары ялтыраткан көянтә ыргагына элә.

Карповка басуында чүп җыю кыен түгел, иң хәтәре—Сакал Шәйхинең күзенә чалынмау. Буш көянтәне кукуруз арасына ыргытып була. Ә кул арбасы чаклы тачканны күрсә—"Победа"сыннан монтажка таягы алып килеп, ватып-жимереп йомычка өеме итә... Үзеңне эләктерсә, капка төбенә житкәнче туктый алмаслык итеп, арт ягына тибә. Елый-елый печәнсез, арбасыз килеш кайтып керсән—өйдә тагын өстиләр.

Берсендә, Фазыллар басуга төшеп, тачканы язгы ташулар ярган ерганак төбенә яшереп өлгергәннәр генә иде, авыл ягыннан теге Алла кәһәрләгән "Победа" килеп чыкты. Малай бер якка, апасы икенче якка сикереп, кукуруз буразнасына сузылып яттылар. Шәйхи, машинасын сүндермичә генә җиргә төште, кыр читендә әрле-бирле йөренде, эчкә кермәде—ак кепкасын чәкән сарысына буярга теләмәде... Ә Фазыл шул минутта, буразна төбендәге эт

эчәгесенә борынын терәп, сулыш алырга куркып ятты. Кукуруз арасыннан өркетеп чыгарырга теләдеме—"Победа" китәр алдыннан сузып-сузып кычкыртты...

Чүп үләне җыйганда күлмәккә тамыр туфрагы коела, анысы берни түгел. Фазыл, апасының тузанга баткан чәч толымын күргәч, күз төбендәге тирне бик озаклап сөртте.

Олы юлга чыккач, Сакал Шәйхи күрсә дә тия алмый. Машинасын туктатып: "Каян җыйдыгыз?!"—дип җикеренсә, җавап әзер: "Андреевка кырыннан!.." "Победа" тачкадагы печәнне төтен исенә батырып кузгалып китә, тәрәзәдән: "Житешмәгән җирләре юк, шул хәерче көчекләренең!"—дигәне генә ишетелеп кала.

Кайтыр юллар кыскарак дип, туган авылны сагынып кайтучылар гына сөйләнә торгандыр. Учың белән йолкып җыйган үләнне челлә кояшына ияреп комлы юлдан тачка белән этеп кайтсаң, һай ерагая ул юллар... Андый минутларда синең өчен бердәнбер этәргеч өмет бар—фермалар янына кайтып житсәң, су эчәсең!

Баганага беркетелгән чуен чүмечнең сыер борынына җайлаштырып бөгелгән тишекле теленә басып су җыясың. Сыерлар көнләшерлек комсызлык белән шул автопоилкага капланып чөмерәсең. Су житмәгәч, бөгәлҗәле тимерне маңгаең белән этәсең... Сулышың беткәч, юеш чыраеңны ферма түшәменә текәп тирән итеп тын аласың да тагын, тагын чөмерәсең. бу җәйнең үги челләсендә синнән дә бәхетлерәк кеше юк!

Син тагын яши башлыйсың. Өенә кайтып егылырлык хәл керә. Рәхмәт су иясенә! Хәтта, шушы сулы фермаларны салдырган Сакал Шәйхигә дә рәхмәт! Кукуруз үстерергә кушкан Хрущевка да рәхмәт!

Харис Якупов үзенең шәкертләре белән авылны рәсемгә күчерә башлады. Кемдер җәйләүгә килеп, сыер көтүен ясап ятты, берсе көтүче Жиһанша малаеның чыбыркысына иярде. Дуңгыз караучы рәсемен ясар өчен Мәрзияны мәктәп күләгәсендә ун көн буе утырттылар, дуңгыз фермасы янында рәссам ярты гына сәгать түзә алган—укшыган диделәр... Араларындагы чандыры Сакал Шәйхинең эш бүлмәсендә яткан. Иртәнге дүрттә килә, идарә утырышында катнаша, нәрәт биргәндә председательнең һәр карашын, йөзендәге һәр чалымны, кул хәрәкәтләрен, басып торышын, кыскасы, сүгенүеннән гайре бөтенесен кәгазь битенә карандаш белән төшереп барган...

Художниклар Казанга бик күп рәсемнәр күтәреп китте.

Фазыл мәктәпне тәмамлап килгән елны сәнгать музеена еш кергәләде. Ул дивар ларга эленгән көчле кешеләр арасында авылдашларын күрер өчен генә түгел, бәлки, теге чандыр рәссамны очратып булмасмы дип йөри иде. Әллә юанайды ул, әллә юллар кисешми—туры килгәне юк.

Авыл турында әле бик күп рәсемнәр булырга тиеш иде. Кая соң алар? Төрле нәшриятларда басылып чыккан яңа альбомнар актарган саен, Фазыл кабаланып-кабаланып таныш күренешләрне эзли... Салам түбәсендә алабута үскән кечкенә өй кая? Үзеннән биек кукурузлар арасында атка атланып позага баскан Сакал Шәйхи рәсеме кая? Колхозны миллионер итәбез дип "Хезмәт көненә" алданып яшәгән көчсез кешеләр кая?..

Хатлар язганда, Фазыл әлеге вакыйганы яңалык итеп бер җөмләгә сыйдырыр:

"Безнең авылга художниклар килеп, җәй буе рәсем ясап яттылар..."

Әйе, иркенләп сөйли китсәң, һәр яңалык зур бер вакыйга. Тәжрибәсез хат язучының дәфтәр битенә яңалыклар сыя—вакыйгалар сыймый...

"Элеккеге идарә бинасын участок больницасы иттеләр. Сакал Шәйхинең жиңгәсе баш врач булып кайтты. Авылда бер исән кеше юк икән, больницада көн саен чират..."

"Районнан "ПМК" төзүчеләре килеп, Казан юлы өстендә зур плотина кордылар. Колхозның бер миллион сум яңа акчасы киткән диделәр. Инеш суы диңгез булып җәелде."

"Яңа мәктәп өчен Питрәч заводыннан кирпеч ташыйлар. Без унынчыны тәмамлаганчы төзеп бетерәчәкләр ди."

"Почта урамындагы Зәйнулла өр-яңа "Москвич-412" машинасы отканые. Сакал Шәйхинең энекәше отышлы билетын сорап килгән. Зәйнулла ризалашкан. Иске машина белән ике мең сум акча өстәп биргәннәр."

"Быел яз көне теге плотинаны ташу алып китте. Цементы юылган, баганалары уалган диделәр. "ПМК" начальнигын алыштырдылар. Шәйхигә сүз булмады..."

"Колхоздан ссуда алып өй салдык. Өмә белән күтәрдек. Бурасы усак катыш юкә иде, өйне кырмыска басты. Атна саен агуладык. Әби мәктәп өеннән безгә килеп үлде..."

"Өйне сатып ссуданы түләдек. Әни апа янына Үзбәкстанга китте. Абый һаман читтә... Мин унны бетердем. Яңа мәктәп өлгермәде әле..."

Һәм Фазылның мәктәпне тәмамлап бәхет эзләп китүе соңгы хатларга кергән соңгы яңалык иде. Аның Мелиорация министрлыгы каршындагы су скважиналары бораулау оешмасына эшкә урнашуы туганнары арасында хатлар өзелүгә сәбәп булды. Фазылның даими адресы юк. Аны хат ташучылар эзләп табарлык түгел. Үз кирәген ул бары тик үзе генә эзләп таба ала иде...

IV. МӘДИЯР

Иске бишмәт

Адреслар өстәленнән бер-берсен эзләүчеләр күбәйгән, ахрысы, Фазыл өчен кирәкле белешмәне калын кәгазь өеменнән көч-хәл белән актарып чыгардылар.

—Миңлегалиев Мәдияр Ярулла улы... Сез эзләгән кеше шушымы?

—Әйе, әйе,—диде Фазыл сөенеп, әйтерсең лә Мәдияр шаяртып адреслар өстәле астында качып яткан. Һәм ул менә хәзер үзе килеп чыгарга тиеш.

—Адресы: Мамадыш районының Зюри авылы.

—Зюри түгел, Шүләнгер... Ул авылдан чыгып киткәненә биш былтыр инде аның.

—Кызганычка каршы, архивта туган авылы гына теркәлгән. Әгәр кая да булса вакытлыча прописка керсә безгә андый адрес хәбәр ителми. Ул чагында туган авылын гына әйтеп бирәбез.

—Кайда туып үскәнен сездән башка да беләм мин аның. Вакыт әрәм итеп, көтеп йөрисе юк.

—Бүтән чарагыз калмаса, телевидение аша фотосын бирегез.

—Мин бит жинаятьчеләрне эзләмим. Миңлегалиев—элеккеге хезмәттәшем—ул эш өчен кирәк.

—Гражданин! Алайга китсә, үзегез табыгыз!

Адреслар өстәленен нәни тәрәзәсе ябылды.

Нәсел агачының тамыры авылда булса адәм баласын эзләп табуы жинелрәк. Туганнары, күршеләре, классташларының берәрсе аның турыда ниндидер хәбәр саклый. Кайтканые, күргәнием, ишеткәнием, дип, син эзләгән кеше хакында өметләндереп юатырлар, күчеп яшәгән жиренең кайдалыгын аңлатырлар. Авыл үз баласын югалтмыйча хәбәрдар булып саклый. Менә шуна күрә дә, курсташлар, хезмәттәшләр, юлдашлар үзара адрес алышканда туган авылларын күрсәтеп язалар. Хәтта, күченеп шәһәр туфрагына тамыр жәйгән кешеләр дә үзенең авылын ышанычлырак адрес итеп исәпли. Бәхет эзләп зур-зур калаларны санап йөрергә була. Ләкин, туган авыл бер генә.

И, Шүләнгер, әле дә ярый Мәдияр өчен син бар!

Мәдияр, Мелиорация министрлыгы таркалгач, су бораулау эшенә кул селтәп, тагын Мамадышка кайтып урнашты. Районның кулланучылар җәмгыяте ишегалдында атналар буе яңа шофер көтеп яткан бөркәүле иске машина бар иде, шуның белән кибетләргә йөк ташырга ризалашты. Шимбә һәм якшәмбе көннәрендә Шүләнгергә ашыга. Саладан кала булып азынган Мамадышның бер читендә фатирда яшәгән буйдак өчен атнаның ике көнендә әти-әнисе янына кайту күңелле юанычка әверелә.

Фазыл аны Шүләнгердә көтеп алды. Өй түрендә бөркәүле машина күренгәч, әти-әнисе нишләргә дә белмәде. Кунак егетне качырып торыргамы, ачык тәрәзәдән дәштерергәме, көтелмәгән очрашуны ни рәвешлерәк оештырырга дип, баш ваткан арада, Фазыл үзе шамакайга әверелде. Ул, әти кешенең малахаен, сырган чалбарын, җиңсез сырмасын киеп, җәй көне дә болдырдан төшмәгән киез каталарны сөйрәп машина янына чыгып басты. Мәдиярның, капка төбенә кайтып туктагач, әти-әни күрсә яхшы түгел дип, кабинадан чыкмыйча гына берәр стаканны "төшереп" куя торган гадәте бар иде. Бу юлысы, стаканны тутырып салып, кулына колбаса сыныгы алуга, капкада колакчынын салындырып кигән малахайлы "әтисе" күренде. Күз алдында оялмыйча ничек эчмәк кирәк—Мәдияр каушавын тыя алмыйча, хәмер тулы стаканны кабина тәрәзәсе аркылы әтисенә сузды. "Чәчрәтеп түгә, әрәм итә инде", дип уйлап куйды үзе, чөнки, ул әтисенең соңгы ун елдан артык авызына грамм да хәмер капмаганын яхшы белә.

Фазыл кырын баскан килеш, йөзен танытмыйча, стакандагыны каплап куйды, аннан соң кабымлык сорап учын җәйде. Әгәр, каушамыйча жентекләп күз салса, эш биялә кадәр кулның әтисенеке түгеллеген таный иде инде ул. Сизмәде.

—Әти,—диде Мәдияр, кыерчыгы сындырып алынган тоташ колбасаны тәкъдим итеп,—өйдә берәр күңелсезлек бар мәллә?

Фазыл дәшмәде, кеткелдәп көлүеннән туктый алмыйча, җилкәсе белән борылып басты.

—Әти, карале, килешә бит сина! Гәүдәләреңә турайды, буең үсеп китте! Әти, сәгать ничә икән инде? Кибет ябылганчы барып тагын бер ярты алып килим. Стаканны кире бир монда, машина бардачогыннан ул.

Кырлы стакан эчендәге ком сәгатен күреп Мәдияр кинәт сискәнеп китте, битендәге шадралары кызыша башлады, бармакларын тарак итеп жирән чәчен еш-еш артка сыпырды.

—Мастер! Фазыл! Кияү! Итит-митит! Нихәл, иске бишмәт?! Сине шушы киемнән буровойга алып китәсе генә бар.

—Әйдә, тизрәк өегезгә керик,—диде Фазыл, туганнарча кочаклашып күрешкәч,—мин исергәнче сөйләшеп өлгерәсе бар.

—Күнелем сизә, кияү, син мине тагын коткарырга кайткансың!..

Качкыннар

Мәдиярның: "Тагын",—дип, ни әйтергә теләгәне аңлашыла—үзенчә, житмешенче еллар башындагы хәлләрне искә төшерүе аның... Әмирне ашык-пошык пенсиягә озатып, Фазылны "Ростов-Донводстрой" мәктәбенә укырга жибәргәннәр иде. Бригада үзеннән-үзе таралды. Мәдияр бермәлгә эшсез калды. Әлбәттә, башка бригадага күчү мөмкинлеге бар иде, сау-таза, тәжрибәле бораулаучылар һәркайда кирәк. Ләкин, Мәдиярның күңел түрендә качып-посып кына яңа хыял яшәп килә... Ни өчен әле, яраткан һөнәрем, дип, гомер буе гаилә жылысы күрмичә яшәгән Әмирнең язмышын кабатларга? Әмир урынына бораулау остасы итеп, Фазылны куярлар, укып кына кайтсын! Остамы ул, бригадир дип атыйсынмы аны, йоласына туры китереп, үткәннәрне гел искә төшерер өчен "Кияү" дип дәшәсеңме—барыбер... Туганың кебек якын егет, ышаныч-лы хезмәттәш һәм тугры дус булса да, Фазыл Мәдияр язмышына артык

яналык өсти алмаячак. Әмирне алыштырганга карап кына, су бораулаучысының авылдан-авылга йөреп эшли торган "зимагурлык" тормышы үзгәрмәячәк. Качарга кирәк бу бәхеттән. Романтикасына, кыргый иреген, акчасына карамыйча качарга, үзгәрешләр матавыгыннан курыкмыйча ияләнгән һөнәрне алыштырырга кирәк... Галина белән кавышкач, бик күп кыенлыклар үзеннән-үзе хәл ителергә тиеш.

—Мин сине озата барам,—диде Мәдияр, беркатлыланып.

—Кичкырын аэропортта чиләнеп йөрмәсәң дә ярар.

—Аңламадың мәллә, Батайскига чаклы озатып куям.

Билет кассасына чиратлары килеп житкәч, Мәдияр үзенең паспортын Фазылныкына кушты.

—Милая девушка, Ростов-Донга ике билет бирегез әле. Урыным менә бу Шәмсетдинов белән янәшә булмаса да үпкәләмәм, эштә гел бергә без аның белән.

Кассирша кыз елмаюга елмаю белән җавап кайтарды һәм урыннарны бергә бирде.

—Шуткыңны аңлап бетермәдем,—диде Фазыл, үз билетын аерым кесәгә салгач.

—Борчылма, кияү, сиңа ияреп йөрисем килгәннән түгел, буш вакыт барда Галинаны күреп кайтырга кирәк. Сагындырды.

Шулай итеп алар, икесе бер самолетта, янәшә утырып Каф таулары итәгенә олактылар. Әмирләр язмышын кабатламыйм, Фазыл кебекләрнен бәхетеннән ераграк качыйм дип, ныклы карарга килгән Мәдияр өчен сәер юл иде бу.

Язилә "Ан-24"нең түгәрәк тәрәзәләренә кул болгап, Арча кырындагы аэродромда елап калды.

Сөйгәне белән көн саен күрешкән кеше сагынуның тәмле газабын, комарлы ләззәтен тоя белмәс. Мәдияр өчен сагынып күрешү яшәү рәвешенә әверелеп бара. Хезмәт хакы алган көнне кабаланып юлга әзерләнсә—кая барасың дип сорыйсы юк. Санаулы ял атнасы беткәч, бер-ике көнгә эшкә сонга калса да аптырамыйлар. Бригаданың кайсы авылга күченәсе алдан ук билгеле. Ростовтан Казанга кайтып төшүгә, ул егетләрне эзләп таба. Көн азагына өлгерсә, кичке ашка кушыла, төн уртасына калса, яшел вагонны дер селкетеп, уятып керә.

Ростов аэропортына төшү белән Фазылга ошаганы шул булды—Мәдияр инде үзен жирле казакларча иркен тота, як-ягына каранмый, аптырап уйланып тормый, тукталышларны сорашмый—ул хәзер барысын да үзе белә. Сабырсызлыгына төкәнеп, сагынуыннан үләр дәрәҗәгә житеп ашкынсан—Азов ягына йөри торган "электричка"га өлгереп, Галинаны ун минутка иртәрәк күрергә була. Мәдияр әллә кайчан бер сынады инде ул мөмкинлекне, ләкин кабаланып килеп утырган вагон бөтенләй капма-каршы тарафка—Таганрогка алып киткән иде. Шул вакыттан бирле, егет Ростовта тимер юл вокзалы барлыгын онытты, Ростовны Кавказның капкасы дип атыйлар, ул Грозный, Тбилиси, Ереван калаларының юл башында тора. Ләкин, Мәдияр Кавказ капкасыннан кергәч, Дон күперен чыгып ярты сәгать үтүгә, автобустан төшеп кала. Аның өчен бу якларда бары тик Батайск шәһәрчеге генә бар. Пассажирлар ана артык игътибар итми, милиция хезмәткәрләре паспортын тикшерми, ник дигәндә ул грузинга-әрмәнгә дә, чеченга да охшамаган. Мәдиярның нур бөркеп торган жирән чәче, шадра чәчрәгән табак бите, шадралыгына карамастан, печтик борыны һәм жирән каш сихерендә калган зәңгәр күзләре шик тудырмый, киресенчә, кара-каршы килгән һәркемнең йөзендә елмаю уята иде.

Батайск—эшчеләр бистәсеннән үсеп шәһәргә әверелгән. Кин яна урамнарында заманча төзелгән күп катлы йортлар тезелешкән. Ә Галиналар яши торган тар урамда һәркемнең саманнан салынган шәхси өе.

Һәр килүендә, Мәдияр бар дөньясын онытып, сөйгән кызының өй түренә

йөгерми, татар мужикларына хас шикләнүен жиңә алмыйча, мин югында кемнәр белән күнел ача икән ул дигәндәй, шәһәр бетереп эзләнә башлый.

Бүген ул ашыкмады.

—Шушы шәһәрчектә бер ел буе укырга тиеш инде син, Фазыл кияү. Күнелсез озын кичләрдә, Казанда калган дусларыңны сагынып газиз башкаеңны кая куярга белмичә монаеп йөргәндә, менә монда рәхим ит,—диде ул "Кавказ" кафесына ымлап. Фазылны юлдан килгән килешкә үк яңа шәһәрнең йөз мең кешесе белән берьюлы таныштырырга теләп йөрүе—әлеге дә баягы, Мәдиярның үзенчә Галинаны эзләве иде.

"Кавказ" кафесында шашлык ашап, "Кавказ" кинотеатрындагы чиратны сөзеп, "Кызыл Кавказ" бакчасын айкап чыккач кына, күнелнең караңгы почмагында посып яткан шик юкка чыккандай булды.

—Саф хатыннар, бозык кызлар була,—диде Мәдияр үзалдына сөйләнеп һәм ниһаять, Фазылны Галиналар яши торган урамга ашыктырды.

Кайткан саен кызның өйдә чагына туры килә: йә ул балалар бакчасының мәктәпкә әзерлек төркемендә ясалган контроль эшләрне тикшереп утыра, йә ишегалдындагы "буржуйка" казанында кер кайната, йә мич тирәсендә йөри. Әти-әнисе Галинаның Казан самолеты көтеп яшәвенә борчылалар иде, ник дисән—әгәр жирән татар өйләнмәсә, гел өйдә утырырга күнеккән бердәнбер кызлары сазамык булып утырып калырга мөмкин...

Бораулау осталары әзерли торган мәктәпкә укучылар атна буе агылды. СССРның дүрт кыйбласыннан Дон буена юл табып жыелганнарын тулай торакта көтеп яткачы, Осадчийларда кунак булуы күнеллерәк, әлбәттә... Килгән көннәрдә Фазыл Мәдиярга тагылып йөрде. Сергей Иванович караңгы чырай күрсәтмәде. Аларга ашау-эчүне хуҗалар белән бергә әзерләделәр. Икесенә ике карават куеп верандада йоклаттылар. Галина егетләр тирәсендә бик чуалмады, әти-әнисе каршында инсафлык саклап үзен сөйгән егете белән кавышасы кыз итеп түгел, ә күбрәк кунакханә өчен жаваплы кеше кебегрәк хис итте.

Укулар башлангач, Фазыл тулай торакка авышты. Алар Мәдияр белән сирәк күрештеләр. Эшләрен ташлап укуга килгән шәкертләр өчен программа бик тыгыз төзелгән иде, кабинет белән полигон, лекция белән практика арасындагы матавык көн саен ун сәгатькә сузыла, төшке ашка дигән озын тәнәфесләре дә егерме минут кына иде... Һәм "кияүләр", тора-бара атнага бер—ял көннәрендә генә очраша башладылар.

Казак молодой...

Кешенең кем булуы, кайда яшәве, нинди эштә эшләве аерылышканда гына кирәк икән ул. Язылышканда берсен дә сорамадылар. Паспортының урта битләрендәге тамгаларына күз салгач, гариза яздырдылар да якшәмбе көнне иртәнге унбергә килергә куштылар. Көне-сәгате житкәч, кулга никах кәгазе тоттырып, зур залга чакырдылар. Дүрт яңа гаилә, үзенең туганнары белән никах вәгазе тыңлады. Мәдиярдан бигрәк Фазыл йотлыгып тыңлады, чөнки, үзенең "чегән туенда" аңа вәгазь укырдай кеше Язиләнең әтисе Әмир генә иде. Ә монда—чәчәкле-чуклы, ялтыр-йолтыр, зиннәтле-гыйбрәтле залда—никах мөдирәсенең һәр сүзе зиһененә сенә, бәгыреңә үтә, кавышу уены гипнозланып чынбарлыкка әверелә. Әле күптән түгел генә мазутлы бушлат, сырган чалбар эченнән чыккан Мәдияр күзләренең зәңгәрлегеннән күчереп кәчтүн чалбар тектергән, кызыл күлмәгенең сәдәфләрен каплаган зәңгәр галстугындагы чәчәк сурәтендә йөзек кашы жемелди.

Никах йортында һәркем үз кияве, үз килене тирәсендә мәш килә, Мәдиярның кара кәчтүн кимәвенә дә исләре китмәде. Гаилә берлеген тикшергән очракта да, Осадчая Галина Сергеевнаның ниндидер Миңлегалиев Мәдияр Ярулловичның хатыны булырга риза дигәне гажәпләндермәде.

Кавказ капкасыннан керден исә, син инде милләтләр бәйләменең бер вәкиле.

Дон аръягында зур туйлар күбесенчә көз көне була. Мәҗлескә чакырып йомышчылар бөтен станицаны йөреп чыга, ничә кунак киләсен хуҗалар белми дә хәтта. Утарда булган бөтен тактадан ишегалдына өстәлләр ясала, утыргычлар кагыла. Батайск үзенә күрә шәһәр дип исәпләнсә дә, анда яши торган халык йоласы, холкы-фигыле белән гел станица казагы кебек иде.

Уртада биергә мәйдан калдырып, өстәлләрне ишегалды тирәли түгәрәкләп тезделәр. Чанғы таягына уралган шакмаклы киң тастымал төргәге әй борынча мәҗлестән-мәҗлескә йөри торган тоташ ашъяулык булган икән... Табында ак күмәчтән гайре камыр әйберсе юк. Ысланган дуңгыз ите тирәли табак-табак тозланган яшелчә, буш урыннарда бакча җимеше, матурлык өчен генә чирекле шешә белән сөтләч көмешкә күпыраеп тора, ләкин, кунаклар кибет аракысын бушата.

Мәдиярның әти-әнисе бармы, кая, кемнәр дип сораучы табылмады. Шуна күрә, аның янында утырган Фазыл үзе шаһит, үзе кода, үзе дус, үзе кунак. Мондагы туйларда сыйлаучы юк, тамада сүз биреп үгетләми, кем аягүрә торып баса—шул сөйли, утырган килеш кенә сөйләүчеләр башкаларны тынламый. Ашап туйганнан соң, төн уртасында яшелчә ашы бирелә һәм халык айнышып киткәндәй булып, янабаштан эчәргә тотына. Татарда: "Килүегезгә рәхмәт, кунаклар, инде кайтыгыз!"—дигәндәй чәй тараталар. Ә боларда чәй, жимеш суы, куас ише эчемлекләрне мәҗлес башында ук бирәләр. Хуҗаның таң әтәче кычкырмыйча кайту турында уйлаучы юк. Үз йорты белән яшәгән кеше шәһәр уртасында да тавык асрый, кунакчыл хуҗа мәҗлес алдыннан әтәчләрен күршегә кертеп куя.

Күп сөйләргә яратучыларны бүлдереп жыр арты жыр яңгырады.

Һәр халыкның күмәк жырлый торган "Күбәләгем" кебегрәк такмазасы бар.

...По Дону гуляет, по Дону гуляет,
По Дону гуляет, казак молодой...

Әлеге жыр туй таралганчы өч-дүрт тапкыр кабатланды. "Молодой казак" роленә кергән Мәдиярны үртәр өчен Фазыл мәҗлес хорына татарча кушылды.

Дим буенда йөри,
Дим буенда йөри
Дим буенда йөри,
Казан малае...

Фазылның бу кыланышын "кияүнен" ин якын күршесе Галина да яратып, балдаклы бармагы белән дирижерлык итеп, ижеген-ижеккә иярттергә тырышты.

—Шүләнгердән берәрсе килгән булса: "Карасана, казакларны гел безнең авыл кешесенә охшаганнар!"—дияр иде. "Атлы казак" дигән кушамат бар бит безнең якларда.

—Нәкъ шуны уйлап утырам, кияү, болар юри генә татарча сөйләшмиләр бугай... Ат яратулары да нәкъ безненчә.

—Әүвәл мин Дон казакларын киң балаклы шароварга кыстырмыйча гына күлмәк кигән, биленә эзәр ураган, бер тотам чук калдырган такыр башлы, салпы мыеклы юлбасарлар дип уйлый идем. Бактың исә, болар безнең кебек кешеләр, киемнәре дә безненчә...

—Әгәр син Галинаң янына гражданнар сугышы чорында килгән булсаң, кемлекләрен күрер иден. Советлар Союзы аларны да чукындырды инде.

Колгаларга эленгән лампочкалар нуры көн яктысы белән тигезләнгәндә Фазыл, вакыт дөреслегенә ышанмагандай, кул сәгатен боргалый башлады һәм шул арада ул күз чите белән генә Мәдиярны күзәтте... Яшь кияү уң кулына тозланган карбыз кисәге тоткан, ә сул кулы кәләшнең тез башында—бармаклары туй күлмәге аркылы массаж ясый иде бугай.

Галинаның ике кулы да өстәлдә, күзләре табын читендә бушлык табып, билгесезлеккә төбәлгән, аның өнсез калуы йокы килгәннән түгел иде. Ул әле туйның озак-озак дәвам итүен тели. Чөнки, кунаклар таралышкач үзен нәрсә көткәнен белә. Ә Мәдияр, киресенчә, вакытны куларга тели. Менә хәзер бөтен күрше-тирәдәге әтәчләр туй мәйданына жыелсын иде дә кунакларны таратырлык итеп кычкырсын иде...

—Миңа китәргә вакыт,—диде Фазыл, яшь кияүне сискәндермәслек тында,—тагын дүрт сәгатьтән дәресләр башлана.—Һәм үз соравына үзе жавап тапкандай өстәп куйды.—Барыгыз, сез дә жаныгызны кыйнап утырмагыз. Кунакларның "Горько!" кычкырырлык та рәте юк. Югалуыгызны сизмәсләр...

Жыр озынга китте.

Галина, сөйгәнен сөендереп, вәгъдәле елмаеп, читкә ымлады. Жырдан ерак та түгел, бакча читендә слива куаклары арасында мунча кебегрәк өй бар иде. Кечкенә тәрәзәле, мичсез, базсыз, түшәмсез әлеге куыш челләборчуларыннан качып ял итә торган урын. Ишек тоткасына исемнәрен белеп бетергесез чәчәкләрдән үреп такыя элгәннәр.

—Мәхәббәт сарае...—диде Галина, такыяны төшермәскә тырышып кына ишекне япканда,—сезнең якларда бармы бу нәрсә?

—Белмим, өйләнеп караганым юк!

Мәдиярның озын-озак итеп сөйләшеп торырга сабырлыгы беткән иде инде. Галина эчке яктагы келәне бикләгән арада куыш эчен күздән кичереп өлгерде. Бүрәнәдәге кадакларга эленгән үлән бәйләмнәрен, чәчәк көлтәләрен, бал тәпәне, гөмбә тубалларын күреп аптырамады, ял итәргә кергәне бар анын монда. Бүген бер кешелек агач караватның бизәлеше сокландырды. Ул операция өстәле кебек, кайчылык сиртмәсенә эленгән озын шнурлы лампочка астына туры китереп уртага куелган. Калын түшәге ап-ак япма белән төрелгән. Мендәрләре юк, аның каравы, япма астындагы калай тәлинкәдә, куагыннан кичә генә өзелгән ике тәлгәш кызыл йөзем бар икән...

—Мин йөземне сиңа күрсәтмәскә тиеш идем,—диде кәләш горур тавыш белән.

—Әгәр ялгыш өстенә ят... утырсаң, бөтен урын-жиргә сытылып, кызылга мана иде ич...

—Нәкъ шуна исәпләнгән инде ул йола.

—Алайса янадан каплап куй. Күрмәдем, белмәдем.

—Минем синең алда гөнаһым юк. Виноград буявыннан башка да исбатлый алам...

Һәм Галина йөзем тәлгәшләрен тәрәзә төбенә куеп пәрдәне корды.

—Рәхмәт, Галина.

—Ә сездә кәләшләр кияүләрне ничек алдый?

—Кичә өйләнгән булсаң мин кыз идем әле, дип, бер үкереп елый да гафу үтенә.

—Гафу үтенергә теләмәсә?

—Кияүгә бик чыгасы килгән кыз хәйләсен таба торгандыр инде.

—Алдатмас өчен кияү өч көн буе эчмәскә тиеш.

—Галя, шушындый минутта ник минем башымны катырасың инде?—Мәдияр аны ярсу көч белән күтәреп алды.

—Мадьярчик, милый мой! Ашыкма! Туй күлмәген бөгәрләргә ярамый. Аны әле кунаклар килгән саен киеп күрсәтәсе. Борылып тор. Мин үзем чишенәм.

—Тизрәк чишен, Галя!

—Ашыкма, бу тормыш безнеке хәзер.

Ләкин кәләш жавап кайтармады. Түземлеге тәмам бетеп, кирәксә бозлы суга, әйтсәләр дөрләп янган утка сикерер хәлгә житкән Мәдияр боерыкны онытып, кызга таба борылды. Ә ул... стенага таба карап баскан

да башын иеп, куллары белән янакларын каплаган килеш тик басып тора, күлмәген салу турында уйламый да... Кияү, кисәк хәрәкәттән чак тыелып, аяк очларын шудырып кына, кыз басып торган сайгакка күчте, бармак очларын чак кыймылдатып, куе кара толым астындагы каптырмага үрелде. Кәләшнең карышмавына тәмам инангач, "молния" йозагын аска төшерә башлады. Озын чылбыр сөендереп бил өстенә чаклы тәнне ачты. Мәдияр, чишендерү турында онытып, кызның ачылган кадәре тәнен үбә башлады. Туй буена шытып өлгергән сакал-мыегы кытыкладымы, әллә hич аңлата алмастай эчке энергия көчәнешеннәнме—Галинаның гәүдәсе җәя кебек киерелде. Иреннәр үз эшен эшләгән арада куллар да тик тормады. Туй күлмәге балавыздай сары идәнгә төшеп өелде. Кызның карышырлык көче, үз иреге белән караватка барып житәрдәй ихтыяры калмаган иде. Кияү аны ак күлмәк өеменнән өзеп алгандай итеп, кулларына күтәрде, түшәккә китереп куйды. Алай да кыз ак япманы ялангач тәненә каплап өлгерерлек көч тапты. Ләкин, кияү әкрен-әкрен генә шудырып, ике тәнне аерып торган әлеге чаршауны жыеп алды. Ул үзен бик житди операциягә әзерләнгән хирург кебек хис итте, туй күлмәгеннән чыккан тәнне сыйпап гүя гаепле урынны эзләде. Кәләш кул белән ул урынны каплап, уң кулы белән тиздән, бик тиздән ире буласы кияүнең гыйшыклы бармакларын озатып йөри. Мәдияр карават читендә басып торган килеш кенә үрелеп, түшәккә чумган Галинаны үбәргә теләде.

—Туйда үбеп туймадыңмы?

—"Горько!" кычкырган саен кеше алдында чын күнелдән үбешә башласаң рәттән егерме инфаркт алырсың, йөрәгең ярылыр...

Кызның гәүдәсе сүнде. Сүлпән сулавы һәм коңгырт күзләренең сагаеп кына егет артыннан күзәтүе жанындагы уяулыкны сиздереп тора. Сәер инде бу әхлак кануннары... Ничә еллар буе кунакка кайткан егете алдында сарафанын алыштырырга да оялып күрше бүлмәгә бикләнә торган, сагынышып үбешкәндә гәүдәләрне артык якынайтмас өчен терсәкләре белән читкә этәрүче сөекле Галина бүген Мәдияр алдында ирекле кол булып ята. Уртага бөкләнгән заем кәгазе чаклы гына никах таныклыгы үсеп буйга житкән, әти-әнисе жил-давылдан саклап егерме өч яшенә чаклы үстергән кыз баланы буйсындырып кулына бирә...

—Ашыкма, берүк ашыга күрмә...—дип күзен йомган жирдән кызый кинәт сискәнеп куйды. Аның кайнар күкрәк өстенә ниндидер салкын тимер кисәге тиеп китте.—Нәрсә бу?!—Галина егет муенында эленеп торган чылбырлы алтын айны учында тотты.

—Талисман. Беренче получкадан алдым. Ә синеке нәрсә?—Мәдияр, кызның муеныннан читкә салынып төшкән алтын тәрене ике бармагы белән уйнатты.

—Унсигез яшемә әтием бүләге.

—Улыбыз тугач, муенына нәрсә элербез икән? Икесен бергәме?!—диде дә тынды кияү. Ул хәзер бәхәс кузгатырлык халәттә түгел иде. Алтын ай белән алтын тәренең чылбыры чуалып бетте...

Әгәр мөмкинлек бирсәң яна парлар "мәхәббәт сарае"нда ничә көн буе бикләнеп ята алырлар иде икән? Мөгаен өч көннән ары түзмәсләр...

Галина, буяу карандашлары белән дәфтәрләр тутырылган сумкасын туй бүләкләре арасыннан көч-хәл белән эзләп табып, балалар бакчасына ашыкты. Дәү балалар төркемен беренче сыйныфка керердәй мәктәп баласы итеп үстерәсе бар. "Мәхәббәт сараен"да үткән өч көн өчен программаны куаларга туры килер әле.

Мәдияр—Михайло өстәлләрне сүтеп, кунаклардан калган чүп-чарны себереп чыккач, кинәт эшсез калды. Ул Осадчийларның көнкүреш мәшәкатьләренә иярә алмады. Сергей Иванович, булачак бораулау осталары яныннан кайткач, Михайлога Фазыл хлопчиктан сәлам әйтә дә каеш алъяпкычын бәйләп, дүңгыз сараена кереп югала. Кияү ана ияреп дүңгызлар

арасында йөрми, хатынын балалар бакчасыннан каршы алырга китә.

Якшәмбеләрдә Фазыл Осадчийларга утырмага килә. Укытучысының өендә кунып калырга теләмәсә дә, көнозын дигәндәй кунак була. Андый көннәрдә Михайло тагын Мәдиярга әйләнә.

Хатынының корсак ялына чыкканын өйдә көтеп ятмасын өчен, Сергей Иванович пропискасыз кияүне, дуслар аша, йортлар идарәсенә сантехник итеп урнаштырды. Михайло моңа бик сөенде. Әле язга чаклы Галинаны алып китеп булмый. Сигезәр сәгатьләп саный торгач көннәр тизрәк үтәр, ни дисәң дә эш урыны су һәм торбалар тирәсендә.

Мин сезнең шәһәрдә укып киткән идем, бер кызыгызга гашыйк булып тагын килдем дигәч, яңа хезмәттәшләре беренче көнне рәхәтләнеп көлгәннәр иде. Хәзер көлмиләр. Михайло су юлын белә, пычрак эштән курыкмый, жирәнми. Ә жирәнердәй көннәр бар... Батайск шәһәре саз өстендә утыра, туфракны күтәреп, жирне тигезләп кеше яшәрдәй урын иткәннәр. Ләкин, өске сулар шул тиклем якын, торбалар тыгылган чакта канализация коелары сазлы су белән мөлдерәмә тулган була. Шул пычракны чиләк белән түкмичә кое төбенә төшәлмисең. Жирәнмәде, зарланмады Михайло, чөнки вакытлыча дигәндә, адәм баласы моның ише кыенлыкларга түзә ала. Йортлар идарәсенең кызыл почмагын душ иткәннәр. Эштән соң хатыны янына гел юынып, кырынып кайтып керде ул. Көндез нинди чокырларда торба чистартып ятканын белмәделәр дә хәтта...

Галя, Галя, Галия...

Корсагы борынына житкән маржа хатынын иртәп кайтканда Шүләнгер бакчалары ак чәчәккә күмелгән, каз бәпкәләре чирәмгә баскан, көтүләр чыккан, чәчүлек бәрәңгеләр үргән иде инде.

Дон күпереннән Нократ кичүенә чаклы ерак кайту юлын үткән Мәдияр үзенең хәләленә жае килгән саен алдан ук үгет-нәсихәт бирде... Бусагадан атлап керү белән: "Исәнмесез?"—диярсең. Киткәндә үзенә: "Хуш!"—диярләр. "Гафу итегез!", "Рәхмәт", "Ярар" кебек сүзләрне тизрәк өйрәнсәң бала туганчы чүкердәшеп яшәрсең. Чын татар кешесе буласың килсә, ин мөһиме: теге, бу, ни, менә, шушы нәрсә кебек алты-жиде сүзне хәтерлә, сине бөтен жирдә аңларлар.

Танышканда киленнең:

—Мин Галя, Галя, я,—дип әйтүен, Ярулла бабай бик ошатты, улы өчен сөенеп туялмады.

—Һи, Галия икән бит, хәзер ана телен белмәгән кызларга исең китәсе юк,—диде.

Хезмәт кенәгәсендә өзеклек чыкмасын өчен Мәдияр Нократ кичүендәге паромга урнашып торды. "КамАЗ" юлы кисеп чыгасы урында таш күпер салалар иде, шуна күрә жүнлерәк эш тапкан ирләр паром ябылганны көтмичә үк үз жайлары белән китә тордылар. Сезонлы эш дип артык борчылмады Мәдияр, Галия бәби тапкач Казанга күчәрбез диде, Фазыл укып кайткач үзен эзләячәкләренә бик нык ышана иде ул.

Бәләкәй Регинаны Шүләнгер кызы дип теркәп куйгач та ике ай вакыт үтеп китте. Галия, көн саен искә төшереп зарлануына карамастан, зур шәһәргә күчеп яшәү хакында житди вәгъдә ишетә алмады.

Ниһаять, тыныч лыгы-муллыгы, жылылыгы белән сөендереп торган жәй холыксызлана башлады. Кояшны сагыш каплады. Көннәр дә сап-сары хәзер. Мамадышның Тирәк яфраклары өстеннән сары буран туздырып йорт казлары күтәрелә. Жиләкле аланнарны бәс сарды. Жәй буе тарих серләрен жылыткан Пугачев тауларына сукмаклар сүрелде. Язга чаклы өяз ягында калдырырга теләгәндәй, төнге салкын иске паромны боз белән яр читенә ябыштырып куя—эш башлаганчы төртке белән ваткаларга туры килә. Кисәк тундырып жибәрсә кичүгә ышаныч юк дигәндәй, халык әйләнгеч юлга

күчте, хәрәкәт азайды. Паром Нократның ике яр арасында сагыш ташып йөри. Көз салкыны елганың йөзенә чыккан...

Малай тумыйча өйләнгәненне белмисең, кызын тумыйча әти дип горурлана алмыйсың. Әти кешенең жаны кыз балада... Эштән кайткач Мәдиярның юынырга да сабырлыгы житми. Ишектән керүгә каршысына килеп баскан Галиянең кулыннан биләүле сөйдергечне ала, ике айлык кызчыкны исни-исни сөя, күккә чөя, кулында йоклатып яңагына сыендыра.

Ә бүген, ишектән керүенә, Галинаның бер кулында биләү, икенче кулында телеграмма... Фазыл үз эшенең остасы булып кайткан. Ул укыган арада эшсез йөргән Мәдиярга канатлар үсте...

—Менә, күрдеңме, Галия, Фазыл безне онытмаган! Минем: "Бүтән бораулаучы эшенә аяк та атламыйм!"—дип ваз кичәргә теләүләрем тукран тәүбәсе генә ул. Яраткан һөнәрне, шушындый дусларны ташлап буламы?! Менә күрерсең, ярты ел үтмәс, безгә Казаннан фатир бирерләр...

—Тагын ярты ел көтәргәме?—дип күпсенде Галина.

Әйтерсең лә шәһәрдә буш фатирлар өелеп ята...

—Ярты елмы, берме, күчкәнче әти-әни янында михнәт күрмичә генә түзәрсең.

—Бәлки алдан ук Казанга күчә торырбыз, ә?! Тулай тораклларда урын бетмәс әле. Гел начальствоның күз алдында булырбыз. Мәдиярчик, милый мой, үз йортыбыз белән яшәсәк тә мин бит тумышымнан шәһәр кызы. Жылы туалетларны, төн уртасында кранннан агып торган кайнар суларны, биек үкчәле түфли киярдәй асфальт тротуарларны сагындым...—Һәм Галина борынын пыршылдатып алды...—Әтине, әнине сагындым, аларның әле Регинаны да күргәннәре юк,—дип шундук балавыз сыга башлады.

—Ярар,—диде Мәдияр, бала карап авыл өендә бикләнеп яткан хатынын юатырга теләп,—мин каршы түгел. Әүвәл үзем барып эшне яңартыйм әле, озак тотмам, сине алып китәрмен.

Казаннан килгән телеграмманы Ярулла бабай хат ташучы кулыннан алгач та укып чыккан иде. Килен белән малае арасында зур сөйләшү барлыгын сизенепме, ул бүген лапаста өч ел буе кипкән каен утынынан мунча яктырды. Эченә карлыган ботагы белән мәтрүшкәләр бәйләп ике каен миллеге кертеп куйды. Бәби туе ясый калсак дип, чүлмәк утыртканнар иде, мичкәдән бер литрлы банкага коры сыра агызып киленә бирде:

—Мә, кызым, чарачадагы чиләкле суга батырып куй, суынсын бераз,—диде.

Гаиләнең бөтен мөһим планнары мунчада хәл ителгәнне хәтерли әле Ярулла бабагыз. Мунча ир белән хатынның тәнен дә, жанын да йомшарта... Малай безне карт көнебездә килен хөрмәтеннән мәхрүм итмәс, Казанга алып китәргә ашыкмас, диде. Галия "әти-әни" дип күнел күрерлек кенә татарча белә, шул житкән. Хохлушкамы, ар кызымы, хет чуаш, хет мукшы булмагае, анын изүе ябык—муенындагы тамгасы безгә күренми...

Телеграмма алып килгән бәйрәм иде бу. Галина бер аяк басасы жиргә биш басып мунчада алыштырырга киемнәр әзерләде. Бала чүпрәкләрен үтүкләде. Гаилә өстәл артына утыргач, кайнана кулыннан сосманы алып, ашны үзе бүлде.

—Бала уянгач, мунчаның кызуына без керербез. Юындырып биргәнче чарачада көтеп торырсын. Аннары әнкәйгә илтеп кулына тапшырырсын. Озак йөрмәссең, син кермичә себеркеләрне пешерми торам.

Бу сүзләрне килен кеше күбрәк кайнана өчен әйтте. Бәби туганнан бирле бала юындыру Мәдияр кулына эләкмәде. Мунча ягылган көннәрдә ике ана бергә кереп алмаш-тилмәш юындылар. Ләгәнле суда тәне шифага кинәнсен дип чиратлашып коендырдылар. Һәрхәлдә, монарчы шулай иде. Бүген килен кагыйдәне үзгәртте. Анын Мәдиярга бәйнә-бәйнә аңлатуы үзенчә хәйлә иде—ягъни, кайнананың колагы ишетсен, яшьләр парлашып керә бүген...

Баланы өйгә илтеп тапшыргач, Мәдияр мунча белән ике арага салын-

ган чирәмле сукмактан үткәндә җиргә басмады бугай... Чарача ишегенең келә шалтыравына мунча эченнән гыйшыклы тавыш ишетелде.

—Милый мой, синме бу?

—Юк. Мин түгел...

Галина сәерсенеп мунча ишеген ачып карады. Беркем күренмәгәч чарача келәсен тикшермәк булды, ләкин өлгермәде, ишек артында качып калган Мәдияр аны арттан килеп кочаклап алды. "Юк. Мин түгел..." дигәнче, өч сүз эчендә чишенеп беткән иде инде ул.

—Ой!—дип курыккандай итте Галина.—Монда булмый. Әйдә, эчкә керәбез.

—Анда эссе, хәл бетә.

—Алайса тыныңны чыгарма.

—Әйе, әйе... Өйләнгән көнне дә бу чаклы сусамаган идем мин сиңа. Сагыну жыелды. Теге "Мәхәббәт сарае"нда ниндидер курку, шикләнү бар иде. Бүген бары тик сине сөяргә теләү генә. Мин синнән башка яши алмыйм хәзер. Озак көттердең. Врач ике генә ай тыелып торырга кушкан. Ә безнең инде ике ай да дүрт көн узды...—дип, өзек-өзек пышылдады Мәдияр.

Галина ирен бүлдермәде, һәр сүзнең чын күнелдән әйтелгәнен кайнар тәне белән тоеп торды. Әгәр алар кайнана-кайнатасыз аерым яшәсәләр, Мәдияр мөгаен түзмәс, врач киңәшен санга сукмыйча әллә кайчан үгетләгән булыр иде инде. Әле ярый, төннәрен салкынайткач верандадан керделәр. Хәзер биш почмаклы өйне пыяла ишек бүлеп тора. Ялынып-ялварып тавыш күтәрсәң, онытылып ыңгырашсаң, йә ләззәтле ымлыклар ычкындырсаң—әрләшәләр бугай, араларына керим дип, Алла сакласын, кайнанаң өстеңә килеп керер. Шуна күрә бу санаулы көннәрдә ике арада бала ятты. Ниһаять, "карантин" чорын үтеп яңадан кавышкач, Мәдиярның тыела алмыйча сөйләнүе аңлашыла. Сөйләсен! Назлы сүзләрне үзең сөйләүгә караганда, сөйгәнеңнән ишетүе ләззәтлерәк.

Галина кыш күрмәгән кеше түгел. Ул туып-үскән якларда йомшак кышның кары азрак та, жилләре зәһәррәк. Вятка буенда яуган карны исәпләсәң Дон буйларына ул өч-дүрт кыш өчен житәр иде. Тегендә кар яуса яшеллек юкка чыга, ә монда чаңгы таягы күмелерлек көртләр өелсә дә урманнар яшел. Якты урманнар авылга киләсе ярсу жилләрнең егәрен тыеп тора. Шүләнгердә кар тынлыгы. Мал-туар ашар өчен генә уянып, түшәлгән салам өстеннән ерак китми. Этләр дә өрергә иренә.

Кышка кергәч, Шүләнгер үз гаменә бикләнеп, Себер урманындагы ялгыз хуторга охшап кала. Жәй буе кабык жебетеп мунчала каезлаган юкәчеләр дә базарга йөрүдән туктый. Көзен сатылып бетмәгән бал аертылмаган килеш кәрәздә кала.

Галинаның ин курыкканы—юл өзеге. "Не дай бог" балаң ныгытып авырып китсә, трактор чанасына салып Мамадышка илтеп житкергәнче ярты юлда ук жаны чыгар. Регина ялгыш төчкереп, йә йөткереп куйса, Ярулла бабайларда ыгы-зыгы куба—бөтен белгәннәре юкә чәчәге белән зәңгәр мәтрүшкә кайнатып эчертү. Медпунктка алып барсаң, фельдшер пеницилин кадаудан арыны белми. Ике айлык баланың укол энәсе төртерлек тәне дә юк бит әле.

Жәй көннәре атнага бер килеп, "передвижка" кино күрсәтә күрсәтүен, ләкин татар хатыннарына ирләреннән башка клубка чыгарга ярамый икән. Кыш көне ике өйнең берсенә телевизор кararга йөриләр. Мәдияр өй борынча йөрмәскә кушты, телевизорны үзем алып кайтам, Казаннан фатир алгач өй жиһазы итеп күчерербез, диде.

Озын кичләр кыскарсын дип, авылның бөтен хатын-кызы кул эшенә тотына. Борынгыдан суык бәгырьләренә үткән—бәйләгән нәрсәләре—йон оек, мамык шәл, гамаж, бияләй, джемпер. Галия киленгә жылы кием кытлыгы юк. Ул челтәр бәйләргә өйрәнде. Мендәр өстенә капларга дип унлы кәтүк жебеннән зур кар бизәге үрде.

Мәдияр кайтырга чыкса, машина тавышын күрше авылдан ук ишетеп алалар бугай...

Ләкин сирәк кайта егет. Кышкы суыклардан көннәр кысылды, вакыт тыгызланды. Җәй көне сигез сәгатьтә өлгерердәй эшләр хәзер атналар буена сузыла. Иртән двигательләрне, пычрак насосны ачык ут белән жылытып, радиаторларга кайнар су салып, нинаять, бораулларга керештек дигәндә генә, инде кич житкән, дөм карангыга калганчы суларны кире агызасы, инструментларны жыеп өлгерәсе бар. Хатынны сагындым дип, су ташучы машинан белән Шүләнгергә кайтып китсән, әйләнеп килгәнче өч көн үтә. Ул арада бригада эшсез торырга тиеш. Әле буран чыкмаса ярый. Мамадышка Казаннан бердәнбер коридор Теләче—Тәкәнеш аркылы уза. Йөз житмеш чакрымлы аранын ярты сы текә тау, ярты сы жәяүле буран оясы. Әби патша салдырган ташлы юлның түшәүләре исән калган урыннарда гына бераз хәл аласын. Мамадыштан Шүләнгергә житкәнче дә утыз биш чакрым буе бульдозер көтәсе бит әле.

Галина ирен Казанга чыгып киткән көненнән көтә башлый. Кызын беләгеннән төшермичә, тәрәзәдән тәрәзәгә йөри. Ләкин Мәдияр биш тәрәзәнең берсендә айлар үткәч кенә пәйда була. Ул кайткан саен Регинаның һөнәрләре арта. Теге телеграммадан соң урап кайтуында кызлары йөз түбән салган жирдән башын күтәреп маташты. Икенче кайтуында—мендәргә сөяп куйган жирдә утырып тора. Яна ел алдыннан чыгыр эчендә тәпиенә басты. Сигезенче март бәйрәмендә йөреп күрсәтте. Ә туган көнендә әнисенә жавап кайтарырлык сүзләр эзләп тапты. Кыскасы, Мәдияр өчен Регина күрше баласы кебек тиз үскәндәй тоелды. Галина, биш тәрәзә арасында яшәүнең, елга унике тапкыр гына сөелүнең, исән-сау килеш әтием, әнием дип әйтер кешеләреннән мәхрүм булуның ни икәнен үзе генә белә иде. "Казаннын яна төзелеш районында—икенче Таулар бистәсендә Мелиорация Министрлыгы өчен дүрт подъездлы өй сала башлаганнар, начальник көтәргә куша"—дигән вәгъдә Мәдияр кайткан саен кабатлана торгач, инде иске әкият булып янгырый иде. Көтәргә кирәк, фатирны да ирне дә көтәргә. Вятка буенда көттең ни дә, Дон буена чыгып көттең ни... Мәдияр янында Галия булдын ни дә, Галина янында Михайло булдың ни...

Коры елның тузаны...

1972 елның язында ут белән су бергә кушылды.

Март ахырында ук кайнар янгырлар явып Нократ ярындагы бөтен карны шулпалады. Ашыгып аккан гөрләвекләр зур елгага төшеп өлгерде, ашыкмаганнары жиргә сенде. Ел фасыллары бер-берсенә һөжүм итте,—апрель азагында ук июль челләсе башланды. Чишмәләрнең гайрәте сүрелгәч, инешләр хәлсезләнде, хәлсез инешләрдән зур елгалар саекты, дингезләр оеды.

Казанның эшче һәм интеллигенциясе, яшел отрядларга берләшеп, Татарстаннын утыз биш районына юл алды. Урман куелыгында күләгә дымына сөенеп яткан тереклек ияләрен өркетеп күгәргән чалгылар уйнады, дистә еллар буе онытылып яткан ураклар юкә, тал, усак һәм имән ябалдашларын кыйды, көн кызуында кикереп яткан симез саз тирәләреннән ике чиртеш калынлыгы кәз каезланды. Һәм барысы да силос базларына тутырыр өчен турагыч машиналар авызына ташланды.

Юлларда көннән-көн тузан калынайды. Машина үтеп китсә, ярты сәгать буе күз ачкысыз томан эленеп тора. Чирәмлек өстендәге намазлыкка манган орып Ходайдан янгыр ялварулар, бер атна буе явачак янгыр турында төш юраулар, балалар көн саен диярлек оештырган "карга боткалары" корыган өметләрне сугармады. Су табигатьнең үзеннән артмады. Әйтерсен лә челлә үзе дә сусаган, ул кешеләр өлешенә кереп туктаусыз су эчә иде.

Кайда су күрсән—шунда эчәргә тотынасын.

Корылык артезиан кое бораулаучыларның яшәү рәвешен үзгәртте.

Бригадалар дошманга каршы күтәрелгән хәрби халык кебек өйгә кайту юлын онытты. Ел фасылларының дөрес килерлегенә исәп тотып алдан ук расланган планнар чигерелде. Фазыллар хәзер иртәгә нинди фәрман киләсен, кайсы авылга күчеп эшлисен дә белми. Чөнки: "Обком кушты", "Министрлыкның махсус карары бар", "Идарә начальнигы рөхсәт итте" дигән зур күрсәтмәләр хәрби приказ кебек яңгырадылар.

Әмирнең биштәр күтәреп эштән бөтенләйгә китүенә инде ике ел була. Фазыл укып кайтып, бригадага үзе хуҗа булгач, өченче кешене алырга ашыкмады. Әмир ял итеп алҗыр да ияләнгән эшенә яңадан сагынып килер кебек иде. Куркынычсызлык техникасы буенча җаваплы инженер Фазылны күргәч, бер-ике тапкыр искәртте инде, бригадаларда ким дигәндә өч кеше исәпләнергә тиеш диде. Без, авылларга баргач шундагы егетләрне яллыйбыз, әлегә шулай ерып чыгарбыз дип аклангач, тагын онытып торалар... Бригадага яңа кеше алу—балалар йортыннан тәрбиягә нарасый алу белән бер бит ул...

Гадәттә, кое бораулаиып беткәч, акча күчерергә тиешле оешма белән "процентовка" дип аталган исәп-хисап кәгазьләре тутырыр өчен генә килә торган прораб Сәфәров, бу юлысы эш башланганчы ук килеп басты. Бостон пинҗәген салып, вагон сандыгыннан эш киемнәре эзләтте. Әмирдән калган сатин комбинизон, киндер бияләй, кирза итек таман гына иде аңа. Прораб җае килгән саен, бораулаучы булып эшләгән яшьлек еллары белән мактанырга ярата иде. Димәк, югарыдагылар ишеткән моны, булышырга кушканнардыр. Корылык елның фәрманнары да коры...

Мелиорация министрлыгыннан пенсиягә чыгып, көчен кая куярга белмәгән Каратаевка электр приборлары заводының директоры урынын биргәннәр иде. Яңа эшкә күчүенә карамастан, бораулаучыларның җәйге маршрутын үзгәртеп, чиратсыз-нисез су скважинасы казытырлык кына сүзе үтә иде әле анын.

Гомер буе ерак районнарга, чит авылларга күченеп эшләргә ризалашкан егетләр кинәт Казанга кайтырга күрсәтмә алгач, әлләни сөенеп өлгермәделәр. Күз-кул астында эшләүдән бизеп гел иркен яшәргә өйрәнгән кешене бер көн эчендә "серле" завод кысаларына күчерсәң кыен икән ул. Кояш сәгате белән яшәргә күнеккән Фазыл төгәл иртәнге җидегә завод капкасына килеп басар өчен вакытның калыбына сыеша алмады. Элеккеге министр алдында оятка калмас өчен ул берәр сәгать алдан килеп баса һәм смена алышыныр чак житкәнче капка төбендә көтеп тора иде. Мәдияр исә, вакытлыча Киндерледәге тулай торакта яши һәм билгеле инде, ярты шар сәгатькә соңга калып йөри. Соңга калгач, аны заводка кертмиләр. Ул табель тутыру бүлегенә барып, үзенең цех эшчесе түгел, ә Су эшләре төзелеш-монтаж идарәсеннән чакыртылган ирекле бораулаучы икәнлеген исбат итәргә, каравылчылар начальнигы рөхсәте белән Каратаевның урынбасарына акланырга тиеш. Шуннан соң гына проходнойдан эчкә уза торган коридорның дүрт канатлы тимер күбәләге сине чакырып ала: "Миңнегалиев, проходите!.."

Үч иткәндәй, завод мәйданы ундүрт метр калынлыгындагы ком өстендә утыра. Бораулый башлаган коең жимерелмәсен дисәң, туктаусыз су ташырга, комлы катламнарны кызыл балчыклы измә белән өзлексез тутырып торырга кирәк. Су ташучы машина аерым капкадан йөри. Кергәндә юл кәгазьләрен тикшерсәләр, чыкканда кабиналарны тентеп, ачкыч тартмаларына чаклы актарып, су мичкәсенең капкачын ачтырып үзеңне капшап чыгаралар. Кайбер көнне бу тамашаны җидешәр-сигезәр тапкыр кабатларга туры килә.

Корылык кызган саен түрәләрнең боерыгы күбәйде.

Каратаевның: "Ашаганыгыз-эчкәнегез чишмә суыннан булыр!"—дип, завод халкы алдында биргән вәгъдәсен ком эчендә калдырып, Фазыл бригадасын ашыгыч рәвешчә, КамАЗ юлы төзүчеләре янына жибәрделәр. Долотоны бораулаиып бетмәгән скважинадан тартып чыгарганда Каратаев

сүгенеп калды: "Хатыны өстеннән ирен сөйрәп төшергән кебек иттеләр, биллəhи!.."

Юл салу—илләр-жирләрне яулап алуның бер төре.

КамАЗ кендеген Мәскәүдән өзмәс өчен олы юлны "Каздорстрой" тресты сала иде. Куштырнаклар эченә алынып, кар көри торган көрәк чаклы фанерага язылган әлеге сүзнең "...дорстрой" дигәнен аңлавы кыен түгел, ә "Каз..." дигәне исә, аның Казан түгел, Казагыстаннан килгән юл төзүчеләре булып чыкты.

Йөгәнсез дала жилләреннән алжыган халыкны озын автопоездлар белән күчереп йөртә торган вагоннарга урнаштырып үзәнлеккә тезгәннәр. Фазылларның яшел вагоны кызыл "вагонград" янында ятимләнеп калды.

Казан ягыннан санаганда туксанынчы чакрым иде бу.

Рәт араларында машина белән йөрергә унай булсын дипме, вагоннарны иренмичә тигезләп тезгәннәр. Электр чыбыкларын күтәреп торган баганалар арасында усак агачлары да туры килгән ахрысы—андыйлары төптән мыек чыгарып, яфрак ярып маташа. Димәк, болар монда көздән бирле яши инде,—дип уйлап куйды Фазыл.

Механизатор ирләрен яңа юл буйлап эшкә озаткан киң маңгайлы, кысык күзле, чем кара чәчле ханымнар, татарлар аңларлык телдә сөйләшеп, су кайнаталар, утын яралар, кер юалар. Шундый ук маңгайлы, чәчле һәм күзле малайлар, аяк астында буталып уен оештырган, уенчыклары—машина-трактордан коелган тимер-томыр.

Шушындый челләдә учак янында маташуларын аңлап була—ут янында су бар! Балаларның кечерәкләрен, авызы зур итеп кисеп алынган калай мичкәләргә тутырып кояшлы суга жебетергә салганнар. Алар юынып чыккач зурракларга чират житә.

Әниләре читкә борылган арада, малайлар буржуйка авызына консерв савыты белән солярка сибеп өлгерәләр һәм калай моржадан гөлт итеп кисәк бүселеп чыккан кара-кучкыл ялкынлы төтенгә күмәкләшеп: "һа-а!"—дип куаналар. Әниләре балчык ата-ата аларны ут яныннан куа, тегеләре тагын качкан була. Күптән уйныйлар күрәсең, мич тирәсендә тиз генә кулга алып ыргытырлык балчык кисәкләре дә калмаган, малайларның битләре дә әниләренекенә караганда корымлырак иде.

—Суны каян ала икән болар.

Әмир киеменә керсә дә, Сәфәров та прораблык позасы исән, Мәдиярга жавапны озак уйлап тормады:

—Әнә, паровоз чаклы тагылмалы мичкә бармы—шуннан!

—Дегеткә баткан ич ул, аннан буялмыйча ничек су алырга кирәк?—дип кушылды Фазыл.

—Эче чистадыр. Су кытлыгы булмаса безне чакырмаслар иде.

—Юлны төзеп бетереп күчеп китсәләр, безнең скважина әрәм каламы?—диде Мәдияр.

—Сез, агайнеләр, башта суны чыгарып бирегез әле, аннан кайгырып утырырсыз. Боларга су күп кирәкми, тизрәк кирәк. Сигезенче номерлы долото житәр.—Сәфәров, үзе биргән күрсәтмәне үзе гамәлгә ашырып, арбадан өч сырлы тәгәрмәчле долотаны жиргә ыргытты.—Жир астыннан чыкканына бер көн үтмәгән, кызыл балчыкка баткан да каткан бу.

—Хәзер, майлыйбыз аны,—диде Мәдияр,—суда жебетәбез дә чүкеч белән кыйныйбыз.

Прораб-бораулаучы Сәфәров, юл төзүчеләрдән соң янадан Каратаев заводына кайтып, башланган коены бораулап бетерәбез дигән иде. Ләкин бер көнгә алданрак "Жиде күл" совхозының директоры килеп өлгерде. Аның кулында Мелиорация министры имзасы куелган рәсми приказ бар иде. Тагын срочно!

Казанга терәлеп торган "Жиде күл"—кәбестә үстерүгә көйләнгән хуҗалык иде. Бөтен хикмәт тә шунда, кәбестә ул жәй уртасында көнгә

унышар литр су эчмәсә үсә алмый. Һәм атналар буе ял күрмәгән бригадага, уткa ташланган янгын сүндерүчеләр шикелле, кичекмәстән "Жиде күл"гә күчәргә кирәк иде.

Сөенеп калды Зөмәйрә

Регинаны урамга алып чыккан жиреннән ишетеп кайтты Галина—иртәгә председательнең брезентлы "УАЗ"игы Мамадышка техосмотр үтәргә барачак икән. Колхоз бухгалтеры белән медсестра янында бер буш урын кала ди.

Әле Мәдияр киткәнгә атна-ун көн генә вакыт үткән иде. Галинаның Казанга барып, иренең эш урынын күреп кайтасы килде. Бәлки, начальствосы белән дә сөйләшергә насыйп булыр, ни дисәң дә бала күтәргән хатыннын ялваруы, ирләрнең горур гозереннән көчлерәк тәэсир итәр. Ярулла абзыйлар күпме генә үгетләсә дә килен баланы үзеннән калдырмады. Иртүк торып документларын барлады, житәрлек акча алды, бала киемнәрен салып жинелчә сумка асты. Председатель машинасына соңга калмас өчен колхоз идарәсе янына ашыкты...

"Әйбәт кенә яшәп торганда..."—дип, карт белән карчык бик еш искә төшерерләр әле бу иртәне. "Какмадык-орынмадык. Тәк томалдан, кисәк уйлады да китеп барды. Әйтәм аны дукаментларын жыйды... Баланы да калдырмады. Бу хәтлек акча нигә кирәк микән ана, дип, уйлаган идем аны... Һай, хәзерге яшьләрнең тешләклеге—тел яшермичә бәхилләшеп китсә ни булган... Ичмасам, онытыбызны туйганчы сөеп кала идем..."

Председательне йөртүче малай кичен әйләнеп кайткач: "Ярулла бабай, киленненне Казан автобусына утыртып жибәрдем!"—дип, тәрәзә аша кычкырып узды. Ул көнне өйдәгеләр аны-моны уйламадылар. Айлап кайтмый торгач, Ходай кушып, берәр бүлмә биргәннәрдер әле дип юрадылар. Көннәрдән-бер көнне, Мәдияр, су ташый торган машинасы белән берүзе генә кайтып төшкәч... Карт белән карчык бухгалтерга, медсестрага, председательгә һәм аның шоферынын өенә барып допрос оештырып йөрделәр: "Киткән көнне килен берәр сүз әйтмәдеме? Юлда еламадымы? Безне орышмадымы? Кунакка-фәлән Ростовка барам димәдеме?.." Кыскасы, сораулар күп, тик ул сорауларга "юк!"тан башка жавап юк.

Галина Казаннын татар зираты артындагы бораулаучылар конторасын эзләп тапканда, эш көне бетәргә ярты гына сәгать вакыт калган иде. Хезмәткәрләрне Киндерле бистәсенә илтергә тиешле вахта автобусы инде капка төбенә килеп ишеген ачып туктаган. Эшен алданрак төгәлләгәннәр берәм-берәм жыела.

Мәдияр Минлегалиевнын хатыны мин, дигәч, контор хатыннары вахта автобусына урынсыз калуларын да онытып, төсе-бите белән әтисенә охшаган бер яшьлек кызны кулдан-кулга йөртеп сөйделәр, аннан әнисен әйләндереп-әйләндереп карадылар, татарча аралашуына ышанмыйча, юк-бар турында сөйләндерделәр. Яна уенчык белән уйнап туйган сабый бала шикелле, соңыннан яшь киленне кадрлар бүлеге инспекторы Зөмәйрә янына кертеп куйдылар.

Инспектор кыз эш сәгате беткәндә чит кешеләр йөрмәслегенә ышанып, ишеккә жилкәсе белән баскан да, әрдәнәләп өйгән чәчен төзәтә, түгәрәк көзгене иреңенә терәп, баш бармак юанлыгы көпшәдән иннек яга иде. Борылып баскач, ул бала иярткән һәм алжыган чырайлы яшь ханымны күреп, каушап калды.

"Тагын алимент сорап килүчедер,"—дип уйлап куйды Зөмәйрә. Ләкин, вәкаләтенең кагыйдәсе кушканча, уйларын сүз белән әйтмәде.

—Сезгә кем кирәк?—диде Зөмәйрә, кирәкле кешенең үзе түгеллеген сизенеп.

—Мәдияр

—Кайсы Мәдияр?—Автобуска ашыгу гаме белән буталганга Зөмәйрә "алимент түләргә тиешле" кешене тиз генә искә төшерә алмады. —Гафу итегез,—диде ул бераз унайсызланып,—без үзебезнең эшчеләрне фамилияләре белән санарга күнеккән.

Галина үзенә карата ышанмау дип кабул иттеме—ЗАГС кәгазе белән паспортын чыгарды, ләкин бирергә ашыкмады.

—Без Мәдияр белән Батайскида язылыштык. Ул сезнең оешмадан укырга килгән иде. Аннан ул мине Мамадышка алып кайтты, шунда бәбиләдем. Минем әти бораулау осталары әзерли торган мәктәптә укыта.

—Зинһар, гафу итегез,—диде Зөмәйрә, сүзнең җитдилегенә төшенеп.—Сез мөгаен, Фазыл Шәмсетдинов бригадасындагы Мәдиярны әйтәсездер.

—Әйе, әйе! Фазыл! Ул әле безнең туйда шаһит булып утырды.

—Баштук әйтәләр аны, гафу, исемеңне ишетми калдым.

—Галина Осадчая. Ну, Шүләнгердә Галия Миңлегалиева булып яшим. Авылдан районга, аннан Казанга килеп житкәнче кич житте. Эш сәгатегез беткәнгә охшый. Иртәгә иртән килермен.

—Казанда туганнарың бармы соң?

—Каян килсен. Абдурахман Абсалямов әтием белән бергә Карелия фронтында сугышкан. Татарстанда башка кешене белмим.

—Мин әти кызы дип, язучы өенә барып керүе читен инде. Ә гостиницалар мәсьәләсе Казанда бик читен, оешмалар исеменнән хат язып, берәр көн алдан заявка бирмәсәң, буш урын табу мөмкин түгел... Беләсеңме, без хәзер мина кайтабыз. Мин әнием белән генә яшим. Әйдә,—диде ул Галинаны иректән ашыктырып,—автобусыбызга өлгерәбез әле.

Һәм Зөмәйрә бәләкәч кызны күтәреп урамга ашыкты. Көне буе юлда килеп алжыган Регинаның чит апаны ятсынып шыңшырлык хәле калмаган иде инде.

Иртәгесен Фазыллар бригадасын ярты көн буе эзләделәр.

Баш инженер әйтә: "Миндә быелгы планның маршруты бар. Фазыллар бригадасы хәзер "Точмаш" заводының пионер лагерында",—ди.

Начальник инженерны сүгеп ташлады:

"Эшчеләреннең кайда эшләгәнен белмәгәч, ник йөрисең портфель күтәреп?! Миңлегалиев бригадасын срочный рәвештә "Ныртының совхозына күчердек!"—ди.

Эзли торгач, тагын бер билгесезлек ачыкланды: идарә управляющиенең шәхси әмере белән Фазылларга "Ныртының барып житәргә ирек бирмәгәннәр, бораулау агрегатын "Электроприбор" заводына кертеп биклә гәннәр имеш.

Чынбарлыкта исә, завод капкасына килеп житкәнче үк, бораулаучылар кәрванын министрның ак "Волга"сы куып тотты һәм кәбестә басуын корылыктан коткарыр өчен ашыгыч рәвештә "Жиде күл" совхозына жибәрде.

Галина, кадрлар бүлеге инспекторының каршына эленгән расписаниеләрне күреп алды. Автобус, поезд һәм самолетлар йөреше турындагы мәгълүматлар аерым-аерым эленгән иде. Бүген сишәмбе көн, тагын өч сәгатьтән Ростовка самолет китәчәк икән. Мамадыштан килгән чакта аэропортны күреп калган иде ул—үзәктән троллейбус белән жиде-сигез тукталыштан ары артмас.

—Ярар, сезгә рәхмәт инде,—диде Галина башына килгән яна уйдан кабаланып,—кыр кешесен шәһәрдән эзләп кем тапкан?! Зарплата алгач, үзе кайтыр әле, өйдә генә көтеп ятыйм.

Гараждагы буш машина белән сөйләшеп, Зөмәйрә балалы хатынны "Совет мәйданы"на чаклы илтеп куярга кушты. Теләче, Тәкәнеш, Мамадыш кешеләре юл унае кайтучы машиналарны шунда көтә. Бу тукталышта төшеп, якында гына аэропортны күреп алгач, әй сөенер әле Галина...

Озатырга чыккач, капка төбендә Зөмәйрә сорап куйды:

—Ә Фазылның сезнең якта сөйгән кызы калмадымы?

—Юк... Ул беркем белән дә йөрмәде...

Ни өчендер Галинаның шушы жавабыннан сөенеп калды Зөмәйрә...

Үскән чакта, кеше әйберенә кызыксаң: "Каян алдың—шунда куй!"—дип кулга суга торганнар иде. Безгә—сүз тыңламас, уеннан туймас, иләс-миләс малайларга үгет-нәсихәт биреп, акыл өйрәтеп, әрәмгә күпме михнәт кичергән әти-әниләребез! Балачак уеннарында мавыгып, вак-төяк мажараларга алыштырдык без ул гыйлемне. "Милый мой! Кайтып життем. Эшкә урнаштым!" дип, Ростовтан телеграмма килеп төшкәч кенә аңлады Мәдияр, димәк, ул Идел ягында, ә Галина Дон ярында калды. Бу язмышның ике яры. Ярдан-ярга күчәр өчен беркем ярдәм итә алмый...

Өйдән йөкле килеш чыгып киткән Галинаның бер яшьлек кыз бала ияртеп кайтуы сөенечле көенеч иде. Исән-сау кайткан, ләкин аерылмаган; ирне көтә, ә үзе эшкә урнаша; Регина маржа кызына охшаган, тик фамилиясе дөрес итеп яза торган түгел...

Табын артында икәүдән-икәү генә калган бер мәлне, язмышның Идел-Дон каналын кичеп кайткан Галина, Сергей Ивановичка гомер буе гаиләне сөендергән хезмәтеннән гайрәт чигерерлек сүз әйтте:

—Әти! Син бәхетсез ирләр әзерлисең! Мин синең профессиян корбаны...

Бишкә-биш

Галинаның бөтенләйгә киткәнен белми иде әле Мәдияр...

Жир астында чүлләр юк, андагы комнар лай булып тора. "Жиде күлдән" әйләнеп килгәнче Каратаев заводында төгәлләнмичә калган коенын авызы ишелеп бүрәнкәләнгән иде, бораулау агрегаты белән якын килеп иске эзенә бастырырлык түгел. Озын-озын калын такталар белән жиргә идән жәеп, эш урынын ныгытырга туры килде.

—Мин нәрсә әйтсәм, шуннан артыгын эшләмәгез!—диде Каратаев һәм сүгенү урынына илдәге хужасызлыкны эттән алып эткә салды.—Эшләнгән эшне ярты юлда калдыру—ялкау жәмгыять галәмәте ул. Тоташтан төгәлләп чыкмагач, ике-өч тапкыр мәшәкатьләрәк булачак хәзер. Һәр артык мәшәкать, ахыр чиктә, заказның бәясе артуга китерә.

Бораулаучылар каршы дәшмәде, акча түлисе заказчик белән дошманлашу—үзең утырган ботакка селтәнү кебек килеп чыга.

—Комның өске катламын унике дюймлы кондуктор белән ныгытыгыз!—Каратаевның тавышында житәкчеләргә хас басым бар. Ләкин кыска жинле, ачык изүле соры житен күлмәген тирән төпле чалбарына кыстырмыйча гына кигән сандалыйлы әлеге агайның кайчандыр су министрлыгының хужасы булганлыгына читтән карап торучы берәү дә ышанмас иде. Бүгенге бораулаучылар да бу турыда инде ишетеп кенә белә. Безнең илдә кечкенә буйлы кәй-кәрләләрне зур урыннарга житәкче итеп куймыйлар, партия уставы кушмый. Фазылдан да кечерәк булып калган күптәнге пенсионер Каратаевның директор кәнәфиенә куелуы "Серле" заводның бер середер. Муены киң жилкәдән алга таба авып төшсә дә ул йөзен текә тота, сөйләшкәндә әнгәмәдәшен күз карашыннан читкә жибәрми, хәтта, ике-өч кеше белән берьюлы сөйләшергә кирәк булса да.

—Кондуктор дигән нәрсә трамвайда билет сатучы апаңнар гына түгел. Буровойда ул бөтенләй башка әйбер.

Һәм экс-министр, өйрәнчек малайларга дәрес аңлаткан остаз роленә кереп, сүзен дәвам итте.

—Өстә ком катламы калын булганда, алга таба борауларга комачауламасын өчен, аны юан торба белән ныгытып калдырырга кирәк. Аннан соң тынычлап эшлисең, йөз метрга төшсән дә скважина эченә ком ишелми. Аңладыгызмы?!

—Ие, ие,—диештә Фазыл белән Мәдияр.

Әле ярый Сәфәров кәгазьләр артыннан куып трестка китте. Өч ел эшләгән, өстәвенә махсус белемнәре булган егетләргә бораулау әлифбасы укытып вакыт әрәм иткән "бывший"га аркылы төшмичә түзмәс иде ул. Хәер, Фазыл да түзмәде.

—Сезнең сүзегез үтә. Кондуктор өчен кыска-кыска торбалар сорагыз. Базада бар алар, резервта ята.

—Нәрсәгә кирәк ул кыскалар? Юан торбаларны резьбага утыртуы бик авыр. Биш метр саен бора-бора ялгаганчы, унышар метрлы ике оч төшерүе тизрәк була. Ком өстендә бораулаганда иң мөһиме—вакытны сузмаска кирәк.

—Минем әле ахырынача төшеп утырган кондуктор күргәнем юк. Ишелгән катламда төртелеп кала да кисеп ташларга туры килә. Автоген белән кискән җирдә резьба калмый.

—Нәрсәгә соң ул резьба?—Каратаев малай актыгын сөзәргә теләгән үгез кебек, текә йөзен җиргә төбәде.

—Эченнән шалтыр-шолтыр бораулый башлагач кондуктор үз урынына төшеп кача. Резьбасы булса аны эзләп табуы җиңел.

—Все! Житте! Акыл сатма. Техникасыз заманда мин кулдан бораулап йөргәндә син әле атаң башында булгансыңдыр. Мин ничек әйтсәм—шулай эшләгез.

Мәдияр, белдекле кешенең күнеле кителмәсен, өйрәтсен дигән алымга күчте.

—Абый, мин аңламыйм, ник кондуктор дип атала соң ул торба?

Каратаев ана якынрак килеп басты.

—Элеккеге агач трамвайларда микрофоннар юк, билет сатучы кондукторлар тукталышлар исемен атап кычкырып тора иде... Безнең кондуктор да юнәлеш биреп тора.

—Абый, йә, нәрсәдән башлыйк?

—Платформагызны тигезләгез. Дизельне кабызыгыз. Вышканы күтәрегез. Редуктор, ротор, картерларның маен тикшерергә онытмагыз,—дип тезеп китте Каратаев диктант әйтеп яздырган кебек.

Күтәреп-төшереп дөмбәсләүнең файдасы тимәде—чынлап та егерме метрлы юан торба билгеләнгән тирәнлеккә төшеп утыра алмады. Кагып карадылар, селкеткәләделәр, боргаладылар, әмма аның җир өстеннән артып калган оч метр чамасын барыбер кисеп алырга туры килде... Ә инде эченнән үтеп, алга таба бораулый башлагач, "башмак асты" юылып, кондуктор шуып төшеп китте һәм күздән югалды. Ана хәзер ялгап та булмый, тартып чыгарыйк дисәң—тотар жире юк, жир астыннан торба башы эзли торган ин зур "колокол"ның юанлыгы житми.

Фазыл дәшмәде, ахыры шушылай бетәсен алдан ук әйтер өчен әлләни әүлия булуның кирәге юк иде. Комлык ул кайда да холыксыз.

—Абый инде нишлик?

Каратаев хәзер Мәдияр белән генә сөйләшә.

—Менә, энекәш, кондуктор ерак түгел, эченнән бораулауны дәвам итегез, мин астан чыккан балчыкны үз кулларым белән тикшереп торам, су катламына житсәк әйтермен.

Алга таба да кызыл балчык катламы ком белән аралашып барды: йә ул сыек плывунга әверелә, йә шикәрләнеп ката. Проектта күрсәтелгәнчә сиксән метрга чаклы төшеп тә Каратаев су катламын сизә алмады. Бораулаганда куерган су жир астыннан чыккан балчыкны гел үзе белән әйләндереп йөртә, шлам утырмый.

—Абый, инде нишлибез?

—Бу сиксән метрны да сигезле торба белән каплыйбыз.

—Алайса, ике катлы кондуктор булып чыга түгелме?

—Әйе, зыян юк. Сиксән метрдан соң Казан астында дингез ята, аның суы бихисап.

—Ә проектны яшерәбезме?

—Проект ул банктан акча күчергәндә чыгымнарны чамалар өчен генә. Чын бораулаучы суны үзе эзләп таба. Тирәнгәрәк төшәсез икән—сезгә акчасы күбрәк килә.

Сиксән метрдагы диңгез ярыклы-карстлы таш арасында иде. Аны белгечләр төп катлам дип әйтергә ярата. Ләкин, Каратаев моңа сөенмәде.

—Скважинаны юдырыйк та анализга алып карыйк. Әгәр каты су булса—андые безгә кирәкми.

Башка вакытта су анализы өч көннән соң гына әзер була торган иде. Каратаев, санэпидстанциягә барып, үзе тикшерткән. Ярты сәгать эчендә әйләнеп кайтты. Ләкин алынган судагы магний белән кальций катнашмасы, гади генә итеп әйткәндә юшкыны, рөхсәт ителгәннән өч тапкырга күбрәк иде.

—Абый, нишлибез инде?

—Шартлатабыз!—диде серле завод директоры.—Сез төче су катламын үтеп киткәнсез.

—Сез ни әйтсәгез без шуны үтәп торабыз инде, абый.

Гомер буе су бораулап, скважина шартлатканны күрмәгән остазлар бар. Фазыл да әлеге авария очрагын дәреслекләрдән укып кына белә. Башта, махсус машина белән гамма-каротаж ясап, торба артында капланып калган су катламын эзләп табасы. Шул турыга буын-буын шартлаткыч бәйләме төшерелә. Ядрә урынына корылган корыч кадаклар көчле шартлау белән торбаны тишә һәм су йөри башлый... Монын өчен завод эшчеләрен эвакуациялисе юк, жир өстенә чыккан тавыш Чыршы бәйрәмендә атылган "хлопушка" чаклы гына. Ә инде серле завод эченә шартлаткычны алып керер өчен Оборона министрлыгының махсус әмере кирәкми. Шартлатырга килгән ике малайның дүрт кулына бер сумка, ачып карагач, каравыл начальнигы:

—Нәрсә бу?—дип, вазифасын үтәү йөзеннән генә сорап карады.

—Электр кирәк-яраклары...—дигән жавап, серле заводның жисеменә зыян китерердәй шик уятмады. Чынлап та, сосискалар чылбыры сыман бәйләнеп, төсле чыбыкларга уралган төргәк бик гади нәрсә булып күренде.

Шартлатучы егетләрне үз итеп "браконьерлар" дип үртәп йөртәләр. Моның ике сәбәбе бар. Беренчедән, су эчендә маташалар, икенчедән, сыйфатсыз, ягъни "бракланган" скважиналарны төзәтеп йөриләр.

"Браконьерлар", ярты сәгать эчендә гөрселдәтеп, утлы кояш астында исән-имин саклап алып килгән динамитларыннан котылгач, сулы күләгә эзләп Үзәк парк ягына юнәлделәр.

—Абый, инде нишлибез?

—Теге сиксән метрдан соң бораулангән өлешне бетонлап куясыз, тозлы су үтеп кермәсен.

—Абый, цементлы измәне завод алып кайтамы?

—Юк, энем, үзегез әзерләрсез. Килешү кәгазендә "тампонаж ясау" дигән яңгыравык юллар бар. Цементлы измәне кулдан болгатып, бер кубометр бетон ыргытуны шулай купшы сүз белән алыштырганнар. Шуна өстәп ике кондуктор арасына вак чуерташ тутырасыгыз бар—анысы фильтр өчен...

Бәхетсез прораблар бар инде бу дөньяда... Идән такталарыннан жыелган зур утлык янына егерме капчык яшел цемент китереп бушаткач кына, Сәфәров килеп житте. И, сөенде егетләр...

—Нишләп ятасыз шушы заводта һаман? Сезне ике көннән бирле "Ныртьі" совхозы эзләтә.

—Ныртыга юл юк,—диде Каратаев, һәм цемент болгатыласы утлык янына өч көрәк кадап, кабынырга торган яңа бәхәскә алдан ук нокта куйды.—Каравылчыларга әйтеп куям, минем рөхсәттән башка сезне заводтан чыгармаячаклар...

—Бәлки ярдәмгә эшчеләр бирерсез?—дигән иде Сәфәров, ләкин комбинизон киеп азапланган прорабның сүзе үтмәде.

—Безнең заводта көрәк тотардай белгечләр юк...

Уф, эссе...

Кояшның җылысы ел саен бер градуска күми дигән галимнәрне эзләп табасы килә. 1972 ел исләреңә төшкән саен бизгәк тотар аларны... Күктән ут ява, жирдән кызу бәрә. Кырык градустан башка яши алмый торган сәрхушләр дә кар базына төшеп утырды—пешеп үлгәнче өшеп үлүең жиңелрәк... Радиолардан: "Күләгәдә утыз алты градуска житә..." дигән хәбәрләрне ишеткәч, үзеңне юньсез кешеңең куенына кергән кебек хис итәсең. Көпчәк күчәрләрендә мае кипкән трамвайлар өч тиенлек мунчага әверелгән, пассажирлар салырга мөмкин булган киемнәрен кулына тотып, түбәдәге төннектән һава йота.

Халык балыкка әйләнде. Ул мөмкинлегеннән чыгып инеш, күл, сазлык, елга һәм диңгез буйларында телсез ята. Су... Су... Су кирәк! Кояш көн саен байый, шуна күрә ул байлар яклы. Хәерчене өтә, мөлкәтлегә ял бирә. Хәллеләр сыра күбеге, жылы куас, кайнар су сата, ут йотарга күнеккән хәлсезләр чират торып чөмерә.

Утны су жиңә. Ләкин суны ут жиңә алмый. Серле заводның ишегалдында салкын су фонтаны бәреп чыкты.

Фазыл ком сәгатен кояшта кызган платформа өстенә куйды. Бер куыктан икенчесенә кайнар ком агыла... Жир куеныннан кызган асфальт өстенә салкын су коела. Биш минутлык вакыт үлчәмен кисеп ком агып бетә. Ә су һаман ургыла, димәк, ул бар, димәк, ул бик күп!..

Серле заводның су шаулавы ишетелерлек хәрби тынлыгы бозыла. Ак халатлы пролетариат урамга агыла. Аларның кызган таш өстенә жәелгән салкын рәхәткә яланаяк басып тыпырдашуы сай күлдә йорт казлары биюен хәтерләтә. Ак халатлыларның чыр-чуына кызыгып карап торган капка каравылчысы да чишмә янына якыная башлаган иде, ләкин, шул минутта Каратаевның: "Эш урынынны ташлама!"—дигән ымлавыннан кире борылды.

—Абый, инде нишлик, агрегатны жыя торсак ярыймы?

—Демонтаж качмас, өлгерерсез. Әйдәгез, дебетны үлчәп карыйк, скважинагыз күпме су бирә икән?

Сәфәров ун литрлы чиләкне су шарлавыгына куйды.

—Бер-ике...—диде ул үзенчә ашыгыбрак санап, һәм кинәт батыраеп, баш бармагы белән чәнтие тырпайган йодрыгын Каратаевның йөзенә терәде,—секундына биш литр—артыгы белән!

Серле завод директоры иненә төймәләре коелып беткән халат элгән ялтыр мангайлы бер ирне чакырып алды:

—Бишкә-биш! Егетләргә биш литр спирт китерегез! Бездән башка бүләк юк...

Салкын мунча пәриләре...

Жир шарының теге ягыннан офык астына кояш килеп терәлгән—аның нуры ялгыз болытларга балкыш булып сенгән һәм ярау тынлыктан изрәгән жиһанга сүрән яктылык сирпеп тора. Таң атыр алдыннан шундый илаһи халәт бу—дөнья тыныч, тормыш имин, табигать дөрес, кешеләр һәммәсе тигездер кебек. Ләкин кояш күтәрелеп, көн ныграк ачылган саен, әлеге мәрхәмәтле минутларны яшәү гарасаты күмеп китә.

Яңа төзелә торган "КамАЗ" юлы өстендәге урманнан көткән бораулаучылар Казан ягыннан килеп төште. Колакка сизгер, күзгә үткер, телгә житез Ныртылар: "Көн саен ару гына "карга боткасы" пешерә торгач Кодай безне ишетте, яңгыр яудыручы карендәшләребезне жибәрде",—дип мактанып йөрде.

Артта калган колхозны илленче елларда гына "чукындырып" совхоз иткәннәр. Ныртының кунакханә тотарга хәленнән килмәде, кунакларны директор үтенече белән Марфа түтинең өенә урнаштыралар иде. Ялгыз

карчыкның биш почмаклы өе, кеше теленә кереп, тора-бара "колхоз гостиницасы" дигән ялган статус алды. Килгән кунакларны совхоз ризыктан өзми, вәкаләтләренә карап саллы гына мәҗлесләр дә оештыра. Марфа түтигә бигрәк тә әнә шул сыйлаулар ошый. Түгәрәк аяклы зур өстәле карават кырыенда. Табын түрендә сыйлаучы булу аның эше, кунаклар үпкәләмәсен өчен алар белән тигез эчә, тиз исерә. Авырайгач, утырган җиреннән ястыкка авышып, сандугач йокысы чаклы гына черем итеп ала, ул уянганчы әле кунаклар таралышмый, түти яңадан башлый.

Мәдияр, күчтәнәч итеп фатир хуҗасына спирт алып кергәч, Марфа түти биш литрлы банканы кочаклап, өй эчендә түрле-бирле йөренеп, яшереп куйрдай тыныч урын эзләп "ah" итте. Ахыр чиктә, ул аны идән астына төшереп куйды, калай тышлы коргаксыган сандыкны баз капкачы өстенә шудырды.

Бораулаучыларны өч көннән бирле көтеп, тәүлек саен мунча өлгертканнәр. Дөрес, өченче көнне Марфа түти мичкә утын өстәүдән баш тарткан. Урамдагы кызу мунчаны сүрелдерми, ташы суынмаган, суы—кайнар. "Башта килсеннәр әле кое казучылар, аннары күз күрер",—дигән.

Кызу көннәрдә мунча аеруча тансык. Челләнең тозлы тиреннән тән әчетә, тузан ягыла, киемне алыштырып өлгерер хәл юк. Ныртыга килеп, агрегатны урнаштыру белән, егетләр мунчага ашыкты. Серле завод комнарын, цемент тузаннарын, гомумән, Каратаев тирәсендә җыелган авыр тәэсирләрне юып төшереп тәннәрен жинеләйтәсе килде аларнын.

Юынып чыгып, ачык тәрәзә янында чәй эчеп утырганда, ишегалдында ике хатын-кыз пәйда булды. Кулларындагы сумкаларының зурлыгына караганда кызлар мунчага юынырга баручыны түгел, сабан туена бәйрәм итәргә әзерләнеп чыккан гаиләне хәтерләтә иде. Марфа түти кызлар янына ашыкты. Мунча сукмагында көлешә-көлешә нәрсәләр турында сөйләшкәннәрдер, анысы ишетелми, ләкин шунысы аңлашыла, кызлар чакырылмаган кунаклар түгел иде.

—Татый белән Галка,—диде Марфа, тирләп-пешкән бит алмаларын халат итәге белән сөртә-сөртә кереп,—директорыбыз сезнең арканы ышкырга дип жибәргән. Бик ару кызлар, савхуз өендә торалар. Берсе пекарняда эшли, икенчесе дуярка.—Һәм түти түр почмак шүрлегендәге икона каршына басып көлә-көлә чукынып алды.

Мәдияр, әнисе кушкан йомышны онытмаган күрше малае шикелле аптырап басып торды. Фазылның, кияүне фаш итәргә теләп мут елмаюын күргәч, ниһаять, аның кырарга килде.

—Монда иркенләп яшәргә туры килмәгәе әле. Совхозның ятмас Дусай бүлекчәсенә дә бораулыйсыбыз бар. Зур эшкә тотыныр алдыннан Шүләнгергә кайтып килергә кирәк. Үземнең Галкам нишләп ята микән? Кызны сагындым. Эти-әни үпкәләгәндер,—дип санап китте Мәдияр акланган кыяфәт белән.—Әйдә, Фазыл, киттек, ерак ара түгел, сине күреп сөенерләр генә...

Нишләп Шүләнгергә кайтып йөрсен инде Фазыл?! Айлар буе күрешмәгән Мәдиярның Галина белән пышылдашкан серләрен тыңларгамы? Бераз ял итәргә мөмкинлек барында, мунча кереп тугарылгач, тагын юлга чыгаргамы? Яныңда сөекле ярың табылса, парлашып кунакка йөрешүләре күнелледер. Ләкин ялгыз башың түбә күләгәсендә, бүрәнә ышыгында челләдән качып ятуың—бәхетле Мәдиярга иярчек тай булып тагылып йөрүгә караганда, мең өлешкә яхшырак!

Мәдиярга канатлар үсте—Шүләнгердәге оясына очты... Марфа түти өстәл артындагы ястыгына түнтәйде. Фазыл буш караватларның берсенә ял итәргә дип ятып торган жирдән йокынын иң тирәненә чумды.

Иртән ул завод капкасына соңарган эшче кебек сискәнеп уянды. Күзен ачса—Марфа түти ястыгына сеңгән. Тәрәзәгә төшкән кояштан мич кызуы бәрелә. Мәдиярның өйдә юклыгы исенә төшкәч әйләнеп ятмакчы иде Фазыл, ләкин йокы туйган. "Урын өстендә аунап, ял иткән гәүдәнне

таушалтканчы, торып юынырга кирәк, җылы су бардыр әле"—дигән үй аны мунчага алып килде... Сәер күренешкә юлыкты әле ул—мунча ишеге ачык, сайгакта ялтыравык түфлиләр, сәкегә күлмәкләр, эчке киемнәр өелгән. Фазылның мунча эченә керергә кыюлыгы житмәде, корымлы тәрәзәдән генә үрелеп карады—ләүкәдә ике шәрә кыз ята, куллары салынып төшкән, аяклары бөкләнгән, чәчләре тузгыган, баш очларында аумаган ике шешә... Фазыл кабаланып өйгә йөгерде.

—Марфа түти, тор, тор әле!—диде ул фатир хуҗасын уятырга теләп. "Үлгәннәр!" дип кычкырырга ашыкмады, махмырдан уянган кешегә кинәт авыр хәбәр әйтсәң, йә йөрәге ярылыр.

Ул аны ястыгы белән күтәреп стенага сөяп утыртты. Аннан соң, өстәл өстендә калган ярты стакан чамасы спиртны иснәп карады—су кушылган иде.

—Марфа түти, баш төзәтергә вакыт!

Хуҗабикә спирт исенә күзләрен ачты, ләкин тозлы кыяр кисәген генә кабып куйды.

—Суң, ниемә дип куалыйсың, миндә махмыр гупчым юк?!.

—Марфа түти, мунчада теге кызлар үлеп ята. Ис тиеп микән?

—Китсәнә! Өченче көн ягылган мунча, ниткән ис калсын?!.

Марфа түти мунчадан җәһәт әйләнеп кайтты. Жавап көтеп тилмергән Фазылның йөзенә туры карамаска тырышты.

—Ул салкын мунча пәриләренә чуртым булсынмы! Уяттым. Сезне көтеп ятканнар. Директор сүзен олылап килгәч, уңның бер гаебе жук. Сораша-нитә калса ипләбрәк әйтегез. Кызларны жаманламагыз...

* * *

Мәдиярнын Ныртыдан Шүләнгергә ашкынып кайтуы заяга түгел, әлбәттә. Туып-үскән нигезендә иман нуры бөркеп торган әти-әнисе бар бит әле... Әнә, янадан үз эшенә әйләнеп кайткан төпчек малай өчен ничек сөенәләр алар! Үз балаң алтыда да, алтмышта да сабый инде ул. Бәләкәй чакта сабыеннын һөнәре арткан саен сөенәсең, ә зур үскәч, анын эшкә урнашуы, вакытында гаилә коруы, тормышларынын муллыгы куандыра. Бала күнеле далага чыгып очса, нигез капкасына эзләре суына, сирәгрәк кайтыр өчен кырыкмаса-кырык сәбәпләре табыла.

Галинаның кайнана белән кайната янында тотык булып калуы Мәдиярны бик еш кунакка кайтырга мәжбүр итәчәк иде. Киленнең оныкны күтәреп Дон аръягына китеп олагуы картларнын өметен кисте.

Ай буе командировкада йөргән малай өйгә кайткач ял итеп, туган-тумачаларнын хәлен белеп, абзар-кураларны төзәткәләп, ким дигәндә, икеөч көн юана торган иде. Бу кайтуында, ишектән керүенә алпан-тилпән атлап, Регина килеп сарылмады, акчадан бигрәк фатир ордеры көткән Галина кочаклашкан унайдан куен кесәсенә кулын тыкмады. Юк алар бүген... Әтисе белән ирләрчә иңнәрне иңгә бәреп күрешкәндә Мәдияр башын читкә борды—тәмәкеле тынын яшерү өчен түгел, ул бүлмә эчендә уенчык куып йөргән кызы белән сөекле хатынын эзләде. Юк алар бүген... Бүтән булмаячаклар да...

Унлы жептән үреп бәйләнгән кар бизәге генә салкын карават өстенә өелгән мендәрләрне каплап тора.

Табын артына утыргач, улларынын беренче сүзе шул булды:

—Мина бүген үк китәргә кирәк, карангыга калганчы Чияле урманын чыгасы иде. Анда Фазыл үзе генә калды. Һәр минутыбыз исәптә. Дөньясы көя, бөтен кеше су сорый.

Әле дә ярый, кайтып керүгә: "Нихәл яшәп ятасыз соң, әни?"—дип хәл белешеп өлгергән иде.

* * *

Сәгать комы әле бер, әле икенче якка ага торды.

Саный китсәң—инде адреслар өстәле аркылы дусларыңны яңадан эзләрлек вакыт үткән. Мәдияр бүген урта яшьләрдәге тол ир... Фазыл белән чагыштырганда аның язмышында әллә ни аерма юк шикелле. Шүләнгер хохлошкасы Регина егерменең бу ягына чыккандыр. Ул әле, һич көтмәгәндә әтисен эзләп табар кебек. Фазыл үзенең Салих улы белән очрашты ич әнә...

Адәм баласына бәхетле булыр өчен яраткан эш, сөеп иркәләрдәй кеше һәм саулык кирәк. Әлеге өч шарт кәҗә, бүре һәм кәбестә турындагы әкият кебегрәк: берсе исән торсын дисәң—икенчесен югалтасың, монысы янында калам дисәң—тегесен алып китәләр, яратканын саклап ятсаң—бүтәннәреннән колак кагасың. Мәдияр сау-таза кеше. Фазыл аны тагын яраткан эшенә чакырып килгән. Димәк, бәхетнең өчтән ике шарты бар. Инде сөекле кешесең яңадан эзләгән кешеңең юлда булуы хәерлерәк.

V. ЯҢА ВӘЛИ

Бер үбеп кал

Туган авылына кайтыр өчен дә юлны кат-кат сораштыра торган заман бу.

Теләсә кайсы авылның исемен әйтеп бирегез, Фазылга... Анда ничек барасы, кайдан юл кыскарак, яңгырлы көнне кайсы тирәдән әйләнеп үтсәң яхшырак, теге яки бу күпер бораулау агрегатын күтәрә аламы, дип, вакытояклап аңлатып торасы юк. Бирегез сез аңа зур ак кәгазь, тоттырыгыз кулына каләм, күчермичә, дәреслекләргә, атласларга карамыйча Татарстан картасын сызып куя ул сезгә! Урманнарын киметмичә, елгаларын турайтмыйча, юлларын югалтмыйча, авылларын кимсетмичә сыза да куя, менә күрерсез! Дөрес, кайбер үзгәрешләр кертмичә, купшылык өстәмичә калмас ул аңа. Әйтик, Казан каласы Баш кала дип аталган икән, ни өчен әле татарның Баш саласы булмаска тиеш ди? Чагыштырмача иң зурысы, эшләп яшәүчеләре саныннан беренчесе, алдынгысы, танылганы, вак авылларның атаманы... Бик беләсең килсә, Фазыл ул Баш саланың гербын һәм байрагын да уйлап куйды. Герб туры почмаклы булырга тиеш. Аның аскы өлешендә кылычка-кылыч килгән ике балта сурәте, ә уртада—тәрәзәләре көлеп торган ак түбәле нарат өй. Байрагы да бик гади: тегермән кәүшәсеннән бушап кайткан кычыткан капчыкның кырыйларын башаксыман укалар белән чигәсең дә, авылның иң биек ноктасына—янгын сүндерү каланчасына элеп куясын. Әлбәттә, мондый геральдикага лаек бер генә саланы белә Фазыл—ул Шәле! Шәле саласы—Баш сала! Калган авыллар аның янында энекәш һәм сенелкәш кебек кенә.

—Жиде күлдә көтәләр сезне,—дип башлады сүзен Наил Кадыйрович, бораулау агрегатын ремонтлап яткан егетләрнең эшен беркавым күзәтеп торганнан соң.—Гараждан кайчанрак чыгып китәрсез икән?

Шушы соравына жавап ишетмичә генә китеп барса ярый иде кана, ләкин Наил Кадыйрович бүген монарчы сиздермәгән үҗәтлек белән жавап көтте.

Фазыл арбада пычрак насос белән маташа иде, начальник янына сикереп төште. Күрешергә туры килсә дип, комбинезон кесәсеннән мамык кантары чыгарып, мазутлы кулын сөртә башлады. Ләкин "Ак Чишмә" президенты кул бирергә ашыкмады.

—Ыслушай, Фазыл, агрегатыгыз аягына басты, запчасть сораудан

туктадыгыз, бригадан тупланган—тагын нәрсә дип казынып ятасыз гаражда?! Жәй беткәнне көтәсезме?

—Алмагачлар чәчәк коймаган ич әле.

—Бакчачылар өчен урак өсте инде бу. Көннәр көзгә авышкач суның кирәге юк.

—Кыш көннәре дә коелар казыдык ич.

—Элек ул Фазыл, элек! Ә хәзер, кем әйтмешли, вәзгыять үзгәрде. Бакчалар, дачалар, вилла, коттеджлар, арендаторлар—яңа байлар су сорый.

—Ә колхозлар, авыллар, шәһәрләр?

—Сорамый. Дөрес, аларга да су кирәк, ну скважиналар бораулатырлык акчалары юк. Акча яңа байлар кулында хәзер, безгә менә шушы чорны файдаланып калырга кирәк.

—Яңа байлар искергәнче, арендаторлар бөлгәнче, ярлы халык үлгәнче, ул акчаларны безнең кулга күчерергә кирәк. Әйеме, Наил Кадыйрович.

—Нәкъ шулай! Тик сәяси телдә сөйләшмә, матди телдә сөйләш. Менә сез бригадада өчәү... Һәр бораулангән су скважинасыннан өчегезгә илле процент хисабыннан түләнер, калган яртысы контор файдасына. Сез ул акчаны үзара ничек бүлешерсез—анысына мин катышмыйм. Ә бер коедан конторга күпме табыш кергән—монысына син катышмыйсын! Килештекме?

Карданның "тәресенә" май төеп яткан жиреннән Мәдияр тавышы ишетелде. Ул үзе платформа астыннан күренмәсә дә сүзләре аермачык аңлашыла иде.

—Гафу итегез, минем дә сүзгә катышасым килә. Элек без айга икеөч коедан ары бораулый алмый идек. Эшенә күрә яңа вәгъдәләрегезне бик төшемле урын дип әйтеп булмый икән.

—Әйттем бит, "элек"не онытыгыз дидем. Элеккегечә йөз илле, өч йөз метрлы су скважиналары төшегезгә генә керәчәк сезнең. Яңа байларга йомшак су кирәк. Ә йомшак суны беләсез—Казан тирәсендә ул өске катламнарда гына. Димәк, җәйге көннәрдә сез көн саен берәр кое бораулый аласыз!

—Ул хәтлек эшне безгә каян табып өлгерерсез икән, Наил Кадыйрович?

—Эш күп. Бүгенгесе көндә Жиде күл авылындагы бакча ширкәтен алсак кына да, унжиде заказ бар. Акчалары түләнгән, скважина бораулаңды дип күл гына куйдырасы бар. Йә, Фазыл, гараждан куып чыгарыйммы, әллә үзегез кузгаласызмы?

—Арканнарны алыштырасы бар да, пычрак насоснын пешкәкләрен сүтеп жыясы...

—Вәт! Төгәл ике көнлек эш. Жиде күлгә барыгыз да заказчикның өй түрена җәелеп ремонтыгызны төгәлләгез.

—Ник ватык агрегат белән килдегез дисә?

—Димәс, димәс! Киресенчә, ниһаять килделәр, дип сөенер генә. Юкса һәр заказчик көнгә икешәр-өчәр кат шылтырата: "Бораулаучыларыгыз кая, кайчан килә?!" Аптырагач йөдәгәч, юатыр сүзем, яңа вәгъдәләрем калмагач, телефонны алыштырдым, автоответчик куйдырдым. Язылган гозерләрен кереп тыңлый аласын. Әйдә...

—Юк, ышанам инде, болай да.

Наил Кадыйрович хәйләкәр елмаеп кына Фазылны читкәрәк дәште. Тегесе: "Эштә минем бернинди серем дә юк",—дигәндәй, инбашларын сикертеп егетләр ягына ымлады. Начальникның чынлап торып чакыруын күргәч, берәр мөһим сүз барлыгына ышанып ризалашты үзе.

—Кадрлар бүлегенә кереп, контрактка кул куярга онытма.

—Зөмәйрә янынамы?

—Әйе, Зөмәйрә Харисовна әбәткә бикләнгәнче кәгазь эшләрен бетереп чык.

—Ник Харисовна, ник әле Зөмәйрә ханым гына түгел?

—Анысын да әйтиммени инде?—Наил Кадыйровичның рәхәтләнеп елмаюдан күзләре кысылып бетте.

—Нәрсә, бәбәкләрең ярыгыннан карап көлеп торасың президент яшьти?! Бер башлагач җомлаңне әйтеп бетер инде.

—Син куенында төн кунып чыккач...

—Монысын да беләсеңме?

—Соң, Фазыл, бер авыл кешеләре лә без. Кемнең кем янында кунып чыкканы сер түгел.

—И шуннан?

—Син киткән көнне үк ханымың гәжиткә белдерү биргән, танышу-кавышу өчен. Күрсән, Фазыл, ярты Казан буйдак картая диярсен—сәгать саен шылтыраттылар: "Зөмәйрә Харисовна! Зөмәйрә Харисовна" дип, өзгәләнеп очрашуга чакырып торалар. Инде без дә хәзер "Харисовна" дип дәшәбез.

—Э, теге танышлары?..

—Берсен йортка кертте. Үземнең күргәнем юк, ну егерме яшькә кече диделәр ирен. Зөмәйрә бала тапты. Ике ел була инде... яшәп торалар.

—Вәт Фазыл, мәхәббәт һәм нәфрәт кайда ул! Гомер бакый бер коллективта эшләп Зөмәйрәнең серенә төшенмәгәнбез. Тол картаергa ант иткән ханым, синең белән бер төн эчендә үзгәрде дә куйды... Бар, кер, күр үзен, сөендер...

—Син инде крутой президент, контракт кәгазьләрен юри аңа бирдең әйеме?!

—Юк, Фазыл. Маркетинг эшләре дә Зөмәйрә Харисовна кулында хәзер. Так што, бергәләп эшлисе.

"Ашыгып кияүгә чыкты, бала тапты, ике ел инде",—дигән сүзләрдән Фазыл кинәт сискәнеп китте. Әйтерсең лә, моңарчы аның жанында нерв жепселләренең иң кирәкле чылбыры өзек булган, шушы өч фикер ул өзеклекне өч катлап бәйләп төенләп куйды. Һәм Фазылның жанына ут капты. Кызыксыну, көнчелек, тизрәк күрешергә теләүдән иде ул ут... Өч төен бергә төйнәлгән икән—монда очраклылык юк... Машинасына ут капкан абзый янгын сүндерү почмагына комлы чиләк эзләп килгәндәй, Фазыл "кадрлар бүлегенә" кабаланып килеп керде:

—Зөмәйрә!

Зөмәйрә үзе генә түгел, аның янында тагын ике кыз төшке чәйгә әзерләнәләр. Кайнап чыккан ак чәйнекнең шнурын уттан өзмәк булып үрелгән чагы иде аның. Фазылны күргәч, каушавыннан ялгыш, оядан чыгып бетмәгән штепсельгә кулы тиеп алды. Һәм Зөмәйрәне дерелдәтеп ток сукты. "Ой!" дип өзгәләнеп өлгерде. Ләкин, бу аваз ток чеметеп алган имән бармакның авыртуыннан түгел, һич түгел... Фазылның жан уты Зөмәйрәгә дә күчте. Кызлар кызгану йөзеннән тынсыз калганнар иде, Зөмәйрәнең елмаюын күргәч, аңа кушылдылар.

—Зөмәйрә Харисовна,—диде Фазыл, әлеге кызларның ике арадагы серне белгәнен белмәмешкә сабышып.—Зөмәйрә Харисовна, контрактка кул куясы бар икән.

—Әле сез аңа кул куймадыгызмыни?—дигән булды Зөмәйрә һәм ашыкмыйча гына калын өемнән килешү кәгазен эзләргә кереште. Эзләмәде, кайда ятканын белә ул. Күреп кал мине дип, соңгы тапкыр мөмкинлек бирүе анын Фазылга.

Зөмәйрә... Яшәрүнең әллә нинди ысулларын белә... Соңгы өч дистә елда хезмәттәшләре аны бары тик озын муенлы шәмәхә свитердан гына күргергә күнеккәннәр иде. Бактың исә, ачык изүле, кыска жинле, сыланып торган футболка да бик килешә икән үзенә. Әрдәнәләп өелгән жирән толымнарын юксынып өлгергән иде Фазыл—жилкәсенә тузгытып салгач та купшыланып ымсындыра. Өр-яңа балдак киелгән бармагы белән читкә сыпырып куяр өчен генә калдырган маңгай чәче чын яшен яшереп самимилек өстәп тора.

Контрактка кул куйгач, иркенләп сөйләшер вакыт бетте, тик әйтәсе

килгән сүзләр бар әле. Зөмәйрәнең бүлмәдәш коллегалары артык яшь күренсәләр дә күзгә-күз карашып сүзсез калган ике йөрәкнең аулак минут көткәнен генә аңларлык иделәр, кайнар чәйнекне күтәреп, салатка диелгән яшел кыярны юар өчен урамга ук чыгып киттеләр. Ябык түтәлләрдә үскән "Зозуля" сортлы озын кыяр турындагы Шәрәфи мәзәген искә төшерделәрме—кызлар артыннан серле көлү ишетелеп калды.

Икесе аулакта калгач, вакытны әрәм итмичә, бер-берсен борчыган сорауларга жавап эзләделәр. Гадәттә, мондый аңлашулар аерылышканнан соң, күп вакыт үтеп кинәт очрашкан элеккеге ир белән хатын арасында була торган иде.

—Мин сине икенче көнне үк көттем, ник кайтмадың, Фазыл?

—Саубуллашып киткәчме?..

—Эзләгәненне таптыңмы соң?

—Өйләнү кайгысы юк әле миндә, күрәсең ич—эш яңартып йөрим.

—Кызыл кар яуганчы сайлан инде алайса.

—Ә син үзең ник ашыктың, Зөмәйрә?

—Сонга калам. Ана буласым килде.

—Шулай, көтмәгәндәме?

—Мәхәббәттә бала тиз туа.

—Миңа кызыңны күргә ярыймы?

—Юк! Әгәр син аны күрсәң—тормышыбыз пыран-заран буталып бетәчәк.

Дөреслекне ахырынача ачып бетерергә теләмәде Зөмәйрә. Әгәр ул шушы минутта баланың чын әтисе кем икәнен әйтсә, соңарып корылган гаиләнең терәүләре жимерелер, куанычлары коелыр иде.

—И Фазыл, теленә салынып вакытыңны әрәм итмә, ичмасам, кызлар әйләнеп кергәнче бер үбеп кал, теге төндәгечә татлы итеп, соңгы тапкыр... Бу күрешү иремә хыянәт итү дип аталмас. Минем моңа хакым бар...

Кайда йөрдең?

Егерменче гасыр төгәлләнер алдыннан бик күпләргә "Текә" дигән кушамат тагылды. Гомер кыскартып озын берлек артыннан куу, инглизчә аталган исерткечләргә мөкиббән китү, эксклюзив киемнәргә төренү, мактаныр өчен генә юкка-барга көрәкләп акча чәчү, тән сакчылары белән масаю—Текәләрнең яшәү рәвешенә әверелде.

Унсигез миллион коммунист сулъяктан унга борылып яткач, байракларның төсе алышынды, кешеләрнең холкы үзгәрде, дөньяның асты-өскә килде—явызлар өскә менде, мәрхәмәтлеләр аска төште. Эшсез, өйсез, мөлкәтсез калганнар сулга каерды; эшсез, өйсез, мөлкәтсез калдыручылар унга сөйрәде... Текә Вәли боларның берсенә дә керми—ул урталыкта. Әлеге мактаулы кушамат ана руль артындагы тәвәккәллеге өчен ябышты.

Түрәләрне Рәсәй машиналарына күчереп утырту турында Мәскәү хакимиятенең Указы чыккач, Наил Кадыйрович үзенең "Волга"сын иске шоферы белән бергә сатып жибәрде һәм жаваплылыгы чикләнгән ширкәттән яңа "Джип" кайтартты. Әлбәттә, кирәкле төсне эзләп тапканчы бер ай чамасы көтәргә туры килде. Ул дүрт атна буе машинасыз эшләде... Ак Чишмәгә иртәнге жидедә килеп житәр өчен бишләрдә өеннән чыгып, автобустан трамвайга күчте, шәхси таксилар туктатты, яңадан тәпи йөрергә өйрәнде... Дөньяга карашы үзгәрде. Көн саен шәһәр транспортында изелгән гади халыкны яклап шәһәр мэриясенә хатлар язарга жыенган иде инде ул. Вакыты гына житмәде...

Яңа джипка килешеп торырлык яңа йөртүче кирәк иде.

Колхозның мактанчык житәкчеләре, банкетларда ярыштырыр өчен, жырга-биюгә һәвәс кызларга өйләнергә тырыша... Кабул итү бүлмәсенең юл өстенә "мисс..." конкурсларында жинган чибәркәйләрне секретарь итеп

кую да түрәләр арасындагы бәйгенең бер төре... Шәхси шофер сайлау исә— үзе бер сәнгать: машинасына карап начальствоны бәялиләр, ә йөртүче исә, үзенә утырып йөрүченең ни сөйләгәнен ишетмәскә, кем янына йөргәнен белмәскә, күрмәскә... әйтмәскә һәм кирәксә, машинасын сүндермичә, көнетөне көтә белергә тиеш.

Ак Чишмәдә вакантлы урыннар бушаса, баганаларга игъланнар ябыштырып, радио-телевидение аша чакыртып, кадрлар эзләү гадәте юк. Наил Кадыйрович кирәкле кешене үзе эзләп таба. Аңа Салмачы бистәсеннән "Оргсинтез" факелы астындагы эш урынына төгәл килеп житәр өчен, елның теләсә кайсы фасылын тигез күреп, зарланмый һәм каушамый торган асыл йөртүче кирәк.

Түбән Осланнан килгән бакчачылар ширкәте рәисе белән бораулanасы коеның бәясе хакында ишек бикләп килешә торгач, өйгә кайту вакыты чамадан сикергән иде. Кичке жидедән соң: "Кайда йөрден?!"—дип чырайга-чырай килә торган хатының барында кабаланмый нихәл итәрсең?!. Әлбәттә, Түбән Ослан заказчигына әйтсәң, "УАЗ"игы белән шәһәр читендәге әйләнгеч юлдан "эһ!" дигәнче Салмачыга илтеп куя ала. Ул чагында, горефгадәт кушканча, рәисне өенә дәшеп сыйларга, кунак итәргә туры килә. Бу исә, яңа таныш белән якынаю, дуслашу дигән сүз. Ә дус-ишләргә һәм туган-тумачаларга коеларны чиратсыз бораулыйсы, бәяне дә төшерәсе була... шуңа күрә, Наил Кадыйрович ширкәт рәисенә сер бирмәде, коры гына саубуллашып, очраклы машина ауларга дип олы юлга ашыкты.

Озак көттермәде, шәфәкъ күләгәсеннән бер "Жигули" килеп чыкты. Кул күтәргән кешене узып илле метрлап үткәч, кинәт туктады үзе һәм Наил Кадыйровичның куып житкәнен пошынмыйча көтеп торды.

—Шеф, кая барабыз?—диде ул ачык тәрәзәдән башын тыгып.

Пассажир—Шеф, йөртүчесе—Командир булып юл хакын килештеләр. Шеф өйгә ашыгуы турында ашыгыбрак әйтеп ташлады бугай, Командир завод тирәсендәге ерганакларны үткәнче үк куаларга тотынды. Чокырчакырларны кистереп, каршы килгән машиналарны өркетеп, узарга тиешләрен янга кысып, җәяүләләр сукмагын юл итеп тизлекне арттыруын белде. Шеф саклану каешын каптырып, ишек тоткасына ябышты. "Исемең ничек, Командир?"—дигән өч сүзле җөмләсе дә дүрт жирдән өзелде, сорау жавапсыз калды.

Шунысы сәер, ун минут чамасы узгач, Шеф бу тизлеккә тәмам ияләнде һәм аның командирга ышанычы арта барды, ишек тоткасыннан кулын алып, каештан тугарылып, утыргычка җәелде.

Урамда көзге кич, кабинада июнь рәхәте. Ян тәрәзә ярыгыннан кергән тыгыз жил борын төбендәге гарәп касәсенә салынган жофар маеның хуш исен туздыра.

Ул җәйге чама белән киенгән. Кыска жинле ак күлмәгенә элмәген бушатыбрак яшел галстук таккан. Мул гәүдәсен искәртеп кесә авызы чекрәеп торса да чалбары сызык төшереп үтүкләнгән. Туры башлы олы түфлиләре педальне бөтенләй каплаган. Аяк савытына күрә буе таман, утыргычны соңгы сырына чаклы этеп куйган, арткы рәттә аның турысына кеше сыярлык хут калмаган. Тагын искәрердәй нәрсә шул: егетнең башы зур, күзләре кечкенә; сыны авыр, кул хәрәкәтләре житез; чәче кара, чырае ак. Вак тешләре тезелешеп тулган зур авызы тәжрибәсез рәссам ясаган шаяру кебек шыксыз күренсә дә ул аның үзенә килешеп тора хәтта.

—Ашыгам дигәннән, Шеф, бервакыт гаишник туктатты,—дип, ятланган хикәясен тезеп китте егет,—кырыклы знакны күрмисең мәллә, кая куалыйсың шулхәтле, ди бу миңа. Минәйтәм, Яңа елны каршы аласым бар... Ниткән Яңа ел, 8 март житә бит инде, ди бу... Вәт, вәт, минәйтәм, шуңа ашыгам да, хатын ике айдан бирле борчылып көтә торгандыр дим... гаишник карап-карап торды да якын ук килеп: а ну, өреп кара әле, ди... Мин: "Һау, һау, һау!"—дип өреп күрсәттем үзенә.

—Штраф түләттеме соң?

—Юк, иске булса да анекдотларың ошады, бу юлга гафу итәм,—диде.

Шоферларны күп күрде инде, Наил Кадыйрович. Әлеге егет әрсез йөртсә дә светофорларны санлый, ашыгам дигәнгә карап сары утларга ыргылып керми, юл аркылы чыккан гамьсез җәяүлеләргә сүгенми, кычкыртмый, янәшәсендәге пассажир белән сөйләшеп барганда алгы тәрәзәсен онытып җавап көткән якка башын боргаламый. Бу галәтләрен бик яратты ул аның...

—"Шестеркан" искергән, яңартасы бар,—дип башлады Наил Кадыйрович, сүзне вакансия тирәсенәрәк борырга теләп.—Өр-яңа машинада йөрисең киләме?

—Килә шул. Менә, яңа машинага җыеп йөрим ич инде. Сезне гаиләгезгә илтеп тапшырсам, яңа домкратлык була. Кичә юл ныграк уңды—карбюраторлык җыелган иде... Хәер, төн озын әле, бүген дә җыелырга мөмкин.

—Җыеп бетерәсеңме соң инде, машинаңны?

—Төнлә "бомбить" итеп йөреп кенә куандырып булмый, бәяләрне куып житәр хәл юк.

—Көндез берәр җирдә эшлисеңме соң?

—Кибеттә каравыл торам. Бер төн эшлим, ике төн ял итәм. Акчасы әллә ни юк инде, аның каравы, буш вакыты күп кала.

—Ә мина шофер кирәк. Машинаны фирмачлардан үзеңә сайлап аласы. Әйдә, тәвәккәлләп кара?!

Егет хутлы барган машинаны кисәк туктатты: "Ә син үзең кем буласың соң?"—дигәндәй, Наил Кадыйровичка таба борылган жиреннән, симез ияген инбашына терәп хәрәкәтсез калды.

—Шеф, может синең "таксига" түләргә акчаң гына юктыр, шуна шыттырып барасыңдыр, бушлай йөрткән юк минем, кул китә...

Наил Кадыйрович сул кесәсеннән визит карточкасы, уң кесәсеннән йөз сумлык чыгарды. Егет визитканы алды алуын, ә акчаны кая куясын имән бармагы белән ике утыргыч арасындагы тартмачыкка таба төртеп күрсәтте.

—Шабашка акчасын кулга алсаң хәрәм була... Кул китә,—дип кабатлады ул.—Ак Чишмә Президенты!.. Бүген графигым каравылга туры килгән булса, Казанда "Ак Чишмә" дигән акционерлык кампаниясе барлыгын белми каласы икәнмен.

Яңадан кузгалып киткәч, егет машинасын артык куаламады. Хәер, Наил Кадыйровичның өенә дә ерак калмаган иде инде.

—Мин алай ук лихач түгел, сез ашыкканга гына куган булдым,—дип акланды егет, әлеге начальникның үзенә яңа хужа булу ихтималын күздә тотып.

—Алайса, таныштык дип исәплик.

—Әйесең әйе, тик минем исемем сезнеке шикелле катлы-катлы түгел, просто—Вәли генә.

—Вәли дисәң, бигрәк кыска килеп чыга, мин Текә Вәли дип кушып әйтермен... Кайсы коттедж янында туктыйсы, дип ник сорамыйсың, олы урамнан барасың да барасың.

—Бу Салмачының почти бөтен ташпулатында кемнәр яшәгәнен беләм инде мин. Әйттем ич, төнлә такси булып машинага акча җыям дип, әнә теге—өч катлы, чатыр түбәле, ике гаражлысы сезнекедер дип уйлыйм.

—Әйе, нәкъ үзе. Бакчасындагы су мичкәсеннән чамалап әйттеңме?

—Юк. Балконыннан ярты лаш чыгып, бер ханым бинокль белән безне күзәтә—шуннан таныдым.

—Һе... бүген ерак юлга чыгасым юк, кичке кинәшмәләр дә күренми, вакытында кайтырмын дип иртән эшкә киткәндә ялгыш шапырынып өлгергән идем. Вәт, борчылып көтә инде...

—Борчылу—көнләшүнең бер төре!.. Алай да мин сезнең акчагызны кире бирмим. Сезгә эшкә киләмме әле, юкмы—билгесез. Ә балконга чыгыплар көтә торган хатын миндә дә бар. Акчасыз кайтсам, ул да бик... борчыла...

—Инде Ак Чишмәнең кайда икәнен беләсең, иртәгә иртүк кил.

—Бәлки... Кем белгән?.. Ниме, Наил әфәнде, ә сезнең оешмада хатын-кызлар күп эшлиме?

—Коелар бораулау—ирләр эше ул. Бухгалтерия белән кадрлар бүлеген кушып санасаң дүртәү булыр.

—Хатын-кызның күп булмавы әйбәт икән анысы.

—Өйдәгеләреңне борчыламы?—Наил Кадыйрович "Борчыламы" дигән сүзгә аеруча басым ясады.

—Өйдәгеләрдән бигрәк, үзем борчылам... Хатын-кыз күп булган җирдә тынычлап эшли алмыйм мин...

Килде Текә Вәли, иртәгесен үк килде...

Президентны кем йөртә?

Шул көннән башлап "Ак Чишмә" президентын Вәли йөртә башлады. Каравылга чыгар төн житкәнче үземне сынап карыйм дип килгән егет яңа машинадан төшәргә теләмәде.

Дус-ишләрен, таныш-белешләрен күргәч, Наил Кадыйровичның беренче сүзе "Исәнмесез?" булса, икенчесе Текә Вәли турында башлана иде: "Сез ул егетнең ничек йөрткәнен күрсәгез!!!"

Һәм күрергә теләгәннәр дә шактый табылды. "Мелиорация" траст компаниясенә, Кремльгә барасы булса, Һичьюгы Юдино станциясенә килергә тиешле адреслы вагоннарны каршы алырга дигәндә, Наил Кадыйрович машинасына гел артык юлдаш иярә торган иде. Вәлинең руль артындагы кыланышларын күреп сокланучылар да, яшәүдән туйган каскадер яңа машинаң жылы төнендә тузсын дип үртәүчеләр дә табылды, шунысы сәер, телдән-телгә күчеп халык шоферына әверелә башлаган Текә Вәлине кызык өчен үз ягына авыштырырга теләүчеләр дә юк түгел иде. Ләкин егет, көндезге түләүгә артык зарланмыйча, материаль ярдәмнәр сорап гаризалар язмыйча гына эшли торды. Юлда йөргәндә үзе узынып сүз башламады, Наил Кадыйрович сораулар бирсә, жавапсыз калдырмады. Эшлекле очрашуларга жыелганда кабинадан чыгарга ашыкмады, юкса буесынына карап һәм заманча киенүен бәяләп дигәндәй, яңа танышлар ин әүвәл Текә Вәлигә кул бирә торганнар иде. Ә гәүдәгә шактый кайтыш һәм жәяү йөргәндә колхозчы адымнарыннан бизә алмаган Наил Кадыйрович, киресенчә Текә Вәлинең шоферы сыманрак күренә иде. Президентның кисәткәнен көтмәде, Текә Вәли моны үзе сизеп алды.

Диңгезнең яшь дулкыннары төсендәге машинаның рәхәтен күреп өлгермәде Вәли... Көннәрдән бер көнне Наил Кадыйровичны Салмачыдагы таш пулатына илтеп куйгач, кайтыр якка дип борылган иде, аяк астыннан гына дигәндәй, бер милиционер калкып чыкты, үзе ашыккан юлчы рәвешенә кереп, болгый-болгый кул күтәрә. Туктамый чараң юк. Дөрес, бу халыктан юл хакы түләтә алган шофер тумаган әле безнең Рәсәйдә. Шуна күрә, артыгын көйләмичә, өенә хәтлек илттермәсең өченгә кискен сәбәп табарга кирәк иде.

—Иптәш капитан, трамвайга чаклы гына булса—рәхим итегез!—Һәм Вәли сәгатькә карап алгач, тавышын кырысландырды.—Һай, тагын ун минуттан, гаражга кайтып житеп, машинаны икенче сменага тапшырып өлгерәсем бар, бик ашыгам.

—Ярар,—диде капитан,—бу байлар тупигыннан чыгып житсәм, кайда төшереп калдырсаң да үпкәләмәм.

Юл читендә ян белән басып торгангамы күренмәгән—капитанның

биләндә уенчык шлагбаумсыман аклы-каралы таякчыгы эленеп тора иде. ГАИ инспекторы икән үзе... Күкрәк кесәсендәге селектордан постларның үзара сөйләшкәне ишетелеп бара.

—Мин дә ашыгам,—дип сүз башлады инспектор тыныч кына.—Рәхмәт әле, менә син очрадың.

—Жәяү йөри торган гаишниклар да бар икән! Житмәсә үзегез офицер кеше.

—Экипаж кибеткә дип киткән иде. Берәр авария күреп туктадылар, ахрысы, мине оныттылар.

—Ярар соң, алай ашыккач... ГАИ капитаны гел утырмый безгә, кем әйтмешли инспектор үзебездә, юлдагыларыннан шүрлисе юк.

Һәм Текә Вәли, бераз масаеп, бераз капитанны үртәп, дигәндәй, джипка көч бирде.

—Син элек "скорый"да эшләмәдеңме?

—Юк, иптәш капитан "О1-02-03" машиналарына утырганым юк әле минем.

—Круто йөрисең.

—Гел начальство йөрттем мин, ә начальство, үзегез беләсез, ашыга торган халык.

—Штраф түли-түли синең техталонда кул куярга урын юктыр инде.

—Ялгышасыз, иптәш капитан, талоным чип-чиста.

—Инспекторларның бер дә туктатканы юкмыни?!

—Туктаталар. Праваны сорый башласалар машинамны калдырам да китәм. Икенче көнне китереп бирәләр. Әйтәм ич, начальство йөртәм дип.

"Финляндия" кибете янына килеп житкәч, капитан туктарга кушты. Үзе кабинадан чыгарга ашыкмады.

—Барыбер ышанмыйм. Крутой шоферлар бездә дә бар ансы, тик рульдә шушылай йөреп, техталонына бер кисәтү язылмавына ышанмыйм... Праваң бөтенләй юктыр әле синең, шуна шапырынасыңдыр.

—Минме шапырынам? Менә, пожалысты, ике категорияле.

Капитан Вәлинең юл кәгазьләрен учына алды.

—Тәк, гражданин Сабиров, Салмачыдан монда килеп житкәнче унҗиде нарушение ясадың: кырыктан арттырмаска дигән дүрт знакны сиксән белән үттең; алты очракта, ярамаган килеш, узарга кердең; олы юлдан килгән өч транспортны үткәреп жибәрмәдең; ике тапкыр рөхсәт ителмәгән жирдә трамвай юлын кисеп чыктың... Саныймы тагын?..

—Шаяртмагыз инде капитан, әйтәм ич ашыгам. Документларны бирегез дә хушлашыйк. Ярар, шуна күрә рәхмәт әйтеп тормассыз.

—Бернинди шаярту юк, гражданин Сабиров,—капитан документларны куен кесәсенә салды.—Әнә, минем экипаж килеп туктады. Ул безгә Салмачыдан бирле ияреп кайтты, син ана игътибар да итмәден. Хәзер шунда күчеп утырып унҗиде статьялы беркетмә язабыз.

—Иптәш капитан, үзегез ашыгам дидегез ич, шуның өчен генә.

—Син рульдә. Пассажир нәрсә димәс сиңа, һәрберсен үти башласаң...

Һәм Текә Вәли, Казан шәһәренең Мәскәү районында, Чистай урамындагы Финляндия кибете каршында правасын алдырды. Ярты сәгать буе беркетмә язганнан соң, капитанның йөзендә канәгатьлек хисе чагылды:

—Гражданин Сабиров! Бәлки, сиңа праваңны иртәгә үк китереп бирерләр. Ләкин минем әле моңарчы, болай рәхәтләнеп, протокол тутырганым юк иде...

Икенче көнне түгел, ике ай үткәч тә китереп бирмәделәр. Беркетмә шундый бай эчтәлекле иде ки, хәтта Урман арты бистәсендәге хужалыгына чиратсыз су скважинасы казытып биргән өчен рәхмәтләр укыган полк командиры да ярдәм итә алмады.

Фазыл бригадасына кушылганда Текә Вәлинең машина йөртергә хокукы юк, кушаматы гына бар иде. Тик, Наил Кадыйрович аны эштән

куарга рөхсәт итмәде. ГАИ капитанын эзәрлекләп чыгарга мәҗбүр иткән шикаятьчеләргә үч итеп, башка байлар кулына эләкмәсен өчен ул аны ничек кенә булса да, "Ак Чишмә"дә калдырырга теләде.

Ул әле бригадада беренче атнасын гына, Фазыл белән Мәдияр ни кушса шуны гына эшләп йөри. Килгән көнне үк агрегатның һәр җиһазы, һәр эш коралы белән җентекләп танышып чыкты, һәм үзен шундук тәҗрибәле бораулаучы кебек хис итте. Аның көндәлек эш барышында еш телгә алына торган ротор, редуктор, барабан, вертлюг, насос ише кирәк-яракларны күргәне бар. Ләкин төп эш жир астында бара. Тирән катламнарга су каян килә? Аны ничек эзләп табалар? Син тәҗрибәсез әле, дип, әзрәк түләмәсләрме? Үзләре белгәнне өйрәтерләрме?.. Кыскасы, жир астындагы һәм яңа һөнәр эчендәге билгесезлек аны мажарасы белән түгел, ә көн күрергә ярардай гамәл буларак кызыксындырды...

Байлар коесы

Алар тагын Жиде күлгә килеп төште. Төште дип чын мәгънәсендә әйтергә була, чөнки машина туктап өлгердеме-юкмы, Фазыл инде жиргә сикереп тә төште. Мәдияр да сикерергә ашыкты, Фазылны кабатлар өчен түгел, сагынып, үз итеп, таныш болыннарда еллар чалымын тоеп. Ул елларны санар өчен бармакларың житмәс. Хәер, Текә Вәлине дә кушып санасаң житә. Ләкин аның өчен Жиде күл әле хатирәләргә уелмаган билгесез авыл гына. Әнә ул, кабина ишеген ачып куйды—аякларын урамга чыгарып утыргычлар өстенә сузылып ятты. Аңа: "Төш!"—дип әйтүче юк. Ул әле яңа кеше, әйтеп тормасалар нәрсә эшлисен белми. Фазыл белән Мәдиярның тау итәгенә ник төшеп барганын да аңлап бетерми. Кирәксәм чакырырлар әле, дигәндәй, буш вакыт барында ял итә. Жиде күлгә килгәндә янда утырып барды. Фазыл аңа рульне бирмәде, правасыз йөртүчеләргә машина ышанып тапшырган кешенең үз правасын алалар, диде. Хак әйтә, әйтүен. Текә Вәли үзенең хокуксыз көннәрен бик авыр кичерә, белмим, озакка сузылса нишләр?!.

Фазыл белән Мәдияр, үзәнлектә ярышып-ярышып, нидер эзли.

—Кайсы тирәдәрәк әле ул?

—Хәзер табабыз аны, Мәдияр!

—Мина ияреп йөрмә, читкәрәк чык.

—Үзәнлеге нәкъ шушы, өянкесе күренми...

—Әллә кайчан авып, учакларда янып беткәндер инде. Син хәзер кычыткан өелеп үскән жирне тап, өянке төбе шул булыр.

—Менә, вагон торган жиргә охшаган. Вышка әнә тегендәрәк—кәбестә басуы читендә иде.

—Ат колагы басуы бу... Нинди жир кыргыйланып беткән.

—Бүлгәләп сатасылары бардыр, шуңа сөрмәгәннәр...

—Фазыл! Менә безнең скважина!

Алар икәүләшеп әйлән-бәйлән уйнадылар. Көлтәләнеп үскән кара әрем уртасыннан тырпаеп торган торба башы—әйтерсең лә, балачак бәйрәмнәренең яшел чыршысы! Сөенечтән шигырьсез, моңсыз такмаза туды:

Тиле-миле күп төрле,
Диваналар бер төрле...
Их-ма!
Күргән кеше шаккатыр,
Безнең яшьлек тап-такыр...

Вәли сагаеп калды, яннарына килеп баскач әлеге тамашаны нәрсәгә юрарга белмәде. Ил башлыгы булырдай ике ирнең үзләренә генә мәгълүм сүзләр тезеп, ясле баласыдай сикеренүе—дөрес хәл түгел... Бәлки йоласы кушадыр, дип, уенга кушылды. Өчәүләшеп әйләнүе күнеллерәк тә иде.

—Мужики! Сез бурильщиклармы әллә?!

Уен өзелде. Сорау бирүченең эшлекле тавышы сискәндерде:

—Сез Наил Кадыйровичтанмы?

—Юк, без "Ак Чишмә"неке! Ә Наил Кадыйрович кешесе менә бу,—диде Мәдияр, Текә Вәлигә төртеп.

—Мин—Хәсәншин! Ишеткәнегез бардыр...

—Ә-ә-әйе, сезне белмәгән кеше юк,—дигән булды Вәли, һавалы Хәсәншинның мин-минлегенә тимәс өчен.

Ул, Текә егетне остазга санап, күрешкән жирдән кулын ычкындырмыйчарак торды:

—Исәп-хисап тәртиптә, мин сезне кичәдән бирле көтәм.

Ялан тәпиенә мунча чүәге кигән, өзек балаклы джинсы чалбарын хат ташучы сумкасы кебек итеп инбашына каеш белән элгән күлмәксез Хәсәншин үз капкасына таба юл күрсәтте.

—Сезгә яна кое бораулатып акча түгәсе юк,—диде Фазыл хужаны кире үгетләргә теләп.—Менә, чын чишмә бу! Суы—дингез! Әйбәт саклангән—торба башын тимер капкач белән япканнар. Илле адым арага канау казып, ишегалдына чаклы сузасы гына кала.

—Каян беләсең?

—Мастерыбыз ул безнең,—диде Вәли, нинаять, жавап тотуны үз өстеннән төшереп.

—Житмеш икенче елны бораладык,—диде Мәдияр да өлешкә кереп.

—Брат, анысы шулайдыр, ну миңа персональный кое кирәк. Колхоз суына калгач, крәстиянга әйләнәм ич мин.

Мәдияр тагын такмакларга кереште:

Персональный компьютер,
Персональ машина,
Персональ скважина,
Персональный пенсионер...

Беренче көннән үк заказчы белән әчелешле булырга теләмәде Фазыл, тату сөйләшүгә күчте.

—Акча түләгән кеше һәрвакыт хаклы! Без сезнең кулда...

Хәсәншинның күнеле булды:

—Вәт ичмасам, монысы братларча.

Мәдиярның өйрәнчек малай кебек сүзсез басып торасы килмәде.

—Хәзер ишегалдыгызга кереп вышканы урнаштырыйк. Эшне иртәдән башларбыз.

—Карасана! Сез бөтенегез дә мастерлар икән. Бик дөрес, изге эшне иртән башлау фараз ди, теге китап... Өйнең подвалы белән беренче каты сезнеке. Бассейндагы су атна башында гына алыштырылган.

—Каян алдыгыз?—диде Фазыл, иртәгесе көнгә бораулар өчен дә су кирәген белеп.

—Казаннан китерттем, Зәңгәр күлдән... Ярты сәгатьтән сауна өлгерә. Суыткычлар тулы. Тәк, "баяннар" мәсьәләсе нихәл—өчәү житәме сезгә?

Хәсәншинның тел уйнатып әйткән сүзләрен авылчарак кабул итте Фазыл. Баян булгач, жырлата торган нәрсә—мөгәричтер, дип аңлады:

—Кеше саен берәү житәр. Күпкә китсә иртән кыенга төшә...

Балаклары өзелсә дә чалбарының кесәләре исән калган икән, Хәсәншин телефон чыгарып, аягүрә генә кемнәргәдер йомышлар кушты. Бирелгән әмерләрнең барысы да кичке ялны тиешенчә үткәрү өчен иде.

Ләүкә почмагындагы датчик йөз егерме градус күрсәтә! Мәдиярның битендәге, мангаендагы, иягендәге һәр шадрасына тир бөртеге ябышкач йөзе жемелдәп тора.

—Һәр заказчик шушылай каршы алса эшләп үләрсең...—Текә Вәли тагын нәрсәдер әйтмәкче иде, сулыш юлы пеште.

—Борчылма, рәхәттән үлмәссең,—диде Мәдияр, йөзендәге жемелдәвекне сыпырып.

—Без монда парга очып бетмәбез микән? Артыгын утырмыйк,—диде Фазыл,—әле бераз баян уйныйсы да бар.

Ишекләр күп инде ул дөньяда. Ләкин аларның һәммәсен дә шакып, рөхсәт сорап ачасы түгел. Әйтик, кибеткә, кинотеатрга, өенә кайтып кергәндә... Трамвай, гараж, бакча капкаларын шулай ук шакып тормаслар.

Ләүкә тулы ирләр утырганда сауна ишеген шакысалар шиккә төшәсең икән ул... Тиргә баткан күзләр бер-берсенә аптырашып карап торган арада вак-вак такталардан корамаланган ишекнең икенче ягыннан Хәсәншин тавышы ишетелде:

—Егетләр, баяннар керә!

—Чыккач эчәрбез, монда исереп үләсең!—дип әйтеп бетергәнче аккошлар кебек тезелешеп, сәхнәгә менгән балет артистлары шикелле аяк очларына басып, билләренә уралган сөлгеләрне кыска итәк сыман итеп өч кыз кереп өлгерде.

"Привет, мальчики?!"—дигән сәламнәреннән абайлап кына кызларның кайсы милләттән икәнен төгәл әйтеп бирүе мөмкин түгел иде. Хәер, милләтнең мунчадагы роле—сүнгән машинаның руле кебегрәк, әлләни әһәмияте юк. Шулай да Мәдияр: "Боларның берәрсе Ростов якларыннан түгел микән?"—дип, пошаманга төшеп өлгерде һәм күнелдә шик калмасын өчен ачыктан-ачык сорап куйды:

—Девочки, сезнең кайсыгыз Галина исемле?

Өчесеннән дә "юк!" дигән җавап ишеткәч, Мәдияр сөенеченнән авызын жыя алмады.

Күз алдында торган өч кызның берсе—озын, берсе—кыска, берсе—ябык. Озыны—сары чәчле, ябыгыныкы—чем-кара, кыскасы—көл төсенә кергән. Сары чәчлесе—зәңгәр күзле, чем-карасыныкы—яшел, соры чәчлесендә—коңгырт. Зәңгәр күзлесе—үпкәләгән сыман аскы иренен турсайткан, яшел күзлесе—көләргә генә тора, коңгырты—ун бармагының тырнагын ун төскә буяган...

Сауна эчендәге кызулык термопара тоя алмаслык дәрәҗәдә артты. "Мальчики" йөрәк тибешенә кислород житкерә алмыйча, авыз ачып суларга керештеләр.

Алты кеше берьюлы сүзсез калгач, ишек артындагы Хәсәншин шикләнә калды:

—Аныгызны югалттыгыз мәллә? Бу баяннар сезгә миннән бүләк, туйганчы уйнагыз!

"Моны Наил Кадыйрович кушуы буенча оештырганнардыр, иртәгә үк Зөмәйрәгә ишетелер..."—дип уйлап куйды Фазыл.

"Болар чакырулы баяннардыр. Өчесе белән берьюлы уйнап карасаң, ә?!"—Монысы Мәдиярның уе иде.

Текә Вәлинең дә уе бар:

"Кемнәр генә укымаган инде боларны?! Аптеканы үзләре белән йөртәләр микән?.. Вәт блатной эш икән бу! Ә мин дурак, начальство йөрткән булып, рәхәт күрмичә үлеп китәр идем..."

—Әйдә, Вәли, бассейнга чумабыз, кызлар туңып кергән, жылынсыннар бераз,—дип, Фазыл Мәдиярны борчыган уйларга чишелеш тапты.

Картлачлар чыгып китүгә, Мәдияр өч кызны да чыркылдатып, сөлгеләрен жыеп алды...

Бассейн дигәне, саунадан чыгып, ун метрлы киң басмадан үткәч аерым түбә астына иркенләп казылган иде. Фазыл белән Вәли бер ялгызы су коенып яткан Хәсәншингә иптәш булдылар.

—Баяннар ошадымы соң үзегезгә?

Хәсәншиннның комарлы соравына Фазыл төгәл җавап бирергә теләмәде.

—Уйнап карамадык бит әле... Ник "чувиха" йә "телка" йә "мочалка"

дип кенә әйтмисез? Баян дигән шәп, милли музыка коралын хурлап...

—Сезнең Төркиягә барганыгыз юкмыни? Анда ирләрне Бәй—ягъни, Бай диләр. Ә хатын-кызлар Баян булып чыга. Фестивальләргә барган чакта артистларга еш искәртәләр: Баян сорамагыз, мин—Баянчы дип мактанмагыз, ягъни мәсәлән...

Үзенең чит илгә барганы юклыгын сиздереп, Бай Хәсәншин алдында мескенләнмәс өчен, Фазыл сүзне үз жирлегебезгә кайтарды.

—Авыл жирендә канализация юк ич, бассейндагы суны кая түгәсез?

—Бакчага сибәбез: Агачларга, бәрәнгегә.

—Кыш көне күлгәме?

—Юк. Күлне саклыйбыз. Без анда затлы балык үрчетәбез. Яр әйләнәсен унжиде хужага бүлдек тә койма белән уратып куйдык.

—Алайса, кыш житүгә бассейннарны киптерәсез?

—Сезне шуна чакырттым да инде... Хәзер күп кеше бассейндагы суны түгәр өчен дренаж коелар бораулата.

—Коенган суларны түгәр өченме? Пычрак су ич бу, моны ничек итеп жир астына агызмак кирәк?

—Ниткән пычрак? Сез—пычракмыни?

—Ну, юк та. Әнә, саунадагы баяннарны кем белгән. Хәзер шулар госелләнгән юынтыкны коега кусаң... Ул бит якын тирәдәге чишмәләргә ияреп чыгачак!..

—Кем, Фазыл агайне, син мине бөтенләй үк наданга санама. Авылда өй саен кара мунча—ак мунча. Аларның юынтыгын кем кая куя? Шул, яшәгән урынында жиргә сенеп бара бит...

—Өстән сенгән су тирәнгә төшкән саен фильтрлана ул. Ә дренаж өчен казылган скважина жир астына туп-туры алып керә. Жинаять ич бу—жир асты суларына зараза тондыра.

—Ә нефтяниклар нишли? Жир катламыннан нефтьне кысып чыгару өчен елгадан куылган суны чистартып торалармы әллә?

—Шуна күрә чишмәләр пычрак...

—Бөтен Казан халкы Идел суын эчеп ятканда, безнең коелар кәүсәр әле ул. Йөз төрле чистарткыч аркылы үткәрсән дә Идел суы—эчә торган су түгел инде. Эчәләр ич әнә, миллион ярым халык исән.

—Сезгә ул коенын дренаж өчен генә кирәклеген Наил Кадыйрович беләме соң?

—Нинди кое?! Сез мина егерме метрлы скважина бораулап бирәсез. Эчәмме мин аннан, бассейн суын түгәмме мин ана—монысы минем эш. Акчасы түләнгән.

—Акчасы түләнгән, баяны уйналган,—диде Вәли, беренче көнне гаугага әверелдермәс өчен.—Хозяин—барин, ничек әйтсәгез, шулай бораулабыз, әйеме Фазыл! Сауна кызуы башка сукты бугай, үтәр, боерган булса...

Ул арада, саунадан пешегеп чыккан кызларның чыркылдашуы ирләр арасындагы киеренке сүз көрәшен жинде. Алар артыннан, дунгыз көтүчесе кебек куалап, Мәдияр килә. Сул беләгенә эленгән өч сөлгене куярга урын тапмагач, бассейн читендә гәүдәсеннән су саркытып торган Фазылның иненә каплаган иде, тегесе өнәмәде. Ләкин, чиркануын сүз итеп кайтармады, сөлгеләрне йомарлап, талдан үрелгән түрле утыргыч өстенә ыргытты.

—Коеныгыз,—диде Фазыл, әллә үртәп, әллә битәрләп,—берсекөнгә бу суны без казыган коега агызырлар. Аннан соң ул жир астыннан юл табып берәр чишмәгә килеп кушылыр. Бу тирәләрдә озаклап эшләсәк үзебез эчәрбез.

Кызыл тамгалы Шомбай

Көне буе егетләр ни эшләгәнне күзәтеп, хужаларча нәтижә ясап барган Хәсәншиннның, кичкә кергәч сөяге авырайды. Ул бүген, көнозын йөреп, күлгә су коенырга төшмәде, егетләр белән бергә утырып

ашады, туктап ял итсәләр яннарында басып торды. Сөйләгән сүзләренә колак салды, уйларын фаразлады. Инде җәйнең озын көне сүрелеп, ишегалдындагы баганада лампа кабызырлык караңгы иңгәч, хужа кеше түзмәде, черки ябырылган муенын каплардай кием эзләп өйгә кереп киткән жиреннән юк булды. Мәдияр Фазылның күптәнге гадәтен белә, әгәр ул көнетәне эшләргә җыенган икән—димәк, бу урыннан тизрәк китәргә тели... Яңа Вәли исә моны тәнге берләр тирәсендә генә аңлап алды.

—Ник, Фазыл абый, бүген ял итү юкмыни?

—Син кереп ят, агайне. Без Мәдияр белән бик сагындык әле бу эшне.

—Әйе,—дип җүпләп алып китте Мәдияр, алдан ук килешенеп куйгандай, уен кагыйдәсен саклап,—безнең акча көри торган сезон башланды.

—Минем болай гына соравым иде—Вәлинең үзенчә аклануы бу. Төннәрне күргән бар, йокысыз Казан буйлап адашкан юлаучыларны күп ташыдым инде мин. Аннан соң бу бит әле минем гомеремдә беренче кое, беренче чишмә, ягъни мәсәлән. Ничек оялмыйча йоклап ятмак кирәк...

—Синең беренче... Ә безнең өч йөз дә беренче!—Бу сүзләрне Фазыл гына түгел Мәдияр да әйтергә теләгән иде.

Таң яктысы аяк астына төшкәч, Фазыл Вәлине йокла дип үгетләргә үк кереште. Аның аяк астында чуалмавы бик кирәк иде. Мәдияр белән киңәшәсе бар. Һәм чирәм өстендәге сырмага йөзтүбән капланган Вәлинең йокыга киткәненә ышангач, Фазыл бораулауны туктатып, скважина эченнән балчыкны юдыра башлады.

—Нишлибез, Мәдияр? Хәсәншинга чишмә бораулыйкмы, әллә егерме метрлы коры чокыр гына казып бирәбезме? Хәзер су катламы башлана, тимәскә иде ана...

Фазылның "нишлибез?" дигән соравына жавап бирер өчен Мәдияр бераз уйга калды.

—Гамәлгә ярамаган кое казып бирсәк бушлай эшләү була.

—Наил Кадыйрович акчалары түләнгән диде.

—Яңа байларны белмәссең. Без китүгә, насос төшереп суын чыгарып караса. Коры скважина бораулап киткәннәр дип, гауга куптарыр. Әле яңа гына эшли башлаган килеш... беренче скважинадан ук конфликт китсә?!.

—Аның каравы тыныч йоклыйсың. Жир асты сулары пычранмый!

—Әйе! Азатлык мәйданындагы кебек митинг үткәрәсе генә кала: "Суларны саклыйк!", "Яңа байларга хурлык!" Карын ач, киергә юньле кием юк, фатир сатып аласы бар. Галина жинган минем хәерчелеккә бер генә ел түзә алды, качты... Акча кирәк Фазыл яшьти, намуслы бораулау остасы буларак мин сине биш-алты елдан соң мактармын, яме.

—Мәсьәлә хәл ителде...

Агыйделнең аръягына Галя качты,
Утыз еллап куа-куа карным ачты.
Ач тамакны туйдырырга бик күп кирәк,
Байлар белән сөйләшергә хәйлә кирәк...

Татар халык жырыннан бу. Шигырь яза башлаганмы, дип, мине кызгана күрмә!

Һәм Фазыл әйләнеп торган квадрат валның тормозын бушатты. Егерме метр тирәнлектәге долото су катламындагы чуерташларга элэгеп бөтен агрегатны калтырата башлады.

—Үч иткәндәй, суы да күп булачак әле монын! Мин мастер дип, күкрәк кагып әмер бирә торган чак түгел, кирелекне жиңәргә туры килә!

Тәүлекнең егерме алтынчы сәгате киткән иде инде.

Ташлы катламны үткәндә бораулау торбаларының бер-берсенә ялганган урыннары нык кысыла, кувалда белән кыйнамыйча сүтеп ала торган түгел. Тимер тавышына Хәсәншин уянып чыкты.

Ул арада Вәли дә чирәмлектән сикереп торып, астына жәеп йоклаган сырманы өстенә киеп өлгергән иде.

—Нәрсә, братлар, авария мазармы?

Фазыл:

—Юк. Шулай тавышланып эшлибез инде без,—дигәч, Хәсәншин үзенә үзе уйлап тапкан күнегүләр белән ишегалдында физзарядка ясый башлады.

—Хәзер, полиэтилен торбагызны ялгап төшерәбез дә, артына ком тутыргач—вәссәләм.—Мәдияр Фазылга якынрак килеп дәвам итте.—Төне буе эшләгәнгә исе китмәде моның. Суы күп булачакмы дип тә сорамады... Да... Син хаклы бугай, яшьти... Чынлап та чишмә кирәкми, юынтык түгәргә тирән чокыр бораулата бу...

Маршрут кәгазендәге өч исемгә Наил Кадыйрович кызыл кара белән тамга суккан. Күрәсең, бу кешеләрне көттерергә ярамый, йә зур урында эшлиләрдер, йә туганнарыдыр... Егетләр ул каләресен белергә тиеш түгел. "Ак Чишмә"нең президенты кызыл тамга суктыручыларны үзе генә белә. Мисал өчен, әгәр журналист Шомбайның өен күрмичә үтеп китсәң—тагын тынгы юк. Кабминнан шылтыраттылар: "Ни теләсә—шуны эшләгез. Скважина өчен бер тиен акча алмагыз. Чыгымнарын оешмагызның эчке резервы хисабына каплагыз!"—янәсе. Өстәгеләрнең сүзен санламасаң—тигез җирдән түмгәккә абынасыңны көт тә тор... Наил Кадыйрович бик кечкенә президент. Кирәкле кешеләре биегрәк кәнәфидә утыра. Аның куен дәфтәрендәге телефон номерларын барлап чыксаң—кемнәр генә юк! Ул теләсә кайсы генераль директорның, ГАИ начальнигы, министрларның өен белә. Дәүләт эшлеклеләре, премьер һәм хәтта Ил башлыгының үзе белән турыдан-туры элемтәгә керә ала. Гел түгел, тегеләрнең энекәш-сеңелкәшләренә, абый-апаларына, балдыз-кияүләренә, ханым-туташларына, сакчы-хезмәтчеләренә су скважинасы бораулаткан чагында гына. Саный китсәң, аларның туган-тумачалары бөтен илне яулап алган кебек... Әйтерсең лә, суда гына яши ала торган тереклек ияләре—коеларның тирәнен, чишмәләрнең шаулысын сорыйлар.

Исемлекне жентекләп укып чыккач, Фазылның биленә кинәт утлы күмер тиеп үткәндәй булды. Унҗиденче кеше—невропатолог Кукушкин Г. Н. иде... Яңадан туып, дигәндәй, эшли башлавына айлап вакыт үтмәгән килеш, "Әҗәл хәбәрчесе" белән күрешеп, бәхәсләшеп торырга әзер түгел иде әле ул. Фажигале көннәр ерагайсын, онытылсын бераз. Ордым-бәрдем генә хөкем карары чыгара белгән табибка карата күңел рәнҗүе басылсын.

—Бу капкага берәр елдан әйләнеп килербез, боерган булса. Исемлектән сызып торам мин аны,—дигәч, Мәдияр белән Вәли дә каршы төшмәде.

Кызыл тамгалы Шомбайның капкасына ялган йозак эленгән иде. Ачып керсәң—ишегалдында ыгы-зыгы. Ике малай тирес тарата, дүртесе—жир тигезли, түмгәк вата. Гаиләсе зур икән бу Шомбайның, дип уйлап куйды Фазыл. Ләкин сөйләшеп хәл-әхвәлне белешкәч, көрәкчеләрнең дә бораулаучылар кебек үк ялчылар икәнлеге ачыкланды. Малайлар совхоздан килгән, директор кушуы буенча, иртәдән бирле тырышалар, төшке ашка да кайтмаганнар. Монда чәй эчертеп сыйлап каршы алучы бар дип белгәннәрдер. Шомбай иртән күренгән үзе, нәрәт биргән дә югалган, бораулаучылар килә калса менә шушы урында тишсеннәр, дип, мунча кырыена казык кагып калдырган. Жиде күлдәге имеш-мимешләргә ышансаң, Шомбай—ветеран журналист икән. Премьер-министр турында китап яза ди бугай... Гел зарлана торган, көйсез, әмма татарның беренче мактанчыгы икән. Дүрт сутыйлы бакчасын сукалатыр өчен совхоздан чылбырлы трактор чакырткан, әнә дүрт малай сүгенә-сүгенә шул буразнаны тигезли. Ике тазлы мунчасына сиксән метр тирәнлектән су чыгарырга кушып киткән...

—Менә шундый Шомбай,—диде Фазыл үзенекеләргә хәлне аңлатып.—Хәсәншиннның капкасы бикләнде. Шомбай коесын сохари белән бораларга туры килер...

Язгы ташкын чигенгәндә, жәелеп аккан елга эзендә чокыр саен кар суы жыелып кала. Алар кибеп, соңгы бака иске елгага күчеп киткәндә

инде җәй башланган була. Түгәрәк-түгәрәк камышлы тал түтәлләренә карап язның куәтен күз алдына китерәсең.

Яшел Үзән белән Биектау төбәкләренең чиктәш авылларын йөреп чыккач: "Моннан нинди диңгез чигенде икән?"—дип уйлап куясың... Күлләрдән генә торган авыллар бар монда. Жиде күл... Аккош күле, Тирән күл, Олы Күлбаш, Якты күл, Раифа күле, Шарлавыклы чишмә, Суыксу, Аксу... Һәр яралган авылга исем таба алмаганга шулай кушканмы борынгылар? Юктыр... Бүгенгесе көндә исән калган өч мең ярым авылга кабатланмас исемнәр табылган ич...

Ике яшьлек арасы

Зур су тирәсендәге авыллар ачлыкка бирешмәгән, корылык елларны жинелрәк кичергән.

Борынгы бабаларыбыз халыкны үрчетер өчен Идел белән Чулман кушылдыгына күчеп утырган.

Хәзерге эшкуарлар мөлкәтләрен саклар өчен күл тирәсенә тамыр жәя. Элеккегеләр сулы корылмалар белән дәүләтнең башкаласын саклаган. Хәзергеләргә су—күңел ачу өчен кирәк...

Элек су чыгару бөтен авыл сөенерлек изге эш иде. Хәзер исә, Фазыл бораулау остасы дигән һөнәре белән масая алмый. Чәнечкеле таш коймалар эчендә бикләп сакланган персональ чишмәләр суга сусаган гади халыкны куандырмый... Байларга эшләүнең сөенече юк... Ишегалларына кергәч үзеңне батрак итеп тоясың...

Гомер юлы элек һәм хәзер, кичә һәм бүген, яшьлек һәм картлык дигән төшенчәләр белән үлчәнә. Син картайганга карап кына яшьлек югалмый... Әмирне әйтсәк—ул Фазыл белән Мәдиярның яшьлегендә яшәде. Инде Фазыл белән Мәдияр үзләре Текә Вәлинең яшьлегендә эшләп йөри. Кемнең яшьлеге дөресрәк, мактаулырак, күңеллерәк үткән дигән сорауга жавап юк... "Синең" белән "Минем" яшьлекләрне чагыштыру бәхәскә керә.

Без чабата киеп кичке уенга чыга идек; черек бәрәңге күмәче ашап үссәк тә Ватанны дошманнан саклап кала белдек, дияр Әмир. Ә без яшь чакта, яңгыр явып үткәч, гөрләвекләрдә су коена идек, бозау-бәтиләрне кыш чыкканчы өйдә үстерә идек. Ул суыклардан өйнең бөтен бүрәнәләре шарт-шорт ярылып бетә, Сафура буранны авылларны күмеп китә иде. Кар астына төшкән суны кер юарга ташыдык... Ә Казан каласында урамдагы колонка суларына сироп кушып стаканын өч тиеннән саталар иде, дип, элдереп китә Фазыл... Текә Вәли кушылмыйча калмас... Мин кибет суын гына эчәм, беткәннән-беткәнгә фирмачлар баллон белән китереп торалар, һәр көн иртән чиләк-чиләк апельсин, ананас, банан кабыклары түгәм; кызыл уылдык ягылган күмәч кисәкләрен берсенә-берсен каплап, ике катлап ашыйм, дип, кызып киткәч, яңалар исеменнән мактанган Текә Вәлине туктатырлар. Чөнки, черек бәрәңге ашаган, яңгыр суында коенып үскәннәрнең яшьлеге гарьләнә башлый. Текә Вәлиләрдән соң килгән буынның яшьлеге ни белән мактаныр—белмим, Жир шары түгел, Су шары өстендә яшибез лә—аның өчтән ике өлеше диңгез һәм океаннар белән капланган, калган өлешен дә коры жир кисәкләре дип әйтеп булмый—каян тишсәң су бәреп чыга. Житмәсә әле ул сулар катлам-катлам... Су өстендә яшәгәч халык ни күрмәс... Суның өч төрле халәте бар лабаса!..

Яшьлек белән яшьлекне чагыштыру—кешеләр арасындагы бик күп бәрелешләрнең сәбәбен фаш итә... Без йозак күрми үстек, капка-ишекләрнең келәсенә бау гына элә идек—өйдә юклыкны күрсеннәр өчен. Ә хәзер һәр яңа йортның беренче өч каты төрмә—тәрәзәләре рәшәткәле, ишекләр тимердән... Элек кыз бала, укыйсы килмичә клубка чыга икән—аны шундук урлап, тормыш итә башлыйлар иде, ә хәзер клубка чыккан кызыйларга йөк тутырып, тизрәк калага озаталар... Элек ярты кило арыш урлаган өчен

нәселенне корыталар иде, ә хәзер күбрәк урлаган саен зуррак эшкә күтәрәләр...

Яшьлек белән яшьлек бәхәсләшкәндә жинүчеләр була алмый... Элек һәр су скважинасын бораулатыр өчен "Гипроводхоз" институтында махсус проект төзетәсе һәм аны, ким дигәндә, алты баскычтан имзалар куйдырып раслатасы бар иде. Ә хәзер кем кайда, ничек тели—су чыкканчы бораулый да китеп бара. Хәтта, эчәргә ярыймы ул, ярамыймы дип, анализ ясарга кушучы да юк...

—Аның каравы, хәзер кирәкле кешене хөрмәт итә беләләр.

Сауналарда кыздырып, "баяннар" белән су коендыру яшь чагыгызда төшегезгә керәлмаслык, әкият булган әнә...

—Алай димә, Вәли!

—Мәдияр абыенның сиңа әйтәсе килә: саф сөю, керсез-чиста мәхәббәт безнең яшьлектә дә барые...

—Мунчадан соңмы?

—Әйе, Вәли брат, Фазыл белән яшь чакта колхоз хисабына "баяннар" белән мунча кергән көннәрне онытмадык әле без.

Гомердә булмаганны, Мәдияр бүген Вәли алдында калай әтәчләнеп, яшьлекнең башкаларга сөйләргә ярамаган күренешләрен искә төшереп маташа. Нырты совхозындагы мунча керүләрне Текә Вәлигә тасвирлап бирүдән егетлегеннен мәртәбәсе артамы? Шушы, бер очраклы вакыйга белән мактанып, дөрес яшәлгән гомернең матур чынбарлыгын ямьсезләп куяргамы? "Син күргәнне—мин киптереп элгән" диярга телисең икән, димәк, син хәзер үзеңнән егерме яшькә кечерәкләр белән ике арага тигезлек билгесе куярга омтыласын, ике яшьлек арасындагы вакыт үлчәмен санга сукмаска тырышасың...

Юк, сөйләмәде Фазыл Нырты хәлләрен, Вәли алдында Мәдиярны серле, горур һәм мәгънәви итеп саклап калыр өчен сөйләмәде. Нырты мунчасы—су өчен барган көрәшнең бер күнелле сәхифәсе генә ул... Чатнама суыкларның жил уртасында көннәр буе вахтада торган өчен; карлы буранларны жиңә алмыйча, өзелгән юл өстендә кунып калган төннәр өчен; тездән ләпек ерып машина көпчәкләрен казып чыгарган өчен; урман-кырлардан ризык эзләп ачлы-туклы үткән айлар өчен, шәфкать кулы күрмичә төзәлгән тән жәрәхәтләре өчен. Егерменче гасыр казанышларыннан ваз кичеп кыргыйларча табигать кочагында, һәм тагылмалы яшел вагонда үткән яшьлек елларында рухи һәм матди югалтулар бәрабәренә табылган күнел юаткыч иләслек, тыелган алма иде ул Нырты мунчасы.

Иске жәмгыятьтән ваз кичеп, яңача яшәү рәвешенә күчү—иске бәрәңгене ташлап, яңа бәрәңге ашый башлау гына түгел шул. Кешеләрнең үзаңы сульяктан уңьякка бик авыр күчә. Кичәге коммунист Наил Кадыйрович та әнә, үзен яшь капиталист дип исәпли, сул аягындагы итеген ун аягына киеп азаплана. Итекләренне бутап кисәң, юлың турайганчы аягына шактый сөял чыгар... Бер унайга яшәргә өйрәнгән элеккеге бораулаучыларны бүгенге шартларга күнектерәсе бар...

Фазыл, ике гасырның ызан сызыгына басып, як-ягына карана. Иске дә, яңа да түгел әле абзагыз... Ачлы-туклы, кырыс, югалтулар белән тулы үткән заман ни аңа, океан артыннан яңа урысларга ияреп кайткан сәяси хөррият, интернациональ акчалар, базарлы вәгъдәләргә күмелгән киләчәк заман ни... Көянтәсенә эленгән тәлинкәләре буш булса бизмән, як-якка авышмыйча, тигез тора ала. Ләкин Фазылның гамь бизмәне буш түгел... Бүгенге вәзгыять дигән чынбарлык битарафлыкны яратмый, унга авышырга куша. Үткән заман шөгыльләре ял иткәндә искә төшереп юаныр өчен генә кирәк. Бүгенге уңышларны исә эшли, эзләнә, үзгәрә дигән хәзерге заман фигыльләре хәл итә...

"Ак Чишмә" жыйнак оешма, ул үзенә үзе хужа. Аның хәзер ялтыравык кәгазьләргә төреп приказлар, күрсәтмәләр, кисәтүләр жибәреп торырлык трестлары, идарәләре, министрлыгы да юк. Наил Кадыйрович—үзе президент, үзе министр, үзе управляющий... Эшчеләрнең көнкүреш шартларын

яхшырту, ел ахырында өләшерлек табыш китерү, иске бораулау агрегатларын яңарту. Иң мөһиме—бригадалар тик ятмасын өчен өзлексез эш белән тәэмин итү...

Элек бораулаучылар эш күплектән интегә иде. Ел башыннан кулына план тоттыралар. Унөч авылга барып, унөч кое бораулап, колхоз йәисә совхозларны сөендереп кайтсаң әйбәт бригада исәбенә керәсең. Әгәр инде планыңны, өч-дүрт авылга арттырып үтәсәң—син хезмәт батыры! Министр фәрманы белән сиңа матди рәхмәт явачак...

Ә хәзер... Бюджет акчасын капка төбенә җәйгән Яңа байларга персональ кое бораулап бирәсең дә яңадан заказлар җыелганны атналар буе көтеп йөрисең. Димәк, әлеге өзеклекне билгесезлек, мескенлек, хәтта вакытлыча эшсезлек дип атасаң да була. Эш барында жыйнап, заказлар югында тарата торгач, егетләр өметсезләнеп, кайсы-кая үз мәшәкатьләре белән тарала, аларны кабат чакыртып китерүе шактый вакытны ала. Агрегатны гаражга илтеп куйгач, бер-береңне эзләп табарга дигән сурәттә: "Син кая кайтасың, кем тирәсендә югаласың, телефоның ничек әле, кайдалыгыңны туганнарың беләме?"—ише сораулар ява башлый...

—Атна саен шылтыратып торыгыз!—диде Наил Кадыйрович, егетләрне Восстание урамында төшереп калдыргач.—Мин яңадан Ак Чишмәгә киттем. Вәлине сезгә бораулаучы итеп жибәргәннән бирле аның урынына яңа шофер алганым юк әле. Рульдә гел үзем йөрим... Өйләрегезгә таратып тормыйм, үпкәләмәгез, вакыт юк.

—Тупиктан олы юлга чаклы чыгарып куйгач та рәхмәт инде,—диде Мәдияр, джип тирәсенә килеп кунган ике "күбәләккә" сәлам биреп.

Наил Кадыйрович кире борылып "Оргсинтез" ягына юнәлгәч, Вәли джипта шәхси шофер булып йөргән көннәрне юксынганын сиздермәде, киресенчә, хуплады гына бугай;

—Бу кеше мине яңадан үз шоферы итмәкче ахрысы! Юк инде, байларга кое бораулап йөрү ошый миңа!

—Чакырса ризалашмый нихәл итәрсең?! Алар хәзер безгә эш бирүчеләр. Сүзләрен тыңламасаң урамга куа да чыгара.

—Менә Восстание урамына чыгарып ташлады ич әле, тагын кайчан дәштереп алыр, анысы билгесез,—диде Фазыл, Мәдиярны хуплап.

Вәли, әллә үртәлеп, әллә сүз көрәштерүдә алга чыгарга теләп, башында ниндидер хикмәтле уй йөрткәнлегеп сиздереп өлгерде.

—Алайга китсә, минем әле бик шәп планым бар... Тагын берәр ай эшләп карыйк та, әйтермен...

—Юк инде,—дип чәчрәп чыкты Мәдияр,—хәзер үк әйт! Жавабын әйтмичә йөдәтсәләр—табышмакларны женем сөймн. Кроссвордлар чишә башласам—психланып бетәм. Сюрприз дисәләр, сүгенәм... Серем бар дисәләр—йоклый алмыйм... Сүзеңне башлагансың икән—ахырынача әйтеп бетер!

—Мәдияр, син Вәлигә бәйләнмә! Танышканыбызга айлап вакыт үтмәгән, ышанмый торгандыр ул безгә. Бәлки әле аның планнары безгә кагылмыйдыр. Буровойны рәтләп белмәгән кеше яңалык кертә алмас.

—Яңача яшәп карар өчен һәркемгә дә хезмәт ветераны булырга димәгән.—Вәлинең тавышында үпкәләү-сукрану моңы юк, киресенчә, үз уена үзе бик нык ышанганлыгы сизелеп тора.—Кулыннан килгән кеше ялланып эшләргә тиеш түгел. Юкса, хәерчелектән башың чыкмас.

—Бер башлагач, аңлаешлырак итеп әйтеп бетер,—диде Фазыл да сабырсызланып.

—Бораулау агрегатын үзебезгә алабыз!

—Бетең беләнме?!—Мәдияр бу сүзләрне Вәлигә түгел, күбрәк үзенә-үзе әйтте.—Бөтен Советлар Союзы буйлап Галина белән кунача эзләп йөри торгач кесәм такырайды, күнелем бушады.

—Минем дә запас күп түгел,—диде Фазыл, Мәдиярның моң-зарын зурга жибәрмәс өчен.—Коммунистлар заманында эшләп жыйган акчам демократия

жылысында эреп бетте. Житмәсә, авылда өй саласым бар... Дөрес, безнең Әмир дә бар бит әле. Зурдан кубып эшкә тотынсагыз минем барлыкны онытмагыз дигән иде...

—Запас ягыннан үзем дә әллә ни мактана алмыйм,—дип, үзе дә ярлылар ягына авышты Вәли.—Без бит әле эшләп торабыз. Күргәнегезчә алай ук акчасыз эш түгел. Өч борынга "общяк" ясап туплыйк та Наил Кадыйрович каршына килеп басыйк: "Ак Чишмә"дән бүленеп чыгабыз, "Ак су" дигән фирма төзибез, диярбез.

—"Ак су", Ак су... Аксубай кебек, мин ул районны яратмыйм,—диде Фазыл.

—Причем монда Аксубай районы, Ак су, ягъни ап-ак су дигән сүз килеп чыга, әйеме Вәли?

Фазыл Вәлигә сүз әйтергә ирек бирмәде.

—Ак су... Көмешкә кебек. "Ак таныш" фирмасы итик.

—Котырдың инде Фазыл, шул Актаныш белән. Президент итеп Аксубайның берәр кешесен сайлап куйсалар... "Ник?" дигәненә үкенерсең әле...

—Үзең әйтмешли, причем монда ил башлыклары, Актаныш—минем беренчем. Син аны Мәдияр бик яхшы беләсең.

—Беләм, беләм, Аккүздәге Әлфинән намаз ияседер инде, сина да зыян итмәс, әнә акшам вакыты...

Сүз куерту әрләшүгә әверелмәсен тагы дигәндәй, Вәли тавышын көчәйтте:

—Карагыз әле, егетләр, яңа фирмалар өчен менә дигән исемнәр бар икән: Аккүз, Акшам, Аккош, Акбаш...

—Атланма, билен сындырырсың!—диде Фазыл, хыялый Вәлине туктатып.—Сүз башына әйләнеп кайтсак, синең тәкъдимендә җелек бар. Яңача яшәргә өйрәнергә туры килер... Пермь өлкәсенең Кунгур шәһәренә барып килсәк, заводның үзеннән өр-яңа станок алып кайтабыз инде дә, ну өч йөз мең доллар җыярлык гомер калмады... Наил Кадыйрович белән уртак тел табып, үзебез ремонтлаган шул искесен сатып алырга тәвәккәлләп була... Ә бүгенгә таралышыйк...

—Тукта әле, Фазыл, башланган сүз ярты-порты килеш калмасын. Димәк, без, әгәр теләсәк аерым фирма ача алабыз?

—Әгәр Наил Кадыйрович ризалашса—әйе!—диде Вәли, никтер Фазыл өчен жавап тотып.—Әлегә мөлкәт анын кулында.

—Алайса, буш хыял гына бу! Жир астыннан акча көри торган бораулау станогын ник безгә бирсен инде ул!

—Бирә. Һәм фирманың дүрт учредителе була.

—Без өчәү генә ич,—диде Мәдияр, беркатлыга сабышып.

—Наил Кадыйровичны кушып сана.

—Начальниктан котыла алмагач нинди мөстәкыйльлек соң инде ул?

—Табыш дүрт өлешкә тигез бүленәчәк. Фирма кәгазьләренә кул куеп, банк аркылы чеклар үткәрер өчен беребез директор, теләсәк генераль директор итеп исәпләнәчәк.

—Кем? Фазылмы?

—Юк, Мәдияр,—дип аркылы төште Фазыл,—директор да, президент та буласым килми. Мин гомергә начальствоны сөймәдем. Андый хыялым юк!

—Ну, йөрисең инде алайса ялчы булып.

—Тукта әле, Мәдияр,—дип тагын дилбегәне үз кулына алды Вәли,—безнең арада ялчылар юк, барыбыз да компаньоннар булып калабыз.

—Син нәрсә, Вәли, безгә әйтмичә генә Наил Кадыйрович белән алдан ук сөйләшеп куйган идеңме?—диде Фазыл, егетнең үжәтлегендә төпле кинәшче фикере барлыгын сизенеп.

Текә Вәли жавап бирмәгәч, Мәдияр да батырайды:

—Димәк, безнең яңа хужабыз син буласың?!

—Әйе... Ләкин сезнең белән тигез эшләячәкмен мин.

—Буровойга джиптан төшкән кеше генә ич син. Гидрогеологиянең сынар хәрефен дә белмисең.

—Сез белгәне житкән, Фазыл. Аның каравы минем машиналар төзәтү буенча фирма ачып караганым бар. Теләсәм, зур ссуда алып бирә торган чиновникларны эзләп таба беләм. Базар бюрократлары белән уртак тел табуы—кое бораулаудан да катлаулырак ул. Ярый, житәр, бүгенге сөйләшү—киләчәк өчен бизнес-план гына әле ул...

Һәм Текә Вәли, егетләр белән кул биреп саубуллашкан унайдан гына узгынчы машина туктатып китеп тә барды. Ул киткәч, Фазыл белән икәүдән-икәү генә калып кабат сөйләшергә исәбе бар идеме, Мәдияр күзгә текәлеп тик торды. Ләкин, яңача яшәргә өндәгән текә егет хакында бүтән сүз кузгалмады.

—Бар, вакытыңны әрәм итмә,—диде Фазыл, Мәдиярны билгесез тарафка ашыктырып.

—Ә син үзең кая кайтасың? Әйдә минем белән. Аена йөз доллар түләп торышлы аерым фатир таптым, икебезгә дә урын житәр!

—Юк. Мин кунакханәгә ияләштем. Анда кеше күп, ыгы-зыгысы рәхәт. Таныш кунаклар да күп очрый... Фатир хакы синекеннән артык чыкмый...

Аерылышу күнелсез тында бетәчәк иде. Шулчак җете кызыл блузка кигән, кукуруз чәкәнедәй үтә сары чәчле, өлгергән күген җимешедәй зәңгәр күзле бер "күбәләк" килеп басты. Ашыгычлык белән итәген киергә онытканмы—елан кабыгыдай челтәрле кара колготкие тулысынча күренеп тора.

—Мальчики,—диде кыз, ике күзенә бер юаныч эзләп,—ял итәсегез киләме?

—Урам бәясе күпме соң бүген?

—Тулы программа белән дисәгез—ун бакс!

—Урының бармы соң, кызый?

—Болары вак мәсьәлә, кирәк дисәң...

—Ә синең исемең Галина түгелме?

—Юк.

—Жәл.

—Алайса, Галканы чакырам. Бик хәтерләп калгач...

—Кирәкми. Галина ерак инде.

—Аңламадым. Минме, әллә Галка кирәкме?

—Китмә, хәзер миңа кайтабыз!—диде Мәдияр, "күбәләкне" канатыннан сыйпап. Ә үзе Фазыл алдында акланасы итте.—Кайсыдыр жире белән Галинага охшаган бит бу, ә?!

—Галинаң әби яшенә житкәндер инде. Син аның исемен яхшылап сора, Регина түгел микән?..

"Регина" дигән исемнән Мәдияр, бәке суына таеп төшкән малай-шалай шикелле, куырылып калды.

—Ну Фазыл, әгәр чит кеше булсаң, моның өчен ияк төбеңә менеп төшә идем инде.—Һәм Мәдияр, "күбәләк"кә илле сумлык акча сузды.—Бар кызый, минем рәт юк бүген.

—Танымадынмы, тәки?! Хәсәншин мунчасындагы баяннарның берсе бит ул...

—Әгәр уйласаң, беркая китмә! Шушында гына тор. Егерме минуттан әйләнеп киләм мин,—дип кычкырып калды "күбәләк", "Газель" капкасыннан кереп барышлый.

Кызык, дип аптырашта калды Фазыл, челтәр ботлы, кызыл канатлы, сары башлы бу "күбәләк"нең кайсы төше Галинага охшаган икән соң?.. Әйе, бозыклыгына аклану кирәксә, юксынган кешеңне капма-каршы төсләрдән эзли башлыйсын икән ул...

Сәяхәтче күрше

Фазылны ишек шакып уяттылар. "Совет" кунакханәсенең гореф-гадәтләрен яхшы белә ул. Әгәр бикле ишек аркылы: "Сезнең бүлмәгезне жыештырасы бармы?"—дип эндәшмәсәләр, димәк, чакырылмаган кунак кызлар үзенә түләүле юаныч эзләп йөри...

Йокы туйган кебек тоелса да сәгать унике генә иде әле. Төн уртасында хезмәткәрләр борчымый. Бүлмә саен кереп оялаган чикле-шикле фирмалар да офисларын кичке алтыда ук бикләп таралыша. Кунаклар берән-сәрән генә калды хәзер кунакханәләрдә.

Күнелдә коткы бар анысы... Өч йөз тәнкә акча бәрабәренә унтугыз-егерме яшьлек чибәркәйләр тансык рәхәтлекне ишек төбенә үз иреге белән алып килә. Ләкин уйнашчы кызлар, тәнне тауар итеп сатучы сутенерлар, мингерәйткеч үлән таратучылар, арзанга ясалма аракы китерүче шинкарь түткәйләр—барысы-барысы да муллык арбасына ачыктан-ачык ияреп кергән базар вируслары гына. Белгән кешенне генә кочарга, белгән жирдә генә эчәргә, таныган ризыкны гына ашарга өйрәткән заман бу. Әгәр берәр зәхмәт эләктереп, аяктан егылсаң, сине кем карый? Кемгә сыенырсың, газиз башкайларыңны кая куярсың? Чире азынган сукбай кебек, чүп савыты төбендә кәкрәеп катасыңны көт тә тор! Һәм Фазыл, очраклы сөешүләрнең әхлакый ягыннан бигрәк әнә шул зәхмәтеннән курка. Бу курку рәхәткә сусауны төннең теләсә кайсы вакытында да тыя ала.

Шакылдау күрше ишеккә күчте. Тупса чыелдаган тавыштан соң шактый вакытка тынлык урнашты. Ләкин йокы качкан иде инде.

Фазыл асылмалы кара сумкасын бушатып, яңадан тутыра башлады, юл кирәк-яракларын барлады. Гадәттә, ул сумканың йозагын ябар алдыннан иң өскә ком сәгатен куя торган иде. Бу юлысы ашыкмады. Әле юлга чыгарга иртә. Көне буе кайтасы бар, бераз ял иткән очракта юл газабын кичүе жиңеләер. Ул ком сәгатен кулына алып киенгән килеш кенә тагын урынга барып ятты. Биш минут саен вакыт дигәнең ком булып әле бер якка, әле икенче якка агыла. Ком агышына күз ияргәч йокы куера.

Атна башында Актаныш автобусы яртылаш буш йөри икән. Казаннан чыккан чакта егермеләп пассажир бар иде, алары да Чаллы белән Минзәләдә коелып беттеләр. Ахыр чиктә алты гына кеше калды. Юл тигез, йөк әз дигәндәй, автобус үкереп бармый, тәрәзә артында шаулаган жил ике күршенең сөйләшүен дә жиңә алмый. Алты кеше салон буйлап урын сайлый, дөресрәге юл борылган саен күләгә эзләп әле бер, әле икенче якка күчеп, кояштан кача.

—Без яшь чакта Актанышка самолет белән йөрешле иде. Башта "Ил-14", аннан "Л-410" очты,—диде Фазыл, алдагы рәтнең ике кешелек утыргычында үзе генә тугарылган малайга сүз катып. Ул аны Актаныш кешеседер дип уйлады.

—Беләм. Билет бәясе тугыз сум иде... Борылып жавап биргәндә күршенең йөзен күреп алды Фазыл. Юк, яшь егет түгел, буйга гына шулай малайларча бәләкәй икән. Чаларган чәчен кына буявы белән яшергән.—Ә син ник ком сәгате тотып барасың, дару эчәсең мәллә?

—Юк, эчмим. Ком сәгате йөрәгемне тынычландыра. Ә сез Актанышка кунакка кайтып барасызмы?

—Каян белдең?—диде малай-агай, "Сез"гә "син" белән жавап кайтарып. —Әйе, мин кунакка кайтам. Ну, син уйлаганча ялга түгел. Журналист мин. Гомерем буе ерак районнарның арадашчысы булдым. Яшьләр ераккa чыгарга яратмый хәзер.

—Эш буенча почти братлар икәнбез.

—Әллә син дә журналистмы?

—Юк. Мин артезиан коелар бораулаучы. Гел юлда.

—Мин командировкада чакта сезнекеләр килеп бораулап киткәннәр. Премьер-министр миңа көн саен шылтыратып, хәлемне белешеп тора. Сүктем әле бер көнне үзен. Мин димен, атаңның яшьлек дусты, сине энекәшләреңнән белән теземә утыртып сөйгән кеше. Мине сусыз яшәтеп, Жиде күлнең яна акулалары алдында мыскыл итәсең димен... Гафу үтенде, иртәгә үк килерләр буровиклар ди... Сиксән метрга төшкәнче казысыннар, дип әйтеп калдырдым. Байлар суны тирәннән алып эчә. Сай кое—хәерчеләр коесы... Эшләгәннәрен күзем күрмәсен дип, бер атна буе Нурлатта йөреп кайттым. Андагы Глава минем белән кинәшмичә бернәрсәгә дә тотынмый...

—Сезнең исемегез Шомбай мәллә?

—Шомбай—Минем әдәби кушаматым. Ә син каян беләсең мине?

—Сезне белмәгән кеше юктыр ул.

—Анысы шулай. Теләсә кайсы Главаның ишеген тибеп ача алырдай бердәнбер журналист инде мин. Популярлык буенча Салаваттан кала икенче кеше.

Фазыл ни дип тә җавап бирергә белмәде. Жиде күлдәге скважинаңны мин бораулап бирдем синә, карун, әрәмтамак, кызыл сөлек, дип әйтергә теле бик кычытып торса да түзде. Сүзне автобус маршрутына кайтарды.

—Мин Актанышта утыз ел элек эшләп киттем. Менә, сагынып кайтып киләм. Районны аркылы-торкылы йөреп чыгарга исәбем.

—Һи, агайне, Актанышны алыштырып куйдылар, танымассың син аны. Утыз ел элек иске агач авыл иде ул. Ә хәзер бишәр катлы конторлар, бассейнлы сарайлар, Мәскәүчә фатирлар, ресторанлар, игелек йортлары. Инфраструктура гөрләп үсә... Гади халыкка эш кенә юк. Их, шунда бер кечкенәрәк завод салып куярга!

—Шулай дип яздыгызмы соң?

—Син нәрсә, политически неграмотный мәллә?! Ил башлыгының туган ягына кайтып акыл өйрәтеп йөрергә, әллә син мине чын Шомбай дип белденме?

—Нәрсәгә генә кайтасыз соң алайса?

—Тираж эшләргә. Подписка башланды.

—Мин сезнең журналистлар телен аңламыйм.

—Актанышның укый-яза белә торган халкын бөтен республикага начальство итеп таратып бетерделәр. Грамотный кешеләре бик аз калып бара, алары шул—беркая куярга ярамаганнар гына, журнал алдырмый, китап укымый. Тиражлар кими Актанышта.

Автобус Актаныш базарына килеп туктап ике ишеген дә ачты. Идән астындагы әрҗәләрдән тауар бушатырга дип калган дүрт пассажир янына ярдәмче егетләр килеп басты.

Журналист җиргә төшкәч чалбар балакларын сыпыргалады. Жете зәңгәр күлмәк якасын буган яшел галстугын төзәтте.

—Ашыкма, китми тор!—диде ул Фазылга. Һәм бер йозаклы кара портфель кесәсеннән тар, озын тарак чыгарып озак итеп чәчен тарады. Күренеп тора, ул вакытны сузарга тели, үзен каршы алырга тиешле кешенең торкарлануына эче пошканын сиздермәскә тырыша, кечкенә генә гәүдәсен дә мәгърур итеп тота иде.

Каршы алучы егет буй-сынны ныгыткан, тавышы өлгергән, мәҗлескә килгән кунак кебек пөхтә киенгән. Бер минутка соңга калганы өчен ярты минут буе гафу үтенде.

Каршы алучылар йоласы дигәндәй, журналист аңа портфелен тоттырмакчы иде, тегесе аңлашмаганга сабышты, адымын кызулатып алгарак чыкты. Ләкин журналист әрсезләнүен дәвам итте.

—Мәле, иптәш буровой мастер,—диде ул Фазылның буш кулына портфелен тоттырып,—синеке жинел күренә, инбашына эленеп кенә бара.—Ниме,—диде ул хакимият вәкилен тукталырга мәҗбүр итеп,—менә бу абзаңны үземнән калдырмыйм. Минем әле утыз ел редакциядә эшләп кое бораулаучылар турында язганым юк иде. Сезнең районда эшләгән икән. Икебезгә бер машина бирерсез, Актанышны йөреп чыгабыз.

—Гафу итегез. Мондый мәсьәләне глава гына хәл итә ала. Мин бүгеннән Казан кешесе. Мәдәният министрлыгына эшкә күчерделәр.—Вәкил һәр аваз-ның дикциясен төгәл итеп, логик басымны дөрес куеп, ноктaларны ишеттереп әйтте.

—Әһә... сине дә Казанга значыт. Актаныш хатын-кыз түрәләр кулына кала икән...

Фазыл, үзен артыксынып, журналистның портфелен кире бирмәкче иде, тегесе ике кулын кесәсенә тыкты.

—Юк, агайне, бергә барабыз. Монда Мин хужа. Дүртенче власть диләр

Мине, шуны бел.—Ахрысы ул әлеге сүзләрне вәкил ишетсен диебрәк әйтте.

Сигез сәгать буе автобуста кайтып, Фазыл уйларга теләмәгән бер мәсьәлә бар иде: Актанышка килеп төшкән кичне кайда кунып калырга? Әгәр иренмичә, бик жентекләп жавап эзләсәң, әлеге сораудан каушап, килгән автобусыннан төшеп тормыйча, кире Казанга китәргә туры килер иде. Ник дигәндә, район кунакханәләрендә хәзер нибарысы ике-өч бүлмә булып, анысы да үзәктән килгән тикшерүчеләр, салым инспекторлары, министрлыклардан жибәрелгән ревизор, журналистлар һәм артистлар белән тулыр. Әгәр инде төн кунып чыгарга теләсә кайсы авылда элеккеге фатирларның берәрсе танып кертер әле дип ышансаң... моннан утыз ел элек үк илле-алтмыш яшьтә исәпләнгән хужабикәләрнең кайсысы гына исән икән инде?! Тәвәккәллек өчен дә житди сәбәп бар. Әле көн озынлыгы кыскара башлаганга унбиш кенә тәүлек, челләдән кызынып калган жәйге төн таң атканчы суынмый. Фазылның инендәге юл сумкасы жинел, әгәр Казан автобусыннан Богады авылында төшеп калсаң, дүрт чакрымлы сукмакны яктыда үтеп, әби-бабайлар капка бикләгәнче Каенлыкка барып житәргә була. Әлфинәне фәкать Каенлык авылыннан гына эзләргә мөмкин. Анда Ниса кортка исәндер әле бәлки. Фазылны күреп танып, сөенер, онытмаганы өчен хәтта рәхмәт тә әйтер. Якын туганнар да бер-берсен оныта. Ә Фазыл, бөтенләй чит кеше, фатирант, утыз елдан соң сагынып килгән. Ниса кортканы түгел, жәйге каникулда кунакка төшкән Әлфинәне эзләп йөриме? Барыбер горурлык, Әлфинә—Ниса кортканың оныккачы лабаса!

Шомбайның очравы Фазылның сәер сәяхәтенә үзгәреш кертте. Гомер буе каләм белән казынып жан асраса да жир кешесе иде, кунакханәдә үткәрелгән төнге әңгәмәдә бораулаучы абзагызның ни югалтканын һәм утыз елдан соң әйләнеп килеп, кемне эзләп йөргәнен бик тиз төшенде ул. Төшенде, ләкин сиздермәде. Егетнең хезмәт юлы журналистика өчен яңа тема иде. Яңалык—укучының икенче азыгы. Журналист Фазылның рөхсәте белән, диктофонны кабызып өстәлгә куйды. "Истәлеккә" дип языласы әңгәмә озаграк сузылсын өчен ул сүзне Фазылның Актаныштагы яшьлек мәхәббәте турында башламады.

—Фазыл, мин наданга аңлат әле син, Казан шәһәре ник Идел суы эчә? Жир асты саранмы?..

—Казан халкына Идел суы эчертү—бүгенге житәкчелекнең ин зур жинаяте. Безгә килеп житкәнче Идел 1200 чакрым үтеп, үз юлында зур пристаньлы жиде шәһәрнең әшәкесен юып алып төшә. Шәһәрне юу дигәндә, аның канализациясен, завод-фабрика калдыкларын, кыш буе жыелган мазутлы, әшәке кар суларын уйларга кирәк. Шунын өстенә Иделнең әле Ока, Сура, Зөя кебек дистәләгән кушылдыгы бар, аларның нәжесен дә кушып сана.

—Әйтәм жирле өйдәге су юынганда күзне әчеттерә...

—Борынгы кешегә шәһәр торбаларыннан без эчә торган суны бер стакан бирсән—шундук агуланып үләр иде.

Журналист, йөзенә чиркану чыгарып, стаканлы чәйне читкәрәк этеп куйды, ләкин авызында эреп бетмәгән карамель тынгы бирмәгәч, чәйне тагын үзенә алды.

—Фазыл, Казан халкын ничек саклап калырга була, Буралы коелар казырга кирәкме?

—Коеларны, чишмәләрне без өске сулар дип атыйбыз. Янгыр, язгы ташу, юынтык сулар үтеп кергәнгә күрә. Олы юл читендәге чишмәләргә дә ышанмагыз. Асфальт өстендә тузган каеш көпчәкләр цианитка таркала. Аларны янгыр юып төшерә. Әгәр чишмәдән алып кайткан су өстенә юка элпә утырса—берүк кайнатмыйча эчә күрмәгез.

—Алайса "Мәликә", "Хәмит" чишмәләренә дә ышаныч юк?

—Актаныш, Мәслим, Мамадыш, Кукмара, Балтач, Әгерже һәм Идел белән Каманың аръягындагы районнарда мин теләсә кайсы чишмәнең суын улакка ятып эчә алам. Тугайлары, урманнары сау-сәламәт Жирдә—су да сихәтле.

—Безнең редактор саннар белән мисал китергәнне ярата. Сунын киләчәге хакында фикерегез ничек?

—Татарстанның җир астында ике миллиард кубометр төче су бар. Нефть беткәч, без әле валютага су сата башлаячакбыз. Кибетләргә керсәң, су бәясе сөтнекен узып китте инде... Жөмһүриятебез уникаль урынга урнашкан: биш йөз елгабыз, җиде мең күл, өч мең чишмәбез бар. Шуның өстенә, бүгенгесе көнгә алты мең артезиан кое бораулаган.

—Рәхәтләнеп эч, әйеме?! Йөз елга җитә!

—Дөрес, безнең илдә су белән сүзнең бетәсе юк. Диктофонны сүндерсәк тә була.

—Гафу ит, Фазыл әфәнде, әңгәмәне төгәлләр алдыннан үзең турында бер-ике генә сүз әйтеп үт.

—Аны әйтеп торасы юк, Ак Чишмәдә эшләүче бөтен бораулаучыларның да язмышы бертөрле. Авыл малайлары,гомер буе юлда. Хәзер инде безнең эшкә яшьләр бик килми. Элек Ростов-Дондагы махсус мәктәпкә жибәреп, бораулау осталары әзерлиләр иде, хәзер укыту өчен түләрлек оешмалар бетте. Шуңа күрә бүгенге бораулаучылар арасында илледән дә яшьрәкләрне табуы бик кыен. Яшьләр хәзер комфорт ярата: утыз каналлы телевизорлар, төнге клублар, сауна-бассейн, сыраханәләр, әзер кызлар кирәк аларга. Ә без кыр кешеләре...

—Авылдан-авылга йөреп, Татарстанның иң чибәр кызын сайлап алдың инде, әйеме, Фазыл әфәнде?

—Иң чибәр кыз...—Фазыл бармагы белән диктофонга төртеп сүндерергә ымлады. Шуннан соң гына, урындык аркасына терәлеп, җиңел сулап куйды.—Иң чибәр кыз, утыз ел элек шушы Актанышта калды.

Журналист үзе дә туганнарча сөйләшүгә күчте.

—Һәм син аны эзләп кайттың. Кем ул, кайсы авылдан?—Һәм Фазылның көлемсерәп эндәшми калуын өнәмичә, дәвам итте.—Мин Актанышның һәр авылын, һәр жан иясен беләм. Язмаган кешем калмады...

—Ә Аккүздән Самат абыйны?

—Галимжановмы? Аның әле бертуган энекәше райкомда эшләде. Беләм мин аны. Хатынының әнисе "Каенлык" авылында яши иде.

—Нишләп иде?

—Үлгәненә жиде еллап бардыр.—Фазылның, кинәт борылып күзләрен яшерүе, журналист өчен көтелмәгән хәл түгел иде инде.—Димәк, син Әлфинәне эзләп килгәнсең...

—Ерактан гына гәүдәсенең шәүләсен күрәсе иде, тавышын гына булса да ишетәсе иде.

Журналист, мәсьәлә чишкәндә жавабы дөрес чыкмаган мәктәп баласы шикелле, ручкасын өстәлдәге кәгазь өстенә ыргытты. Стенага кадакланган радионы ачып карады—ләкин ул көндез генә сөйли торган нәрсә иде. Тимер өстәл өстенә беркетелгән "Чайка" телевизорының унике төймәсенә басып чыкты, әйтерсең лә үзен борчыган сорауга жавапны шуннан эзли иде ул. Экранда Чаллы программасыннан "боевик" килеп чыкты, ОРТда—сәясәтчеләр мәжлесе, СТСта—сабынлы сериал... Ә калган каналларда "Яңгыр ява".

—Фазыл, агайне, син романтик кеше инде. Ну бит, тормышның чынбарлыгы көчлерәк... Син беләсенме соң, Әлфинәнең ат хәтлек улы, буйга житкән кызы бар. Ире автобус йөртә. Әбиләре үлгәч Чаллыдан күчеп кайттылар. Ниса кортка нигезендә кирпечтән менә дигән өй салып чыктылар, авылда кибет ачтылар. Алар җир кешесе. Рәхәтләнеп яшәп яталар. Син килеп хәзер гаилә бозарга телисең.

—Араларына керәсем димим ич, күрәсем генә килә.

—Очраклы күрешүләр була, анысын аңлыйм мин. Ну бит, син, махсус эзләп килгәнсең, астыртын өмет белән. Яшьлек—ул, Фазыл, альбомнарда кала торган фото гына. Тимә, якын килмә син Әлфинәгә. Давай, иртәгә торабыз да иртәнге автобус белән Казанга китәбез.

Ут сүндереп, мендәргә чумып, бер-берсеннән төнге карангылык белән ерагайсалар да уйлар һаман ике арада йөрде.

—Фазыл, ниме, синең башка туганнарың бармы?

—Апам... Караком чүлендә яши. Үзбәкнең алты баласын үстерә.

—Вәт, барып кайт янына. Сөендер апаңны. Үзенә бер күңел юаткыч сәяхәт булыр...

Журналист йокыга киткәнче әйтеп калыйм әле дигәндәй, Фазыл үзенең үтенечен җиткерде:

—Син боларын яза күрмә, йәме...

—Кайсыларын?

—Ну, диктофонга сыймаганнарын... Йәме?!

Фазыл, кабат сорап, журналистны "Ярар!" дип әйтергә барыбер мәҗбүр итте.

Бер күрешү—үзе йөз доллар

Автобус базарның капка төбендә кунган бугай—тәрәзәләре тыштан тирләгән. Кузгалырга бер сәгатьләп вакыт бар, шуңадырмы шофер ишекләрне ачмый, салонда утыргыч япмаларын төзәтә, канистра, чиләк ише калай савытларны шалтыратып урнаштыра. Руль артындагы панель өстенә беркетелгән тирән эчле сабын савытына кесәсеннән вак акчалар бушата. Кыскасы, урамда басып торган пассажирларны утыртырга ашыкмый, вакытны суза.

Кодрәтеннән килсә, журналист үзеннән калдырмас өчен Фазылны белә-геннән тотып торыр иде—бер адым читкә жибәрми, китеп басса—артыннан иярә.

Яңа сәүдәгәрләр сөйрәгән куларбаларның майланмаган көпчәк чыелдауларын, көнбагыш сатучыларны көтеп күкшегән чыпчык чыркылдауларын һәм эчтәге урамнан ара-тирә үтеп киткән жинел машиналарның шыбырдавын исәпкә алмаганда, иртәнге тынлык инде бу. Кояш һаман Агыйдел үзәнендә, Актаныш басмалары буйлап өскә күтәрелмәгән. Тау битендәге "Нахаллар бистәсенә" бишәр катлы йортлар салып күчерелгән гаиләләр йоклый әле. Аста—Иске Актанышта истәлеккә калган әби-бабайлар эт өрдереп көтү куа. Сәяхәткә килердәй кунакларны көтеп, Мәликә чишмәсе өстендәге каенлыкта ялгыз былбыл өзгәләнә.

Ниһаять, Казанга барырга теләүчеләрне ишек ачып керттеләр. Журналист Фазылны тәрәзә кырына утыртты. Ул әле һаман да аның төшеп калу ихтималын онытмый, янына утырып, үзенчә чыгар юлын каплаган иде. Сәфәр мәшәкате белән иртәнге йокылары кимегән пассажирлар йомшак утыргыч-ларга арка терәгәч, автобус кузгалып киткәнче үк тынып калдылар. Журналист та тынычланып күзләрен йомды, йоклар өчен түгел, күршесен сынар өчен.

Ә күршесе Фазыл, автобус кузгалып киткәч, коточкыч зур югалтуга дучар булган адәмдәй, журналистның тезләре аша сикереп кенә чыкты да шофер янына килеп тукталырга кушты.

—Гафу итегез, гостиницада документларым онытылып калган, төшәргә кирәк,—диде ул үз ялганына үзе ышанып.

—Көтәргәме?

Шофернын нияте изге иде. Монысы Фазылны тагын да ныграк каушатты.

—Юк, юк! Мин калам. Менә билетым, мәгез!—Һәм ул үгетләмәсеннәр тагын, дигәндәй, кабаланып ишекне ачтырды.

Автобус Казан юлына сенеп, күздән югалгач, и сөенде Фазыл! Әйтерсең лә ана Актаныштагы яшьлеге әйләнеп кайтты, әйтерсең лә ана Әлфинәле хатирә белән тулган сөенечле язларны, өметле төннәрне, күрештерергә атлыгып торган юлларны бүләк иттеләр. Менә ул, ниһаять, Актаныш! Нинди генә сукмакка бассаң да кая алып бара икән, дип баш ватасы юк. Монда бар да таныш... Шушы минутта, гүя, Жирнең тарту көче утыз тапкырга кимегәндәй булды—атлаганда очып-очып адымнарын зурайтты, гәүдәсе утыз тапкырга жиңеләйде, гомеренең утыз елы юкка чыкты.

Ул басмаларны саный-саный кояш янына төште. Көтүне куып чыгар-ганнан соң авыл тагын тәрәз пәрдәләрен корган. Тын урамнарда абзар исе эленеп калган. Бәрәңге бакчалары киселгән жирдә Агыйдел өелеп тора. Иске

Актаныш Чулман сусаклагычына корбан итеп калдырылды. Мондагы халык иртән уянган саен идәнгә басканчы карават астыннан дулкын эзли. Шөкер, берәүнең көчле кулы, бакча башындагы иске-москы киртәләр белән терәп, ул дәһшәтле дулкыннарны тотып тора бугай. Әйтергә кирәк, бүген-иртәгә батып үләбез дип, егерме ел буе көтә торгач, әби-бабайга әйләнгән абый-апалар инде Әҗәл белән туганлашты, коткарырга килгән Нух пәйгамбәр көймәсе кебек тау башында калыккан биек йортка күчәргә ашыкмый. Актаныш басмаларыннан менәргә аларның дәртләре дә, теләкләре дә юк. Балалары телефон керттерде, көн саен диярлек хәл белеп тау башыннан шылтыратып торалар.

Бар иде бу авылның гөрләп торган чаклары.

Министрлар Советы карары буенча, Актаныш белән Минзәлә кушылып, ике генә ел бергә яшәп карады. Фазыл килгәндә аларның аерылышып, мал бүлешкән еллары иде. Берара вәкаләтсез калган административ йортлар, оешмалар һәм конторлар яңадан җанланып үз эшенә керешкән. Яңа район үзәгенең йөз чакрымга ерагаюын өнәмәгән халык, нинаять, яңадан сөенеп, йомышы булса да булмаса да Актанышка килә. Иртәнге алтыдан, дүрт урамны тутырып, машина-трактор гөрли. Ашханә, универмаг, райком, почта һәм "Үзәк" колхозы идарәсенә чаклы сузылган таш сукмактан кирәген эзләп көр халык йөренә. Чәчәкле-чуклы гөлләрен күрсәтер өчен урам ягындагы тәрәзәләр ачылган. Тузан керә дип борчыласы юк. Яңгырлы көндә ерак авыллардан машина көпчәгенә ияреп килгән үзле кара балчык, кояш чыккач, асфальт юл өстенә сумала булып ката... Әгәр вакыт-вакыт сукмакка сыймыйча, халык төркеме олы юлга чыкса—йә Казан белән Свердлаудан, йә Бөгелмә белән Минзәләдән самолет төшкән булыр. Портфель күтәргән, кызыл галстуклы йәисә комсомол значоклы балаларның татарча жырлап кайтуы район үзәге дип аталган авылның көндәлек тормышына аһәң бирә. Кичкә таба ашханә тирәсендә мотоцикллар күбәя, Культура йорты ишегеннән репитиция авазы яңгырый. Кунак егетләр идел буена төшеп сабан туеннан адашып калган кызларны эзли... Кулларына читән таягы тоткан әбиләр, Фридрих, хәсис кулына эләкмәсен тагы дип, көтүдән аерылып калган кәҗәләрне чакыра.

Ә бүген Иске Актанышта су асты тынлыгы.

Атлый торгач, авылдан бер чакрымлап үтелгәндер, олы юлдан бүленеп чыккан көяз сукмак үзенә ымсындырды... Күрәле, "Хәмит" чишмәсен уенчык иткәннәр. Улак тирәли купшы утыргычлар куелган. Тау итәгеннән бәреп чыккан суның көче үрелеп эчәрдәй фонтан булып бөркелә. Фонтан, агымга әверелеп, бетон божраларны тутыргач кына, көяз сукмак читеннән йөгереп, Агыйделгә төшеп кача.

Фәлән чишмәнең тәме төгән чишмә суына охшаган дип сөйләнгән кешеләргә ышанмагыз. Һәр чишмәнең үз тәме бар. Фазыл да, әнә, "Хәмит" чишмәсеннән үрелеп су эчте. Улак төбендәге яшькелт комташка карап ул аны үзе бораулаган артезиан чишмәләр суы белән чагыштырып карады. Адай авылында эчкән су тәме дә бар кебек, Уразай чишмәсенә дә тартым, Әлфинәләр өй түрендәге коеныкына да охшаган... Ләкин "Хәмит" чишмәсенең тәме үзенә бер аерым, тешеңне сындырырлык салкын булса да тамак төбенә зәйтүн мае кебек ягыла. Фазыл үзе бораулаган өч йөз коеның да суын хәтерли сыман. Йә, Хода, ник шулкадәр хискә бай соң бу хәтер?! Үзең рәссам, үзең музыкант, үзең әкиятче бит син хәтер... Хәзинәндә хатирәләр күбәйгән саен үзеңнең үткәнеңне ныграк сагына башлыйсың һәм синең бүгенге белән киләчәккә карата омтылышың сүрелә, канатларың салына, өметең кими. Әнә шул хәтер тозагыннан котылыр өчен килде инде Фазыл Актанышка. Каенлык авылына барып ике сусауны тыясы бар: анда—Әлфинә, анда—иң беренче бораулanган чишмә...

Кояш әкренләп тау башына менеп бара. Көн бөркүләнде, "Хәмит" чишмәсенең суы тиргә чыгып бетте. Егерме чакрымлы араны җәяү үтәсе килү теләге сүрелде. Изүне чишеп, жиңнәрне сызганып атласаң да юлда күләгә юк. Гадиерәк машина очраса кул күтәрергә иде исәбе. Ул арада, узып киткән кара "Ауди", илле метрлап үтмәгәндер, кинәт әкренләп арткы тизлеккә күчте дә Фазыл турысына житеп туктады. Машина унсигезенче регионнан иде.

Тәрәзәләрнең арттагысын төшереп татарчалатып дәштеләр.

—Бу юл Чаллы трассасына алып чыгамы?

—Чыга, әгәр борылышларны бутамасагыз.

—Короче, кәгазьгә сызып аңлата аласыңмы?

—Богадыга чаклы утыртып барыгыз. Аннан сезгә ерак ара калмый.

Берәр минут үзара киңәшкәннән соң, алдагы ишекне ачтылар. Һәм Фазыл бу яктагы юлларны әйбәт белгәненә сабыйларча сөенеп иномаркага кереп утырды. Шунысы сәер, алдагы рәттә буш урыннары була торып, өч егет арткы рәткә кысылышкан, өчесе дә кара күзлектән, лач-лач сагыз чәйниләр.

Кара тәрәзәләр ябылгач машина эчендә кич житкән кебек булды. Салкын һава өрә башлагач, Фазылның кәефе күтәрелде.

—Әгерҗедә бораулаганда Ижауга еш бара идек без,—диде ул караңгы тынлыкны өнәмичә.

Ләкин, беркем сүзгә кушылмады, унсигезенче регион егетләре Ижау дигән шәһәрне әйтерсең лә ишетмәделәр дә. Әллә жавап урынына инде—магнитоладан көчле музыка жибәрделәр. Юл өйрәткәндә Фазылга "уңга-сулга" диясе урынга бармак белән төртеп күрсәтергә туры килде.

Фазыл Богады урамына кергәч рәхмәтләр әйтешмичә генә төшеп калды. Һәм саубуллашу урынына:

—Шушы юл туп-туры трассага алып чыга,—диде.

Шофер егет, ярар, дигәндәй ияк чөйде һәм машинасын сүндермичә генә колонкадан салкын су алырга төште.

Кеше дигәнең рәхәткә бик тиз ияләшә. Егерме минут буе кондиционер жиләндә утырып, салкынча һавага күнегелгән. Урамга чыккач кояш үч алгандай, сулыш юлларын көйдерде, бит тиресе чатнарга теләгәндәй тартылды, беләкләрне пешереп, кайнар жил сирпелде. Фазыл, капылт килгән уйдан рухланып, колонка янына ашыкты. Шофер егет пластик шешәгә тутырып салкын су эчә иде инде.

—Братан, зур йомыш бар иде, бушка түгел, түлим.

—Ну,—диде теге, эчелеп бетмәгән суны жиргә түгеп. Ул иптәшләре өчен янадан тутырды.—Әйт, шабашканны.

—Ике чакрымда гына бер авыл бар. Иномарка белән кайтып күренәсе иде шуларга.

—Озак торасыңмы?

—Исәнмесез, дип әйтәм дә китәм.

—Күпме түлисең абзый?

—Мең сум...

—Ну, абзый, грунтовой юлдан, "Ауди" белән.

—Яхшы, өч мең бирәм. Башкасы юк, әле Казанга кайтырга кирәк...

—Йөз бакс, значит... Утыр әйдә, күрсәт авылыңны.

Ике жиләк

Элек Богадыдан Каенлыкка күнитек кимичә үтмәле түгел иде, дамба күтәреп чуерташ сипкәннәр. Фазыл белән Мәдияр кайчандыр Әлфинә белән Нәсфияне озата кайткан сукмак калын балчык астында, эзләрне юл күмгән.

Ике авыл арасы шул тиклем кыска, Фазыл хәтта Әлфинә белән күрешүне күз алдына китереп тә өлгермәде. Сораулар бер-бер артлы туа тора, жавапларын кем әйтер? "Утыз ел буе кайда йөрдең, ник моңарчы килмәдең димәсме? Күрешү белән күздән яшь бәреп чыкса нишләргә—кызгандырыр өчен елаган атлы булыр. Чукынып йөрмә монда, зимагур, дип куып чыгарса?.. Ире, балалары өйдә булырмы?.. Әллә кире борылып китимме? Ник соң мин әйтер сүзләремне кәгазьгә язып ятлап куймадым икән?"

Дамба авылга кушылган жирдән ерак түгел су күтәргеч озын мичкә бастырганнар. Белгечләр телендә ул "Рожновский манарасы" дип йөртелә. Чиләк-көянтә белән килгән кыз-кыркынга су алырга жайлы булсын дип,

улак рәвешен китереп торба чыгарып калдырганнар. Өч кеше—әби, апа һәм мәктәп баласы чиратлашып су алып торалар иде, аларның "иномарка"га бик исләре китмәде, үз өйләрендә дә машинадан гарык иделәр бугай.

—Суы тәмлеме соң?—дигән булды Фазыл.

—Без гомер буе сазлы коедан ләм сөзеп яшәдек,—диде әби,—намаз саен догадан калдырмыйм, шушы суны чыгарган кешеләргә, әйтәм ич, Ходай мәдәт-куәт бирсен, йөргән жирләрендә фәрештәләр канат жәйсен, бәхеттән аермасын үзләрен.

Фазылның авызы колагына житте:

—Амин! Рәхмәт, әбекәй!

—Ут беткән чакта сусыз утырабыз,—диде апа кеше.

—Безнең бүтән чишмәбез юк, шушыны мактап эчәбез инде,—диде мәктәп баласы.

Көянтәне иңнәренә элгәч тә әби кеше артына борыла-борыла карады, кем өчендер рәхмәтләр әйтеп елмаеп торуларының серен аңларга теләде бугай. Ләкин Фазыл моны сизмәде. Чөнки ул, әлеге мәктәп баласының йөзен күргәч, аның тавышын күңеленнән генә тагын бер кат янгыраткач, өнсез калды.

—Син Әлфинә түгелдер ич?

—Әлфинә—минем әниемнең исеме,—диде кыз, үртәлеп, ә минеке—Әлфия.

Кибеткә килгән саен: "Әнисенең кызы",—дип шаяртуларга күнегә алмады Әлфия. Сатучы кызы булма икән ул—аны бөтен кеше белә, таный, исеме белән дәшә. Житмәсә, бу абзый водокачка төбендә ачу китереп торган була.

Әлфиянең бәхет эзләр чагы житкән, быелгы жәйдә аның соңгы каникулы. Зур үсте инде ул—чиләкләре жирдән биек, әнисенең яшь чагындагы күлмәкләре ярый үзенә. Итәгенә ак челтәр йөгертелгән кыска жинле, күпертмә инсәле кызыл күлмәген Фазыл шундук танып алды. Аккан сулар кире кайтмый диләр, менә бит—утыз ел элек югалткан яшьлек кире әйләнеп кайтты. Хәзер аңа иярсең, Ниса кортканың нигезенә ак кирпечтән салынган "Мәхәббәт сараена" килеп керерсең...

Тимер улакта су агышы туктагач, авыл өстенә ишелеп үскән каен урманы тынып калды. Корылыкка сөенеп черелдәгән һәр чикерткәнең, күләгәдә хыялланып яткан романтик бәпкәләрнең, каенлык яравында сөенешкән һәр кошның, тугай өстенә күтәрелеп сайраган һәр тургайның тавышы аерым-ачык ишетелеп тора. Менә аларны кәккүк тавышы бүлдерде. "Күк-күк-күк-күк-күк..." дигән аңлаешсыз санау жәй уртасыннан ишетелә. Каен яраулыгына ияләшкән кәккүк сакауланган иде. Пыкрау бу—сайрар кошларның жыры беткән, ояларга сыймас балаларны ерак сәфәр алдыннан очарга өйрәтер көннәр житкән... Жәй уртасының сагышлы якка авышкан чагы...

—Ну, нәрсә эшлибез абзый, вакыт үтә бит?!

Шоферның ашыктыруына жавап итеп Фазыл тимер улактан шаулатып су агызды.

—Менә, братан, мин утыз ел элек бораулаган иң беренче чишмә бу! Шагыйрь әйткәндәй: үзем тапкан чишмәләрдән ятып су эчсәм—башка бер ни дә кирәкми!

Фазыл, улакны тутырып аккан суга йөзе белән чумды, яңакларын тидереп иркәләнде, агым эчендә күзләрен ачып карады, тончыга-тончыга йотлыгып эчте, тагын яңакларын тидерде. Шоферның йөрәге түзмәде, ул да кысрыклап улакка үрелде, Фазыл ни кыланган булса—шуны кабатлады. Суның жан ияләрен үзенә тарта торган магниты бар. Нормальный ике кешенең, чүмечтә су коенырга теләгән ата каз шикелле улак эчендә быкырдавы, машинада калган өч егетне дә битараф калдырмады.

—Мужики! Вы че в натуре?!—дип жиргә төшүләре булды, шофер егет аларга кушучлап су сибә башлады, барыбер улакта коенырга, бит кулларын юарга мәжбүр итте. Жәйге челләдә чишмә суы салкынын бернинди кондиционерлар да алыштыра алмый шул. Егетләр көрәйде, тавышлары ачылды, алай

гына да түгел, су чәчрәгән кара күзлекләрен салгач баягы братаннар яңадан гади авыл малайларына кайтып калдылар.

Шофер егет машинадан чәчәкле йөнтәс сөлге алып килде һәм башта Фазылга бирде.

—Авылны "сухой законга" калдырабыз,—диде ул суны туктатып.

—Әрәм-шәрәм итмәү кирәк анысы, но бу авыл диңгез өстендә утыра, кырык метр тирәнлектә генә, искиткеч калын су гаризонты...

—Во, мужик—крупнейщий специалист, ә? Син может безнең кешеләргә дә су скважинасы бораулап бирерсең,—диде шофер. Ул үзе рульдә утырса да әлеге өч малай алдында жаваплырак иде бугай.—Менә минем визиткам, сиңа бер айлык заказ бар.—Һәм Фазыл адреслы телефоннарны укыган арада ул өстәп куйды.—Ә "сто баксов" миндә кала, задаток өчен.

—Ярар, заказ булса безнең регионнар арасында чикләр юк, Чаллы юлында сөйләшеп бетерербез. Ә хәзер, әнә теге кыз кереп киткән өй янына барып туктыйк.

Әлфинәләрнең өе дүрт почмаклы гына иде, зурайтыр өчен арткы өлештә таштан коеп нигез күтәртелгән. Ишек алды иркен, өч торыклы абзар бәрәңге бакчасына кертеп салынган. Лапас түбәсендә әле генә чабылган печән күпереп ята.

Машина көтмәгәннәрдер, өй түрләренә килеп туктагач, урам ягына караган өч тәрәзәнең берсендә дә шәүлә чалынмады.

Ә күке сакаулыгын танырга теләмичә һаман санарга маташа.

Жилкапкадан керүгә Фазыл үзен сәхнәгә чыгып баскан артист кебегрәк хис итте, ана бу рольне ахырынача уйнап чыгарга кирәк иде.

—Әлфинә апа! Әлфинә апа!

Кычкырмады ул, ишегалдыннан чебен-черки кермәсен өчен корып куелган марлялы ачык тәрәзәгә якын килеп дәште генә.

—Кем бар анда?!—дигән тавыш урам ишегенең бусагасына чыгып басты. Исе китми генә, колачын жәеп, ишек янагына таянды. Каршында кем торганлыгын шундук төшенеп, боегып калды.

"Әһә, яшьлек миннән имтихан алырга килгән.."—Әлфинәнең беренче уе әнә шул булды.

"Өенә чакырырмы? Әллә танымаганга сабышырмы?"—Фазыл уйлары ишетелмәсен өчен иреннәрен кысты.

"Әллә, өйләнмичә, шушы гомер мине көтте микән? Язиләсе куып чыгаргандыр әле, аптыраганнан гына искә төшергәндер..."

"Беткән баш—беткән! Каравыл кычкыртып кочаклап алам хәзер."

"Үземнең дә сине эзләп китәрдәй чакларым күп булды, Фазыл!"

"Чегән хатыны юраган сүзләр сакау күке тавышында: баламны кеше үстерде, акча күп эшлим—үзем баемадым, егерме яшь тулганда миңа дигән хатын туар—димәк ул Әлфинә түгел... Яңадан бәхет эзләр өчен озын гомер кирәк... Яшьлегемнең ишек төбендә сакау күке булып басып торам, хәтта күрешкәч сөеклем белән сөйләшерлек тә хокукым юк..."

"Машиналарына чыгып утырсам кая чаклы алып китәр иде икән?"

"Менә бит инде ул—утыз ел буе тынычлап яшәргә ирек бирмәгән Әлфинә! Ник соң сине алып китеп булмый?"

Әнисенең авызына су капкандай телсез басып торуын күпсендеме, Әлфия йөгереп чыкты. Печәнгә барган жирдән чеме белән жир жиләге жыйганнар икән. Әлфинәне биленнән кочаклап ул, бусагадан төшмичә генә, жиләкле кулы белән ишек янагына таянды. Читтән карап торган кеше әлеге күренешне, ике балалы тигез гаилә учагын саклап калу өчен, амбразура каплау дияр иде.

—Инәкәй, нәрсә кирәк боларга? Әле бая гынак улактан су эчеп калганнарые.

—Үзләреннән сора, кызым.

—Алып куйган коньягыгыз юкмы?—диде Фазыл, баласы алдында әнисенең хәлен жиңеләйтергә теләп.

—Безнең авыл халкы аракы гына эчә, шуңа күрә инәкәй коньяк алып кайтмый, әйеме, инәкәй?..

Әлфия, әлеге текә егетләрне үзе артыннан ияреп килгәннәр дип уйлады, шуңа күрә кылтаеп сөйләшүе иде.

—Әйе, юк бездә коньяк. Тотмыйбыз...

—Актаныш универсамында бар.—Һәм кыз иреннәре белән үрелеп кенә кулындагы җиләк бәйләменнән берне өзеп капты.

Артык җәелеп, буш сүз уйнату—һәр мизгеле кеше язмышына торырлык минутлар белән шаяру булыр иде. Уйлар кисешкән җирдә вакыт үлчәме югала икән. Фазыл ике көзгедән бер сурәтне эзләгән кебек әле унга, әле сулга күз ташлады... Эре җиләк—үсә торыр, кечкенәсе—пешә торыр... Кайсыгыз Әлфинә, кайсыгыз Әлфия соң сезнең? Югалган елларның кай ягында басып торасыз? Алар үзара сөйләшкәндә тавышлары бер чордан икенче чорга күчә. Әлфиядә унҗиде яшьлек Әлфинәнең яңгыравык тавышы; Әлфинәдә ул тавыш бераз басынкы, моңлы, бишек җырыдай ягымлырак. Әлфия әнисенең яшьлеген кабатларга тырышыпмы—соргылт чәчләрен иңбашына төшереп кистергән һәм сандык төбендә утыз ел буе сакланган күлмәкне кигән. Әлфинә исә, кызына яшьтәш булырга теләгәндәй, маңгай чәчен тигезләп алга тараган, тез башына тияр-тимәс чия кызыл сарафан өстеннән юка кара жилет кигән. Әлфиянең иреннәрендә сытылган жиләкләре—Әлфинәнең юка иреннәренә орынып үткән иннек төсендә... Менә шушы инде ул мәхәббәтнең мәңгелеге!

"Нишләдегез инде анда?!"—дип әтиләренең чыгуына: "Коньяк сорап килгәннәр!"—дип, Әлфинәнең күздән югалуы булды.

Әгәр шушы минутта Әлфинә: "Мәктәп елларымда сөешеп йөргән егетем эзләп тапкан..."—дип сөенсә, йә булмаса Фазыл: "Мин Әлфинәдән башка яши алмыйм!"—дип, хискә бирелеп ялгыш әйтеп ыргытсамы—бер кеше бәхете өчен дүрт кеше бәхете шундук чәлпәрәмә киләсе иде. Мәхәббәт ул табигатьнең үзе кебек көтелмәгән хәвефле афәтләрдән тора. Уйламаган җирдән зилзиләләр кубып, гомер буена тапкан-табынганыңны туздырып, йортсыз-җирсез калдырырга, балаларыңнан, таянычыңнан мәхрүм итәргә мөмкин. Гадәттә, ул афәт гаилә башына бер минутлык ләззәт сыйфатында, йәисә гафу ителмәслек сүз рәвешендә килеп керә. Табигать стихиясеннән үзгә буларак, гаилә башына килгән гарасатны туктатып калырга мөмкин.

—Коньяк кирәксә, Байсар кибетенә сугылып карагыз!—һәм әти кеше, тамашаны таратыгыз, дигәндәй, Казан юлына таба күрсәтте.

Бар да бетте. Фазыл тагын ачы хакыйкать белән бергә-бер калды. Елларны күчереп, фасылларны бутап, сәгатьләрне алыштырып бары тик җәзалар өчен генә килеп киткән ләззәтле күрешү йөрәккә тагын җәрәхәт өстәп югалды. Әтиләре белән кабат күзгә-күз очрашмагаем дип, борылып карамаган иде Фазыл, караса яраган икән—ике тәрәзәдән ике Әлфинә аңа кул болгап калганнар иде...

Мин риза

Нигезенә чаклы янып төшкән туган йорт урынында түбә корырга күнеле бармады Фазылның. Аңа Яңа планнан чирәмле урын тәкъдим иттеләр. Хуҗалык җитәкчесе яшьтәш егет булып чыкты, ун ел буе күрше классларда янәшә укыганнар иде. Су эшләре буенча универсаль белгечнең күз алдында йөрүенә сөенде генә ул. Яңа урын үсә торган урамның читеннән эләкте, ун якка билгесез күршеләр киләчәк икән.

—Сул ягымда кем? Нигезен таштан коя, коттедж салдырта ахрысы?

—Әнә, үзе килә, сорарсың,—диде житәкче.—Пенсиягә чыкканына унбиш ел үтте, әле һаман председатель булып сөйләшә. Ичмасам, миңа үч итеп идарәгә сайлап куялар, утырыш саен аягүрә басып: "Элек болай иде, элек тегеләй иде",—дип, котыра инде. Әйтерсең лә СССРны мин тараткан... Ярар, вакытояк сорауларың булса мин конторда көтәм. Ә моның белән бик күрешәсем килеп тормый. Президентлыкка сайланырга теләгән иде әле ул. Юаш Нотфул-

ласы белән бөтен районны бетереп имза җыеп йөрделәр... Кандидатурасын теркәмәгәннәр—яшен күпсенгәннәр... Инде кеше күзеннән гарык дип, Яна планга качты.

Әйе, яшь алмагачларга тлә агуы сипкән җирдән эшен ташлап, кулларын юеш чүпрәккә сөртә-сөртә килүче кеше Сакал Шәйхи иде... Киптергәннәр абзыйны—элеккеге пәһлеванлыгы коелып беткән. Пеләше белән тоташкангамы—маңгае шыксыз кин булып күренә. Бер ягыннан терәве төшкән—авышыбрак атлый. Ул, колактан-колакка гына сөйләшергә теләгәндәй, якын ук килеп басты. Туры караса, үтеңне сытарлык күзләре генә элеккечә.

Шәйхи, бөтен яшьлеген берьюлы исенә төшергән хыялый кебек, бер мәлгә инрәп торды да Фазылны кочаклап алды.

—Нихәл, күрше, күптән күренгәнең юк, агайне... Теге кая ашыга?—диде ул "Нива"га утырып киткән председательгә таба күрсәтеп.—Деловойланып кыланган була, үзенең кассасында сукыр бер тиен кереме юк. Елына өчәр миллион табыш китерә торган хужалыкны бомж хәленә төшерделәр. Үләт базын хайван белән тутырдылар, үстергән икмәкләрен сатып алучы юк, сыер савучылар колхоз сөтен урлап май язалар—өендә кәжәдән гайре савымлыгы булмаган Һәдия әби колхоз базарында каймак сатып ята, пнимаете так...

—Шәйхетдин абзый, безнең авылда гына түгел, бөтен сферада шул хәл.

—Мин председатель булып эшләгән чорда алай түгел иде.

—Элекме?! Докладларыгызда мактанган саннарны әле дә хәтерлим... Колхоз миллионер чакта мең моржалы авылыбызда жиде телевизор, ике мотоцикл, бер "Москвич" бар иде—анысы да отышка чыккан машина... Ә бүген—капка төбе саен машина, бүлмә саен телевизор. Байлык шәхси кулга күчте...

—Ну бу бардакны кемдер туктатырга тиештер ич инде, пнимаете так?

—Үзе туктый ул. Житмеш ел буе партиядән куркып эшләгән халык иреккә чыкты. Ял итеп арыгач эшләрләр әле.

—Жимерелеп беткәчме?

—Әйе. Иске урында янаны төзер өчен иң әвәл жимерергә кирәк. Менә сезнең белән безгә яна планнан урын бирделәр—жимерәсе юк,—дип Фазыл сүзне икенчегә бормакчы булды.

—Укыдым, газетага интервью биргәнсең, пнимаете так. Үзең язмагансындыр инде?

—Юк, бер журналист белән Актаныш гостиницасында сөйләшеп утырган идек. Язганын беренче сездән ишетәм.

—Янадан укы әле син аны. Анда теге су скважиналары өчен проектлар эшли торган оешма, ничек әле... "Татводпроект"ның генераль директоры өстәмә фикер белән чыккан... Шәп әйткән, слушай. Казанның ике ягында—Столбище белән Урман арты бистәсендә искиткеч көчле су катламнары бар икән.

—Һәм төче су дигәндер...

—Әйе, пнимаете так, әгәр хөкүмәт акча бирсә, Казанны йомшак су белән тәэмин итәрлек коелар бораулыйбыз дигән, торбалар буенча китерергә. Аннан соң бөтен Казан халкы чишмә суы гына эчеп ятачак икән.

—Гомердә тормышка ашмаячак ул хыял.

—Нишләп алай дисең, Фазыл, пнимаете так?..

—Беренчедән, Идел суын эчерергә өйрәнгән "Водоканал" каршы чыгачак. Икенчедән, шәһәр халкы сихәтле су күрсен өчен акча бирергә тиешле кешеләр үзләре күптән инде чишмә суы гына эчә, таш пулатларына, бакчаларына да хәтта икешәр кое бораулаталар. Һәм өченчедән, Шәйхи абзый... бер күрешүдә үк бөтен проблемаларны илаһи-уптым сөйләшеп бетермик, минем китәсе бар.

—Да, да! Пнимаете так, ну син бит инде яна нигезендә эшне кое бораулаудан башларсың?

—Туры килер ахрысы.

—Мине дә онытма, яме! Полиэтилен торбалар әзерләп куям. Сезне

үстергәндә әниегезгә бик нык ярдәм иттем мин. Утырган казыгыз иске өегезнең мүк арасыннан башын тыгып кычкыра торган иде. Динәгә процентсыз ссуда бирдек.

—Әни шул ссудага колхоздан бура сатып алды—аскы эргәләре каеннан, калган өлеше усак белән юкәдән. Бүрәнәләре куышланып өйне кырмыска басты... Ну, озак яшәмәдек, ссудагызны түләр өчен әни өйне сатарга мәҗбүр булды...

—Иске өйләр күп иде. Урманны санап кына бирделәр.

—Аның каравы Сәрвиназ апага шыңгырдап торган нараттан бушлайга алты почмаклы өй салып бирдең.

—Бер кулда бармаклар да тигез түгел, Фазыл агайне.

—Ярар, Шәйхи абзый, мин үпкә саклап түгел, сүз уңае гына телдән ычкынды. Әйбәт күршеләр булырбыз без...

Ул арада Фазылның куенында кесә телефоны уйнады. Наил Кадыйрович шылтырата: Яңа байлардан заказлар күбәйгән, бригаданы җыярга куша. Тавышы аерымачык ишетелгәч, сөенеп куйды әле Фазыл, Казан белән элемтә әйбәт, димәк, монда яшәргә була! Кирпеч кайтартырга кирәк.

Фазыл тукталышка җәяү төшәргә булды, авылдашлар танып сөйләштереп, вакытны алмасын дигәндәй, ул юл белән янәшә салынган сукмактан атлады. Шәле тукталышын базар мәйданы иткәннәр. Кафе, ашханә, бистро, сәүдә киосклары тезелешеп, ерак сәфәргә чыккан шоферларны, пассажирларны тәүлек буе көтә. Төн узганчы куна калучы машиналар өчен киң мәйдан җәйгәннәр, ләкин ул мазутка лыкырдаган. Инештән су алып килеп кабиналарны юа торгач, аяк асты июль челләсендә дә кипми. Фазыллар ландыш җыярга төшә торган урман тоташ бәдрәфкә әверелгән. Фу!..

Бораулаучыларның төшке ашка туктый торган чагы лабаса бу...

Фазыл бистрога кереп, берәр таяк шашлык алып, Шәйхи белән күрешү тәэсиреннән калган юшкынны юып төшерергә ниятләгән иде.

Мажаралар күбәйде. Балачакта, яшьлектә күргәннәр, аралашканяшәлгәннәр, югалганнар-сагындырганнар сөенечле һәм көенечле мажарага күчеп яңадан әйләнеп кайта тора. Ауга чыккан мәргән кебек гел эзләнеп йөргәнгә шулай микән? Әнә, икмәк сата торган киоск белән янәшәдә Фазылның теге яшел вагоны. Ачык тәрәзә астына буйдан-буйга "китаплар" дип татарчалатып, зур итеп язып куйганнар. Баскыч төбендәге өстәл өстенә елкылдап торган китаплар җәелгән. Кояш астында калҗайган юка тышлыкларын юл җиле уйната. Ә өстәл артында, кайчандыр Әмир, Суфия, Язилә, Мәдияр һәм әлбәттә Фазылның үзеннән калган тимер аяклы табуреткада, Гөлсөяр китап укып утыра иде. Ул шундый мавыгып һәм ышанып укый, хәтта яңа гына килеп туктаган "Газель" йөртүчесенең ашханәгә барган жиреннән онытылып, баласына китап сайлаганын да сизми. Фазылны да сизмәде.

—Мина мәхәббәт турында берәр китап кирәгие...

Егетнең тавышы укый торган әсәрдән яңгырады дип уйладымы, Гөлсөяр кинәт кенә кулындагы китабының тышына күз салды. Шунда гына ул янында кем торганын аңлап, табуреткадан күтәрелде. Кыска итәген китаплы өстәл генә каплап торган икән. Сул кулы ак блузканың төймәләрен санап чыкты, уң кулы итәген төзәткәләде. Үзен күпме генә тыныч тотарга тырышмасын—барыбер сөенечен яшерә алмады.

—Хәтерсез кешеләрнең йөрәге тазадыр ул, әйеме Фазыл? Уйламый, эзләми, сагына белми, тик яши шунда...

—Мин бу вагонны теләсә кайсы базарда күрсәм күрермен, тик менә шушында очратырмын дип һич уйламадым.

—Үзең калдырып киткән жирдән эзләрләр аны. Айдан артык вакыт үтте ич инде... Нихәл соң син?! Сызлауларың басылдымы?..

—Рәхмәт сина, Гөлсөяр, аякка бастырганың өчен рәхмәт!—Һәм Фазыл тизрәк акланырга теләгәндәй тезеп китте.—Бораулау агрегатын жыйнап, көйләп, бригаданы яңадан туплаганчы шактый үтте шул. Аннан соң эш күрсәтеп карадык.

—Алайса, Әлфинәңне барып күргәч жае килмәде әле.

—Бардым. Күрдем.

—Гел сине көтеп яшәгәнме?

—Каенлыкның күкеләре сакауланган инде...

—Әйбәт булган, дисәм, үпкәләрсең микән?

—Аның каравы күңел тыныч хәзер. Күңел тыныч, киләчәгем—ачык.

—Ә бүген авылына Хәмдияңне эзләп кайттыңмы? Рәхәт яшисең син... Яшь чакта сөйгән кызларына кунакка йөрисең.

—Сине эзләп кайттым.

—Ышандылар ди. Менә синең бу китапны күргәнең юктыр әле. Сезнең авыл турында ул. Марат Мөлеков язган. Ишеткәнең бармы шундый кешене? Тарихчы, жәмәгать эшлеклесе, ТИҮ президенты, депутат булган.

—Беләм, беләм, мин укырга кергәндә ул безнең мәктәп директоры иде.

—Әйбәт булган! Китапта әйтелгәнчә, Харис Якупов дигән зур рәссам сезнең авыл кешеләре турында тулы бер альбом ижат иткән.

—Хәтерлим мин аны. Рәсемнәрендә безнең иске өй бар.

—Әйбәт булган! Вәт, альбомны ул "Көчле кешеләр" дип атый... Ә көчле кешеләр хәйләкәр булмый, Фазыл, инде әйт, туган авылыма болай гына, сагынып кайттым диген.

—Сугышсыз-нисез генә егерме сутыйлы дәүләт яулап алдым. Мин анда патша сарае салам, жәннәт бакчасы үстерәм. Һәм син алмагач күләгәсендә китап укып утырырсың... Әйдә, су коенырга киттек. Көн озын әле. Казанга кич кырын китәрмен.

Фазыл Гөлсөярга кире уйларлык чара калдырмады, өстәлдәге китапларны күчкә өеп, вагонга ташый башлады.

Китап сәүдәсенең үз өстенлекләре бар. Менә хәзер Гөлсөяр вагонны бикли дә китеп бара. Сатучысы кая моның, дип, ник берәрсе тавыш чыгарсын... "Кибет басу" дигән афәт тә китап кибетенә кагылмый. Янап, акча дәгъвалап йөрүче текә малайлар синең яннан көлеп кенә үтеп китә. Салым инспекциясе ташламалар бүләк итә. Дөрес, әлеге урында бер тапкыр Гөлсөярнең китап әржәләрен тикшереп вагонны актарып чыктылар, икътисадый жинаятьләр бүлегеннән килгән ике егет сурогат аракы эзләп йөргәннәр. Гафу үтенделәр... Кайвакыт мотоциклга төялеп, тукталыштагы сәүдә мәйданына авыл малайлары килә. Алар инде Гөлсөярне танып белә, шуна күрә "бистро"га кергәнче, китап өстәле кырында телләренә салынып торалар.

"Их, менә бу китапны укысаң иде..."

"Чө! Акчан житсә укы!"

"Урлыйк без аны, өчәүләшеп укырбыз."

Малайларның кем турында сөйләнгәнен чамалый Гөлсөяр, ләкин аңламаганга сабыша. Курыкмый ул алардан, котылыр өчен бер эндәшү житә үзләренә.

"Ягез әле, егетләр, сөйгән кызларыгызга бүләккә берәр китап алып жибәрегез!"

Һәм матайлылардан жилләр исә.

Болынлап бүлеп бирелмәгәч, халык каян туры килсә шуннан печән ташый, печән өсте икешәр айга сузыла. Мишә буенда су коенып ятучылар бар икән—алар авылныкылар түгел, кунакка кайтучылар булыр.

Яр буйлап, агымга каршы атлый торгач, су коенучылар, балык тотучылар күздән югалды. Сайрар кошлар туктагач, чикерткәләр хужа булып калган—чабылган болынлыклар сызгырып тора. Гөлсөяр биек үкчәле түфлиен кулына тотып яланаяк атлады, чабылган камыл, тояк чокырлары, чалгы урап узган шайтан таяклары тиз барырга ирек бирми, Фазыл кулындагы әбәтле пакетны куеп торып аны көтеп-көтеп ала... Мишә борылышындагы ярыматауга килеп житкәч, Фазылга аллә нәрсә булды: гөлжимеш куакларыннан өлгермәгән гөләп өзеп капты, шомырт агачына үрмәләп яшел тәлгәш алып төште, сөзәк ярдан аска таба мәтәлчек атынып кабырчыклы комда аунады, сандалыйларын ике якка ыргытып, маймычлары өерелеп йөзгән су читләтеп йөгерде... Аннан соң

яр өстенә менеп, шомырт куаклары белән кысрыкланган аланга чыкты.

—Менә монда "пионер бүлмәсе" өчен зур палатка тора иде. Бу жирдә әләм колгасы, вожатыйлар чатыры... Ашханә өстәлләре мин басып торган жирдә,—диде Фазыл, пакеттагы ризыкларны ашъяулык өстенә җәеп.—Беләсеңме, Гөлсөяр, иртәнге йокыдан безне нәрсә уята иде?

—Пионер бургысы!

—Аппетит уята!.. Ә бургы кычкыртканда без инде ашханәдә шкаф актара идек. Көне буе һавада, кырда эшлибез, су коенабыз, үсә торган чак—ашау төткәрер хәл юк... Шуннан калгандыр инде, ач карынга хыяллана да алмыйм.

—Аңлашылды. Ләкин шәрабне су коенып чыккач эчәрбез.

—Сал халатыңны, кызынып кал. Тагын берәр сәгатьтән черкиләр котыра башлый, алар монда шундый усал... Пионер лагерьлары беткәннән бирле кан эчәргә кеше таба алмыйлар...

Гөлсөяр судан курыкмый, Чаллыда җае чыккан саен сәүдәгәр кызлар белән жыелып "Нарат" шифаханәсенең Чулман ярындагы комлыгына коенырга йөрделәр. Кирәксә, дулкыннарны колачлап сәгатьләр буе йөзә ала. Ләкин Фазыл белән коенганда ул ярышып йөзәргә теләмәде. Шомыртлы текә ярлар арасына юл салган Мишә елгасының агымы тымызык, дулкыннары вак булгангамы—ниндидер шомлылыгы бар сыман. Ул әле Гөлсөяр өчен яңа елга, төсе томанлы зәңгәр, төбе чоңгыллы, ярлары—аулак... Ләкин суның җылылыгы, йомшаклыгы, чисталыгы һәм Фазылның юк-бар хәрәкәт ясап, тәнгә орынып сәбәп уйлап табуы, әлеге шомны әкренләп онытгырды.

Фазыл сөенә-сөенә йөзә. Чумып беркавым югалып тора да Гөлсөярнең аяк арасыннан килеп чыга, кулларын чәпердәткән атлы кыланып кызның ботларына кагылып үтә, бергәләшеп йөзәргә теләгәндәй, биллэреннән кочаклый, муенына, иягенә сөлек булып ябышырга тели, иреннәренә орына. Гөлсөяр карышмый, чәрелдәп кычкырмый, киресенчә, Мишә гипнозына бирелеп, һәр кыланышка теләктәшлек кылып, очрашу уенына ияре. Ул монда үз иреге белән килде. Су өстендә күрешү кагыйдәләрен алдан ук сизенеп, белә торып, ризалашып, көтеп һәм эзләп килде. Ул, сыену-назлануларны тыймыйча, һаман саен Фазылны газаплап, моңарчы эзләп тапмаганы өчен жәзаларга тели... Ләкин бу жәза уеннан узды. Гөлсөяр үзе дә иләсләнде, карышу көче кимегәннән кими барды, Мишә суы әкренләп кайнарлана төсле тоелды аңа. Һәм ул, кабаланып йөзеп килгән уңайдан, комлы ярга чыкты. Бу ләззәттән качып котылырга теләп, йөгерергә иде исәбе. Ләкин Фазыл аның аякларына тышау булып уралды. Кыз егет өстенә ауды. Назланып орынулар көрәшкә әверелде. Куллар гына түгел—сүзләр дә көрәште.

"Кинәндең минем белән бүген, дәшмәгән саен..."

"Гөлсөяр, бу хәтле ялынуга шомырт агачлары авышыр иде инде..."

"Агачларны давыл гына ега."

"Мин сине монда белеп алып килдем. Яңадан яши башлыйм. Син миңа кирәк..."

"Шатлыкның ялганы күп була. Ышанмыйм."

"Без бүген кавышырга тиеш."

"Болай түгел бит инде!"

Сүзләр көрәшкән арада Гөлсөяр тәнендәге су коену әсбапларының элмәкләре сүтелеп беткән иде инде. Бу хәл кызны бөтенләй каушатты.

"Кавышу түгел, көчләү бит бу!"

Һәм Гөлсөяр, ике кулы белән юеш ком актарып алып, үзенең битләренә сөртте, тагын алып күкрәгенә сылады, иреннәренә якты. Ике арада саз исе таралды, комлы чырайда ике күз генә нәфрәтләнеп калды... Фазылның гайрәте сүнде, куллары хәлсезләнде, гәүдәсе дерелдәде.

Алар көрәш барышында актарылып беткән ком өстендә ярты сәгатьләп чалкан яттылар. Каршы ярдан күзәтеп тормагайлары дип, кыз низаглы әгъзасына кайнар ком сыпырып өйде. Аннан соң алар яңадан парлашып су керделәр. Ләкин бу коену түгел—юыну иде инде. Фазыл киемсез калган Гөлсөярне үз куллары белән юды. Ике арада гамәлгә сыймаслык берни дә

булмады кебек, шулай да кызның саф күңеле уяулыгын югалтты, егет кодрәтеннән әсирләнде, буйсынырга теләде. Жинелмичә жиңдерде...

Фазыл озаклап юар өчен кушучына суны әз-әзләп алды. Мишә исемена сыенып, никадәр чишмә килеп туктаган бу ярыматауга. Һәр чишмә кулга үзе керә. Мине Гөлсөярнең муенына сип, мине—иңбашына, билен коендыр, күкрәгенә чәчрәт, кендеген үзем юам дип, кулга кергән берсе юмалап тора. Кыз балага су күбрәк кирәк бу дөньяда... Ул самавыр куя, аш пешерә, бала коендыра, кер юа... Чишмәләр кызлар өчен кирәк...

Кайтыр юлда, үпкәләшмәгәнне раслау өченме, әллә ком өстендә кабынган утны сүндермичә саклар өченгәме, алар туктап-туктап үбештеләр. Үбешкәннән соң Фазыл аны куеныннан чыгармыйча торды, кызның муеныннан тәмле конфет исе килә иде. Кыз егетне култыклап барды. Аяк астында каты камыл туры килсә кулына асылынып калды.

Вагонга кайтып кергәч, нишләргә белми аптыраган Фазыл китаплар актара башлады. Әле берсен, әле икенчесен укып карады, тагын эзләнде. Әйтерсең лә, кайсыдыр ки нәсихәтле китапка иртәгесе көн өчен кирәкле киңәш язылган булырга тиеш иде.

—Сүтеп жыйдың син мине Фазыл.

—Югалган көмеш алтынга әверелә, мине югалтма.

—Бүген синең тавыш белән йорт иясе дәште.

—Вагонның йорт иясе юк. Өй салып чыгарбыз.

—Ярат кына син мине Фазыл. Артыгын сорамам.

Тагын көрәш башланды. Ләкин бу юлысы көч кулланып түгел. Иреннәр, күзләр, ияклар, куллар үзара сүз куешып, Гөлсөяргә ләззәт һөҗүме оештырды. Мондый һөҗүм мускул көченнән күпкә көчлерәк иде. Кыз барыбер нык торды. Салкын һава эзләп еш-еш сулады, егет кулы ни эшләсә—шуны кабатлады, күзләреннән яшь чыгарып ынгырашты. Мәгәр аягыннан егылмады.

—Йә Хода! Каян килә соң сина шушының чаклы карышу көче?! Әйдә, алайса үзең көчлә мине, Гөлсөяр! Без бүген кавышырга тиеш. Ишетәсеңме, бүген?! Юк икән, бүтән беркайчан да...

—Юк. Әйе. Ну мин болай кавышуны теләмим. Кешечә гариза бирик. Үзәк загска барып. Минем бик күпләргә күренәсем килә.

—Зурдан кубып никах тантанасы кичәргә оялам. Минем бәхетем өчен генә саклангансың икән—исбат ит бүген. Иртәгә үк авылга менеп язылышабыз.

—Юк! Болай түгел... Китаптагыча кирәк...

—Димәк, ялганың бар. Куркасың.

—Ирештермә, үртәмә! Юк дигәч—юк!

Гөлсөяр Фазылны ачу белән этеп жибәрде.

—Безгә бүген бер түбә астында калырга ярамый.

—Мин беркая да китмим. Иртәгә шылтыратам да, Текә Вәли килеп алыр әле.

—Алайса мин китәм. Китаплар калсын, укып чыккач китапханәгә тапшырырсың.

—Озатып куям.

—Юк! Мә, вагон ачкычыңны ал.

—Шуны бел Гөлсөяр, син мина бик кирәк...

Жинелчә сумкасын иненә асып, зурысын беләгенә элеп, чыгып китте Гөлсөяр. Вагон эче кинәт ятимләнеп калды. Никтер, сабыйларча үксеп-үксеп елыйсы килде Фазылның, тик күз яшьләре чыкмады—Мишә суында юылып беткән иде ахрысы. Иртәгә дигән киләчәкнең мәгънәсе калмады. Көне буе июль кояшында кызган вагон эчендә тәмуг уты йөри. Мордарлыкка илтә торган бушлык иде бу. Ләкин әле сакау күке саный алмаган еллар һәм чегән хатыны юравының рас килеп бетмәгән шартлары бар. Шуларны күрер өчен булса да яшәргә дә яшәргә!

Юл читендәге заправка станциясенә авыл тракторы килеп туктаган иде. Солярка салган арада Фазыл хәлне аңлатып бирде. Тракторчы егет аны танымаса да бу якларны белеп сөйләшүеннән авылдаш дип кабул итте. Бәхет

эзләп арыганнар берәм-берәм кайтып егыла ич туган авылга, бу да шуларның берседер инде, диде. Яшел вагонны "Яңа планга" китереп, тагылмадан ычкындыргач, акча да алмады. Астагы урамда тора икән, кирәк чакта чакырырга кушты.

Сакал Шәйхи аңа дүрт бүкән бирде. Һәм Фазыл, яшел вагонны шул бүкәннәргә утыртты. Ә салдырылган көпчәкләрен тракторчы егеткә биреп жибәрде—бөтенләйгә!

Төн уртасында, калай суынып, вагон эче яраулангач кына изелеп йокыга китте Фазыл. Ул таң әтәчләре кычкырганны да ишетмәде, "Яңа план" аркылы көтү киткәнне дә тоймады, йоклады да йоклады. Кояш түбәгә менеп кыздыра башлагач ул Мишәгә су коенырга ашыгучы малай-шалайлар тавышына уянып китте. Тәрәзәдән караса, ни күрсен—икесе зур сумка бавын тоткан, дүртесе Гөлсөярне житәкләгән. Вагон ишеген ачтырдылар, апаларын баскычтан этеп менгезделәр, сумканы калдырдылар да читкәрәк китеп бастылар. Ни белән бетәсен көтәләр, янәсе.

"Низам белән Шәмсия кавышты",—дип уйлап куйды Фазыл сөенүен тыя алмыйча.

Гөлсөяр бу төнне кафеда эшләүче кызлар янында үткәрде. Каядыр китеп күздән югалырга исәбе юк иде аның. Пешекчеләргә артыгын сөйләп тормады ул—Гөлсөярнең хәлен азмы-күпме беләләр алар. Ләкин төнгә каршы чыгып качуын ошатмадылар, Фазыл абый кебек кешене бүтән таба алмыйсың түлке, диделәр. Иртән су коенырга барышлый, әниләре янына тәм-том эзләп кергән малайлар, Гөлсөярне "Яңа планга" чаклы озатып куйдылар.

—Мин риза...—диде Гөлсөяр һәм әле йокы жылысы суынып та өлгермәгән урын өстенә барып утырды.

Фазыл ишек ачып малайларга бер уч акча сипте:

—Миннән сезгә кияү бүләге тиеш!..

2000-2002 еллар.

Флера Гыйззәтуллина

Милли моң

Сиртмәле тирән коелар табып,
Без элек шигырь сугара идек.
Тупырдап торган шигъри атларны
Кое буена тугара идек.

Моң коелары коргаксып килә:
Заман сулышы йончыта моңны...
Моңсыз—коега чүп-чар ыргыта.
Моң иясенә—юк хәзер тынгы.

Рухи азыкка юк кадер-хөрмәт,
Илһам бакчасы ташландык хәлдә!
Байлар миллиардлап акча туздыра
Шагыйрь—тиенен санаган мәлдә.

Доллар давылы тауларны ишә,
Моңсызлык өскә боз булып ява.
Шагыйрен санга сукмаган дәүләт
Әҗәленә дә табалмас дәва.

2

Сиртмәле тирән коелар табып,
Без элек атлар эчерә идек.
Тирәнлекләрнең серен төшенеп,
Эчкерсез ләззәт кичерә идек.

Хәзер кан төсе белән офыкта
Әҗәл хәбәре—яңа көн туса,
Рухыннан язган Ил-йорт кайгысы
Һәръяклап тотып йөрәкне кыса.

Җир шарын кыса—доллар колының
Акылын җуйган нәфес хатасы.
Чиген югалтып кысыла шунлыктан
Гади халыкның гомер картасы.

Флера ГЫЙЗЗӘТУЛЛИНА–*шагыйрә, "Чишмә юлы", "Сәлам хаты", "Йөрәгемдә шаулый карурман" һ. б. китаплар авторы. Казанда яши.*

Шул чиксезлектә, хаклык таптырып,
Ялангач хәлдә милли моң гизә...
Ераста калган ат кешнәүләре,
Исемә төшеп, үзәкне өзә.

Сорамагыз!..

Син бәхетлеме?—дип сорамагыз!
Үз бәхетем өчен җан атмыйм мин:
Җир тирәли очкан чал бөркетнең
Канат кагышларын кабатлыйм мин.

Яр сөйдеңме?—диеп сорамагыз!
Күрдегез бит... сөйдем... Яшермәдем:
Җырга салып инде көен көйлим
Бәгыремне өткән яшеннәрнең.

Ник елыйсың?—диеп сорамагыз!
Елыйм җаным шигырь яралтканнан.
Язып туйдыңмы?—дип сорамагыз,—
Җыр языла—милли яралардан!

Тау башында уйдык-уйдык җиләк пешә,
Янып-пешеп печән чабам үзем дә мин...
"Ah, язмыш!"—дип, уелыплар китәмен дә,
Чалгы кайрап тернәкләнәм—түзем лә мин...

Тау башында ак каенлы урман үсә.
Кылганнарны тибрәлдереп җилләр исә.
Урманга тиң язмышны син иңләп кара,
Гомереңне сагышларда җилгәрмичә...

Ак каеннар җырын җырлый-җырлый,
Көннәр буе карурманда йөрдем.
Тузып кара көйгән гомеремә
Җырларымдай ап-ак өмет өрдем.

Әмма милләтемнең кайгыларын
Каенлыкта адаштыралмадым.
Яңгырлардан ышыкланыр өчен
Яфраклардан шалаш коралмадым.

...Инде аңлатыйм дип, милләтемә
Бу кайгыга ничек чыдаганым...—
Күкрәп яуган яңгыр асларында
Үз ирегем белән чыланамын.

Йөрәк җыры

Бала табып, бәхет багып, дөнья танып
Туган җиргә хис эрләдем, көч эрләдем.
Балаларны эш белән тик сихерләдем:
Бернинди дә тылсым суы эчермәдем.

Балаларым алтын акыл... алтын куллы...
Ләкин илдә эш юк хәзер алар өчен—
Урамнарда өер-өер "банда" үсә
Балкып торган акылларын талар өчен.

Балаларны мин талашка өйрәтмәдем:
Миннән күчкән хис назлады йөрәкләрен.
Байлык өеп, тотсалар да күпме урын,—
Талаучылар ишетми шул йөрәк җырын.

Эшсезлектән мескенләнгән ач баланы
Гомерлеккә сихерләрме рухи азык?—
...Инде менә бурыч тулим балаларга
Шигырь язып, Язмыш язып... Һуштан язып.

Чиксезлек

Иреккә тугрылык—Ватанга тугрылык!—
Юл яру киләме көченнән?
Мәйданда "Ирек!"— дип
Тилмергән көннәрнең
Минуты чыкмады исемнән.

Милләткә тугрылык—вөҗданга тугрылык!—
Онытмый яшәрбез йөзгәчә...
...Бер милләт кенәме?
—Вөҗданың барла!—дип,
Безгә бит күк дәшә, Җир дәшә.

Безгә Хак Тәгалә ышанып тумыштан
Шагыйрьлек сәләтен йөкләгән.
Шигырьгә тугрылык—газапка тугрылык!
Кем безнең газапны чикләгән!?

Тәлгаткә

... Син киткәндә җирдә—ак кыш иде.
Ачы буран иде—ак буран!..
—Кая куйдыгыз!—дип, мин бүген дә
Бураннардан сине таптырам.

Хәтеремә сарган ак буранда
Җилферди күк аклы күлмәгең...
Тар гүрләргә иңеп, күмелсәң дә,
Син аклыктан туя белмәдең.

Синсез генә язлар килде, менә
Җил тарата җиргә гөл исен...
Бураннарга "бурыч"ыңны бүген
Син гөлләтә, бәлки, түлисең?!

Гөлчәчәккә, әйе, күчерәсеңдер
Күзләреңнең җете зәңгәрен...
Син, гүяки, әҗәлләрең белән дә
Кайгыртасың дөнья ямьнәрен.

...Язмышларның Язы булса үткән,
Көзләре дә җитәр—саргаеп:
Көзләремә сугылыр дип куркам
Бураннарга яккан бар гаеп...

Флүс Латыйфи

СЕБЕР ХИКӘЯТЕ

ХИКӘЯ

Менә икенче көн инде без Төмән автовокзалында бәйләп куелган эт хәлендә. Атна буе туктамый коеп яуган яңгыр, районнарны өлкә үзәге белән тоташтыручы, болай да сазламык юлларны үтә алмаслык баткакка әйләндергән дә куйган. Багана башына эленгән әлүмин чиләкне хәтерләтүче зур динамик дөмберди башлауга йөрәкләр өмет белән кысыла, күзләргә нур инә. Менә-менә хәзер безнең маршрутны игълан итәрләр, автобусның йомшак урындыкларына кереп утырырбыз, ул безне бәллүләтеп кенә тайга кочагына сеңгән, галәмәт зур күлләр буена сыенып утырган Каскара авылына илтеп куяр дип хыялланабыз. Ул авыл инде безгә ниндидер бер ожмах түре, ымсындырып торучы жәннәт кочагы сыман булып тоела башлаган иде. Әмма иртәдән бирле бер үк сүзләрне кабатлаудан туйган диспетчерның карлыккан тавышы сөендерерлек хәбәр китерми. Теге яки бу автобусның маршрутка чыкмаячагын игълан итүгә динамиктан калайга чүкеч белән суккандагыдай ямьсез, чыкырдаган тавыш яңгырап куя. Өметләр тагын өзелә. Шунысы гажәп, автовокзалда халык кимеми генә түгел, һаман арта бара. Берәүләр иртәгә килербез инде, дип, кулын селтәп китә тора, әмма аларны икенчеләре, өченчеләре алыштыра. Безнең шикелле үк бәлки бүген юлга чыга алырбыз дип яшерен өмет саклаганнар байтак икән шул.

Безгә исә ничек тә тизрәк авылга барып житәргә кирәк. Юкса, ничәнче көн эчтә бүреләр улый. Казаннан чыгып киткәннән бирле поездда аннан-моннан, коры-сары белән тамак ялгап килгәнгәме, иң олы хыялыбыз утырып бер кайнар аш ашау иде. Алай-болай автобус-фәлән, яисә юл уңаена баручы машина туры килмәсме дип, ераккa, читкә китеп тә йөри алмыйбыз. Автовокзалның көн буе халык кайнаган шыгрым тулы буфетына сугылгалый-быз сугылгалавын. Ә анда кофе, пешкән йомырка, бәясен күрүгә үк чәчләрең

Флүс ЛАТЫЙФИ (*1943*) – *прозаик, публицист; "Хыянәт", "Ишелеп төшкән бәхет", "Тамга", "Бәйсез этләрне атарга" һ. б. китаплар, өч томлык "Сайланма әсәрләр" (2001) авторы. Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре. Казанда яши.*

үрә торырлык кыздырган тавык, шикәргә катырган коржик ише нәрсәдән гайре әйбер юк. Студент кесәсе генә күтәрерлекмени!? Кофе дип аталган болганчык суы гына да егерме тиен тора бит аның. Ә безнең кесәләрдә инде байтактан жилләр уйный. Юлга чыгар алдыннан группа житәкчебез Госман Жаббаровның: "И ул Себер халкының кунакчыллыгы! Анда барып эләксәк мантыйбыз инде без. Өйдән-өйгә кунак булып кына йөрерсез. Гомердә күрмәгән кадер-хөрмәт, нигъмәтләрдән сыгылып торучы табыннар барысы да сезнеке",— дип, теш суларын суырып әйткәненә чын күнелдән ышанып, без жүләрләр поездда тугарылып фарсит иткән идек шул. Поезд чакрым саен диярлек туктый. Туктаган саен станциягә төшәсең. Ә анда ширбәтле тундырма, баллы, газлы лимонад, учма-учма жиләк сатучылар өере. Иркенлеккә чыккан студент нәфесен тыя беләмени?!

Ә хәзергә автовокзалга каршы якта гына урнашкан, кыйшайган вывескалы, безнең яклардагы авыл лавкаларыннан бер ягы белән дә аерылып тормаган кибеттәге килька консервасы белән канәгатьләнергә туры килә. Группадашыбыз Нурия әйтмешли: "Иртәнгә томат соусындагы килька, төшке ашка килькалы томат, кичкә томатлы килька". Кыскасы, һаман бер балык башы. Тышына берничә вак балык сурәте төшерелгән бу юка калай банкаларны күргә үк эчебез борып авырта башлый. Нишләмәк кирәк, студентның башы белем белән шыплап тутырылган булса да, кесәсе такыррак шул.

Шулай күпме яткан булыр идек, билгесез... "Болай булмый, тотам да обкомнарына барам. Без дә үз мәнфәгатебезне кайгыртып йөрмибез. Бәлки ярдәм итәрләр..."—дип, чарасызлыктан үртәлеп чыгып киткән Жаббаров кош тоткандай канатланып кайтты. Күзләре очкынланган, әле автовокзалдан чыгып киткәндә генә төрлесе төрле якка тырпайган бөдрә чәчләре яхшылап таралган, муенындагы галстугы тураеп үз урынына утырган иде. Сөенмәслекмени, без барасы якларга нефтьчеләр машинасы чыгып китәргә тиеш икән.

—Әйберләрегезне жыеп куегыз, таралып йөрмәгез. Озакламый машина киләчәк,—диде ул боерык бирүчән кискен коры тавыш белән. Кыяфәтенә Ватерлоо сугышында жиңеп кайткан француз генералы чалымнары кунды. Хәер, генерал булмагае, ник генералиссимус булмый, без аны кочаклап күккә чөяргә әзер идек инде.

Кәсебенә керешсән була икән. Бер-ике сәгать үттеме-юкмы, күзләребезгә ышанмадык, автовокзал янына гөрелдәп, чыннан да, хәрби походка әзерләнгәндәгедәй, арткы тәгәрмәчләренә калын чылбыр чорнаган, өсте бөркәүле зур "Урал" вездеходы килеп туктады. Жаббаров безгә эре генә караш ташлап кабинага кереп утырды. Без капчык-чемоданнарыбыз белән машина әржәсенә үрмәләдек. Себер якларына жыр, әкият, бәет, табышмак, мәкаль, әйтем, кыскасы, халык ижаты үрнәкләре жыярга экспедициягә чыккан Казан студентларының, ягъни без фәкыйрьләрегезнең сәяхәте әнә шулай башланды.

Без дигәнем исә, тыйнаксызлыкта гаепләмәгез, башта үземне әйтим әле, миннән, янә тагын дүрт студенттан—Харис, Миннурый, Фидания белән Нуриядән һәм группа житәкчебез аспирант Жаббаровтан гыйбарәт иде.

Без килеп житкәндә көн сүрелә төште, жәйге кояш та тәмам арып, офыктагы агач башларында ялкау гына тәгәри башлаган иде инде. Салулый-салулый, сикәлтә саен телләребезне тешләргә мәжбүр иткән машина да, ниһаять, күнеллерәк гөрелдәргә кереште кебек. Алдыбызда куе таллыклар арасына ташланган сихри көзгедәй ялтыраучы озын күл буенда таралып утырган зур, төзек авыл пәйда булды. Йөзләребез бердән яктырып китте, эчкә жылы йөгерде. "Машинадан сикереп төшәрбез дә тымызык күлгә чумарбыз. Юлдагы талчыгу да, ару да юып алгандай юкка чыгар, эче эчкә ябышкан ашказаннарыбызга жылы ризык керер". Шуларны уйлап һәркайсыбыз ләззәтле минутлар кичерде бугай. Хәтта юл буе Хариснын беләгенә чатырдап ябышып килгән Фидания дә торып, кузовны кабинадан аерып торган биек тактага килеп ябышты.

Теләгебезгә ирештек ул көнне. Аксыл комлы яры белән ерактан ук күнелләрне ымсындырып килгән тирән күлдә дә коендык, чын Себерчә уттай кыздырылган мунчасына да кердек, туйганчы жылы аш ашап, иртәгесе көнгә планнар корып, йокларга яттык.

...Авыл җирендә таң тиз ата. Без торганда йорт хуҗаларыбыз Шәмсетдин бабай белән аның корткасы Хәдичә әбинең эшләп алҗып, инде икенче тапкыр чәй табыны янына утырулары икән. Без дә авыл малайлары түгелмени?! Сикереп тордык та күлгә йөгердек. Чистарынып, сафланып кайтканда өстәлдә чын бәйрәм сые әзер иде инде. Менә сиңа Хәдичә әби! Ниләр генә юк бизәкле ашъяулык өстендә. Әле иртәнге чык бөртекләре энҗедәй ялтыраган яшь кыяр, яшел суган кебек нәрсәләрне әйтеп тә тормыйм, аның янында каймакка салынган, Себерчә әйткәндә, тукмак җиләк, парын бөркеп утыручы ит, ярмаланып торган бәрәңге һәм башкалар, һәм башкалар... Оятыма көч килсә дә әйтим, филология бүлегендә укып йөреп тә, әле исемнәрен белмәгән ризыклар, тәм-томнар бар икән! Тамакка бик үк хирыс булмаган кызларыбыз да, патшабикәләр шикелле ялындырып тормады, өстәлдәге сыйлар берәм-берәм эреп юкка чыга барды.

Хәдичә әби белән Шәмсетдин бабай бездән бик канәгать иде күрәсең. Бабайның күзләре хәйләкәр елтырый, битендәге һәр җыерчыгыннан мәрхәмәт һәм миһербан бөркелгәндәй тоела. Ул көмеш агы кунган сакалын сыпыра-сыпыра вәкарь белән генә һаман сыйлый да сыйлый:

—Үз балаларым кебек якын тоелдыгыз әле миңа... Меңәр чакрымнар үтеп, Казаннан үк килгәнсез бит. Яле, оланнар, ит белән картупына да житешең. Көне буе йөрисегез бар. Ризык җыеп чыгыгыз. Эсседә ашалмый ул...

Хәдичә әби исә күп сөйләшми. Аркасына җәеп бәйләгән чигүле ак яулыгының чите белән тыйнак кына бит очларын сөртеп ала да әле беребезгә, әле икенчебезгә елмая. Шундый ерактан килгән кунакларга сыеның ошавы күңеленә бик хуш килде бугай аның. Ә безгә нәрсә?.. Студент корсагы резин туп бит ул, күпме тутырсаң да сыя. Тулай торактагы кефир малайлары дип башына да китермәссең... Аспирант Жаббаров кына бик белдекле кеше шикелле үзалдына елмаеп нәзберекләнеп утырган була.

Тәмам хушланып, әби белән бабайга рәхмәт укый-укый өстәл яныннан күзгалдык. Инде эшкә тотынсак та ярый. Парлашып бүлештек тә, жирәбә салып, авылның кайсы урамы кемгә туры килүен билгеләдек. Миңа Нурия белән күл буендагы түбән оч урамы эләкте. Дөресрәге, Нуриянең минем белән чыгуын бик-бик теләсәм дә, аңа бу хакта үзем әйтмәгән идем. Жаббаровка рәхмәт, ул, уйларымны сизгәндәй, каш астыннан сынап карап алды да миңа таба карап тамак кырып куйды, кычкырып әйтте:

—Син инде, әлбәттә, Нурия белән чыгарсың,—диде.

—Сез әйткәч, шулай итәрбез инде,—дигән булдым мин битараф тавыш чыгарырга тырышып. Әллә нишләп кенә битем кызара башлады. Сиздермәс өчен дәфтәр тышына иелеп исем-фамилиямне язарга керештем. Жаббаровка ачуым да килеп китте әле. Бу хәтле кычкырып әйтмәсә ярамыймыни?! Нуриягә карата булган хисләремне минем беркемгә дә, хәтта аның үзенә дә белдергәнем юк иде канә.

Хәер, Нуриянең миңа карап елмайганын күргәч барысы да онытылды тагы. Көне буе аның белән бергә булачагыбызны күз алдына китерүдән башларым әйләнеп китте.

Тук тамакка бераз авырая төшсәк тә, кәгазь-каләмнәребезне алып, түбән очның иң аргы башына үк чыгып киттек. Шуннан килә-килә әбәткә чакырып калган Хәдичә әби янына төшке ашка кайтып житү иде исәбебез.

...Авыл кырыендагы беренче йортның капкасын шакыдык. Әллә көтеп үк торганнар инде, безне йорт хуҗабыз шикелле үк сирәк сакаллы, бәйрәм көннәрендәгечә, башына кара түбәтәй, әле генә үтүкләнгән ак күлмәк өстеннән камзул да киеп жибәргән бер карт каршы алды. Тирән җыерчыклар белән чуарланган көрәктәй ике кулын бирепкүрешкәч, күптән көткән кунакларыдай күреп безне ак өйгә чакырды.

—Бергә-бергә шунда чәй янында гәпләшеп утырырбыз. Карчыгым да күптән көтә инде сезне... Сүз иярә сүз чыгар...

—Юк, юк, бабай, рәхмәт!.. Без озаклап, чәйләп утыра алмыйбыз шул. Йөрисе жиребез дә күп. Аннан... Әле без яңа гына өстәл яныннан кузгалдык,—дип такмаклады каушап калган Нурия.

Дөресен генә әйткәндә, икебезнең дә бер генә кабар җиребез дә юк иде. Бөтен теләгебез тизрәк халык ижаты хәзинәләрен җыя башлау, әле бер генә хәреф тә төшмәгән дәфтәрләребезгә моңарчы адәм колагы ишетмәгән борынгы җырлар, кинаяле такмаклар, тылсымлы әкиятләр, дастаннар теркәү, мәкаль-әйтемнәр, табышмаклар дөньясына чуму. Икебез дә тизрәк әнә шул сафландыргыч чишмәгә кушылырга хыялланабыз. Авылдагы һәр өйдә таныш булмаган моннар, риваятьләр, һәр бабай, һәр әби хәтерендә алтынга тиң шундый хәзинә бөртекләре сакланадыр сыман тоела иде безгә. Кеше аягы басмаган ерак Себер авылларында ни генә булмас дисең!

—Бабай, чәй эчеп тормыйча гына сөйләшик инде. Казаннан ук җырлар, әкиятләр язып алырга килдек бит,—дип дәвам итте Нурия үрсәләнеп.

Ачык, мәрхәмәтле йөзле бабаебызны көтмәгәндә алыштырып куйдылармыни. Ул кинәт кенә кырт кисте дә куйды:

—Сөйләй алмаем сиңа, йөрәгем. Хәтерем дә тишек инде. Хәтерләмәем. Әнә кәмперемнән сорап карап...

Бабайдан картрак күренсә дә, җитез хәрәкәтле, бәбәй итәкле киң күлмәк өстеннән озын яшел казакиен да киеп җибәргән карчык инде баскыч төбенә чыгып баскан икән. Ул сүзгә кушылды:

—Сиңа әйтәм, нигә ишегалдында сөйләшәсең, нигә өйгә чакырмыйсың? Самавырым суынаты бит инде.

—Әби, ичмасам, сез белмисезме соң? Безгә... ни, җырлар кирәк иде бит, —дип эндәште аңа Нурия.

—Хажәтен белгем киләте. Нигә соң ул?

—Без шуларны җыеп йөрергә дип килгән идек.

—Ярар, балалар, уйлашырбыз. Башта сыйдан авыз итик тә.

Ах, шул сый дигәннәрен. Ансыз гына булмыймыни инде.

—Юк, әби! Рәхмәт! Чәй эчеп тормыйбыз инде,—дидек без икебез беравыздан.—Ьичьюгы, яшь чакларыгызда яратып җырлаган бер-ике җырны әйтсәгез, безгә шул да ярап торыр иде. Йә бию такмаклары...

Ярамаган сүз әйтмәдек бит инде. Аңламассың бу Себер кешеләрен. Әбекәебез безгә чын-чынлап үпкәләде. Иреннәре кысылды, битендәге җыерчыклар тагын да тирәнәя төште.

—Нинди сүз ди ул. Карт башың белән көпә-көндез урамда җырлап утыру. Сез инде үпкәләмәгез, белмибез без.—Аннары, картына карап, тагын өстәде.—Аяк-уенга[1] да үнәребез юк.

Безгә хушлашып чыгып китүдән башка чара калмады.

Күнелебез шактый ук төшәргә, баш өстебездәге алсу хыялларыбыз тарала башларга өлгергән иде инде. Тагын ни булыр икән дип, кыяр-кыймас киттек өй борынча. Яшьләр күбесе эштә, күрәсең. Гадәттә карт-карчык каршы ала. Керәбез, сәлам бирәбез. Ачык йөз, тәмле сүз белән каршы алалар, хәл-әхвәл сорашалар һәм... өстәл янына чакыралар. Җыр, әкият, мәзәк турында ишетергә дә теләмиләр. Бу турыда сүз чыккач: "Әй, кара син аны! Хәзер шуны җыеп йөриләр икән",—дип тел шартлаталар, бот чабалар, гажәпләнәләр. Ә үзләре ник бер нәрсә сөйләсеннәр. Бар сүзләре шул:

—Үнәрем юк шул, балам.

—Белмәем...

—Хәтерем тишек иләк кебек.

Чираттагы өйдән чыгып Нурия белән бер-беребезгә карашып торгач, аптырап кулларымны җәеп жибәрдем.

—Каскара авылы картлары җыр белми икән, ә?!

—Шулай икән шул. Гомеренда уйламассың,—дип сүзләремне куәтләде Нурия.—Безнең авыл картлары алтын икән.

Шулай карашып тордык та, өйдән-өйгә йөрмәс булып, авыл кырыендагы Пыктын Карагае дигән күл янына төшеп киттек.

Себер кояшы көньякныкыннан ким кыздырмый икән. Рәхәтләндек бер, ичмасам. Ничә көн кояш күрмәгән тәннәребез, кызарып, ачыта башлаганчы

[1] А я к - у е н —бию *(Себер диалекты).*

кызындык, су коендык. Көн кичкә авышкач кына: "Госман Жаббаровка ни әйтербез икән?" дигән уйга төшеп, кайтырга чыктык. Бик тә ашыйсы килә иде. Иртәнге сый-хөрмәтләр искә төшеп, авыздан сулар ага хәтта.

...Капка төбендә Шәмсетдин бабай каршы алды. Койма янындагы калын бүрәнәдә, черем иткәндәй, оеп утыра иде. Безне күргәч, үзе яныннан урын күрсәтте.

—Йә, оланнар, кайларда булдыгыз, ниләр күрдегез? Ничек сыйладылар?..—дип тезеп китте ул ашыкмас тавыш белән.

—Булмады ла, бабай... Берни язып ала алмадык.

Шәмсетдин карт ышанмыйча, бер күзен кыса төшеп, безгә карап торды.

—Ничек? Аит Сәйдулласы да берни сөйләмәдеме?

Аның соравына сорау белән җавап биргәнебезне сизми дә калдык.

—Кем соң ул?

—Соң, беренче булып шуларга кергәнсездер ләбаса. Түбән очның иң кырыйдагы йорты. Авылда беренче ерауцы, аяк-уен остасы иде бит ул яшь чагында.

—Шуларга кердек,—дип сузды Нурия.—Берни дә сөйләмәде бит.

—Чынлап та аларның өенә кердегезме?—дип төпченүен дәвам итте бабай.

—Ю-у-к! Өйләренә үк кермәдек, анысы. Ишегалдында гына сөйләштек.

—Чакырмадымыни?

—Нишләп чакырмасын?!. Чакырды... Үзе дә, карчыгы да... Чәй эчәргә чакырдылар. Сыйдан авыз итегез, дип теңкәгә тия яздылар,—диде үпкәләгән сыман иттереп Нурия.—Без бит тамак туйдырып барган идек...

Шәмсетдин бабай, нидер уйлагандай, колак артын кашып куйды да картларча кеткелдәп көлеп җибәрде:

—И балалар, балалар! Үзегезне аштан өстен куйгансыз бит. Бергәләп ризык жыймагач, сыен авыз итмәгәч, ишегалдында сезгә кем жыр жырласын да, кем әкият сөйләсен ди инде.

—Хәзер нишлик соң инде, бабай?

Җавап көтеп, икебез дә аңа текәлдек.

—Нишлик-нишлик,—дип үртәгәндәй кабатлады Шәмсетдин бабай.—Иртәгә барасыз да, яңадан керәсез. Аш ашка, урыны башка.

Бераздан Харис белән Фидания дә кайтып керде. Аяк атлашларыннан үк сизеп торам, безнең шикелле үк берни дә кыра алмаганнар. Бары тик Госман Жаббаров белән Миннурый гына, дәфтәрләрен уалыр дип курыккандай, кадерләп тотып, яныбыздан үтеп киттеләр.

Ярар, иртәгегә таңны аттырсак, без дә ак сакаллы карт булырбыз дип, йокларга яттык. Ә иртән, Хәдичә әбине үпкәлятмәс өчен, берәр чынаяк кына чәй эчеп, кире Сәйдулла бабайларга юл тоттык. Кичәге хатаны кабатларга ярамый иде безгә.

—Хәерегез белән киләсез,—дип елмаеп каршы алды ул.—Кире безгә керәсезегезне сизенгән идем мин. Жыясы ризыгың булса, тешеңне сындырып керер, ди бит.

Нурия белән икебезнең дә колакларыбыз торды. Кара син бабайны, бүген беренче сүзеннән үк мәкальләр сибә түгелме?..

Шатланып авызымны ерырга өлгермәдем, жилкәмә Нуриянең йодрыгы килеп төртелде.

—Кичә мин сөйләшкән идем. Инде бүген сөйләшүне син алып барырсың,—дип пышылдады ул.

Ризалыгымны белдереп, бабайга сиздерми генә аңа күз кысыйм дип борылган идем, кыз жиңемнән тартты, теш арасыннан ысылдап чыгарды:

—Минем белән түгел, бабай белән сөйләш!..

Картыбыз ашыкмый, салмак кына атлап килеп күреште, кулларыбызны сыйпап торды. Хәер... бу юлы да кичәге шикелле башлады:

—Ягез инде, без картлар янына килгәнсез икән, өйгә үтик. Әбиегезнең самавыры суынып өлгермәгәндер әле.

Карышып тору кая! Чакырмаслар инде дип, куркыбрак та килгән идек

әле. Әдәп өчен икенче тапкыр әйткәнне дә көтеп тормастан, ашыга-ашыга аякларыбызны салып эчкә үттек.

Әллә Себер картлары самавырсыз яши алмый инде. Чынлап та, түрдәге өстәлдә самавыр җырлап утыра. Аның янында эреле-ваклы чынаяк-касәләр, өсте чигүле сөлге белән капланган савыт-саба иде.

—Йә, утырыйк, балалар. Бүген дә шул җыр эзләп йөрүме?

—Әйе шул, бабай,—дип, инициативаны үз кулыма алдым.—Халык җырлары... алар бит безнең халыкның "мәңге күгәрмәс вә тутыкмас җәүһәрләре"...

Шул вакыттагы сөенүемне күрсәгез!.. Нурия алдында авторитетым бердән күтәрелеп киткән кебек булды. Ишетсен әле абзагызның ничек итеп сөйләшүен. Университетта алай-болай гына укытмыйлар икән. Габдулла Тукайның мәшһүр сүзләрен ничек оста китереп "сыладым".

Бабай ризалыгын белдереп, ике куллап юка сакалын сыпырып алды. Khым, khым дип, тамагын кырып куйгач, чаршау артында кыштырдаган карчыгына эндәште.

—Сина әйтәм, чык инде монда. Менә бит кичәге кунакларыбыз килгән.

Озак көттерми карчыгы да күренде. Тышына чык типкән балчык чүлмәкне киндер сөлге белән сөртә-сөртә кичәге сөйләшү булмаган да кебек кин итеп елмайды:

—Менә баздан шомырт суы алган идем әле. Сөйләшкәндә тамак кибүчән,—дип сөйләнә-сөйләнә өстәл янындагы эскәмиягә килеп утырды.

Авызыбыз бер пешкән бит. Бүген инде без кыстатып тормадык. Студентлар әйтмешли, өстәлдәге сыйны урдык кына. Әмма чама ягын да онытмадык. Әле тагын башка кешеләргә дә керәсе булыр бит.... Бары тик шуннан соң гына язарга әзерләнеп, дәфтәрләребезне чыгардык.

—Йә, ни эшкә инде ул безнең җырлар?—Бабай тагын соравын кабатлады.

—Ни эшкә дип, белә торгансыздыр инде... Аларны җыеп, китап чыгаралар, тарихны өйрәнәләр....

—Әйе, бабай, әле халыкта җыеп алынмаган меңнәрчә җыр, әкият, мәкаль, бәет булырга мөмкин. Киләчәк буыннар өчен югалырга тиеш түгел, хәзинә алар,—дип сүзгә кушылды Нурия. Сөйләсә, сөйли белә дә инде!

—Ә-ә... анысы кызык икән... Ерлар күп инде ул, аларны ницек хәтерләп бетермәк кирәк. Үзегез ниндиләрне беләсез соң? Нәпример, уен ерларыгыз ниндирәк,—диде бабай. Көлемсерәгән күзләре миңа текәлгән иде.

Кирәк чагында ник берсе искә төшсен икән. Үземнең туган авылдагы ял кичәләрен искә төшереп карыйм, күз алдына университет дискотекалары килә. Җыр җырламыйбыз икән ләбаса. Күбрәк тыңлыйбыз гына микәнни соң? Өмет белән Нуриягә карыйм. Ул исе китмәгән кыяфәт белән дәфтәренә нидер язып утыра. Әллә мин җырлаганны язмакчы ук инде.

Тавышым юк минем. Хәтта әни дә: "И бала, бигрәк тавышың юк инде. Жырлаганың тавык жырлаган кебек кенә",—дип жәлли мине. Ну монда сынатырга ярамый. Бабайның телен ачасы бар ич әле. Шул вакыт кылт итеп хәтеремә бер җыр килде. Кычкырмасам җырлый алмыйм мин, күкрәгемне тутырып тын алдым да түшәмдәге такта ярыкларына карап, тамак төбе белән бар көчемә кычкырып җырлап та жибәрдем:

Комбинезон алган, диләр,
Шинелен салган, диләр.
Шинелен салса да, солдат
Гадәте калган, диләр.

Башка куплетларын бик белеп тә житкерми идем. Жырлый башлагач, үзе чыга икән. Бер генә кавым да туктап тормыйча дәвам иттем:

Шинелен салган, диләр дә,
Шинелен салган, диләр.
Әллә каян күренеп тора,
Солдатта булган, диләр.

Булдырдым бит әй, гомердә җырламаганны җырладым дип Нуриягә караган идем, аптыраудан каттым да калдым. Миңа арты белән борылган кызыйның иңнәре дерелди. Житмәсә, авызын кулы белән каплаган. Әллә елый, әллә көлә. Хәер, бу минутларда аның бәясе әллә ни кирәк түгел иде миңа. Иң мөһиме—картлар. Алар ни әйтер!..

Бабай исә рәхәтләнеп елмая, күзләрендә шаян очкыннар биешә. Ул мин җырлаганнан бик канәгать калган иде бугай. Әбигә карап күз кысып та алды әле.

—Маладис, егет икәнсең,—диде ул.—Монысын радиодан безнең дә ишеткән бар анысы. Тагын берәрне җырлап күрсәтсәң бигрәк тә шәп булыр иде.

Инде чирканчык алынган, күп уйлап тормый, икенчесен дә әйттерә башладым:

Утыр әле яннарыма,
Ял булсын җаннарыма.
Син утырсаң яннарыма,
Ял була җаннарыма.

Казандагы танылган бер җырчы шикеллерәк иттереп җилкәләремне дә сикертеп алам, күзләремне уйнатам, көй ритмына аякларым белән идәнгә дә тибеп куйдым. Тагын да дәртләнебрәк җырлыйм диеп, тәмам азартка кереп барганда Нуриянең пырхылдап көлеп җибәрүе тукталып калырга мәҗбүр итте. Борылып аңа карадым. Ул исә битенә дәфтәрен каплаган, иңсәләре дерелдәпме дерелди.

И рәнҗедем аңа шул вакытта. Әллә үзен концертта дип белә микән, чытлыкланып утырырга. Үтергеч караш ташлап, шуны әйтергә авызымны ачмакчы идем, әби кулыма тустаган китереп тоттырды.

—Тамагың кипкәндер, улым, эцеп йибәрең әле...

Шомырт исе аңкып торган ширбәтне йотып куйгач, ачуым басыла төште тагы. Әле һаман пырхылдаган Нуриягә:

—Соң, алай булгач, үзең җырла,—дип кенә әйтә алдым.

Җырга минем кебек кенә түгел инде ул. Анысын яхшы беләм. Сәхнәләргә чыгып басса сандугачлар бер якта торсын. Тик аңа җырларга туры килмәде. Сәйдулла бабай егерме яшьлек егетләр шикелле итеп кәләпүшен кыңгыр салып куйды, камзулын жилбәгәй җибәрде дә Нурия каршына килеп басты һәм, үзе әйтмешли, "ерлап" та ебәрде:

Карагай ла башы кәвеш-кәвеш,
Сызылып ла килә бер тавыш.
Бармаккаең камыш, йөзең кояш,
Акылларың камил, үзең яшь.

Ашыкмыйча гына, көйнең һәр бормасын җиренә житкереп, моңның чын тәмен белеп, һәр сүзенең мәгънәсен йөрәге аша үткәреп, яшерен дәрт белән жырланган бу жыр икебезне дә телсез калдыргандай булды. Нуриягә генә кара син! Әйтерсең лә үзенә атап жырлыйлар. Битләре үк алланып китте. Житмәсә, көязләнеп, бабайга елмаеп утыра. Мин жырлаганда борылып та карамаган иде.

Әсәрләнеп, дәфтәргә теркәп барырга да онита язганбыз. Тиз генә каләм-дәфтәргә ябыштык. Хәер, инде бабай безнең турыда үзе үк оныткан иде, күрәсең. Әллә Казан хәтле Казаннан килгән студентларның һәр сүзен кәгазьгә теркәп утырулары күңеленә хуш килде, әллә егет чакларына кире әйләнеп кайтты, бабабыз карчыгы янына барып, инде аңа атап жырлый башлады:

Кимә итек, ки читек,
Аякка жинел итеп.
Аргы урамдин ярлар сөйдем,
Бирге урамга үч итеп.

Аңа калтырап чыккан тавышы белән, әмма ниндидер борынгы көйнең бормаларын үзенчә бик рәвешенә китереп, әбиебез дә кушылды:

Агыйделкәйләрнең аръягында
Ат аунаган кара җирләр бар.
Чакырсам барман, кулың салман,
Күнелкәем калган ярым бар.

Бабай да җавапсыз калмады. Салмак хәрәкәтләр белән идән уртасында түгәрәк ясап җырлый башлады:

...Үзем дә лә генай сөйгән ярны,
Күз күрмәгән якка озаттым.

Әби башына чәйгән яулыгының бер чите белән йөзенең ярты сын каплады, оялчан кызлар шикелле иттереп, сузып кына җавап бирде:

Зәл килә сәлки, Садрый сәлки,
Камзуллары яшел гарнатур.
Сән сорамайсың, мин әйтмәем,
Сәлам дигән сина бер матур.

Күнелем белән сизеп, тоеп утырам, болар безне тәмам оныттылар, болар яшьлекләренә кайттылар. Әйтерсең лә егерме яшьлек Сәйдулла кичке уенга чыккан да гармун тартып күрше кызына йөрәгендәге хисләрне аңлата. Ул чактагы җырларда әллә ничә төрле яшерен мәгънә, кинә-киная, тел белән әйтеп булмаслык тәкъдим вә җавап хисләре дә булган икән шул. Йөрәгендә бәргәләнгән хисләренә урын таба алмыйча урамнан бер җырлап үткән егет моңнарына барысы да: сөюсагыну да, юксыну да, очрашырга чакыру да, кыскасы, яшерен мәхәббәтнең бөтен чалымнары да сыйган. Егет-кызлар җыр белән аралашкан, аларның жаннары, күнелләре шул моң дулкынында тирбәлгән, шул моң дулкынында табышкан, кавышкан. Их, Нурия белән дә шулай җырлашып аңлашырга иде, дип уйлап куйганымны сизми дә калдым. Күнелдәге хисләрне тел белән әйтеп бирүгә караганда, җыр аша сиздерү мең мәртәбә отышлырак, үтемлерәк, тылсымлырак булып тоела башлаган иде инде. Кеше күнеле җыр белән яшәргә тиеш икән! Ә менә мин үзем ни эшләргә тиеш соң? Жырлый белмәгәч нишлим?! Аннан... Безнең заман жырлары тозсызрак икән шул. Аларда сагыштан саргайган ике йөрәк кенә аңлый алырлык яшерен мәгънә, сер юк кебек тоелып китте. Сөйгәнең каршына килеп "Әллә каян күренеп тора, солдатта булган диләр" дип жырламассың бит инде. Шашкан икән бу диярләр...

Бер-ике тапкыр самавыр янарттык без ул көнне. Әби белән бабайның хәтерләре бер дә тишек түгел икән. Сүз иярә сүз чыгып дигәндәй, аларның бер такмаклары икенчесен хәтерләтте, бер бәеттән икенчесенә күчтеләр, авылда төрле елларда булган вакыйгаларны, аларга карата кемдер чыгарган такмакбәетләрне бәйнә-бәйнә сөйләп бирделәр. Кеше халәтенә жырның ничек тәэсир иткәнен үз күзләребез белән күрдек без. Сәйдулла бабай белән карчыгы бердән яшәреп киткәндәй булдылар. Әйтерсең лә жилкәләренә заман, чорлар авырлыгы белән басып торучы сигез дистәгә якын ел чалымы да, битләрендәге жыерчыклары да юкка чыкты. Аларның гәүдәләре тураеп китте, күзләреннән яшьлек нуры бөркелгәндәй булды. Себернең адәм генә түгел, киек жанвар адашырлык кара урманнары арасына кереп поскан татар авылларының чал үткәнен безнең алда янарттылар, жырлары белән безне дә шул чорга алып кереп киттеләр алар. Иртән килгән жиребездән без төш вакыты житкәнне дә, кояшның кичлеккә авышканын да сизмәгәнбез. Яза-яза кулларыбыз арыды, дәфтәрләребез тулды. Инде Сәйдулла бабай сүзне үзе очлады:

—Менә шулай, оланкайларым. Килгәнегезгә рәхмәт. Яшь чакларыбызны искә төшердегез әле,—диде ул. Аннан соң, карчыгы белән күзгә-күз карашып алгач, ягымлы көлемсерәп өстәп куйды.— Дөресен әйткәнгә үпкәли күрмәгез тагын, кичә кергәндә бик эре нәрсәләр икән дип хәтер кала язган иде. Ялгышканбыз... Бүген сөендердегез тагы... Инде сезнең жырларны да тыңларга насыйп итсен. Жырлап яшәгез, оланнар,—диде.—Кеше күнеленда жырга сыймаган бер генә нәрсә дә юк.

1986-2003.

Бикә Рәхимова

БОЛГАРЫМА БАРАМ ӘЛЕ...

Иделебез

Күңел сөйгән Иделебез
(Сөю белән көчле без!),
Күңел белән тирәнлеген,
Киңлеген дә үлчибез.

Идел өстендә акчарлак
Ак яулык болгыймыни?
Әллә инде саубуллаша,
Шуңарга боекмыни?

Акчарлак юл хәстәрендә—
Иделдә сые беткән,
Ә безнең күңел, нур булып,
Иделгә сыеп беткән.

Акчарлак Иделсез яши
Идел туңган чагында.
Безнең күздә зәңгәр боздан
Язгы хыял чагыла.

Без китмибез, Иделебез—
Мәңгелек тукталышы.
Колакта: "Китегез!" түгел,
"Кайтыгы-ыз!.."ның тавышы.

Бикә РӘХИМОВА–*шагыйрә, публицист, тәрҗемәче; "Сәрвиназ", "Иделләр Казанында" һ.б. китаплар авторы. Казанда яши.*

Мин көтәм

Болгарыма барам әле,
Һәрбер ташын сагындым.
Сагынмакка—таш җыйсам да,
Түрендә ул сандыкның:
Безгә дигән мал-мөлкәтләр
Чит кулларда әрнегән.
Болгардан калган ташлар да
Кадерлерәк мәрҗәннән.
Болгарыма барам әле,
Болгар кызы мин үзем.
Болгарыма кайтуны да
Мин көтәмен. Мин түзем.

Җилгә бирмик

Үтәли җил үтә үзәгемә,
Әйтерсең лә кырда бер агач:
Җилгә каршы җырлыйм җырларымны,
Йөрәккәем тәмам ярсыгач.

Җил көенә җырлап, моңыбызны
Җилгә бирмик әле, җырчылар!
Үз җаныңны җилдән саклаганда
Үзәк өзгеч моңлы җыр чыгар.

Ку җаныңнан иләс-миләс җилне.
Җил аздыргыч, җил ул—замана.
Замананың көйләреннән таный
Сизгер йөрәк бәла-казаны.

Пыяла баш—заманага төзәп,
Куенымда йөртмим үч ташы,
Тик язмасын безгә, тик язмасын
Заман җилләрендә адашу.

Заман җилен җиңгән өчен генә
Шундый түзем, чыдам бүз халкым.—
...Сынау арты сынау үтеп кенә
Җирдә даулый алам үз хакым.

Моң иясе

"Кызыл байрак" инде артта калды,
Чал Иделдә ярсу моң ага.
Сәйдәш уйный сыман нечкә кылда,
Моң иясе җанны сугара.

Иделенә салып калдырган ул
Җаныңың бар хисси әрнүен,
Бу көйләрдә шифа өчен кирәк
Ачылары бардыр әремнең.

Үзәк өзгеч көйләр җан сугара,
Дәртлесе дә якын күңелгә...

Болгар бабам яудан кайтып килә,
Һич ышанмыйм алай түгелгә...

Сәйдәш көе чаптырып китерәдер
Атилланың ярсу атларын...—
Атилланы Әтил улы, диеп,
Тарих аръягына атладым.

..."Кызыл байрак" инде артта калды,
Чал Иделдә ярсу моң ага.
Сәйдәш уйный сыман нечкә кылда,
Моң Иясе җанны сугара.

Үтте

Мизгелләре үтте хыялларның,
Булган форсат очты, кош кебек,
Күңелләрем мөлдерәмә, дисәм,
Әллә ниләр җитми, буш кебек.

Бәргәләнгән җаным таңнар көтә,
Бигрәк соры инде бу кичләр...
Хыялларның кайсы якларында
Калды икән утлы ул хисләр?

Күңелемдә шыткан ышанычым
Тамырлары белән йолкына.
Ал кулыңны, әй алабай дошман,
Тамырларым минем йолкыма.

Кайтарыплар алып ул көннәрне,
Тагын бер мәртәбә үт икән,
Кире чолгар булсаң гына аны,
Хыял йомгакларын сүт икән.

...Сүтеләсе йомгак тәгәрәр бер,
Табып җаен, серле көнен дә...
Азатлыкны алыр түзем халкым,
Рәнҗетмичә җирдә кемне дә.

Җәйге бакча

Түбәләмә тырыс җиләк җыйдым—
Яшел җәйнең кызыл түбәсе.
Пешкән-тулган җиләк нурлар эчкән,
Һәрберсен килә үбәсе.

Туйлар иткән җиләк патшалыгы,
Нур белән сут икәү кушылган.
Аллы-гөлле тормыш төзегәннәр,
Киенгәннәр бигрәк купшыдан.

Патшаларга тәхет биргән бәхет
Рәхәтлеге җәйге бизәктә.
Җан эретер шатлык бирә уңыш,
Үз бакчаңнан җыйсаң бигрәк тә.

Чуар күбәләктәй оча күңел,
Аңа инде күптән җәй ия.
Алгысынган күңел әйткән җырым
Булсын—миннән җәйгә мәдхия.

Чынлыкта

Гамил Афзалга

Кыя ташка менгәнмени—
Уйлары күккә тоташкан.
Җисми тәне җирдә йөри,
Үзе гүя күккә ашкан.

Югары дөньяда яшәү
Бер—читендер, бер—рәхәттер.
Сүздән челтәр үргән тормыш
Бер—михнәттер, бер—ләззәттер.

Хисе белән җир җылыткан
Күктән төшкән бер кояштыр.
Адәмнәрнең нәфсен күреп,
Илаһ каршында ояттыр.

Гөнаһларның юлын буу—
Тормышында бер хыялдыр.
Хыялыйдан чыккан нурлар,
Күзгә кереп, бер оялтыр.

Үткен фикер, хисле йөрәк—
Бар тормышы менә шушы.
Чынлыкта булмый дөньяның
Атлант баганасы—күпшы!

Сандугач

Сандугач сайрый да сайрый
Йөрәге кушып кына:
Киткән ул ләззәт иленә—
Бары тик үз хушына.

Кунган ботагы бәхетле,
Ә сандугач аңламый...
Кунган ипле булган өчен,—
Башкачалап сайламый.

Тамагы сайрап торганда
Аңа җәл түгел берни,
Әллә җиле, әллә силе—
Бәрсәң, әйдә, бәр инде.

Саксыз шул көчсез сандугач
Йөрәгеннән... ут ташый,
Челтерәп аккан көеннән
Ул моң дәрьясы ясый.

...Көзләр килде. Яңгыр, суык...
Кычыткан арасында
Сары сандугач гәүдәсе...
Ышанмыйм, карасам да...

Кем отты?

Рөхсәтсез керү ярамый
Хөжрәбезгә—күңелгә.
Тик бу заман ак күңелгә
Дөнья чүбе түгелә.

"Ярый", "ярамый" дигәнне
Инде барсы онытты.
Кем онтылды, кем отылды,
Иблислек—шайтан отты!

Рафис Корбан

Бишек җыры

Бишек җыры. Аны җырлар өчен
Кирәк түгел хәтта гармун да.
Аналарның йөрәк түрендәге
Иң мөкатдәс моңнар бар монда.

Бишек җыры. Иң беренче тапкыр
Ишеткән җыр, җиргә тугач та:
Елавыннан туктасын, дип, балам,
Көйләнгәндер безгә ул башта...

"Әлли-бәлли, әлли-бәлли бәү",—дип,
Газиз әнкәй аны көйләгән.
Шушы җыры белән әниләр бит
Сабыена бәхет теләгән.

Бишек җыры—безнең иң беренче
Җырлаган җыр дөнья йөзендә.—
Әнкәемә кушылып, бишегемдә
Көйләгәнмен аны үзем дә!

Телебезне ачкан җыр ул безнең,
Әлифбасы туган телнең ул.
Бишек җыры—иң бөек җыр җирдә,
Гомерләрне башлый безнең—Ул!

Җыен

Кушкапка җыены булган
Элек безнең якларда.
Яллар иткән шулай халык
Эшләп арган чакларда.

Бәйрәм иткән дүрт-биш авыл,
Кашка-тауда—кушкапка!
Хәзер инде онытылган,
Кереп калган китапка.

Рафис КОРБАН *(1957)–шагыйрь, балалар өчен "Буран нигә туктаган", "Капкорсак", "Куркуын җиңгән куян", "Алмалы төн" һ. б. китаплар авторы.*

Яңгырап торган тирә-як,
Җыр-бию, көлке-уен.
Гайрәтлеләр мәйдан тотып,
Башлаган сабан туен.

Кыңгыраулы пар атларда
Килен төшергән авыл.
Кодалардан кодаларга
Кунакка йөргән авыл.

Күчкән авылдан авылга—
Җыеннар йөргән күчеп.
Халыкның матур бәйрәме
Килә дәверләр кичеп.

Асыл исемен җуйса да
Җыеннар һаман да бар!
Кунаклар җыеп җыенга,
Сабантуй ясый татар!

Җанга якын бу болыннар,
Җанга якын бу үзән.
Чеметеп ала йөрәкне.
Әле дә ничек түзәм!

Кошлары да шундый таныш,
Ишеткән җырны көйли.
Әһ, кушылып шул кошларга
Күңел җырларга тели.

Һаман шул икән гөлләр дә,
Шул ук хуш ис бөркелә.
Бу болын, бу үзәннәрдән
Балачак исе килә.

Сөйләшәбез бер үк телдә!
Вә ләкин гажәп бу ныk—
Милләтебез төрле-төрле:
Мин—татар, ә син—кумык.

Корбан

Кемнәр генә каләм тотмаган да,
Кемнәр генә шигырь язмаган!
Язганнарның һәммәсенә дә тик
Бөек шагыйрь булу язмаган.

Мин дә язам! Язмый яши алмыйм.
Әверелде бу эш чиргә бер.
Шушы чирдән инде беркайчан да
Савыга алмам кебек мин хәзер.

Әйтә алмыйм бөек шагыйрьмен, дип.
Шәһит китсәм шушы юлдан мин,
Әйтсен халык: "Лира-сылу өчен
Корбан булды Рафис Корбан",—дип.

Икейөзле кешеләрне сөймим,
Әүлиядәй йөреп яныңда,
Этлек эшләр алар артыңда—
Юк, аларга һичбер ышаныч!
Баксаң, алар иң зур дошман ич!

Дуслар, әгәр миңа карата
Икейөзле булса берегез,
Мин сезне дә сөймим, белегез,
Ишегемне шакып керегез!

Алма биреп ашатырлар,
Ашама, бәгырькәем.
Халык җыры

Чәчкәләрем җилгә очты,
Кыраулар алды инде.
Яшьли сөйгән чибәр кызлар
Ятларга калды инде.

Утлардан алды да язмыш,
Суларга салды инде.
Йөргән юлларына карап
Күзләрем талды инде.

Алма биреп кызыктырып,
Бу дөнья алдый инде:
Ятлардан калган ярларны
Сөяргә калды инде...

ДОКУМЕНТЛАРНЫҢ ДА ҮЗ ЯЗМЫШЛАРЫ

Нигъмәт Хәким (1899–1937)–Хәкимов Нигъмәтулла Гыйниятулла угълы–тел галиме, фольклорчы, әдәбиятчы, Казан педагогия институты доценты әзерләгән "Идегә дастаны"[1] ның озын һәм фажигале тарихы бар.

1919 елда Себердә элекке Тобол губернасы, Тара өязе, Еланлы авылында Ситдыйк Зәйнетдиновтан (1854–1927) язып алынды, дип Н. Хәким бер җыйнама төзи. Ягъни, халыктан бер вариантны алып, башкаларыннан өстәп, төзәтә, зурайта, үзенә бер тәртипкә сала һәм, китап итеп чыгарыр өчен кереш сүз язуын үтенеп, бер нөсхәсен остазы, Ленинград университеты профессоры, академик Александр Николаевич Самойловичка (1880-1938) җибәрә. Төрки республикаларда җанланып киткән фольклор өйрәнү, бастыру эшләре белән үтә мәшгуль бу галим ул вакытта якут фольклоры китабына кереш яза. Баку, Ташкент, Ашгабат, Алма-Аталарга барып, фәнни докладлар ясый һәм Истанбулда узасы Тел конгрессына җыена. Шулай да "Идегәй"нең яңа вариантын Казанга кире озатасы килми. "Ленинградтагы язу өстәлемдә бик озак яткан бу нөсхәне Мәскәү–Алма-Ата поездында гына ачып карый алдым һәм кереш мәкаләне Кече Алма-Атинка елгасы буенда, гүзәл таулар арасында әзерләгәндә "hadent suo fata libelli"–"документларның да үз язмышлары була"–дип язып куйдым", диелгән А. Н. Самойловичның Хәмит Ярми (1904-81) шәхси архивында саклана торган "Кереш" мәкаләсе нөсхәсендә.

"Идегәй" дастаны язмышында тарих, әдәбият, фольклор кебек үк, кешеләр язмышы да аянычлы рәвештә чорналган.

XIX гасыр уртасында "Идегәй" дастанын Җомагыл дигән казакъ акыныннан бөек галим, мәгърифәтче, тарихчы, фольклорчы, этнограф, рәссам Чокан Вәлиханов (1835–1865) язып ала. Үпкә авырулы улына ярдәм итәргә теләп, аның әтисе Чыңгыз Солтан тагы ике акынны табып китерә һәм өч кешедән гарәп имлясы белән җыйнама казакъ версиясе төзелә. Шул ук вакытта ул русчага тәрҗемә ителә. 1905 елда П. М. Мелиоранский аның казакъчасын *(Сказание об Едигее и Тохтамыше. Киргизский (казахский) текст по рукописи, принадлежавшей Ч. Ч. Валиханову. Издатель проф. П. М. Мелиоранский.–СПб., 1905.)*, 1904 тә Н. И. Веселовский русчасын *(Ч. Ч. Валиханов. Сочинения. под. ред. Н. И. Веселовского–СПб., 1904 (ЗРГО по отд. этногр., т. XXIX).–223–264 и 265–273.)* бастыралар.

П. М. Мелиоранский үзенең укучысы И. Беляев аркылы "Идегәй"нең бер каракалпак вариантын тапкач, киләчәктә бу эпосның барлык вариантларын җыеп тәрҗемә итәргә, таралу даирәсен билгеләргә һәм чагыштырып өйрәнергә васыять итә. Икенче шәкерте һәм кафедрада урынын алып калучы А. Н. Самойлович 1911 елда Петербург университеты студентларына алтын медальгә дип, шул эш өчен конкурс игълан итә. "Идегәй" һәм "Туктамыш"ның төрле версияләре җыйнамасын әзерләүдә башлап йөрүче булуы өчен бу медальне А. Н. Самойлович курсларында тыңлаучы булган П. А.

[1] Н. Хәким дастан исемен шулай алган.

Фалев ала. Аның хезмәте 1922 елда Ташкентта кыскартып басыла *(Лекции, читанные проф. П. А. Фалевым в 1921 году в Туркестанском Восточном Институте. На правах рукописи.–Ташкент, 1922.)*, үзе бик яшьли үпкә авыруыннан вафат була, кулъязмалары Ленинград архивларының берсендә саклана.

П. А. Фалев "Идегәй"не "ногайское сказание" дип атый һәм В. В. Радловның себер татарларыннан язып алынган өч вариантын, шул бер әсәр дип уйлап ахры, искә алмый. Алар турында П. А. Мелиоранскийга багышланган махсус фәнни җыентык өчен С. Г. Кляшторный әзерләгән мәкаләсендә А. Н. Самойлович тарафыннан әйтелә һәм Н. Хәким әсәре "Идегәй"нең халык авызыннан язып алынган дүртенче варианты дип билгеләнә *(А. Н. Самойлович. Вариант сказания о Едигее и Тохтамыше, записанный Н. Хакимовым// Тюркологический сборник, 1972.–М., Наука, 1972.–С. 186–211.)*. Без исә аны галим, шагыйрь Н. Хәким әзерләгән беренче җыйнама вариант дип карыйбыз *(Ф. В. Әхмәтова. "Идегәй" дастанының татар вариантлары // Языки, духовная культура и история тюрков: традиции и современность. Труды международной конференции в 3-х томах. 9–13 июнь, 1992 г.–Т. 2–М.: "Инсан", 1997.–С. 160–162.)* һәм текстны тулысынча беренче тапкыр "Казан утлары"на тәкъдим итәбез. Чөнки, В. В. Радлов *(В. В. Радлов. Образцы народной литературы Тюрских племен.–ч. IV–СПб., 1872.)* телдән язып алган өч вариантның икесе шулай ук язмадан таралган чичәннәр җыйнамасы, ә өченчесе (барабадан) чәчмә әкият шәкелендәге әсәр.

Н. Хәким "Идегәй"не татарның тарихи дастаны дип атап, сәнгатьчә фантастика чараларыннан тәмам арындыра һәм үз шигъри куәсен дә өстәп, җыйнама рәвешендә үзе иҗат итә.

Аның әсәр ахырындагы: (Идегәй сүзләре)

Минең инде илгә күренер йөзем дә юк,
Борынгыдай йортка карар күзем дә юк,
Билгем дә юк! Дошманнарым, тиз үлтерең!
Сезгә инде башка әйтер сүзем дә юк!–

дигән авторлык шигырьләренә карап, А. Н. Самойлович "Ситдыйк бабай борынгы китапларга ияреп үзе язмады микән", дигән шиген дә белдерә *(А. Н. Самойлович. Вариант сказания...–С. 205.)*. Ә инде академикның Ситдыйк бабай борынгы төрки һәм гарәп сүзләреннән тоткавыл, ясавыл, чагдавыл, коралай, бүз юшан, бүз тойгын, мосахар итү, намарт һ. б.ларны белүенә гаҗәпләнүе мәкаләдән төшереп калдырылган. Шуңа Н. Хәкимнең 1930 елгы бер шигырен китерү мәслихәт:

Садаклар артып, җәя тартып,
Ук атулар кая югалды?
Сорнайлар тартып, биеп, җырлап,
Тын ятулар кая югалды?

Ч. Валиханов җыйнамасын популярлаштырып, казакъ телендә гарәп һәм латин алфавитларында бастырганда Ә. Диваев *(Серия "Батурлар". Изд-во бывшей Казах-киргизской научной комиссии (араб. алфавитом)–Вып. 7–ч. 5.–Ташкент, 1922.)*, К. Сатпаев, С. Сәйфуллин *(Batirlar cirlarinin cijnaqi. Ekinci cijnag. Cijnagan Saduaqas Sejpulla uli (SəKen). Almat//, 1934 5-39b. Sejpulla uli Səken. Qazag ədəbijati, Almati, 1932.–157–159; 181–187 b.)* һ. б. "Идегәй"нең нугайлар иҗаты гына булмыйча, тарихлары Алтын Урда белән бәйле башка төрки халыклар иҗаты дип тә каралырга тиешлеген әйтәләр. П. А. Мелиоранский хәтта бер каракалпак вариантын татар телендәге әсәр дип билгели *(Едиге. Каракалпак халык дәстаны. Нөкис, "Каракалпакстан", 1990.)*. Андагы сүзлектә Идел, Җаек, Сарытау сүзләре Волга, Урал, Саратов дип русча, *арыш, ару, айдар, айбалта, баяр, байтирәк, байбәтчә, бәддога, зәгъферан, гауга, хәмилә, халас, хәтерҗәм, фани дөнья*, һ. б. сүзләр каракалпакчага тәрҗемә итеп бирелә. В. В. Радловтагы "Идегәй" вариантлары Себер өчен Урал арты, Иделнең теге ягында иҗат ителгәненә дәлил булып тора.

Шулай ук, татар халкының мәгълүм галимәсе, Гаяз Исхакыйның кызы Сәгадәт ханым Чагатайның Хаймана авылында (Төркия) бер Кырым татары авызыннан язып алган "Әдигә"се *(Die Adiga-Sage von Saadet Cagatay(Ankara).–Ural-Altaische Jahrbucher. Forsetzung du Ungarischen Jahrbucher. Hevangegeben von Julias von Favkas. Band XXV, Heft 1-2, 1953. (Бу хезмәтне табып җибәрүе өчен "Азатлык" радиосы хезмәткәре мөхтәрәмә Фәридә ханым Хәмидкә олуг рәхмәтемне күндерәм)* безнең Себер вариантларына гаҗәеп якын икәнен әйтеп, узган гасыр башыннан бу көннәргә табан бер чигенеш ясыйк.

"Идегәй" дастанын, архив тузаннарын кагып-сугып, укып чыкканнан соң,

ниндидер бер ерак туганың чит-ят илләрдән әйләнеп кайтканын күргәндәй хис кичерәсең. Балачактан, әби-бабайларыңнан ул туганың турында нәрсәләрдер ишеткәнеңне шәйләгәндәй буласың. "Кем ул Идегәй? Ничәнче буын туганыбыз? Кайсы якларда йөргән? Нишләп озак кайтмый торган?" кебек сораулар да әйләнә башта. Ул кайсы яклары беләндер үзебезнең нәселгә дә охшаган, кай якларына сәерсенебрәк тә карыйсың. Көткән дә син аны, ишетеп тә беләсең, әле танымыйчарак, үз итмичәрәк тә торасың сыман.

1988 елның 14 апрелендә СССР Фәннәр академиясе Казан Филиалының Галимҗан Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият, тарих институты конференц-залында нәкъ шундый атмосфера хөкем сөрә иде. Бу залда Институтның ел йомгаклары турында, төрле юбилейларга багышланган фәнни конференцияләр еш булып тора. Зал тулыр-тулмастан булганда дәресләреннән алып, университет, пединститут талибләре чакырып китерелә. Бу көнне әлеге зал үзләре теләп килүчеләр белән шыгрым тулы иде. Аннан әз генә элек узган Ш. Мәрҗани хәзрәтләре 170 еллыгына багышланган фәнни конференция кебек бер мәҗлескә әйләнде ул. Аудитория дә ниндидер бердәм фикерле, әлеге "туганын" кайтару ният белән килгән кешеләрдән тора иде. "Кертмик ул килмешәкне", дигән уй берәрсендә булды микән? Хәлбуки, аңа хәтле "ул безнең халыкныкы түгел, монголлар әсәре", "ул Алтын Урда заманыныкы", ниһаять, "ханнар-феодаллар иҗаты" дигән фикерләр дә йөрмәде түгел. Бу утырышта да кайберәүләрнең: "Ул әсәр халык телендә таралмаган", "Гомумтөрки дастанны татарныкы дип була микән?"–дигән үтә дә сак карашларын әйтүгә зал: "Ник булмасын?", "Булырга тиеш",–дип дәррәү гөрелдәп алгалады. Ә бит бу әле фәнни конференция дә түгел, Г. Ибраһимов исемендәге Институт каршында оештырылган "Мирас" комиссиясенең чираттагы утырышы гына иде. Аның әүвәлге утырышларыннан берсе язучы Гаяз Исхакый әсәрләрен кайтару мәсьәләсенә багышланып, демократиянең саф җилләре исә башлавын сиздергән иде. Халык телендә дастанга әйләнгән "Кыйссаи Йосыф"ның дәү китап булып басылып чыгуы да әле 1984 елда гына зур, күңелле вакыйгага әйләнгән заман иде бу.

Илле ел чамасы "зинданда" яткан "Идегәй" хакында сүзне башлап, өлкән язучыбыз Әмирхан ага Еники: "Бу әсәрнең 1940 елда "Совет әдәбияты" журналында басылган вариантын укып, аның хәзер чыкмый ятуына сәбәп булырдай нәрсә тапмадым",–диде, шуның белән әсәрне бастыра башлауга юл ачты сыман.

1973 елда Институт архивындагы "Идегәй" вариантларын барлап һәм гомумэпос кануннарыннан чыгып, бу фәкыйрь алар турында бер белешмә шулай ук "Дастаннар" томына кертү өчен тиешле вариантларын сайлап әзерләп биргән иде. 45 битлек ул кулъязма "Белешмә" Мәскәүгә, Алма-Атага, башка галимнәргә җиткерелеп, шактый хезмәт итте фәнгә. Әмма 1974 елда академик В. М. Жирмунскийның "Тюркский героический эпос" дигән зур китабы басылып, анда "Идегәй" дастанына гомумтөрки эпос буларак, объектив бәя бирелсә дә, татар фольклорының 12 томлык тупланмасында 1984 елда дөнья күргән "Дастаннар" томыбыздан "Идегәй" төшереп калдырылды.

Әйе, "Алпамыш", "Манас", "Коркот", "Героглы" һ. б. дастаннарның да зинданга ташланмыш көннәре бар иде. "Алпамыш" һәм "Манас" кебек алып дастаннарны дөньяга чыгаруга В. М. Жирмунский, М. Әүвәзов, Һ. Зарифов кебек галимнәр инициативасы белән фәнни конференцияләр багышланды. "Китабы-дәдәм Коркот" академик А. Н. Кононов ярдәмендә китап булып чыкты. "Угыз эпос"ын кайтару эшендә Халык Гусейн угълы Короглы зур хезмәт күрсәтте. Күренекле төркмән галиме Баймбет ага Каррыев 25 елын тутыра язып сөргеннән кайтты. Сталин төрмәләрендә сәламәтлеге какшаган милләттәшебез Мәдинә Искәндәр кызы Богданова гомере Мәскәүдә нәкъ шул "Идегәй" дастаны буенча докторлык диссертациясе якларга йөргән көннәрендә үзелә. "Идегәй"нең җыйнама вариантын әзерләгән Нигъмәт Хәким үзе һәм аның әсәрен укып, кереш сүз язган академик А. Н. Самойлович та шәрекъ буенча зур хезмәтләре өчен якты дөньядан сөреләләр: *"habent suo fata libelli"*.

"Идегәй", "Манас", "Урак-Мамай" һәм "Бүрихан" дастаннарын "җәен телгә алсаң–яңгыр, кышын–көчле буран буласын көт тә тор", диелә халык ижатында.

Академик В. М. Жирмунский моңа игътибар иткән һәм андый ырымнарны камнау (шаманлык) күзаллаулары белән аңлата *(В. М. Жирмунский. Тюркский героический эпос.–Л., Наука, 1974–С. 496.)*. Әмма халык хәтерендә озак, нык саклана торган ниндидер авыр хәлләр чагылышы кайбер ижат жимешләренә шулай күчүе мөмкин.

Нигъмәт Хәкимнең "Идегә дастаны" дигән бу әсәре Татарстан Фәннәр Академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият, тарих институты Мирасханәсендә берничә нөсхәдә саклана.

Төп нөсхә–14х21,5 см.лы 43 биттән башланып, 137гә хәтле бит саннары сугылган

сызыклы дәфтәрдән гыйбарәт. Архив пагинациясе 2-49. Барлыгы–49 бит. Ике яклап куе шәмәхә кара белән матур гарәп имлясында язылган текст. Аңлатмалар бит астында бирелгән. Дәфтәрнең беренче битендә Казан дәүләт университеты доценты Якуб ага Агишев кулы белән: "Бу кулъязманы 1940 елның 19 октябрендә базарда сатып алдым; 1940 ел, 8 ноябрьдә ТАТНИИЯЛИгә бүләк итәм" , дип язылган *(МХ, ф. 52, оп1. сак. бер. 178).*

Икенче нөсхә–64 битле, яңалиф шрифты белән машинкада басылган. Анда "Казан пединституты доценты, журналист, язучы Нигъмәт Хәким (1889–1937) Ситдыйк Зәйнетдиновтан (1857–1927) элекке Тобол губ., Тара өязе, Еланлы авылында 1919 елда язып алган",–диелгән *(МХ, ф. 52, оп. 1, сак.бер. 167)* өченче нөсхә Институт фәнни хезмәткәре Салим Гыйләҗетдинов тарафыннан (1990 елда)кулдан кириллицага күчерелгән 176, 177 берәмлекләр саклана.

Әсәрне Якты дөнья йөзенә беренче тапкыр чыгару өчен гарәп хәрефле Я. Агишев нөсхәсеннән үзгәрешсез күчереп, бу фәкыйрь әзерләде. Н. Хәким мәгълүматларыннан аермалырак аңлатмалар В. В. Радлов, С. Будагов, Ш. Сами, Д. Тумашева һ. б. сүзлекләре, шулай ук, үзем себер татары буларак төшенүем буенча җәя эчендә курсив белән һәм бит астында * белән бирелде. Текстта булмаган сүзләр квадрат җәя белән өстәлде. Җыйнама өчен калкан итеп алынган Ситдыйк карт авызыннан диелүче себер сүзләрендәге кайбер төгәлсезлекләр аңлатыла барылды. Мәсәлән, "таң яру" (ату) һәм "күзегез айдын!" (якты) идиомалары, "кул тамырын тоту" (пульс буенча кәефне белү) "кул тамыры тарту"дан төзәтелде һ. б.

Н. Хәким "Идегә"сенең берәр нөсхәсе тагы кая да булса сакланадырмы (мәсәлән, А. Самойлович архивында), безгә әлегә мәгълүм түгел. Аңа "Кереш" нөсхәсен соратып, В. М. Жирмунский 1969 елда Хәмит ага Ярмигә хат язгач, Х. Ярми элек Казан пединституты татар теле һәм әдәбияты кафедра мөдире булган профессор Латыйф ага Җәләй аркылы әлеге "Кереш"не табып, Ленинградка җибәргән, һәм ул "Тюркологический сборник, 1972" дә Х. Ярми архивындагы нөсхәдән шактый аермалы рәвештә бастырып чыгарылган.

Сәхнә өчен "Идегәй"не әзерләгән Юныс Сафиуллин Н. Хәкимнең басылмаган әсәре эчтәлегеннән архив буенча нөсхаләре файдаланды.

Башкортстан Фәннәр Академиясе һәм БР "Мирас" татар милли-мәдәни Үзәге Н. Хәкимнең 110 еллыгына багышлап документ, материал һәм истәлекләр җыентыгы бастырып чыгарды *(Возвратим имя твое истории... Сборник документов, материалов и воспоминаний, посвященный 110 летию со дня рождения Нигмата Хакима.–Уфа, Гилем. 2002. 218 с.–Составители Мухаметов И. Ш., Аскаров Р. Р., Сакаев А. З..).*

Хәзер "Идегәй" дастанының академик басмасы Мәскәүдә М. Горький исемендәге Дөнья әдәбияты Институтында чыгып килүче "Эпос народов Евразии" Сериясе өчен Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият, сәнгать институты фольклорчылары тарафыннан әзерләнә. Ул Серия таләпләренә туры китерелеп, Н. Хәким җыйнамасының фәнни-идентик тәрҗемәсе шулай ук фәкыйрегез тарафыннан әзерләнде.

Тулаем "Идегәй" дастаны үзе фәндә, мәдәниятебез тарихында тиешле урынын ала бара. Композитор Резеда Ахиярова дастан сүзләренә көй язды. Рәссамнар Тавил Хаҗиәхмәтов һәм Рушан Шәмсетдинов иллюстрацияләр ясады. Язучылар Ренат Мөхәммәдиев, Ренат Харис, Галимҗан Гыйльманов һ. б. "Идегәй" дастанының Н. Исәнбәт җыйнамасын матбугатта бастыруга үз өлешләрен керттеләр. Нәкый ага Исәнбәт үз җыйнамасы өчен 34 чыганактан файдалануын әйтә *(Совет әдәбияты. 1940, № 11, 77–92бб.; 12, 97–98бб.).* Аның архивындагы "Омск өлкәсе Кушкүл авылы сельпо складыннан табылды" дигән вариант Н. Хәким җыйнамасына иң якыннардан булуы мөмкин.

Галимнәр тарафыннан да дастан төрле яклап өйрәнелә. Профессор Ф. Урманчеев ике монография чыгарды *(Фатих Урманче. Народный эпос "Идегей".–Казань, Изд-во "Фән", 1999. 200 стр.; Идегәй, Нурсолтан, Сөембикә.–Казан, "Таткитнәшр", 1997. 174 бит.).* Аның аспиранты В. Хәйруллина "Идегәй" эпосының тарихи нигезләрен тикшереп, кандидатлык диссертациясе яклады. Төрек галиме Фикрәт бәй Төркмән аспиранты шагыйрь Рәстәм Сүлти дастанны төрекчә Измирда (1998) бастырып чыгарды. Казанда чыккан татарча һәм русча басмаларына кереш вә соң сүзләр язып, И. Надиров *(Идегәй. Татар халык дастаны.–Казан. Таткитнәшр., 1988.–5-106б.)* һәм академик М. Госманов дастанның шигърият чараларына, тарихи урынын билгеләүгә игътибар юнәлтеләр *(Идегәй. Татарский народный эпос. Перевод Семена Липкина.–Казань, Татарское книжное изд-во, 1990.–С. 247–254.)*

Флора ӘХМӘТОВА-УРМАНЧЕ,
филология фәннәре кандидаты.

ИДЕГӘЙ ДАСТАНЫ

Туктамыш хан—Идегә би—Норадын—Кадыйр Бирде. 1388—1419 еллардагы вакыйгалар 1919 елда элекке Табул губернасы, Тара өязе, Еланлы авылында Ситдыйк карт Зәйнетдинов авызыннан язып алынган халык әдәбияты.

Нигъмәт Хәким.

I

Борын-борын заманда, Идел-Йаек буенда Туктамыш дигән хан үткән, гомер кичергән. Йорты зур, халыгы күп, малы мул булган. Күп патшалар ман *(белән)* сугыш кылган. Түрәләре, батырлары да күп булган. Халык көтеп, мал көтеп кенә калмаган, киек тә аулаган, кош та чөйгән. Күлләрдән каз, үрдәк, куулар да *(аккошлар)* чөйдергән. Боларны чөйдерү өчен кара лачыннары, бүз тойгыннары *(ак бөркетләр)* шоңкарлары булган.

Аучы кошларны асрау, аларны йомыркалату, балаларын чыгарту, балаларны чөйгәле өйрәтү өчен ханның үзенә аерым бер мырзасы булган. Бу мырза хан кашында *(каршында)* башка мырзаларга караганда иң якын бер кеше итеп саналган. Мырзаның аты *(исеме)* Котлы-Кая булган. Котлы-Кая асраган, ул өйрәткән кошларның даны бөтен дөньяга таралган. Бу кошларның үзләрен генә түгел, хәтта балаларын, йомыркаларын кулга төшерү өчен дә Котлы-Каяга төрле патшалардан яшерен илчеләр килгән. Күп акчалар, күп алтыннар биреп карасалар да, Котлы-Кая боларның берсенә дә бирелмәгән.

Көннәрнең берендә Төркестаннан илче килгән. Дөньяны күп күргән, чичән бер кеше икән. Котлы-Каяны моның татлы теле артык чөчөткән, кызыл алтын, ялтырап, артык кызыктырган булса кирәк, Котлы-Кая мырза кара лачынның ике йомыркасын алып "сатып" ийгән *(жибәргән—Н. Х.)*[1]. Лачын елына бары өчәр йомырка гына сала торган булган. Котлы-Каяда бер генә йомырка калган. Йомыркаларның юклыгы беленмәсен өчен, теге ике йомырка урынына Котлы-Кая ике бидаяк *(карчыганың бер төре)* йомыркасын куйган.

Күп вакыт та үтмәгән, моны ханга чакканнар *(житкергәннәр)*, бу эш ханга беленгән. Туктамыш хан тикшереп күргәннән соң бер кара лачын оясындагы ике йомырка бидаяк йомыркасы булып чыккан. Котлы-Каядан йомыркаларның кая киткәнен, бидаяк йомыркаларының кара лачын оясына ничек килеп кергәнен сораган. Котлы-Кая әйтмәгән. Туктамышның бик ачуы килгән сатып йибәрүгә. "Йомырка сатып мал тапкалы кызыккан Котлы-Кая ул хан хәбәрләрен, хан серләрен дә сатарга мөмкин,—дип зур шөбһәгә төшкән Туктамыш хан.—Мондый кешенең яшәве минем өчен зур бәла булыр",—дип уйлаган. Котлы-Каяны бөтен өй эче мән үлтерткәле хөкем кылып, илгә хәбәр салган. Калганнарга зур гыйбрәт булсын, дип бөтен илне колакландырган *(ишеттергән)*.

Котлы-Каянын якыннарыннан булган Йантимер аталык моны ишетү мән яхшы нәселнең токымын өзмәс өчен берәр баласын яшереп калу чарасына керешкән.

---

[1]Аерым сүзләргә Нигъмәт Хәким тарафыннан бирелгән аңлатмадан соң җәя эчендә аның инициаллары (Н. Х.) күрсәтелде.

Хәйләне тапмый куймаган. Котлы-Каяның Идегә атлы бишектәге имчәк баласын алып, анын урынына үзенең Кобогыл атлы баласын салып калдыргалы булган. Шул ук мәлдә шуны эшләп тә өлгергән. Озак та үтмәгән, ханның хөкеме йиренә йиткерелгән. Котлы-Кая бөтен өй эче мән астырылган.

Моннан соң күп кенә сулар аккан, йилләр искән, көннәр, айлар, еллар үткән. Йантимер аталыкта калган "Кобогылда йиде-сигез яшьләренә йиткән, Йантимер аталыкның аяклы малларын көтә алырлык хәлгә килгән. Анарга көтүче булып, утлыкта *(көтүлек)* мал утлаткалы *(үлән ашатырга)*, мал баккалы йарай башлаган.

Идел буендагы күлләрдә кыр казлары, кыр үрдәкләре, куулар бик күп булган. Кайбер кошчыларның аулауларын-чәюләрен күп мәртәбәләр күргән Кобогылда да кошчылык дәрте кузгалган. Атасы Котлы-Кая кебек Кобогыл да кош чөйгәле өйрәнгән. Ул моңарга бик әвәс булган. Кара лачыннар, бүз тойгыннар, шоңкарлар чөйгәле ярата торган булган.

Садагын алып, урман, дала йөреп, уклар ман сыкыр *(ана поши)*, киекләр *(ата поши)* аткалы, ауга чыккалы да бик яраткан.

Зур йиеннарда әйтешкән чичәннәр мән авыз көрәштергәле, йыраулар ман йырлашкалы да әвәс булган, дәртле булган, чичәннәрнең, йыраулардың күбесеннән өстен дә чыга башлаган.

Көрәшче батырлар ман көрәшә, аларның иң көчле, иң осталары ман да алыша башлаган. Кобогылның аты-чабы илгә тарала, телләрдә сөйләнә башлаган. Илнең иң өлкән кешеләре дә моны айбарламый *(абайлау)* калмаганнар, үзенә аларның да игътибарларын тарткан. Шуннан соң аны өлкәннәр йыелган йыеннарга да чакыргалай башлаганнар. Данлыклы чичәннәр, атаклы йыраулар белән ярыштырып күргәннәр. Ил көтүгә караган эшләрдә дә йәйәсен (*тенгелен*—Н. Х.) тартып караганнар. Кайбер кечерәк орышларга катнаштырып та сынаганнар. Йегет боларның берсендә дә сер сынатып сыртка төшмәгән, барысында да алдын чыккан.

II

Кобогылның егетлеге, анын алгырлыгы *(зиһенлелеге)*, батырлыгы кебек эшләре Туктамыш ханга да бик ошаган. Аны үзенең сарай сакчылары янына чакыртып алган. Моңа да сарай сакчыларына төбәлгән киемнәр, атлар һәм башкаларны биргән. Үзенә төбәп кайбер эшләр дә тапшырган.

Явырыннары *(калак сөяге)* каймалы,
Төймә бавы тартмалы
Ал кара кеш тун бирде:
"Моны өстенә ки!"—диде.
Күгала юрга ат бирде:
"Аны иярләп мен!"—диде,—
Күн давылбаз (барабан) бәйлән,—диде,—
Очан (ике канатлы көймә) ман динғезне әйлән,—диде.
Тотам бавы (кош аягына бәйләнгән тасма) сум алтын
Ак шоңкар кош та бирде: "Күл әйләнә чөй!—диде,—
Әй, Кобогыл би,—диде. Кырымнан кыен дау килсә,
Түрәсен (чишелешен) шуның бир,—диде,—
Кырымнан калын яу килсә,
Кобогылым, шуны кыр,—диде.

Кобогыл Туктамыш хан йомышын йомышлагалы тотынды. Кырымнан килгән яуларны да, Кырымда калган яуларны да бастырды. Туктамышның үзе мән Мәскәү өстенә йөреп тә килде.

Сарайдагы башка биләр Туктамышның янына хәл сорашкалы кергәне кебек Кобогыл да керәдер иде. Хан, башка биләр кергәндә урыныннан кузгалмаса да, Кобогыл кергәндә аяк өстенә торып, ачык йөз мән каршы аладыр иде. Ханны Кобогылның тыны, мәһабәте басадыр иде, ул килеп кергәндә хан үзе дә сизмәстән торып киләдер иде. Кобогыл үзенең мәһабәт күренеше, карчыга күзе кебек күзе мән караса, кешенең эче чымырдап китәдер иде.

Кобогыл халык кашында гына түгел, хәтта Туктамыш кебек өлкән хан кашында да зур хөрмәт казанган иде.

Кобогыл якын дуслары анын Йантимер улы Кобогыл булмаганын, бәлки

Туктамыш тарафыннан үтерелгән Котлы-Кая улы Идегә икәнен беләдер иде. Котлы-Каяның нәселе бер яктан дөньяның ин өлкән, иң изге шәехләреннән булган Баба Түкләскә, икенче яктан хәзрәти Әбүбәкергә барып тоташкан. Менә шуның өчен дә халык аны үз эшенә карап гына ардакламый *(олылау)*, бәлки, бабаларының изгеләрдән, өлкәннәрдән булуларына карап та ардаклайлар иде.

III

Кобогыл Туктамыш ханның йомышларын үтәп, аның боерыкларын йиренә йиткереп йөрсә дә, аны олыласа да, ил көтү эшләрен яратмый башлаган иде. Моның өстенә Кобогыл үзенең атасы Котлы-Каяны үлтергәне өчен Туктамыштан үч алгалы, атасының конын *(кан үче)* алгалы да уйлаштыра башлаган иде. Шуңа күрә Кобогыл Туктамышның ил көтү эшләре ничек барганын, аның нәрсәгә таянганын, дуслары, дошманнары кемнәр булганын яхшы тикшереп, өйрәнеп барадыр иде.

Кобогылның аты-чабы шулкадәр үсте, хәтта Туктамыш хан үз урынына Кобогыл хан булып ултырудан да шикләнә, курка башлады. Кобогылны монарчы күтәргән Туктамыш соңгы вакытларда аның дәрәҗәсен төшерү, аның атын-чабын сүндерү турысында гына уйлай башлады. Монарга хәйлә табылмыйча теңкәсе корыды. Бара торгач, Туктамыш хан өнендә генә имәс *(түгел)*, хәтта төшендә дә Кобогыл ман саташадыр иде.

Төннәрнең берендә Туктамыш хан бер төш күрде: төшендә бер тулы ай янында ун йолдыз күрде. Йолдызларның тугызы караңгырак, тоныграк янадыр иде. Арадан берәүсе айдан да яктырак булып янадыр, яктырадыр иде. Туктамыш йокысыннан уянгач та шул төшен ничек юрагалы уйлай башлады. Уйлана торгач, йурагын тапты. Тугыз йолдыз—сарай катындагы тугыз би булгалы, тулы ай—үзем булгалы, тулы айдан да яктырак янган йолдыз Кобогыл булгалы кәрәк, диде.

Кобогыл турысында ханышларына киңәшеп күрде. Ханышлары: "Башка биләр кергәндә аякка торып каршы аласыз. Аның белән сезнең тыныгыздан басым булганын күргәзәбез. Ул кергәндә азаматыгызны югалтасыз. Ни дә булса бер нәмә бар",—диделәр.

Кобогылдан шөбһәләнгәне күнеленә ултырып йитте. Аның ата-бабаларын, ханга карашын белгәле кәрәк тапты. Аның турысында яман хәбәрләр йийнагалы кәрәксенде. Зур йыен йийнагалы булды.

Йәй көне иде. Ак сөякләрдән үзенең сарай түрәләрен, тирә-йүн түрәләрен йыйдырмак булды. Кара сөякләрдән, кәттә йыраулардан, чичәннәрдән дә кешеләр чакыртты. Сарайдан читкә, бер су буена чыгарып, йөз алтмыш утау *(аерым тирмә, өй)* тектерде, күрәгә-күрәгә баллар койдырды, ту бияләр, зур үгезләр суйдырды. Мең чырак кандил яктырды. Зур бер аш-су, эчке-уен мәжлесе ясатты. Мәжлес башланды. Ирене юка сараяклар, кадәхләр белән тулган бал йолдызлары күрәгә тирәсендә бер туып, бер батарга башлады. Кубызлар кубзайды, сорнайлар сарнайды, йырлар йырланады, биюләр биеләде. Ханны күкләргә күтәреп мактаулар барады. Мәжлес кайнайды, гөж киләде.

Туктамыш аякка торды. Гөж килгән мәжлеснең игътибарын башка мәсьәләгә борды. Ул, мәжлескә карап хәйләле көләч йөз, йомшак матур сүз белән бер мәсьәлә салды: "Зур биләрнең, данлы батырларның хан мәжлесенә ямь-тәм бирүләре мән котлаем. Мәжлескә йан биргән атаклы йыраулар, кубызчы, сурначылар катнашулары ман котлаем. Бигрәк тә күрәгә төбендә бал коеп кунакларны сыйлаучы, зур хөрмәт казанган Кобогыл кебек кешеләрнең булуы ман котлаем һәм үземнең чиксез-кырыйсыз шадлыгымны белдерәм: hурра, hурра!—Хан сарае тирәсендәге биләрнең кайберләрен бер урыннан икенче урынга күчергәле, кайберләрен түмән (*түбән*—Н. Х.) дәрәҗәдән югары дәрәҗәгә күтәргәле уйлаем. Моның өчен мина кайбер кешеләр турысында, мәсәлән, угланнар турысында бигрәк тә Кобогыл турысында кайбер мәгълүматлар ишеткәле кәрәк. Сүзне Кобогылдан башлагалы кәрәк. Кобогылның яхшы эшләре, егетлекләре һәркемнен күз алдында. Бу турыда сүз ачу артык булар. Аның ата-бабасын, токымын белгәле кәрәк, аның киләчәктә тагын да ниндәй уңышлар эшләй алачагын белгәле кәрәк. Бу турыда белгәнләрнең тулгап бирүләрен сораем",—диде.

Мәжлестәге кешеләр арасыннан Кобогылның Идегәй икәнен, аның ата-бабасын яхшы белгән кешеләр булса да, эшнең кая барачагын сизенделәр булсалар

кирәк, ханның теләгәнен берсен дә әйтмәделәр. Әйткәле теләгәннәрнең дә авыз ачкалы батырлыклары йитмәде, халык бер авыздан "Кобогылның үзен белсәк тә, аның ата-бабасын белмибез",—дип кычкырдылар.

Туктамыш хан болай сорап кына эш чыкмаячагын күрде дә белмәгән, белергә мөмкин дип уйлаган кешеләреннән аерым-аерым атап сорашкалы башлады:

Туктамыштай өлкән хан
Ал ягына карады:
Яулыкчым да минем, комганчым,
Яу күргәндә байракчым,
Яза бәрсә (ялгыш язса), казначым,
Яулыбаем, син тулгачы,—диде,
Тулгап-тулгап күрде дә
Хан кәефенә якмады,
Күңеленә батмады,
Синнән булмады,—диде,
Туктамыштай өлкән хан
Уң ягына карады:
Иңсәңә суксам иңкәймәс,
Искене бирсәм кәкләмәс (хаһламас—хуш күрмәс)
Исәнтәй углы Ходай-Бирде
Батырым, син тулгачы, дип иде.
Ул да торып тулгады,
Хан күңеленә якмады,
Күңеленә батмады,
Синнән дә булмады,—диде.
Туктамыштай өлкән хан
Сул ягына карады:
Ынраучым да минем, моңраучым,
Яхшы көндә йырлаучым,
Яман көндә бузлаучым,
Туктар углы Тугача (Тугуча, Туй-хужа)
Син тулгачы,—дип иде.
Тулгап-тулгап салды да
Хан кәефенә якмады,
Күңеленә ятмады,
Синнән чыкмады,—диде.
Туктамыштай зур бер хан
Сырт ягына карады:
Карт куяндай кашкарган,
Кап-караңгы төннәрдә
Сансыз колны башкарган,
Көн дә сөңге сындырган
Ир күңелен тындырган,
Алмаган яу куймаган,
Эчсә, канга туймаган
Ак балтырлы Уагым,
Монҗон углы Чуагым,
Икәвең бергә тулгачы!—дип иде.
Кул кушырып тордылар,
Тулгап-тулгап салдылар.
Болары да якмады,
Хан күңленә ятмады,
Сездән дә булмады,—диде.
Туктамыштай зур ханлар
Аптырады, йөдәде,
Ян-ягына карады да:
Бу йыенның эчендә
Кемнәр бар да, кемнәр юк,
Аптыраган көнемдә
Тулгамага кешем юк!—дип,
Мәҗлескә үпкә сүз ташлады.
Нугай илнең агыр *(зур)* йорт
Аптырауда әйләнде,
Әйләнеп киңәш тапмады.
Башкалар тулгавыннан канмаган

Туктамыш хан үзенең сарай мырзасы, сарай йыраучысы Янбайга күз текте:

Киң эшемнең алды иден,
Киң сабамның *(кымыз савыты)*
куры *(кымыз төбе)* иден,
Аптырап, йөдәп торганда
Киңәшләр тапкан син иден,
Кәмал углы киң Янбай,
Булса синнән булыр,
Тулгап бирсәнче!—диде.
Янбай тулгады:
Син дә белмәс эш икән.
Мин дә белмәс эш икән;
Унике мырза агасы
Кыпчак белмәсме икән?
Белсә белер—ул,—диде,
Өмид андадыр,—диде.
Туктамыш хан тәхеттән торып:
Әй, Кыпчак би, син белер икәнсең,
Нигә миңа әйтмәдең?—диде.
Кыпчак би торып тулгады:
Әй, ханым, иям, түрәм!
Мин дә белмәс эш икән,
Син дә белмәс эш икән.
Нугай иле тапмастай,
Бу бер авыр төш икән.
Камнаудай башы кашкарган *(агару)*,
Кондыздай теше саргарган *(саргаю, сирәгәю)*
Чокчытлары *(янак)* бушаган,
Йөз туксан яшь яшәгән
Сабрау дигән йырау бар,
Моны белсә ул белер,—диде.

Сабрау сарай тирәсеннән ерак булган далада, берничә көнлек юлда торадыр иде. Туктамыш хан: "Сабрау белсә, аны алдырмак кәрәк, сыбай илче йибәрмәк кәрәк"—диде. Мәҗлес Сабрау килгәч йыелмакчы булып таралды. Хан боерыгы буенча Сабрауга ат кушлатып *(пар ат жигеп)* сыбай *(атка менгән кеше)* илче йибәрелде:

Илче атка менде, ди,
Юрта-чаба китте, ди.
Сабрау дигән ерауга
Алты көндә йитте, ди.

Илче Сабрау янына керде, аны картлыктан түшәктә яткан күрде. Элек Туктамыш ханның сәламен әйтте. Исән-саулыгын, мал-жан аманлыгын сорашты. Болар соңында Туктамыш ханның Сабрау йырауны зур мәжлескә, туйга чакыруы, ат йибәргәнен әйтте, баруын үтенде. Ләкин Сабрау йырау үзенен артык картайганлыгын, сыбай йөри алмаганлыгын әйтте. Илче эшнең болай гына булмаячагын аңлап, кире кайтып китте. Туктамышка икәнен аңлатып болай диде:

Сабрау дигән йырауның
Атка менәр хәле юк,
Менсә, төшәр хәле юк.
Картайган, әмәле юк.
Йөз туксан яшь яшәгән,
Азулары (яңак) какшаган,
Буынлары бушаган,
Мөчәләре (бил, гәүдә) йомшаган.
Атка менәр хәле юк,
Менсә, төшәр хәле юк,—диде.

Моны ишетеп, тыңлап торган тәжрибәле Янбай Туктамыш ханга карап:

Әй, ханым, иям, түрәм!
Атка менеп килмәстер;
Менсә дә килә белмәстер.
Алты кара ат тоттырсаң,
Алтынлы көймә йиктерсәң,
Күп түшәкләр түшәтсәң,
Мамык ястыклар ясатсаң,
Ике нүгәрең (дус, ярдәмче) ултыртсаң,
Сабрау килмәсме икән ай,—диде.
Туктамыш хан боерды:
Алты кара ат тоттырды,
Алтынлы көймә йиктерде,
Күп түшәкләр түшәтте,
Мамык ястыклар ясатты,
Ике нүгәрен утыртты.
Сабрау йырауга йилдертте.
Юрта-чаба киттеләр,
Сабрауга барып йиттеләр,
Түшәктә яткан Сабрауның
Өенә кереп киттеләр.

Сабрауга барып кергәннән соң, исән-саулык, мал-жан аманлык сораштылар. Ханның сәламен, хәбәрен әйттеләр. Ханның:

Алты кара ат тоттырып,
Алтынлы көймә[1] йиктереп,
Күп түшәкләр түшәтеп,
Мамык ястыклар ястатып,
Алгалы йибәргәнен әйттеләр.

Сабрау өши-өши түшәктән тора килде. Баргалы булды. Йөз туксан яшь яшәгән, буыннары бушаган, чокчытлары какшаган икән. Чокчытларын бүз мән урап, өстен тунандырдылар *(тун кидерү)*, билен кушак ман будылар. Арышына *(тәртә)* сиятләр *(бизәк)* тактырган, ян-ягына гөлләр түктергән көймәгә култыклап чыгарып утырттылар. Сабрауның юлга чыкканын хәбәр бирү өчен ханга алданчабар юлладылар. Туктамыш хан Сабрауның килү хәбәрен алу ман мәжлесне йийдыргалы боерык бирде. Сабраулар килүләрендә дәвам итте.

Алты ай йиккән кушы ман
Юрта-чаба китте, ди.
Алты суның буенда
Куна-кичә йитте, ди.
Туктамыш хан олылап,
Каршы чыгып алды, ди,
Түр башыннан йир биреп,
Мамык ястыкка ултырып,
Исән-саулык, малларын—
Барын сораша калды, ди.
Сабрау артык карыган,
Карылыктан юл килгәндә арыган,
Ишеткәле хәле юк,
Сөйләшкәле хәле юк,
Тамакланып алмастан,
Бернигә әмәле юк.
Сабрауны тамакландырып,
Тыналдырып *(хәл кертү)* аласы бар.

[1]Өсте ябулы арба йә чана.

Ирне юка сараяк ман *(савыт—чара+аяктан)*
Хан иям бал бирәде,
Сабрау аны алады,
Алады да салады.
Сабрау карыган *(картайган)* икән,
Юлда арыган икән,
Сөйләшкәле хәле юк,
Дәрте бар, дәрманы юк.
Уң ягыннан бирәделәр,
Сул ягыннан бирәделәр,
Сабрау йырау алады,
Алады да салады.
Бал карынга төшәде,
Карын балдан пешәде,
Карт Сабрауның йөзләре
Бераз аллана төшәде.

Туктамыш хан Сабрауның көл йөзләренә кызыллык йөгерә башлаганын, тонган күзләре яктырып ялтырый башлаганын күрәде, аңа хәл кергәнен сизәде. Туктамыш хан Сабрауны аулак урынга алып чыгады. Аны чакыртудан үзенең теләге нәрсә булганын аңлаткалы булады... "Миңа Кобогылның халык арасында ачык эшләгәннәре барысы да билгеле. Анысы турысында сөйләшүнең мәнесе *(мәгънәсе)* юк. Миңа башка нәрсә кәрәк, Кобогылның ата-бабасы, аның кем углы булганын белгәле кәрәк, миңа яман караштамы-юкмы икәнең белгәле кәрәк. Аның батырлыгы ни дәрәҗәгә йитәчәген белгәле кәрәк. Ишетелгән хәбәрләргә күрә, аның миннән атасының үчен алгалы уйлаганы да сизелде. Аның атасы ман минең арада нәрсә бардыр, мин аның атасын белмәем. Шуны беләсе иде. Аннан соң ул минең сарайда берничә елдан бирле би иде. Мин Төркестанга орышка киткәндә ул үзе урынына Тимер-Котлык дигән бер яшь егетне калдырып, минең янга килгән иде. Соңгы көннәрдә ул үз урнына шул егетне утырткалы теләйде. Хәлбуки, сорашканның соңында бу егетнең Тимермәлик углы икәне беленде. Аның атасы минең тарафтан үлтерелгән бер кеше булып чыкты, монысы билгеле. Кобогылның гына кем икәнен белеп булмайды. Аны белгәндә, төенле серләр тиз чишелер иде. Мин аны син беләсең дип ишеттем. Син аның кем углы икәнен мәжлестә тулгагалы, ачкалы кәрәк, буш кул калмассың",—диде.

Туктамыш Сабрауга тагын бал бирәде. Сабрау алады да эчәде. Бераз уйланып утыргандан соң Сабрау телгә киләде:

Иделдә булды сигез хан,
Йаекта булды тугыз хан.
Эре ханның уагы,
Уак ханның эресе.
Карт бабаң да хан иде,
Алымы синдән аз иде,
Биреме синдән күп иде.
Тулга да тулга, дисез,
Ерла да ерла, дисез,
Мин ерласам сезләргә,
Ни бирәсез безләргә?—
Диде карт ерау.
Туктамыш хан әйтте:—
Ал кара кеш тун бирәен мин сина,
Сайлап алып кияр булсаң, ераучым,
Кыңгыраулы күк карчыга бирәен,
Күл кандырып чәяр булсаң, ераучым.
Алпан да тилпән йөгертеп,
Адымын йирдә куыртып,
Аргамак ат бирәен:
Камчы тартмай менәр булсаң, йыраучым.
Кузыкайдан артык ару бар,
Күзекәйдән артык сылу бар,
Аны да алып бирәен,
Уң йиреңә ултырып,
Яшь баладай аркасыннан
Кагып-кагып сөяр булсаң, ераучым,—
диде.

Сабрау килгәннән соң, йыелгалы булып таралган мәжлес, ханның боерыгы ман тагы йыелды. Мәжлес тайяр *(әзер)* булды. Мәжлес тайяр булганнан соң, Сабрауны алып Туктамыш хан да мәжлескә керде. Бераз тамакланып алган соң, бал мәжлесе башланды. Мәжлес күгендә баллы йолдызлар бер туып, бер батарга, күрәгә тирәсендә әйләнергә, йемелдәшергә башлады. Кубызлар кубзарга, сорнайлар сарнарга, чалгылар чалынырга башланды. Ханны күкләргә күтәреп йырлаулар китте. Мәжлеснең күтәренкелеге халыкны канатландырып, очар хәлгә йиткерде. Аяк очыннан гына басып ялгыз биюләр, күмәк биюләр китте. Биючеләрнең аяклары

кубызларның кылы ман, сорнайларның теле мән тоташкандай баса башладылар. Мәжлес гөж киләдер иде. Бу вакытларда Сабрауның кан тамырлары да яхшы гына тибәдер иде. Үзендә көч, дәрт сизенә башлаган иде.

Мәжлесне күзәтеп барган Туктамыш аякка торды. Мәжлес Туктамышның авызына карап тынлыкка калды. Шылт иткән тавыш та калмады. Туктамыш Сабрауга карады. Халыкның бөтен игътибарын Сабрауга юнәлдерде.

Супы *(саф, олы, шәп)* аяклы,
супы бүрекле *(биек, зур бүрек)*
Супы арасында супы ерау,
Күпне күргән, күпне белгән
Ардаклыбыз Сабрау
Үзенең янына өч батырны чакырды, ди.

Батырлардан өч кеше Сабрау янына киләде. Сабрау баллы сараякны кулына алып күтәрәде дә: "Кайсыгыз батыррак булса, бу балны шул алып эчсен!" ди. Балны Кобогыл алып эчәде.

Сабрау: "Афәрин, углым, батыр икәнсең! Син әгәр ханың өчен батырлык итә торган булсаң, ничек батырлык итәр иден?"—диде.

Кобогыл әйтте: "Кала бозармын, казна китерермен",—диде.

Сабрау: "Әгәр ханга дошманлык итсәң, ничек батырлык итәр иден?"—диде.

Кобогыл әйтте:

Арсаеп (мәгъруренә) атка менәрмен,
Карчыга булып очармын,
Куып барып басармын—
Башын алып канҗагама *(күн кап—иярга бәйләнә)* асармын.
Казнасын алып илгә,
Ханлыгын алып бигә бирермен.
Мин дигәнне кылармын,
Әгәр дигәнемне кылмасам,
Атамның хәрам углы булырмын,—диде.

Сабрау Кобогылдан бу сүзләрне ишеткәннән соң, мәжлестәге халык алдында Туктамышка карап йырлайды:

Мин картыңмын, картыңмын,
Йөз туксанга тартыммын,
Йөз туксан яшь эчендә
Ни күрмәгән картыңмын.
Дөмбер, дөмбер, Дөмбер хан,
Аны күргән картыңмын,
Аблак хан, Азак хан,
Аны күргән картыңмын.
Колакчынлы Колга хан
Аны күргән картыңмын.
Олы бабаң Тумбаул,
Аны да күргән картыңмын.
Унике тотам ук тарткан,
Тартканда өзә аткан,
Тимер уктай Чыңгыз хан,
Аны да күргән картыңмын.
Өзәңгесе өзмә алтын,
Бер үрмәсә мең алтын
Үзбәк дигән хан үткән,
Аны күргән картыңмын.
Ябулары йәймә алтын,
Бер шайманы *(ярак)* чын алтын,
Манарасы кырык колач
Жанбак дигән хан үткән,
.....[1]
Аны күргән картыңмын.
Карт бабагыз Туктага,
Аның углы Туйхужа
.....[2]
Аны күргән картыңмын.
Әҗәл туры килмәсә,
Азраил корык салмаса,
Әле дә булса, Туктамыш,
Синнән дә калыр картыңмын,—

дип, Сабрау халыкның бөтен дикъкатен үзенә тартты. Чыңгызның аталарыннан башлап, үзенең күргән ханнарын искәртеп чыкты. Туктамышның озак яши алмаячагына да ишарә кылды. Сабрау боларны әйткәндә, Кобогыл йыендагы халыкка күрәгә төбендә бал коеп утырадыр иде.

Сабрау сүзен Кобогылга борды:

Чыкмаган жан йөргәндә,
Йөз туксанга килгәндә,

[1],[2] Нигъмәт Хәким кулъязмаларында бу юллар юк—Ф.Ә.-У.

Кобогылдай ирләрне
Һич күрмәгән картыңмын.
Артыннан килеп карасам,
Каһәрдән пәйда булгандай.
Яныннан килеп карасам,
Еланнан пәйда булгандай.
Алдыңнан килеп карасам,
Нурдан пәйда булгандай син!

Әй, углым! Син кем угланы буларсың?
Әйтсәңче, карт бабаңа!,—диде.
Кобогыл әйтте:

Әй, ата!
Үз атамны сорасаң,
Нәдеркая би иде,
Нәдеркая атасы
Кадиркая би иде,
Кадиркая атасы
Тирмәкая би иде,
Тирмәкая атасы
Газизкая би иде.
Газиз җәриз[1] күп газиз бар,
Барын сорап нитәсең?
Төп атамны сорасаң,
Баба Түкләс Чәчле Газиздер иде,—
диде.

Бу вакытларда Туктамыш ханга бал яхшы ук кына тәэсир иткән иде. Идегәгә булган яман караш эчтә генә саклардыктан үтеп барадыр иде. Аның яман карашы йөзенә дә чыккан иде. Идегә һәм аның тугыз иптәше мәҗлестәге эшнең кая таба барганын күзәтеп торалар иде. Сабраунын сораулары ханның яшерен боерыгы ман барганы, Кобогылның Янтимер углы Кобогыл түгел, бәлки Котлы-Кая углы Идегә икәнен, атасының үчен алгалы тайярланганын ачуга таба барганын сизделәр. Качмаганда тиздән үлем булачагын анык белделәр. Ләкин ничек чыгып сызарга? Аның да хәйләсе уйлап елгерелгән иде.

Күрәгә төбендә бал коеп утырган Кобогылга сараяклар бер-бер артлы әйләнеп килеп торалар иде, бал койдыргалы Кобогыл үзенең уң ягына карап, уңындагыларга бал коеп торганда, ханның вәзире Янбай ерау сараякны Кобогылның сул як колак төбендә генә тотып, аерым ашыгыч тавыш ман: "Кобогыл! Кой әле тиз генә" дигәндә: Кобогыл кинәт борылып караган булып, Янбайның сараягына борынын бәреп канатып: "Һай, борыным канады", дип тас сорады борын канатырга. Янбай тиз генә алып килде дә борынын таска тоттырып, тас ман бергә тышка алып чыкты. Тиз качкалы кәрәклегенә ишарә кылып, [Янбай]:

Табаны ялпак Тарлан бүз
Төн катуга көн сиңа.
Өстендәге камка *(биредә: камчат)* тун
Түрдә утырган биләргә,—

диде дә, мәҗлескә кереп, Идегә урынына ултырып бал коя башлады. Идегә һәрбер сулышын, вакыт үткәрмәстән, үзенә тайярланган Тарлан бүзгә таба атты. Бер аягы бусагага тигәндә, икенче аягы Тарлан бүзнең өзәңгесенә тиде. Артыннан чыккан буран ман күтәрелгән тузан бер сулыш эчендә кара төндә ак йеп булып сузылды. Идегәне юлда көткән иптәшләре дә кушылды. Халык әле Кобогыл койган балны эчә иде. Сабрау Кобогылның тайганын сизенгән хәлдә үзенең Кобогыл турысындагы сүзен дәвам иттерә иде:

Әй, ханым, иям, түрәм!
Әйтмәсәм мин, әйт дисең дә куймайсың,
Әйткәле авызым бармайды,
Бармаса да әйтәен:
Кара лачын, бүз тойгын—
Икесе ике оянын кошы икән,
Аларны остауларына *(тотучы)* тоттырып,
Бер тур *(кош кундыра торган)* агачка кундырдын.
Үзеңнең алдында ике егет бар:
Берсе аның олы угыл,
Берсе аның кече угыл.
Аргы угыл да бирге угыл,
Батыр икән олы угыл.
Куллары озын күренә,
Мәргән икән олы угыл.
Тарлан бүзне иярләп,
Ботка тартып менәр ул,
Ике саклык турыны

[1]Җәриә *(текстта: җәриз)*—кыю, батыр, куркусыз.

Олауга йайдак алыр ул.
Ач көзәндәй бөгелеп,
Ач бүредәй чыелдап,
Читәнендән кыйкулап *(һай-һулап)*,
Аччы сөрән салыр ул.
Ала-кола малыңа
Каулап корык салыр ул,
Ансыз кузы, сансыз куй,
Күп гаскәре туйсын дип,
Суеп казан асар ул.
Алтыннан суккан урдаңны,
Көмештән суккан ишекне
Төсе суык чын булат
Очы ман тиз ачар ул.
Кисмә-кисмә сары алтын
Кисеп улжа итәр ул,
Кашыклап йыйган малыңны
Соскалап чәчеп бетәр ул.
Кола чәчең агартып,
Ике күзең кызартып,
Картайганда илеңнән
Сөрән салып куар ул.
Кузыкайдай аруны,
Күзекәйдәй сылуны
Уң ягына ултыртып,
Үбә-коча сөяр ул.
Картмын, кеше танырман,
Әгәр кеше танысам,
Котлыкыя би углы
Идегәй ул—олы угыл,—диде.

Сабрау әйтеп биргән соң моңача Кобогылның ата-бабасын яхшы белгәннәр дә белде. Кобогылның Янтимер углы Кобогыл булмаганын, бәлки Котлы-Кая углы Идегә икәнең аңлады.

Туктамыш хан сакчыларына Идегәне борын канатып торган йирдән тотып алып кергәле боерды. Халык: "Йа, Ходайа, ни булады инде"—дип, шул минутта зур бер вакыйга булуын көтеп, дәһшәт алдында калды. Халыкның күзе Идегәне алып керәчәк ишеккә тегәлде. Сакчылардан берничә кеше йөгереп кереп, хан алдына тезләнеп: "Йа, ханым! Бөтен йортны актардык, Идегәне тапмадык. Ни эшләгәле боерасыз?"—диделәр. Туктамыш шашар хәлгә килеп: "Ни эшләргә, ничек кулга төшерергә"—дип, аптырау алдында калды.

Сабрау:

Ялгыз ерак китмәстер,
Иделдән ары үтмәстер,
Тугыз ирне йибәр дә,
Алдап-йолдап кашыңа ал,
Кашыңа ал да, башын ал!
Исән-аман китсә ул,
Иделдән ары үтсә ул,
Шаһтимергә китәчәк,
Шаһтимерне алып килеп,
Сарайны харап итәчәк,—диде.

Туктамыш нишләгәле белмәстән: "Кемне йибәргәле кәрәк, кем алып кайта алыр?—диде.

Биләр: "Янбай, Янбай аның дусы!—диделәр.

Туктамыш: "Янбай, тиз булгын, син бар, син алып кайт!"—диде һәм:

Әй, тугыз ир, тугыз ир,
Янбай ман тиз бара күр,
Алдап-йолдап Идегәне
Үз кашыңа ала күр.
Алдап-йолдап кашыңа ал,
Кашыңа ал да, башын ал!—диде.

Янбай бик ашыгып тугыз ир мән Идегәне кугалы өйдән чыкса: иярләнеп саклыкта торган атларның барысының да өзәнгеләре киселгән, түшлекләре, аеллары, *(ынгырчак бавы, ызма)*, коешканлары *(иярнең арткы башы)* кыркылган табылды. Нишләптер, аерым торгангамы, Янбай атына гына тиелмәгән иде. Кугын тиз генә китә алмады. Ат иярләп тә вакыт үткәрелде.

Янбай үзенең тугыз куары белән иң яхшы аргымакларга менде дә ярым караңгы төндә бер генә күренеп калды. Атларның тезгеннәрен бушатып, бөтен чабышларына куйдылар, йиргә тимәгәндәй очтылар. Ләкин Идегәне Иделнең бу ягында күрә алмадылар. Идегәләр күптән инде, көн туган вакытларда ук Иделне чыгып, ярның башында тын алып, атларны утлатып яталар иде. Сарайдан тел алып киткәле *(яшерен хәбәр алу—Н. Х.)* көтәләр иде.

Идегәләргә Иделнең артта калган ягыннан, ерактан төтендәй күтәрелгән тузан күренде. Тузанның Идегәләргә таба сузыла килгәне беленде. Ләкин Идегә дә, аның иптәшләре дә моннан курыкмады. Кугыннын килеп йиткәнен көттеләр. Кәрәк була калса качкалы, атышкалы да тайярланып куйдылар.

Кугын аһалга төшеп *(биредә: шушы жир, бу урын)*, Идегәләр турысына килеп

йитте, ләкин Идегәләр күптән инде Иделнең икенче ягында, аргы ягында иде. Кугынның саны да ун кеше, качкыннар саны да ун кеше, ләкин качкыннар көчлерәк булганлыктан, кугын Иделнең аръягына чыгуны уйлап та карамады. Кугын Идел аша аңлашкалы, Идел аша чакыргалы булды.

Янбай ерау Идегәне кайткалы чакырып ерлайды:

Идегә би, дусым ай,
Идегә би, дусым ай,
Ханың—ияң чакырадыр,
Борылып Идел кичсәнә.
Кайтсана, Идегә, кайтсана,
Каерылып атың башын тартсана,
Инсәсе биек Ак Урдага
Иңкәеп сәлам әйтсәнә.
Ирене юка сараяк ман
Ханияң бал бирәде,
Эчсәнә, Идегә, эчсәнә!
Колагын бездәй кадаган,
Кәгелен *(мангай чәче—хохол)*
кыздай тараган,
"Чү" дигәндә очкан кошны
Узып киткәле яраган,
Ияренең кашы алтын,
Йөгәненең башы алтын
Арабтан *(гарәп аты)* ат бирәде.
Менсәнә, Идегә, менсәнә!
Итәге алтын, йиңе алтын,
Бер күрүе мең алтын.
Кара кештән тун бирәде,
Кисәнә, Идегә, кисәнә!
Тотам бавы сум алтын
Кыңгыраулы күк карчыга бирәде,
Күл кыдырып чөйсәнә!
Байталдан байтак *(өлеш; ил; тәхет)*
бүлеп бирәде,
Бәйләтеп кымыз эчсәнә!
Байтактан байтак бүлеп бирәде,
Падишалык сөрсәнә!
Кузыкайдан артык ару бар,
Күзекәйдән артык сылу бар.
Аны да алып бирәде,
Уң тезенә ултыртып,
Битләреннән суыртып,
Аркасыннан кагып-кагып сөйсәнә!
Туктамыштай ханияң
Сиңа үпкә кылады,
Үпкә булган әйтсәнә!
Кил, Идегәй, дусым ай,
Безнең белән кайтсана!—диде.

Идегә Янбайның чакырып әйткәннәрен тыңлап торганнан соң, йаваб кылып ерлайды:

Кәмал углы Киң Янбай,
Киңәше елкән эт Янбай!
Арырак торып сөйләче,
Бирерәк килеп тыңлачы,
Ачма күзең, тишәрмен,
Сөйләмә, телең кисәрмен.
Авыз ачма, тешеңне сындырып,
Башынны чәйнәп изәрмен.
Атаң кара кеше иде,
Мал биргәннең колы иде,
Анаң кара кеше иде—
Аш биргәннең күне иде.
Син дә шундай кешесең:
Аш биргәннең колысың,
Мал биргәннең улысың.
Кайтман да, Янбай, кайтман да,
Каерылып атым башын тартман да,
Инсәсе биек Ак Урдага
Иңкәеп сәлам әйтмән дә.
Колагын бездәй кадаган,
Кәгелен кыздай тараган,
"Чү" дигәндә очкан кошны
Узып киткәле яраган.
Ияренең кашы алтын,
Йөгәненең башы алтын
Арабтан ат бирсә дә,
Менә алман, Янбай, менә алман,
Авым *(ыштан төбе)* котсыз булганда,
Итәге алтын, йиңе алтын,
Бер күрүе мең алтын
Кара кештән тун бирсә дә,
Кия алмам, Янбай, кия алмам,
Йилкәмә мөез беткәндә *(үскәндә)*.
Тотам бавы сум алтын
Кыңгыраулы күк карчыга бирсә дә,
Күл әйләнә чөя алман,
Канҗагам кансыз булганда.
Байталдан байтал бүлеп бирсә дә,
Бәйләтеп кымыз эчәлмән,
Эчем котсыз булганда.
Байтактан байтак *(гавам, масса—Н.Х.)*
бүлеп бирсә дә,
Падишалык сөрәлмән,
Алла үземә бирмәсә.
Бу киткәннән китәрмен,
Шаһ Тимергә йитәрмен,
Шаһ Тимер миңа кул бирсә,
Юртар атка юл бирсә,
Ходай Тәгалә уң бирсә,
Бу Идел дигән суыңны
Кайругым *(карый торган ком—Н. Х.)*
кылып кичәрмен,
Туктамыштай ханыңны аягыма
Бер мосахар итәрмен *(баш идерү)*,—диде.

Янбайның чакырып әйткәннәренә җавап биреп бетергәннән соң Идегә үз сүзләрен әйткәле булды. Тиздән Ак Урданы алачагын, алган соңында ниләр эшләячәген, боларны эшләй алмаса, Идегә дигән аты корыячагын әйтеп болай ерлады:

Бу киткәннән китмәсәм,
Кин чүлләрне үтмәсәм,
Ходай мина юл биреп,
Шаһ Тимергә йитмәсәм,
Шаһ Тимер мина кул биреп,
Теләгемне мул биреп,
Кырык убага *(калку жир)* кырык басып,
Яу булып килеп йитмәсәм;
Ач көзәндәй бөгелеп,
Ач бүредәй чыелдап,
Читәнендәй кыйкулап,
Ачы сөрән салмасам,
Кирәгәсен киртмәсәм,
Киртеп утын итмәсәм
Алтынлап суккан Ак Урдасын,
Көмешләп суккан ак ишеген,
Төсе суык чын булат
Очы белән ачмасам,
Кузыкайдан аруын,
Күзекәйдән сылуын
Үз түрендә шул вакыт
Түш астына салмасам,
Туксан башлы Ак Урдага
Бер генә ия булмасам,
Угланнарны сатуга
Бер чигара куймасам,
Кырык көнлек юлына,
Кырык көнлек чүленә
Кырык кое каздырып,
Кырык йорт—ям *(почта тукталышы)* салмасам,
Әйткәнемне кылмасам,
Мин үчемне алмасам,
Баба Түкләс бабам биргән
Идегә атым корысын!

Моның соңында Идегә үзенең юлдашлары ман аргамакларга атланып, бер катар булып тезелгәч, Янбайларга карап, тагын да болай ерлады:

Мин миндермен, миндермен,
Юкны димәс ирдермен!
Дустым утын сүндермән,
Дошманым утын яндырман.
Үзем димәс намартка *(кешелексез—Н. Х.)*
Аппак бүз ат мендермән.
Туксансыз йибә *(бүләк, һибә)* салдырман,
Асылын сорамай аш бирмән,
Яралыштан асаумын,
Бугалак салса туктаман.
Карагайдан биекмен,
Давыл өрсә дә кайрылман,
Кайнашып беткән ботакмын,
Балталаса да аерылман,
Тылтанлаган *(уйнаклау)* көрәнчә ат
Кадырауны екканмын,
Ягасы алтын кирәүкә
Ягалашып ертканмын!
Туксан баулы ак көбә
Тунаган йирдә кигәнмен.
Ягалашып, уклашып,
Күпләр башын игәнмен.
Моннан ары мактанман,
Әгәр дә мин мактансам,
Уникә тотам ук тарткан,
Тартканда өзә аткан,
Борындагы Чыңгызның
Үзе белән тиңдермен,—

дип, аргымакларын Шаһ Тимергә таба борып, берәр тибенеп юнәлә бирделәр.

Юнәлде Идегә, юнәлде
Шаһ Тимергә баргалы,
Шаһ Тимергә барган соң,
Аннан гаскәр алгалы.
Чокыр-чакыр юлларны
Басып китеп барады,
Ашкар-ашкар тауларны
Ашып китеп барады.
Авызлыгын Тарлан бүз
Бирмәй китеп барады.
Барган саен шәбәеп,
Ярсып китеп барады.
"Чү!" дигәндә чабады,
Авызлык ман алышып,
Камчы тартмай барады,
Очкан кош ман ярышып.

Бара торгач, аннан-моннан йыелып, Идегәнең юлдашлары унжиде булды. Берничә көннәрдән соң Йаекка йиттеләр, аны да үтеп киттеләр. Йаектан алып, очы-кырые күренмәгән чүлгә *(ком даласына)* барып керделәр. Сусызлык, утсызлык *(үләнсезлек)*, эсселек, юл ераклыгы атларын да, үзләрен дә каплап алды.

Идегәнең юлдашлары берничә көн барганнан соң сусызлыктан, эсселектән, ашау-эчү начарлыктан йөдәшә, күңелсезләнә башладылар. Шул чакта Идегә юлдашларына карата ерлай биреп, шуларны әйтте:

Ай, унйиде, унйиде,
Унйидебез бер кеше,
Мин кушылгач, унсигез,
Унсигезнең бер эше.
Сусадым дип карыкма,
Ачыктым дип камыкма,

Чаршадым *(ару)* дип талыкма,
Юл озак дип болыкма *(боегу)*,
Тамагың синең ачыкса,
Тамак табып бирәен,
Киемең синең ертылса,
Кием табып бирәен.
Атың үлсә, түләен.
Үзең үлсәң, нитәен?
Унйиде дуст, син үлсәң,
Женазаңны чыгарып,
Баялычтан[1] ут ягып,
Таза-арулап күмәен.
Ирмен дигән ир егет,
Арысланга тиң егет
Утка салсаң янмайды,
Суга салсаң батмайды,
Барган йиренә йитмичә,
Юлда үлеп ятмайды.
Ярен әйтмә, борын әйт,
Мин исәндә үлмәссең,
Үлмәссең дә белмәссең,
Авырлыклар күрмәссең!—диде.

Идегә һәм аның юлдашлары барысы да Шаһ Тимергә исән-сау барып йиттеләр. Бабайларның: "Ялгызга ясак, йәяүгә таяк, ачыкканга тамак булган Идегә" дигән сүзләре менә шул Идегә турысында әйтелгән.

V

Идегә би Шаһ Тимергә барып күренгәч, Шаһ Тимер аны бөтен юлдашлары ман бик хуплап каршы алды. Сарай кешеләренең катнашы ман өлкән бер мәҗлес ясатты. Идегә Шаһ Тимергә Ак Урда *(Алтын Урда)* иле турысында бераз сөйләгәннән соң аны барып алгалы чакырды, болай диде: "Әй, Әмир Күргән[2] теләгең өлкән, гаскәреңкүп, көченне кая куйгалы белмәйсен. Ерак-ерак илләргә, малсыз-фәкыйрь йирләргә, утсыз-сусыз чүлләргә чачаулыклар *(һөҗүм)* кыласыз. Күз алдыгызда яткан, балга-майга баткан монау илне—Ак Урданы күрмәйсез. Туктамыш хан ман аның кайбер биләре, төмән *(ун мең)*, мең башлыклары, тоткавыл *(ярлык саклаучы; каравыл куючы)*, ясавыллары *(яса, карар)* үтәүче; атлы каравыл *(хөкемдар якыны)* арасында берлек булмаганын абайламайсыз, шәйләмәйсез. Аны алу сезгә йинел дә, тиз дә, файдалы да булачак. Сиңа каршы торырлык көч һәм дошман, сиңа тоткар булырлык киртә һәм корган юк. Майга чумарга, балда йөзәргә теләсәң, әйдә тор, гаскәреңне йый! Син үзең баш бул, мин сиңа аяк булаен!" диде. Шаһ Тимергә Идегәнең күрсәткәннәре ятыш күренде. Ул тизлек белән гаскәрен *(чируләрен)* йыйды. Сугыш кораллары, ерткычларны тайярлады. Иравыл *(алдагы отряд артыннан баручылар; ике яктан куелган сугышчылар)*, сургавылларга чагдавылларга *(гаскәр азагындагы отряд)* бүлде. Сарайга Идегә киңәше буенча Урал таулары ягыннан барып баскынлык кылгалы булды.

Сәмәрканддән Ишем, Тубыл суларының башларына килеп, Урал таулары буйлап килеп чыкты. Көтелмәгән йирдән сугыш башлады, бөтен йирне саранча кебек каплап, буранар уйнатып, очкыр уклар алып, кискен кылычлар ялтыратып, очлы сөңгеләр тибрәтеп, кеше буар арысланнар үкертеп, кеше өстенә сикерәр юлбарыслар, капланнар йөгертеп, Шаһ Тимер гаскәре белән килгән Идегә мән шулай ук тайярланган Туктамыш гаскәре арасында сугыш башланды.

Иң элек зур батырлар арасында көрәш башланды. Туктамышның батырларына каршы көрәшкә, гаскәренә куркыныч салу өчен иң элек Идегә чыкты. Көрәш башланды.

Идегә тотып аны элек йиргә атты,
Дошман батыр салмагыннан йиргә батты.
Шуннан соңын: "инде күкне күреп кил!"—дип,
Күтәреп алып тагын аны күккә атты.
Зур батыр менеп китте күккә әйләнеп,
Кылыч, мылтык, садакларын һәм бәйләнеп.
Иртән китеп, кичкә таба зур батырның
Төшеп килә бүз тургайдай кайта әйләнеп.
Идегә шунда күккә тагын карап калды,
"Бүз тургайны" төшермичә кулга алды.

---

[1] Баялыч—төтене белән рух аруландыра торган чүл агачы.

[2] Аксак Тимер кушаматы; гүргән, кияү дигәндә, д-р Рәстәм Сүлти *(Измир)* фикеренчә, "күркәм" сүзе эзе бар.

Бармагының очларында уйнаткан соң,
Мосафирны әйләндереп гүргә салды.

Шуннан соң Идегә Шаһ Тимер ягындагы гаскәр белән Туктамыш гаскәрләре арасында сугыш башланды. Шул кадәр каты сугыш булды ки, бу кадәр сугыш монача йир йөзендә булганы юк иде. Берничә көн буенча көн-төн туктамастан сугыштылар. Актыктан Туктамыш гаскәре жиңелеп качты.

Сарай, Әстерхан шәһәрләрен алгач, Шаһ Тимер Сәмәрканга кайтып китте. Идегә Ак Урдага *(Алтын Урдага)* хан булды. Ил көтә башлады. Туктамыш качып китте.

Туктамыш хан качкан чагында үзенең шәүкәтле ханлыгы, туып-үскән йирләре, Идел буйлары, Сарай шәһәре, үзе торган Алтын ташы ман аманлашты *(саубуллашты)*. Аманлашканда күз яшьләре мән өзелеп аманлашты. Үткәндәге яхшы, матур тормышларының Идел, Сарай ман бәйләнгәннәрен искәртеп, сагынып, кайгырып ерлады.

Туктамыш ханның халыктан аерылганда халкы ман аманлашып ерлаганды:

Әй, байтагым, байтагым,
Сине алдырдым мин тагын.
Дошман талар килгән соң
Әл-әман бул миннән соң!
Байтагымның эчендә
Ун сан минем нугаем;
Ун сан нугайдан азак—
Өч йөз алтмыш йорт казак,
Синнән тагы аерылдым,
Әл-әман бул миннән соң!
Унбиш батыр арталмас,
Унике атан *(печкән дөя)* тарталмас,
Олы туым, биек Урдам,
Башта сезне алдырдым,
Сезне яуга калдырдым,
Әл-әман бул миннән соң!
Үзән дә Үзән, Үзән су
Үзәкләп Урдам кунган йорт,
Үзәкләп кунган Урданың
Башына тынгы кунган йорт.
Тынычлык-мазаң алдырдым,
Әл-әман бул миннән соң!
Тулыксыган ана Идел,
Тулыксып урдам кунган йорт,
Байтагымның баласы
Туып-үсеп унган йорт,
Уңышыңны алдырдым,
Әл-әман бул миннән соң!
Балыклары чумышкан,
Кошлары очып куышкан,
Сыгын *(ата поши)*, киеген *(ана поши—Себердә)* йөгерешкән,
Аюлары үкерешкән,
Елкыларың кешнәшкән,
Сыер, куйларың маңрашкан
Идел-ау, синнән аерылдым.
Әл-әман бул миннән соң!
Агачың айбар *(мәһабәт)* күренгән,
Алмасы жиргә түгелгән,
Талларың сугa иелгән,
Идел-ау, синнән аерылдым.
Әл-әман бул миннән соң!
Кундакка *(куну урыны)* урдам кундырып,
Хан сараен салдырып,
Артыма чатыр кундырып,
Алдыма базар кордырып,
Алтыннан акча кистереп,
Аңарга мөһерен суктырып,
Тагы аз гына мин анда
Хан булаен дип идем,
Аркасындан даулаган
Даным калсын дип идем,
Сине тагын алдырдым,
Әл-әман бул миннән соң!
Уты үскән утлы йорт,
Бия сауган сөтле йорт,
Кымыз эчкән котлы йорт,
Синнән тагы аерылдым,
Әл-әман бул миннән соң!
Ябагалы яшь тайлак
(ике яшьлек тай—Н.Х.)
Ярдай атан булган йорт,
Ятып калган бер туклы
(тукты, алты айлык бәрән)
Йәелеп мең куй тулган йорт,
Атам кияү булган йорт,
Анам килен булган йорт,
Күрекле туган сылуны
Бикәч итеп алган йорт,
Алып кулым салган йорт,
Әл-әман бул миннән соң!—
Йуыктан *(якын)* сина киләлман,
Алыстан *(ерак)* сине күрәлман,
Алтын таш, сина керәлман,
Әл-әман бул миннән соң!—дип,

Туктамыш хан яна-яна аерылып качып китте. Гаиләсе торып калды. Туктамыш хан качканда өстенә көбәсен тимер божралардан үрелгән кием кигән, садагын биленә таккан, тукмак яллы турысын менгән иде. Үзенең сер сакларлык дип ышанган кешесенә элек Төлке-күлгә барып ятачагын, анда куркыныч булса, Ку-күлгә барып качып ятачагын әйтте дә юнәлә бирде. Туктамыш аргымакка бер типкәндә, аргымагы йиргә мең типте. Канатсыз хәлдә кош очты, ләкин күз-колактан ераклагач, акыртын бара башлады. Кызарып тан атты, моңаеп көн чыкты. Туктамыш баруында һаман

да дәвам итте. Бара торгач сусады, далада торган өйгә туктап тиз генә сусын эчте дә, Төлке-күлгә китте. Күлгә йитте. Куаклык-камышлык арасына кереп атын бәйләде дә тынарга ятты.

Туктамыш качканнан соң Идегә гаскәре Сарайга керәр-кермәстән аның (Идегә) яклы кешеләр тарафыннан Сарай шәһәренең төрле ягына төнлә ут салынды. Халык сугыш куркынычы эчендә генә түгел, ут куркынычы эчендә дә калды. Кая баргалы урын тапмастан, Сарай шәһәре эчендә шау-шу күтәрелде. Бөтен шәһәрне дәһшәт каплады. Халык куркыныч астында гөж килгәндә бик аз гына каршылык ман Идегә гаскәрләре Сарайны басып керде. Керү мән Туктамыш ханны эзләделәр, ләкин тапмадылар. Сораша торгач, аның кайсы якка качканын белделәр. Идегә үзенең углы Норадынны Туктамыш артыннан куа чыгарды.

Туктамыш хан качып киткәндә, аның бик сылу ике кызы калды. Олысы Кузыкай, кечесе Күзекәй дип атала иде. Норадын Туктамышның артыннан куа чыкканда атасына: "Туктамышның олы кызын үзеңә улжа (табыш) итәрсең, кечесен мина сакларсың, мин сиңа Туктамышның башын китерермен"—дип үтенде. Идегәй: "Тыныч бул, кечесе синеке,"—диде.

Норадын Тарлан Бүзне менеп, алга иелә биреп, тезгенен бушата төшеп, "чү" дип бер тибенгән иде, койрыгы йорттан чыкканда башы шәһәрне үтеп чыкты. Далада артыннан күтәрелгән тузан басылып та өлгермәде, Тарлан Бүз өстендә очкан Норадын киң даладагы күремнән дә югалды. Озак заманнар чапты, Төлке-күлгә йитте. Камышлыклар арасына кереп карап тормады, камышлыклар өстендәге havara бер күз ташлап чыкты. Һавада бер тирәдә әйләнә-әйләнә очкан кызгачтаулар күренмәде. Норадын күлгә таба үтте.

Бу вакытларда Туктамыш Төлке-күл белән Ку-күлнең арасындагы яртылык юлны үткән иде. Юрта-чаба барадыр иде. Инде Сарайдан яхшы ук ерак жирдә барамын дип уйлады Туктамыш. Авырлык кылган мең чүкеч *(божра)* көбәне куеп калдыргалы булды. Ләкин яшергәле билгеле бер урын тапмады. Аптырап, бүз юшанга (ак эрем, күк әрем—Н.Х.) ташлап калдырды. Ташлаганда шуны ерлады:

Бер билгесе юк икән,
Мең чүкечне салгалы,
Билгесенә каранып,
Кайтып эзләп алгалы.
Карап *(харап)* калгыр кара тун
Бүз юшанга салаен,
Алла үземә биргәндә,
Кире кайтып алаен,—

дип, көбәсен юшанга ташлап калдырды. Байтак кына вакытлар барганнан соң Ку-күлгә житте. Ку-күлнең иң калын урманлы, иң озын камышлы йиренә кереп куян посты.

Туктамыш хан артыннан куа килгән Норадын Туктамышның юшанга ташлап калдырган көбәсенең өстенә килеп чыкты. Аны өстенә киде дә Ку-күлгә юнәлде. Юрта-чаба баруында дәвам итте. Ку-күлгә якынлаша төшүгә акрынлап бара башлады.

Качып яткан Туктамышны бу вакытларда әллә нинди төрле куркынычлар чорнап алды. Бар әйбер дә аны төртеп күрсәтәләр төсле күренде. Тирәсендәге әйберләрдән зарлангалы тотынды:

"Дөрс-дөрс" итеп, "дөрс" итеп
Дөрселдәмә, сум йөрәк;
Тынычлыкка зар чакта
Дөрселдәвең ник кәрәк!
Кыштырдама, бала усак,
Минең казак яткан чак.
Кыштырдавың йаныма
Куркынычлар аткан чак.
Тынламасаң үземне,
Зарлап әйткән сүземне,
Батырларым, биләрем
Сөңге сабына кыярлар,
Кыштырдап япракларың
Йиргә төшеп суларлар.
Тулкынмачы, тоныс су,
Мине өшеткән суык су,
Тынламасаң сүземне,
Өстеңә елкы әйдәрмен,
Бер суырса, корырсың,
Таңга калып торырсың.
Кыйгулама, кызгач кош,
Тавышың зарлы байгыш кош,
Баш өстемдә әйләнмәче,
Канатың куыш, муеның буш.
Батлавык тулган елкым юк,
Ояң таптар малым юк.

Оя тулган йомыркаңны
Итәкләп алыр улым юк.
Син күл иясе булсаң да,
Мин күпләрнең иясе,
Баш очыма әйләнеп,
Кыйгу салып йөрмәче!
Сине күлдән аерган,
Мине илдән аерган,
Минеңдәен саргаеп,
Казак чыксын иленнән!
Садаклары салбырап,
Бер төшмәсен биленнән
Минем газиз байтагым
Тубыктан канга батты ла,
Тугыздан үрмә кыл аел
Аргымакка батты ла!
Әзәлдә яу Идегә
Малымны алып туймадың,
Сылуларның сылуы
Кузыкайны алмай куймадың,
Аттан төшмәй йилдең син,
Арттан эзләп йөрдең син,
Аждаһадай ажгырып,
Баш йоткалы килдең син!—

дип ерлап туктап та өлгермәде, кызгач кошның кыйгулап очып йөргән җиренә Норадын килеп тә йитте. Туктамыш хан сыбай килгән тавышны ишетеп, урман, камышлыклар арасыннан тора килде. Норадыннның килә ятканын күрде дә:

Син ич минем колымсың,
Мин Чыңгызмын, беләмсең?
Үлтермәссең син мине!—диде.

Норадын әйтте:

Мин бер колың түгелмен,
Син дә Чыңгыз[1] түгелсең.
Мин кымырыска булып та,
Син Сөләйман[2] түгелсең!
Камчысы койма[3] алтын
Каныбәк тә хан булган,
Ул да "Чыңгызмән" дир иде,
Тибенгесе тезмә алтын.[4]
Тыныбәк тә хан булган,
Ул да "Чыңгызмын" дир иде,
Ул да Чыңгыз түгел иде,
Өзәңгесе өзмә[5] алтын
Үзебәк тә хан булган,
Ул Чыңгызмын димәс иде,
Ләкин ул Чыңгыз иде.
Мине колым, димәче,
Сине беләм, димәче,
Минем атым Норадын,
Үлтергәле торамын,
Әйтереңне әйтеп кал,
Атарыңны атып кал,—

диде Туктамыш хан өмидсез бер хәлдә кошларга, Аллага әйтеп ярдәм сорайды:

—Кыйгышлар да казкошлар *(кызгачлар)*
Белә алмайсыз, байгышлар,
Сезне күлдән аерган,
Мине илдән аерган
Идегә улы Норадын,
Бер Алладан сораек:
Һич бирмәсен морадын!
Казакъ чыгып йиреннән,
Садагы төшмәй биленнән,
Минеңдәен аптырап,
Куркуыннан калтырап,
Баш куярга йир тапмай,
Куылып йөрсен иленнән!

Шул вакытта Норадын әйтте:

Әй, Туктамыш, Идегәне
Кем качырды иленнән?
Кем йөретте Идегәне
Садагын төшермәй биленнән.
Үз кылганың үзенә кайта,
Икърар юктыр теленнән!

Әйт, Туктамыш! Беренче кизәктә *(нәүбәттә)* син атасыңны, минме? Әйдә, син ат! Беренче кизәк синеке.

Норадын талтая басып[6] торды. Туктамыш аның йөрәгенә карап атты, ләкин Норадынга бернәрсә дә булмады. Чөнки Норадын эчке яктан Туктамыш ханның

[1]Чыңгыз—биредә: Чыңгыз нәселе, *(чингизид)* күздә тотыла.
[2]Сөләйман—хайваннар, кошлар телен белүче дип саналган патша *(б.э.к. 928-965 еллар)*.
[3]Койма—койма, коелган рәвешендә.
[4]Тибенгесе тезмә алтын—тибенгедәге *(иярнең ике ягындагы каеш)* куелган.
[5]Өзмә алтын—өзеп (кисәкләп) коелган алтын.
[6]Талтая басу—киерелеп, мәгъруранә басып тору.

юшанга ташлап калдырган мең чүкечле көбәсен *(тимер киемен)* кигән иде. Туктамыш үзе күлмәкчән иде.

Норадын: "Инде кизәк минеке, туры тор!"—диде. Ук ман үлтермәслек итеп кенә атты да, туңкайтып башын кисеп алып, канҗагасына асты, аннан Тукмак яллы турысына менеп, Сарайга юнәлде. Бара торгач карыны ачты, берәр йиргә туктап төшләнгәле[1], тынгалы, атын утлатып алгалы булды. Алдарак зур бер тирәк күренде. Атын шуңарга таба борды. Тирәккә якынлашуга, анда кара аргымагын утлаткалы бушатып, тирәк күләгәсендә йоклап яткан бер кешене күрде. Норадын атының аяк тавышына, пошкыруына уянып китсә, алдында Норадын килә ятканын күрде. Норадынны таныды. Аның Туктамышны куа киткәнен ишеткән иде. Норадынның астында Туктамыш ханның Тукмак яллы турысы булуы мәсьәләне тагын да ачыкландырды, ул:

Әй, Норадын, Норадын,
Һич бирмәсен морадың!
Тукмак яллы турыны
Кайда менден, Норадын?
Мең чүкечле көбәне

Кайда кидең, Норадын?
Саурык бия сөте булган,
Тыныч йортка кот булган,
Туктамыштай ханымны
Син нишләттең, Норадын?

Норадын әйтте:

Тукмак яллы турыны
Тунаган йирдә менгәнмен;
Мең чүкечле көбәне
Үлтергән йирдә кигәнмен!
Саурык бия сөте булган
Тыныч йортка кот булган,
Туктамыштай ханыңны,

Синең якын коныңны
Төлке-күлдә эзләнеп,
Эзен чыгарып алганмын;
Ку-күл дигән урында
Баса барып йиткән соң,
Уклашып[2] көрәш иткән соң
Туңкайтып башын алганмын.

Туктамышның якыны тагын:

Әй, Норадын, Норадын,
Һич бирмәсен морадын!—

диде дә, үткәннән өмид өзеп, киләчәккә өмид баглап әйтте:

Түбәгә качкан дүртәүгә[3]
Түрә булыр көн туармы?
Аркада[4] торган алтауга
Идегә мән Норадын
Көне батар көн туармы?

Түбәдәге дүрт йолдыз
Таңы атар көн туармы?
Калган-каткан ил булып,
Кадыйр Бирде хан булып,
Борынгыдай дан булып
Торыр көннәр туармы,—диде.

Ачыктан әйтеп сөйләшкән кешене үлтерүне Норадын урынсыз санап, бу кешене үлтермәй калдырды, тимәде. Төшләнгәннән *(төшке аш ашаганнан)* соң атасына, Сарайга кайтуында дәвам итте.

Сарайга барып йитте, атасының йортына көлә барып керде дә Туктамышның башын ияр канҗагасыннан чишеп алып, атасының алдына китереп салды. Китереп салганда әйтте:

Төннәр, көннәр куган соң,
Төлке-күлдә эз алып,
Төлке-күлдән Ку-күлгә
Юнәлгәндән сүз алып,
Ку-күленә барган соң
Күз йөгертеп алган соң,
Казкошларны кычкыртып,

Тукмак ялны пошкыртып,
Поса-поса баргалап,
Туктамышны тапкан соң,
Ул мина, мин аңа
Күп сүзләрне әйткән соң
Туңкайтып башын алганмын,
Алдына китереп салганмын,—диде.

Идегә: "Афәрин, улым, афәрин! Һурра, Һурра!"—дип кычкырып каршы алды. Туктамыш ханның башын алып килгәннән соң Идегә һәм Норадыннар бәйрәм

---

[1]Төшләнгәле—төшке ашны ашарга.
[2]Уклашып—ук атышып.
[3]Түбәгә качкан дүртәү—Туктамыш ханның дүрт улы *(варисы)* күздә тотыла *(Н. Х.)*.
[4]Аркада торган алтау—Туктамыш ханның якыннары.

иттеләр. Туктамышның гаиләсеннән анын хатыны, кызлары үксеп-үксеп елаштылар. Күп гомерен Туктамышның сарай ерлаучысы булып үткәргән Янбай да әсәрләнде моннан. Гаиләсенең сөйләнеп-сөйләнеп, Янбайга да ниләрдер әйтеп елашулары аңа да тәэсир итте, анын да күнеле йомшады. Башка өйдәге бу вакыйганы күргән Янбай Идегә янына барып болай ерлап сорайды:

Каз төшермәс күлләргә
Каз төшердең ни өчен?
Ятим бәбкә тавышы ман
Кан елаттың ни өчен?
Куу төшермәс күлләргә
Куу төшердең ни өчен?
Атылган куу тавыш ман
Зар елаттың ни өчен?

Идегә Янбайга жавап ерлайды:

Каз төшермәс күлләргә
Каз төшердем ил өчен,
Ятим бәбкә (чүри) тавышы ман
Кан елаттым ил өчен.
Куу төшермәс күлләргә
Куу төшердем йорт өчен,
Атылган куу тавышы ман
Зар елаттым ил өчен!—диде.

VI

Идегә хан булды, теләгәнчә идарә кыла башлады. Ил эшләрен яхшы белгән кешеләрдән биләр куйды. Эше яхшы барадыр иде, ләкин күпме вакыйгалар үткәчтен үзенең углы Норадын белән икесе арасында каршылык чыкты, көрәш китте. Каршылык Туктамышның матур кызлары һәм ханлык өчен иде. Туктамышны куа киткәндә Норадын атасына карап: "Олы кызы синеке, кече кызы минеке булыр",—дип киткән иде. Норадын Туктамышны үлтерүгә шактый гына вакытлар үтүгә, Норадын кызның корсагы үсә башлаганын күреп, кыздан: "Сина ни булды, эчендә ни бар?"—дип сорады: Кыз: "Бу хурлыкны атаң эшләде",—диде. Норадынның моңа ачуы чыкты. Атасына яман ачуланды. Шуннан Норадын атасына каршы эшләр күрә башлады. Йола буенча, бер ханның ханлыгын кем алса, ханлыгы кемдә булса, анын бөтен халкы, йире генә түгел, бәлки бөтен казнасы, гаиләсе дә шул кешенеке булырга тиеш иде. Идегә шул йола буенча эш күрде. Туктамышның олы кызын да, кече кызын да үзе түшәкләде.

Туктамышны үтергән Норадын исә: "Туктамышны мин үлтердем, ин кимендә кече кызы минеке булырга тиеш",—дип тавыш чыгарды.

Янбай Норадынга караганда Идегәне якынрак күрә, борынгы йола буенча эш кылуны яхшырак саный иде. Шунлыктан Туктамышның кече кызы да Идегәгә улжа *(табыш)* булырга тиеш дип караган булып күренде. Ул Идегәгә киләдер дә: "Туктамыш ханның олы кызы гына түгел, бәлки кече кызы да синеке булырга тиеш. Туктамышның ханлыгы кемдә булса, анын гаиләсе дә шул кешенең иркендә булады. Ханны кем үлтерсә, анын ханлыгы да, гаиләсе дә шул кешенеке булады, дигән йола юк",—дип, Идегәне яклаган булды.

Норадын янына барадыр да: "Ханны кем үлтерсә, анын ханлыгы да, гаиләсе дә аныкы булырга тиеш..."—диядер иде.

Норадын бер яктан Туктамышның ин чырайлы, ин матур кече кызын үзенә алгалы тартышса, икенче яктан хан булгалы да даулаша торган булды. Норадын Туктамышның кече кызын мактап, аны даулап, атасын бермә-бер көрәшкә чакырып ерлады:

Кашы яйдай бөгелгән,
Керпеге уктай тегелгән,
Караган кеше өнелгән
Күзекәдәй сылу кыз—
Йә синеке, йә минеке!
Тулы айдай нур йөзле,
Коралайдай[1] саф күзле,
Шикәр, балдай сүзле

[1]Коралай—кыр илеге, жәйран—(Н. Х.).

Күзекәдәй сылу кыз—
Йә синеке, йә минеке!
Коландаен кара чәчле,
Энҗедән саф тешле,
Чәнчелеп торган түшле
Күзекәдәй сылу кыз—
Йә синеке, йә минеке!
Бакса, жанны эреткән,
Көлсә, канны йөреткән,
Әйтсә, авыру терелткән,
Күзекәдәй сылу кыз—
Йә синеке, йә минеке!
Көрәш булсын түрәмез,
Түрә хөкемен күрәмез,
Ексаң, ата, синеке,
Егылсаң, Күзекәй—
Сылу кыз, ул минеке!—диде.

Идегә Норадынга: "Туктамышның кече кызын гына түгел, олы кызын да, хәтта аналарын да ал, кәрәк булса",—диде дә, кече кызны Норадынга бирде. Туктамышның сылу кызын һәм ханлыгын даулаган Норадынга карата Идегәнең ерлаганы:

Әй, Норадын, Норадын,
Аңламаем морадың.
Күзекәйне сорасаң,
Күзекәйне бирәен.
Анасыны сорасаң,
Анасын да бирәен.
Ләкин ханны үлтереп,
Башын миңа килтереп,
Хан булаен, димәче,
Дан булаен димәче.
Ялгыз башың, халыксыз
Сан булаен димәче!
Туктамышка каршы мин
Гомрем буе көрәштем,
Ничә еллар орышып,
Сеңгеләшеп терәштем.
Шаһ Тимергә дим салып,
Күз алдына йим салып,
Туктамышны аяктан
Егар өчен сөйләштем.
Туктамышның иленда,
Туган-үскән йиремдә
Ач бүредәй караштым,
Эт-мешәктәй талаштым.
Биле савырлы көрәнне
Боракка охшаш менгәнмен
Тамгасыз углы Баракан
Иректсез алу алганмын.
Алтын тавына барганмын,
Түрә булып алганмын,
Халкын аерым алып килеп,
Ак Урдага салганмын.
Ягалашып орышкан
Батырларның кайберен
Идел нүгәре кылганмын.
Минем белән бер булып,
Халык өчен тартышкан,
Ягалашып *(биредә: якалашып)*,
көрәшеп,
Дошманнар ман чәнчешкән
Ыруларның батырын
Кайсын бием кылганмын,
Кайсын ханым кылганмын.
Әй, Норадын, Норадын,
Кандай *(нинди)* юан булса да,
Ялгыз агач өй булмас,
Кандай ятыш булса да,
Яңгыз егет би булмас.
Әй, Норадын, Норадын,
Нидер синең морадың?
Хан булаен димәче,
Дан булаен димәче,
Яңгыз башың, халыксыз
Сан булаен димәче!
Үтәр еллар, үтәр ай,
Килер вакыт, килер йай,
Хан буларсың шул чагын,
Дан буларсың шул чагын...—диде.

Идегәнең әйткәннәре Норадынга ошамады. Ул атасының сүзләрен мине кимсетәде, мине хурлайды, мине егарга тырышады, дип аңлады. Үзенең тумышыннан ук башка булып пешеп туганлыкларын әйтте, андый үгетләргә карамаячагын аңлаткалы теләде. Әгәр эш аныңча булмый икән, үзенең Шаһ Тимергә барып, аның белән берләшеп эш күрәчәген әйтеп, шүрләткәле уйлады. Атасы Идегәгә жавап урынына ерлаганы:

Фирештәдәен атам,
Һәр эштә даим атам,
Нигә мине хурлайсың,
Нигә мине ерлайсың?
Ерласаң мине, атам,
Ерлавынны отармын:
Хурласаң мине, атам,
Хурлавынны остармын[1].
Буранлы көн туганмын,
Борыч бирсәң еламан;
Арыслан булып туганмын,
Төрткәнеңә коламан.
Бораклы[2] аттан ярышмын *(ярсумын)*,
Бугалак салсаң туктаман;

[1] Остармын—күтәрермен мәгънәсендә.
[2] Бораклы—Бораклай (Борактай), мифик ат сурәтендә.

Борычтан яман ачымын,
Шикәр түксән, чәчемән *(төчеләнмәм)*.
Китәрмен, атам, китәрмен,
Шаһ Тимергә йитәрмен,
Тимер биргән Кир атны
Тирләткәнче менәрмен.
Тимер биргән тимер тун
Сүтелгәнче киярмен,
Уникә тотам укларны
Бетергәнче чәярмен.
Тимер мән зур антым бар,
Тимер мән зур шартым бар,
Тимер биргән сылуны
Алныма алып сөярмен.

Норадын тагы әйтте:

Уй дигәйдә кыр дигәй,
Уйны баскан морзамын,
Ханнар ман да биләр мән
Коймалашкан *(аралашкан)* морзамын
Коймалашым беткән соң,
Алыс-алыс йирләргә,
Үзгә телле илләргә,
Илче кылып игәнмен.
Ай кашында Зөһрәдәй
Балкый-балкый торганмын,
Таң алдында Чулпандай
Яна-яна торганмын.
Сүзле адәмне сөйләтмәс
Инәдән чичән туганмын,
Тешле адәмне тешләтмәс
Инәдән тешле туганмын.
Китәрмен, атам, китәрмен,
Шаһ Тимергә йитәрмен,
Тимер биргән Кир атны
Тирләткәнче менәрмен.

Норадын атасының сүзен тыңламаганны күреп, анасы да ачынды. Норадынга карап анасы әйтәде:

Әй, Норадын, Норадын,
Идел дигән су килер,
Аны ничек кичәрсең?
Итәгендә ил булыр,
Аны ничек үтәрсең?
Әй, Норадын, Норадын!
Йаек дигән су килер,
Аны ничек кичәрсең?
Ягасында ил булыр,
Аны ничек үтәрсең?

Норадын анасына әйтәде:

Идел дигән су булса,
Ике чумсам, кичәрмен,
Итәгендә ил булса,
Ике орсам, үтәрмен.
Әй, инәкәм, инәкәм!
Йаек дигән су булса,
Бер чумганда кичәрмен,
Ягасында ил булса,
Бер органда үтәрмен!

Анасы тагы әйтәде:

Әй, Норадын, Норадын!
Бер агачта мең ботак,
Аны кисәен, диденме?
Бер үзенә мең кеше,
Аны изәен, диденме?

Норадын анасына әйтәде:

Әй, инәкәм, инәкәм!
Бер агачта мең ботак,
Бер ботактан нисе артык?
Бер үземә мең кеше,
Бер кешедән нисе артык?—

дип ерлады.

Йайлы табылган бер вакытта Норадын Шаһ Тимергә качты. Анда барып, Идегәгә каршы көч сорады, гаскәр сорады. Шаһ Тимер бирмәде. Шулай да Норадын күпкәме-азгамыдыр, анда торып калды.

Идегә Норадынны өлкән хан итеп куюга каршы булса да, бәләкәйрәк берәр би итеп куюга каршы түгел иде. Норадын читтә вакытта ул аны сагынып та аладыр иде. Аны сагынып ерлаган чаклары да булгалыйдыр иде. Идегәнең Норадынны сагынып ерлаганы:

Алыстан кара күренсә,
Айланышкан морза улым,
Йуыктан кара күренсә,
Тулганышкан морза улым.
Йиде дәрья кушылып,
Котырынып ташканда,
Йил-каектай утравын
Йилгә биреп дәрья ашканда,
Ташкын тирән дәрьяны
Болыттай үткән морза улым,
Бурай-бурай кар яуса,
Бүз киерешкән[1] морза улым,
Бурасыннан ук килсә,
Булат калкан—морза улым!
Читтә солтан булудан
Илдә олтан булу артык.
Күктә чулпан[2] булудан
Суда чуртан булу артык,
Әй, Норадын улым—ай,
Сагындырдың мине артык.

Идегә Норадынны сагына. Норадынга карата кайбер яхшылыклар эшләгәнен дә хәтерли, аны читкә качып китәрлек хәлгә китерүен дә сиздергәли иде. Әгәр Норадын Шаһ Тимер кашында озак заманнар торып калса, моның Идегә өчен көтелмәгән бер куркынычка әйләнеп китү ихтималы барлыгын да уйлый иде. Идегәнең башында мондый уйлар булганын Янбай ерау да бик яхшы сизәдер, беләдер иде. Көннәрнең берендә Янбай Идегәгә Норадын турысында болай ерлады:

Идегә, син таңдагы көн,
Яу өстенә яу килсә,
Яңгыз нигә ярарсын?
Дошманың аулай үләрсен.
Норадын яман улың түгел иде,
Кендегеңне борарсын,—диде.

Идегә әйтте:

Яхшы әйттең, Ян әкәсе,
Бик хуш әйттең яу нәкәсе.
Яу өстенә яу килсә,
Яңгыз нигә ярармын?
Дошманым аулай үләрмен,
Йә дошманга калырмын.
Норадын яман улым түгел иде,
Кендегемне борармын,—диде.

Идегә шуннан соң Норадынны кайткалы чакырып берничә кешедән торган илче йибәрде. Алар Йаекны кичеп, очы-кырые күренмәгән далаларны үтеп, Норадынны барып таптылар. Норадынның илдән чыкканына байтак кына вакытлар үткән иде. Ул илен яхшы ук кына сагына башлаган иде. Норадын илчеләрдән сорап ерлайды:

Әй, илчеләр! Безнең күргән ил аманмы?
Биләр белән киңәш кылган йир аманмы?
Үзем барда кошлар салып, эт йөгерткән
Айдын-айдын Идел белән күл аманмы?
Кашкайлары йәйәдәен киерелгән,!
Керпекләре атар уктай төз тегелгән,
Колан чәчле, коралай күз, уймак авыз
Күзекәйдәй сылу, нечкә бил аманмы?—диде.

Илчеләр кайтарып ерлайды:

Әй, Норадын! Синең күргән илең дә аман,
Биләр белән киңәш кылган йирең дә аман,
Үзең барда кошлар салып, эт йөгерткән,
Айдын-айдын Идел белән күлең дә аман.
Кашкайлары йәйәдәен киерелгән,
Керпекләре атар уктай төз тезелгән,
Колан чәчле, коралай күз, уймак авыз
Күзекәйдәй сылу, нечкә билең дә аман,—диделәр.

---

[1] Бүз киерешү—кар, яңгырдан сакланыр өчен ябынча күтәрү, бүздән чатыр *(зонт)* ясау. Бердәмлек символы.

[2] Чулпан—таңгы Венера *(Зөһрә—кичке Венера)*—(Н. Х.)

Илчеләр сүзне үзләренең төбәп килгән төп мәсьәләләренә бордылар. Алар үзләренең ирекле атасы Идегәдән илче булып кайткалы чакырып килгәннәрен аңлаттылар. Илчеләр әйтте Норадынга:

Кәмал улы Янбайдан,
Соргантай улы Собрадан,
Аргылның улы Карагужадан,
Акның улы Булаттан,
Алчыгар улы Морзадан,
Исән улы Ходай Бирдедән,
Ирекле кеше атаңнан,
Өндәү килде "Кайтсын!"—дип,
Чабар килде "Кайтсын!"—дип,
"Үпкәләсә, үпкә сүзен әйтсен!"—дип.
"Ике канат, бер койрык
Инеп шоңкар чөйсен!"—дип,
"Ирене алтын сараяк
Ир саргытын эчсен!"—дип,
"Ай кашында бер йолдыз—
Зөһрә[1] балкый торсын!"—дип,
"Таң алдында бер йолдыз
Чулпан балкый торсын!"—дип,
"Кызыл канлы кылычын
Ак сөт белән юсын!"—дип,
"Иргә сәлам бирсен дә
Иңкәеп тәгъзим кылсын!"—дип,
"Асыраган атасын,
Кичерү сораган атасын,
Аз гына гаеп булса да,
Анасы аша кичсен!"—дип.

Норадын әйтте илчеләргә:

Кәмал улы Янбайдан
Соргантай улы Собрадан,
Аргылның улы Карагужадан,
Акның улы Булаттан,
Алчагыр улы Морзадан,
Исән улы Ходай Бирдедән,
Ирекле кеше атамнан
Өндәү килсә дә кайтмасмын,
Үпкәләсәм дә үпкә сүзен әйтмәсмен,
Ике канат, бер койрык,
Инеп шоңкар чөймәсмен.
Ирене алтын сараяк—
Ир саргытын эчмәсмен,
Ирнең күңеле ефәктәй,
Бер төйнәлсә чишелмәс,
Таразуга салсан, тиңәлмәс,
Мыскалга салсан, мин имәс.

Илчеләрдән тагы берсе әйтте Норадынга:

Бер дигәч тә ни яман?
Ходаны белмәс ул яман!
Икенчеләй ни яман?
Фарыз укымас ул яман!
Өченчеләй ни яман?
Өзелеп чыгар ян яман!
Дүртенчеләй ни яман?
Төркене *(туганнары)* юк кыз яман!
Бишенчеләй ни яман?
Бишектәгеләр елашып,
Атасыз калса ул яман!
Алтынчылай ни яман?
Йитәкләшеп ятимнәр
Елай калса ул яман!
Йиденчеләй ни яман?
Турбала[2]-кош баласы
Ояда калса ул яман!
Сигезенчеләй ни яман?
Яңгыз туган угыл яман!
Тугызынчылай ни яман?
Үз иреннән сирпелеп,
Дәүләт китсә ул яман!
Унынчылай ни яман?
Ултырган йире йопарлы[3],
Ун бармагы кыналы
Күзекәйдәй туталар
Елай калса ул яман.

Илчеләрнең соңгы сүзләрен ишеткәннән соң Норадын ата-анасы, гаиләсе янына кайткалы булды. Чакырып барган илчеләр мән бергә Норадын да кайтты:

Кайтып килде Норадын
Кашка көрән ат менеп,
Ата-анасын үз санап,
Башкаларны ят белеп.
Чаба кайтты Норадын,
Атасына ялынып,
Язығы ман гөнаһысы
Үз муйнына алынып.

Идегәй Норадынны чын шатланып каршы алды. Аны мактап шуны ерлады:

---

[1] Зөһрә—Себердә сәрә, сөрә, заря атала торган Венера йолдызы.
[2] Турбала—чөелергә тиешле кош баласы.
[3] Йопарлы—җофарлы (хуш исле).

Уяу батыр баламсын,
Уяныклы морза улым,
Бүз аргымак баласындай
Буйлы-сынлы морза улым.
Алсу-кара битле улым,
Иплеләргә ипле улым,
Алача епәк тун кисә,
Ярашыклы *(килешле)* морза улым.

Катем Тайдай[1] юмартсың,
Арсландай адусың *(көчле)*,
Камзәдәй[2] палвансың *(пәһлеван)*,
Галинең гали[3] улысын,
Арыслансың, морза улым.
Садагың алтын, угың алтын,
Чамыргап *(үпкәләбрәк)* әйткән сүзең алтын,
Саф азамат *(олы, бөек)* морза улым.

Йәмәннән[4] кеше җыйсам,
Уртага агач тексәм*(тезсәм)*,
Мин тугыз күрек бассам,
Сине дәрәҗәгә чиксәм,
Саф алтынсың, морза улым.

Норадын кайткач, Шаһ Тимер килү куркынычы бетте. Идегә моннан тыныч-ланды. Ләкин бөтен Урданы үз кулында тоткан Идегә ниндидер сәбәпләр мән Норадынны тагы да ханлык дәрәҗәсенә күтәрмәде, билек дәрәҗәсенә генә күтәрде. Хәлбуки, Норадын атасының: "Сине дәрәҗәгә чиксәм, саф алтынсың, мырза улым!"—дигәненә карап, анардан ханлык дәрәҗәсенә күтәрүен көтә иде. Норадын-ның бөтен Ак Урданы үз кулында тота торган кеше буласы киләдер иде. Ул, бу дәрәҗәне булдыру өчен нинди генә нәрсәне булса да эшләгәле тайяр *(әзер)* иде, ләкин эшне кайдан башлагалы, нинди сылтау күрсәткәле генә белмәй иде.

Идегәнең Норадынны ханлыкка утыртмавы, бер би итеп кенә калдыруы улына ошамады. Атасына карап Норадын: "Син мине дәрәҗәгә меңдергәле сүз биреп чакырган идең, кайтып кергән вакытымда да дәрәҗәгә чигәчәгеңне[5] аңлаткан идең. Кайда синең вәгъдәң? Кайда синең сүзең? Син миңа Туктамыш хан артыннан аны үлтергәле куа киткәнемдә, аның башын алып килсәң, кече кызы сиңа булар, дип вәгъдә биргән идең, шул вәгъдәңдә дә тормадың. Мин даулаша башлагач кына ул кызны бирдең миңа. Мин синең билек дәрәҗәңә карап, шуңа канәгатьләнеп кенә кала алмаем",—диде һәм моңа шуларны ерлады:

Кисәкчә чыккан болытмын,
Яумаенча таркалман,
Анадан кара туганмын,
Сабынлап юсаң агарман.
Атадан аеры туганмын,
Би үткәрсәң, ныгайман[6].
Йә мин сине үлтерәмен,
Йә син мине үлтер,
Яки күземә күренмә,
Казак чыгып кит,—диде Норадын.

Идегә әйтте:

Кузагачтан *(кузы агачы, кедр)* биекмен,
Болытка йитмәй тынмасмын,
Башымнан давыл өрсә дә,
Мин анардан сынмасмын.
Көлсәм, мин бер чуакмын[7],
Киреләнсәм, йокың бозармын,
Көрәшсәм, сине егармын,
Йөгерсәм, сине узармын.
Әй, Норадын, Норадын,
Унмастайны даулама,
Унмастайны даулашып,
Казак чык, дип каулама.

Янбай Идегәне яклап Норадынга әйтәде:

Кауданлы йиргә ут салсаң,
Утны кайдан утларсын?
Ана Иделгә кан койсаң,
Суны кайдан эчәрсең?
Кара аргымак катырсаң,
Атны кайдан менәрсең?
Кара лачын качырсаң,
Атны кайдан менәрсең?
Кара лачын качырсаң,
Кошны кайдан чөярсең?

---

[1]Катем Тай—Хатәм Таи *(Тай хатәме)*; юмартлык сурәте.
[2]Камзә—хәзрәти Хәмзә—гарәп батырларыннан (Н. Х.)
[3]Галинен улы галисең—югары (затлы) улы, затлысың мәгънәсендә.
[4]Йәмәннән—ил түгел, тирә-юньнән мәгънәсендә.
[5]Чигәчәгең—туендырасың, ирештерәсең мәгънәсендә.
[6]Би үткәрсән ныгайман—билек белән генә нык булмам дигәне.
[7]Чуак—жылы, йомшак, аяз *(Н. Х.)*.

Катибаны *(хәтфәне)* хурласаң,
Тунны кайдан киярсең?
Күзекәйне елатсаң,
Сылуны кайдан кочарсың
Колан чәчен чалартып,
Коралайдай күзен кызартып,
Карт атаңны кауласаң,
Кайда барып унарсың?
Языгы белән гөнаһысын
Кайда барып юарсың?

Норадын әйтте:

Кәмал улы киң Янбай,
Кире сүзгә эт Янбай!
Кауданлы йиргә ут салсам,
Яз яхшыны утлармын.
Ана Иделгә кан койсам,
Суны ширбәт эчәрмен.
Кара аргымак катырсам,
Атны тулпар менәрмен.
Кара лачын качырсам,
Кошны шонкар чөярмен.
Катибәне хурласам,
Тунны турка[1] киярмен.
Күзекәйне елатсам,
Сылуны таңлап *(мактап)* сөярмен
Колан чәчен чалартып,
Ике күзен кызартып,
Карт атамны кауласам,
Тәңре өе Кәгъбәне
Өч әйләнсәм, йолармын,
Йә казакъ чык, йә үлтерәмен!—ди
Норадын.

Идегә үз баласыннан моңдый сүзләрне кабат-кабат ишеткәннән соң Норадынны ниндәй уйлар ман, ничек асрап үстергәннәрен күз алдына китереп, Норадыннан зарланып ерлап әйтәдер:

Әй, Норадын, Норадын,
Сине теләп тудырдым,
Син туганда хисапсыз
Ту бияләр суйдырдым.
Йә колыным, мин сине
Бигә лаек туды дип,
Йә морзам, мин сине
Ханга лаек туды дип,
Карыңдаштан, ырудан
Туена кеше йыйдырдым,
Галимнәрне туйдырдым,
Ятимнәрне туйдырдым,
Хан кашында туды, дип,
Атыңны Норадын куйдырдым.
Сина бишек кәрәк дип,
Алтыннан бишек бөктердем,
Чөмәген алтыннан уйдырдым,
Төбәген көмештән койдырдым.
Туганында мин сине
Биш биләүдән биләттем,
Биш биләүне яманлап,
Кара камкага[2] биләттем.
Камка каты булыр, дип,
Сусар түшәк йәйдердем,
Сусарым суык булыр, дип,
Күк тиен түшәк йәйдердем.
Гарәп китабы укыган
Галимнән мәгънә сораттым,
Кочаклап Коръән укыган
Мулладан мәгънә сораттым.
Сүзгә чичән булсын, дип,
Артыңнан Янбайны иярттем,
Егет атың чыксын, дип,
Артыңнан егетләр иярттем.
Егет чагына килгәндә
Тулпар сайлап менгердем.
Хан сөярдәй булсын, дип,
Тимер туннар кидердем.
Мәргән булып үссен, дип,
Биленә садак будырдым,
Йөрәгең батыр үссен, дип,
Качкан яулар кудырдым.
Йә колыным, мин сине
Бигә лаек туды, дип,
Бидә нүгәр алдырдым.
Ханга лаек туды, дип,
Ханнан кәпәч алдырдым.
Колан чәчем чалартып,
Коралайдай күзем кызартып,
Картлыгымда син мине
Ник куасың, Норадын?
Нәрсә синең морадың?

Норадын әйтте:

Әйткәненне барысын
Кылганың хак, әй, ата,
Әйткәнемнең берсен дә
Кылганың юк, әй ата.
Вәгъдә иман иде,
Берен дә кылмадың мина,
Йә казакъ чык,
Йә үлтерәмен,—диде.

Идегә Норадынга әйтте:

---

[1] Турка—кытай ефәге.

[2] Камка—камчат (выдра); ефәк катнаш тукыма мәгънәсе дә бар.

Каулыйсың, улым, каулыйсың,
Карт атаңны яудай яулыйсың.
Мин яу түгел сиңа, ә син үзең
Мин бирәлмәс нәрсә даулыйсын.

—Мине каулагач та хан буласың, эшләр бары да төзәлә дип уйлайсың, ахыры. Хан да була алмассың, эшне дә яхшырта алмассың. Син теләгән урынга башкалар ултырыр. Моны тиздән аңларсын, ләкин эш үткән булыр,—диде дә казакъ чыгып китте.

Ханлык Идегә кулыннан китте, башканың кулына керде, Норадын һаман да хан була алмады.

Тәхеттән куылгач, казакъ чыгып киткән Идегәнең үз углы Норадынга үпкәләп, аның да хан була алмавына ачынып ерлаганы:

Тирлегем алтын булмады,
Тәгем *(тәхет)* минәр *(бизәк)* булмады,
Хан йияне[1] би улы
Норадын хан булмады.
Карга кунмас агачка
Каз кундырдың, Норадын,
Козгын кунмас агачка
Куу кундырдың, Норадын.

Норадын атасына кайтарып әйтте:

Тирлегең алтын булмаса,
Тәгең минәр булмаса.
Хан йияне би улы
Норадын хан булмаса,
Хан ултыртты тәхеткә,
Ирешер ил бәхеткә.
Карга кунмас агачка
Каз кундырдым ил өчен,
Козгын кунмас агачка
Куу кундырдым ил өчен.

Атасы каршы әйтәде:

Карга кунмас агачка
Каз кундырдың йил өчен *(бушка)*,
Козгын кунмас агачка
Куу кундырдың йил өчен.

Анасы Норадынга тагын сорап әйтәде:

Әй, Норадын, Норадын,
Каз төшермәс күлләргә
Каз төшереп уйнаттың.
Каздай башын агарткан
Атаңны нигә уйлаттың?
Әй, Норадын, Норадын,
Куу кундырмас күлләргә
Куу кундырып уйнаттың,
Куудай башын агарткан
Анаңны нигә уйлаттың?

Норадын анасына кайтарып әйтте:

Әй, инәкәм, инәкәм!
Каз төшермәс күлләргә
Каз төшердем ил өчен,
Каздай башын агарткан
Атаны уйлаттым ил өчен.
Әй, инәкәм, инәкәм,
Куу кундырмас күлләргә
Куу кундырдым йорт өчен,
Куудай башын агарткан
Анамны уйлаттым йорт өчен:

Анасы Норадынга әйтәде:

Әй, Норадын, Норадын,
Кара суга кан койсаң,
Суны кайдан эчәрсең?
Халык белән даулашып,
Яхшыны кайдан табарсың?
Каулы йиргә[2] үрт салып,
Утны (үлән) кайдан табарсың?
Халык белән яулашып
Яхшыны кайдан табарсың?

Норадын анасына кайтарып әйтәде:

---

[1] Йияне—ана ягыннан туганы.
[2] Каулы йир—кипкән үләнле жир.

Әй, инәкәм, инәкәм!
Кара суга кан койсам,
Суны ширбәт эчәрмен.
Халык белән даулашсам,
Йорт яхшысын табармын.

Әй, инәкәм, инәкәм!
Каулы йиргә үрт салсам,
Ут яхшысын табармын.
Халык белән яулашсам,
Йорт яхшысын табармын.

Норадын анасына тагы ерлайды:

Әй, инәкәм, инәкәм!
Иртә тордым таң белән,
Тирә-ягым карандым,
Яуга чыктым яңгызым,
Яңгыз атам санандым[1].

Әй, инәкәм, инәкәм!
Иртә тордым таң белән,
Тирә-ягым карандым,
Яуга чыктым яңгызым,
Яңгыз анам санандым.

Норадын анасына тагы ерлайды:

Әй, инәкәм, инәкәм!
Ике ташны култыклап,
Идел кичкән Норадын
Икедән яуга төшеп,
Исән чыккан Норадын.

Әй, инәкәм, инәкәм!
Яңгыз ташны култыклап,
Йаек кичкән Норадын,
Яңгыз гына яуга төшеп,
Исән чыккан Норадын.

VII

Туктамыш ханның Кадыйр-Бирде атлы углы бар иде. Ул атасы Туктамыш хан белән дошман булган Идегә һәм аның углы Норадыннан үч алгалы тайярланып йөри иде. Әллә ничә кат сугышып та Идегә һәм Норадыннарны йинә алмады. Яңгызларын кулга төшерә алмады. Иң актыгында Норадынга хезмәттә булган Янбайны сатып алу юлына керде. Норадын янында булган Янбайга зур бүләкләр белән яшереп хат йибәрде. Хатында Янбайның Туктамыш ханга иткән зур хезмәтләрен санады. Янбайның ул заманнардагы шөһрәтен хәтерләтеп мактады... Норадынны кулга төшергәле булышлык итә алса, зур бүләкләр бирәчәген, Туктамыш ханга һәм аның балаларына эшләгән хаталарын кичерәчәген, үзенең янына зур хезмәткә алачагын вәгъдә кылды...

Янбай хатны алып укыгач та күп уйлап тормады: "Була... Ләкин фәлән күлгә ауга барудан башка чара эшләп булмас. Шунда алып барганда камышлыкта яшеренеп яткан гаскәр һәм икәвебезне тоткын кылып алып китәр..."—диде.

Ил эшеннән бушаган араларда, сәел *(матур күренеш)* көннәрендә Норадын кош чөйгәле, кош аулагалы бик яратадыр иде. Йайлы көннәрнең берендә Янбай Норадынга: "Бүген көн бик яхшы. Безнең монавы... күлдә кыр үрдәкләре, кыр казлары, куулар бик күп, диләр. Ауга чыккалы чамагыз юкмы?"—диде. Каядыр баргалы ирегеп, ашкынып торган Норадын: "Чама бар. Чыккалы кәрәк",—диде.

Янбайның киңәше буенча өстенә көбә кимәстән, кылыч такмастан гына чыкты. Күлнең тирә-ягы калын камышлык ман капланган иде. Күлнең үзенә барып йитәр өчен камышлыкларны үткәле байтак кына вакыт кәрәк булды. Калын камышлыкларны үтеп күлгә чыгып та өлгермәделәр, Кадыйр-Бирденең гаскәре боларны камап та алды. Норадын үзенең алданганлыгын сизсә дә, бернәрсә дә эшләргә мөмкинлек булмады. Норадынны үзенең Янбай морзасы ман бергә кул-аякларын бәйләп алып та киттеләр Кадыйр-Бирдегә. Кадыйр-Бирдегә Норадынны тотканлыкларын, ана алып килә ятканлыкларын алдан ук хәбәр иттеләр.

Ул эченнән Норадынны китереп йиткергәнче үк бәйрәм итәдер иде. Үзенең атасы Туктамыш ханны үлтергән Норадынны көтәдер иде. Ак Урданың иң яхшы шәһәрләрен яндырышкан, казналарын талашкан, өлкәннәрен үлтерешкән Идегә углы Норадынны көтәдер иде. Норадынны хөкемгә ултыртачак урындык аны язалау өчен бөтен ягы очлы кадаклардан эшләнгән иде. Ялан аяк кертеләчәк өйнең идәннәренә дә очлы кадаклар кадакланган иде.

Куллары артына каерылып бәйләнгән Норадынны килтерделәр. Әлеге кадаклы идән аша йөргезеп, кадаклы урындыкка ултырттылар. Кадыйр-Бирде Солтан

[1] Санандым —абруй казандым.

инде Норадын тарафыннан Туктамыш ханга һәм аның балаларына эшләнгән бөтен явызлыклар, усаллыклар турында сораша башлайды.

Кадыйр-Бирде Солтан ерлап сорайды:

Кауданлы йиргә ут салдың,
Утны кайдан утларсың?
Кара суга кан койдың,
Суны кайдан эчәрсең?
Карт атаңны кауладың,
Гөнаһын кайда барып йоларсың?—диде.

Норадын ерлап йавап бирәде:

Кауданлы йиргә ут салсам,
Язын сайлап утлармын,
Кара суга кан койсам,
Суны баллап эчәрмен.
Карт атамны кауласам,
Кәгъбәгә барып йолармын.

Кадыйр-Бирде сорайды:

Аргылдан күчкән алты арбам,
Алтавы да казна арбам,
Катиба-епәктән сарган,
Аны кайттең, Норадын?
Тулгай-тулгай йөгергән,
Йөгергәндә йир бавырын кыдырган,
Тустаган күзле турыны,
Аны кайттең, Норадын?

Норадын кайтарып ерлайды:

Аргылдан күчкән алты арбаң,
Алтавы да казна арбаң,
Тәңре үземә биргән соң
Сәубан батырга биргәнмен.
Тулгай-тулгай йөгергән,
Йөгергәндә йир бавырын кыдырган,
Тустаган күзле турыны
Тукыш *(сугыш)* иткән көннәрдә
Үз астыңнан менгәнмен,
Менеп алып тукышка
Үзеңә каршы килгәнмен.

Кадыйр-Бирде сорап ерлайды:

Сигез йирдән чигелгән,
Тугыз йирдән тугылган,
Кара кештән тегелгән
Тунны кайттең, Норадын?
Тугыз кызлык, мең куйлык
Нургоба атлы көбәне,
Аны кайттең, Норадын?

Норадын кайтарып ерлайды:

Сигез йирдән чигелгән,
Тугыз йирдән тугылган,
Кара кештән тегелгән
Тунны Тәңре биргән соң,
Сыртыма салып йөргәнмен.
Тугыз кызлык, мең куйлык
Нургоба атлы көбәне
Тәңре үземә биргән соң
Бөктәр тышлап кигәнмен.
Кигән соңда сугышып,
Үзеңә каршы килгәнмен.

Янбай сорайды:

Тулгамалы айбалта
Аны кайттең, Норадын?
Тугыз солтан атасы,
Тулай байтак иясе
Туктамыштай ханнарны,
Аны кайттең, Норадын?
Кисмә-кисмә сары алтын,
Мөһер суккан саф алтын,
Энҗе, җәүһәр, якутны,
Аны кайттең, Норадын?

Янбайга Норадын кайтарып ерлайды:

Тулгамалы айбалтаң
Тукыш иткән йирләрдә
Уң кулыма алганмын,
Алып кайрап салганмын.

Туктамыштай ханнарны
Төнәй-төнәй куганмын.
Иртеш башы Каратунда
Куа барып йиткәнмен,
Тулгамалы айбалтаң ман
Туңкайтып башын алганмын,
Кисек башын кан көе
Яулыгыма сарганмын,
Канжагама бәйләп китереп,
Атам алдына салганмын.
Шулай итеп анардан
Атам үчен алганмын.
Кисмә-кисмә сары алтын,
Мөһер суккан саф алтын,
Энже, җәүһәр, якутны
Халкыма мин барын
Кисеп олжа кылганмын.
Кузыкайдан аруны,
Күзекәйдәй сылуны
Уң теземә утыртып,
Үбә-коча сөйгәнмен.
Кәмал углы Кин Янбай,
Кире сүзгә эт Янбай,
Арырак китеп сөйлә син,
Бирерәк килеп тыңла син.
Колан коега төшкәндә
Корбака айгырлык кылар.
Норадын турга төшкәндә
Янбай аударлык *(аучылык)* кылар.
Ачма күзең, тишәрмен,
Сөйләмә, телең кисәрмен,
Эченә кереп мин синең,
Кара елан булып гизәрмен.
Кара кешенең улы син,
Мал биргәннең колы син.
Коллык кылып йиде балаң,
Йиде буының корысын!
Ә мин Рамазан аенда,
Айның унбише көнендә,
Пәйшәмбе көн, йома акшам,
Айның тулы төнендә,
Ай, көн бергә йөргәндә
Асылдан пәйда булганмын.
Кузагачтан биекмен,
Болытка тисәм бөгелмән.
Кайнашып беткән ботакмын,
Өермә сукса да иелмән.
Боралкы аттан ярсумын,
Бугалак салсаң туктаман,
Йөрәгемә пычак тыксаң да,
Әйтермен, һич курыкман.
Коралсызларны кыйнау,
Йоклаганнарны үлтерү—
Көчсез кеше эше ул,
Юньсез кеше эше ул...—диде.

Норадын бу сүзләрне сөйләгәндә үткен кадаклы урындык өстендә ултырадыр иде. Тәненә кадаклар кереп, сөякләренә тиеп торадыр иде. Моны күреп торган Кадыйр-Бирде Солтан аның бөтен кылган эшләрен туры сөйләвенә, коралсызларны кыйнау, йоклаганнары үлтерү—көчсезләрнең эше ул, дип һич курыкмастан әйтә алуына карап, бөтен явызлыкларын кичте, бөтен ачуларын онытты.

Норадынның сүзләре Кадыйр-Бирденең йелекләренәчә кереп утырды һәм: "Әйткәннәреңнең барысы да дөрес, кылганнарыңны танмадың, бир кулыңны, яшә, Норадын, килешик!"—диде. Норадын бу вакытларда тәненнән каннар агып, ярым үле хәленә килгән булса да, килешкәле булды. Ул бу яралардан айлар соңында гына савыга алды. Савыккан соң Кадыйр-Бирде Солтан аны үзенә төмән башы итеп билгеләде. Норадын моннан соң да кайбер сугышларда батырлыклар күрсәтте. Ләкин озак яши алмады, бер сугышта яралары кабаттан ачылып, каны агып—кансырап[2] дөньядан үтте.

VIII

Кадыйр-Бирде үзенең атасы Туктамышның шәүкәтен кайтару өчен Идегәгә аледән-алегә баскынлык кылып торадыр иде. Ләкин һаман да Идегәне йинә, аны кулга төшерә алмыйдыр иде. Шулай да өмиден өзмидер иде. Баскынлык ясагалы унай бер форсат кына сагалап йөридер иде. Көннәрнең берендә Кадыйр-Бирдегә аның шымчылары: "Идегәнең таркау чагы" дигән хәбәрне китерделәр. Кадыйр-Бирде моны тикемләп *(төпченеп)* сорашып булганнан соң баскынлыкка, чачаулыкка ашкынды. Ана кайбер аркадашлары: Идел тунсын инде, аны кичкәле тунганын көтмәк кәрәк. Юкса, гаскәр өчен Иделне чыгу авыр булар. Урынсыз күп зәхмәт тартырмыз",—диделәр. Кайберләре: "Идегә инде 60 яшьләрне узган, картайган, тиздән үзе дә үләчәк. Нинди мәгънә чыгар соң аны үлтергәле яу булып, кыргын ясап йөрүдә?"—диделәр. Кадыйр-Бирдегә боларның сүзләре охшамады, ул аларның сүзләренә колак асмады:

---

[1] Боралкы—Нигъмәт Хәким далада иясез йөргән ат, дип аңлаткан. Күп телләр белүче профессор Гайшә ханым Рорлих *(Лос-Анджелес)* аңлатуынча, Боралкы—Бораклының ялгыш язылуы: Бораклай—Боракгай.

[2] Кансырау—кан азлыгы.

Идел тунса кем кичмәс,
Идегә үлсә кем алмас?
Иделне туңмас борын кичмәк кәрәк!
Идегәне үлмәс борын алмак кәрәк!—диде.

Кадыйр-Бирде гаскәрен йыеп Идел буена барды, күп кыенлыклар белән гаскәрен Идел аша кичерде дә Идегәгә таба юнәлде. Идегә дә Кадыйр-Бирде явы килүеннән хәбәр алып өлгергән иде. Ашыгычлык белән гаскәрен йыйды да, Кадыйр-Бирде явына каршы юнәлде.

Яу килгәнен белгән соң,
Күп чирүне күргән соң,
Тарлан бүзне атланып,
Сугышкалы барады.
Гайрәте судай ашады,
Ачуы чиктән ашады,
Атына камчы салган соң
Яуны килеп басады.
Кайда садак тартады,
Кайда мылтык атады,
Кайда кылыч селтәләп,
Кайда сөңге мән батады.
Ул читеннән керәде,
Бу читеннән чыгады,
Куйга керде бер бүре,
Бүре куйны кырады...

Сугыш шулкадәр каты барады ки, һәр ике яктан хисапсыз күп гаскәр кырыла барады. Моны күргән гаскәрләрнең Идегә ягындагылар да, Кадыйр-Бирде ягындагылар да качадылар. Һәр ике якта гаскәрләрдән кешеләр чамалы гына торып калдылар. Идегәне үлтергәле тырышып, Кадыйр-Бирде ин зур көчне Идегә өстенә юнәлтәде. Карт Идегә хисапсыз күп ук, кылыч, сөңге араларында калады. Оста, тәжрибәле Идегә бу баскынлыкның барын да ерып чыгарга якынлашады. Ләкин күп урыннан яраланып, үзеннән күп кенә кан китәде. Тегеләй дә картайган Идегә кан китү белән тагын дә хәлсезләнә төшәде.

Аның арый, хәлсезләнә башлаганын сизенгән Кадыйр-Бирде Идегәгә бермә-бер каршы чыгып, аны үлтереп ат алгалый уйлады да, аның янына кашка турысы ман чабып килеп әйтәде:

Түбәдәге дүрт йолдыз
Таңы атар көн тугандыр,
Көрән туры ат койрыгы
Дүрт чалуга тулгандыр.
Калган-каткан ил булып,
Кадыйр-Бирде хан булып,
Элгәрегедәй дан булып,
Яшәр көннәр тугандыр,
Көбәләр мән корганып,
Чөйдәле (түтәле?) балта кулга алып,
Чөйдәгезгә бер менеп,
Чабар көннәр тугандыр,—ди.

Идегә Кадыйр-Бирдегә кайтарып әйтәде:

Түбәндәге дүрт кондыз,
Таңы атар көн булмас,
Көрән туры ат койрыгы
Дүрт чалуга тулалмас!
Калган-поскан ил булып,
Кадыйр-Бирмәс хан булып,
Туктамыштай дан булып,
Көбә киеп корганган,
Чөйдәле[1] балта кулга алган,
Кадыйр-Бирде чөйдәмә
Чабар көннәр туалмас!—диде.

Яшь Кадыйр-Бирде карт Идегәнең ачы рәвештә көлүеннән гаять каты ачуланды. Ачуы шулкадәр кабарды, зәһәресе шулкадәр чыкты ки, шул ук сулышта бер мәртәбә тирләп-пешкәннән соң Идегәне бер төрле дә аямаслык хәлгә килеп туңды һәм болай диде:

Кантарда *(декабрьдә)* яуган болыттай
Зәһәрле суык төсем бар,
Эзләп килдем үзенне,
Суеша торган эшем бар,—диде.

Идегә Кадыйр-Бирдегә кайтарып:

Кабагымнан кар явып,
Керпегемә боз туңып,
Эзләп килгән Кадыйр мән
Орышкалы көчем бар,—

---

[1] Чөйдәмә—"минем балта түтәсенә" мәгънәсендә.

диде дә чүригә *(бәпкәчкә)* ташланган тилгәткән *(тилгән)* төсле Кадыйр-Бирде өстенә ташланды. Кадыйр-Бирде Идегәне берничә йирдән яралап өлгергәндә, Идегә аны тупрак ман каралап, дөнья мән исәнләштереп тә өлгерде.

Сугышып арыган, кан китеп хәлсезләнә барган Идегә тотты да тукышлактан *(сугыш мәйданыннан)* качты. Юл яздырып өйрәнгән карт төлке Идегә урау юллар ясап, сугыштан бер авылга килде. Төште атыннан, керде бер өйгә, яраларын юып бәйләде, сусын эчте, ашарга-эчәргә алды да бер күлгә таба юнәлде. Күл тирәсендәге куаклык, камышлык арасына кереп бераз ял итеп алгалы уйлады.

Кадыйр-Бирденең берничә бие, яннарына бераз гаскәр алып Идегә аркасыннан кугын төште. Кугын куып китте, тиз генә йитеп үлтергәле уйлады: ары чабып карады, бире чабып карады, кергән йирне айкады, чыккан йирне байкады, якыннан тота алмады, ерактан күрә алмады...

Идегә кача барганында якыннан таныш бер кешесен очратты, үзенең кача барганын, кача барып иптәшләрен көтеп ятачагын әйтте һәм үзе яклы булган кешеләр очрап калса, аларга кайда көтеп ятканын әйтеп, юл күрсәтеп йибәргәле үтенде. Таныш кеше: "Баш өсте!"—диде. Идегә үз юлына юнәлде, таныш үз юлына китте. Идегәнең үтенеч тапшырган танышы юлда барган вакытта Идегә яклы булып күренгән бер кешене очратты. Ул кеше үзенең Идегәдән күз язып, аңардан адашып калганын, аны эзләп кангыраганын әйтте, белә торган булса, Идегәне табу өчен юл күрсәтүен үтенде. Идегәнең әлеге үтенеч тапшырган танышы Идегәнең авыр бер хәлдә булганын, кайда барып иптәшләрен көтеп ятачагын әйтеп бирде, юлын да өйрәтте.

Юл сораучы кеше Кадыйр-Бирденең бер бие, Идегәне эзләп баручы бер кеше иде. Бу кеше үзенең эзләп барган кырык-илле юлдашына барып хәбәр иткәннән соң, болар Идегә качып яткан күлгә таба юнәлделәр. Идегә яткан күл тирәсенә килеп аның ат эзен таптылар. Ләкин ат эзе камышлыкка кергән эз түгел, бәлки чыккан эз булганын күрделәр. Арада берәвесе: "Идегә ул оста кеше, атын чиктереп кергән булар камышлыкка *(әкертен генә)* сез чыгачак юлның ике ягыннан камышлыкка яшеренеп кереп торын, мин тулгап күрәем:

Идегә өлкән ир иде,
Менгән аты Кир иде,
Олыларча йөрер иде,
Үзеннән яшь кешегә:
"Син тора тор, газизем,
Мин атаем!"—дир иде.
Үзеннән өлкән кешегә:
"Мин тораем, газизем,
Син атсанчы!"—дир иде.
Яшә, килдек үзенә,
Колак салдык сүзенә,
Ни диярсең, көтәрбез.
Йавабын-ниең булмаса,
Камышлыкны яргалап,
Үз катына үтәрбез,—диделәр.

Идегә ерак камышлык артыннан әйтте:

Ягасы алтын кирәүкә
Ягалашып ерткан соң,
Тылтаңлаган көрәнчә ат
Кадырауны еккан соң
Сездәен сөлтекләрдән[1]
Курка торган Идегә юк!
Сездәен өтекләрдән
Егыла торган Идегә юк!
Теләгегез там *(тәгаен, бөтен)* булса,
Кадырауга киткәле,
Ашкынуыгыз раст булса,
Аны куып йиткәле,
Көтә торың, чыгармын,
Сөңгем канга тыгармын,
Күк күкрәтеп, кылыч ман
Яшен уйнатып сугармын,—диде.

Кадыйр-Бирде морзаларыннан берәү:

Идегә чыкмай булмастыр,
Екмай күнеле тулмастыр,
Әгәр үзе чыкмаса,
Кеше керми тормастыр,—диде.

Идегә, үзенең яраларыннан кан китүе, картлык көннәре йитүе аркасында артык арыган иде. Ачык мәйданга чыгып сугышмаска, үз янына камыш арасыннан кергән кешеләргә ташлана торырга уйлады. Беренче ату кизәген (нәүбәтен) ана биреп чакырсалар да, камышлыктан чыкмады.

Камышлыкка керәчәк кешеләрнең игътибарларын үзеннән читкә тарту,

[1] Сөлтек—хайван тиресе эченә үлән тутырып ясаган карачкы, чучело.

аларны башка юлга кертү өчен хәйлә корды. Янындагы ун-унбиш колач чамалары булган бер йепнең бер очын үзендә калдырып, икенче очын бер агач кисәге бәйләп камышлыктан керә торган юлның бер як читенә ташлады. Берәмләп керә торган кешеләр шул агач турысыннан Идегә ягына бераз үтү мән Идегә әлеге йепне тартып, кергән кешеләрнең артларында калган камышлыкларны селкетеп кыштырдатты. Керүчеләр, Идегә безнең өскә арттан ташлана икән, дип өч-дүрте дә кинәттән артка борылды. Идегә йепне тагы бер тартып куйды да, артларыннан өсләренә ташланып, барын да үлтереп өлгерде. Хәйлә йебе яңа керүчеләр өчен дә тартылды. Аларны да үлтерде. Хәйлә сизелде. Күпләп керә башладылар. Идегә аларны кычкырып туктатты да: "Әйтә торганнарны тыңлап беткәч, керәрсез",—диде. Идегә әйтеп ерлайды:

Яшьлек көнем беткән соң
Чәчкәм атар таң булмас,
Картлык көнем йиткән соң
Элгәрегедәй дан булмас.
Дан булмаса булмасын,
Булганнарның нисе артык,
Сан булмаса булмасын,
Булганнарның кайсы артык,
Үлем белән куркытма,
Курка торган уем юк;
Үлем килсә, аңардан
Котыла торган буем юк!—

дип, үлемнән курыкмаганын кычкырып ерлады. Шуның белән бергә үзенең илен сөеп, йирен яратып, гомере буе шулар өчен көрәшкәнен аңлатмыйча үлмәячәген әйтеп болай ерлады:

Илем өчен илсенеп,
Йирем өчен йирсенеп,
Халыгым өчен яхшы уем
Күкрәк тулып йилсенеп,
Көрәшкәнне халыгым
Аңладымы, белә алман,
Аңламаса халыгым,
Аңламастан үлә алман!—

дип, камышлык арасыннан бер гайрәт орды. Идегә өстенә күмәкләп керә башладылар. Керә килгәннәрнең тагы берничәсен камышка сөяп өлгерсә дә, соңыннан кергәннәре белән чәнчешкәле мөмкинлек тапмастан, күлгә ташланды да, икенче ягына таба йөзә башлады. Арадан берәү, йөзә барган Идегәнең башына, җилкәсенә төзәп ук белән аткалы кереште. Идегә йан ачуы белән су өстенә суга-суга күл яңгыратып сүгенгәле тотынды, "күлдән чыкканнан соң кәрәгегезне бирәрмен әле сина" дип тешләрен кайрады. Атылган уктан башын тайпылдырып калу өчен укчыларга карап чалкан йөзә башлады. Берничә укны юл яздырса да, тоташтан атыла башлаган укларның берсе Идегәнең битен сыдыра тишеп кереп, бер күзен дә чыгарды. Идегә укны суырып алып суга атты. Укчыларга йилкәсен биреп йөзә башлады. Аркасына тагы ике-өч ук кадалды, аларның биленә кадалган икесен суырып алып ташлады, ләкин берсен суыра алмады, инде күп йөзә алмаслык, өч-дүрт минутлардан артык су өстендә тора алмаслык хәлгә килде. Үлем өзгәләнүләре белән сыкрана, бер батып, бер калкып сулар пошкырып, арсландай "ah" ора башлады. Моны күргән берничә егет күлгә ташланып йөзә киттеләр. Идегәне икәвесе ике яктан тотып, йөзә-йөзә күл читенә тартып алып чыктылар, өстерәп чыгарып, күл читенә салдылар.

Идегә инде үзенең үлемнән котыла алмаячагын, үлтермичә калдырсалар да яшәүнең мәгънәсе булмаячагын уйлап, актык өмидләрен өзеп болай диде:

Минең инде илгә күренер йөзем дә юк,
Борынгыдай йортка карар күзем дә юк,
Билем дә юк—дошманнарым, тиз үлтереп,
Сезгә инде башка әйтер сүзем дә юк,—диде.

Муйнына кылыч күтәрелде.

Тапшырылдым, Ходай, Үзеңә,
Ни кылсаң да иркең үземә!—

дип әйтеп, бетәр-бетмәстән муйны өстендә кылыч ялтырады.

Нурулла Гариф

АВЫЛЫМ КАЙТАВАЗЫ

БЕЗ АВЫЛНЫ ташлап китүчеләрнең беренчеләре сафында булмадык. Безгә чаклы да бәхетне туган йорттан читтә табу өметенә алданып китүчеләр бихисап агылган. Авылны дөнья белән тоташтыручы беренче сукмаклары да алар тарафыннан тапталган. Соңрак та бу юллар шул китүчеләрнең кул, ат арбасы тәгәрмәчләре астында киңәеп, чылбырлы трактор-машина тәгәрмәчләре басымы астында тирәнәеп, чокыр-чакырланып беткән иде. Ә бу юллар кай тарафка сузылсалар да, үз юлчыларын олы юл чатына бастырды. Шул олы юллар кешелеккә чыгарды безне, кешелектән чыгаручылары да алар иде.

Бүген дә менә олы юллар чатында үйланып басып тору әле. Бу юлы юлым кайтыр тарафка, туып-үскән якка, туган авылыма юнәлгән. Бар дөньясын артта калдырып, кискен генә уңга борылам. Әнә, күз күреме ераклыгында туган авылымның манзарасы ачыла. Тик анда кайтып җиткәнче, бүгенге Чечен җире фаҗигасен искәртеп торучы колхоз фермалары янәшәсеннән узасы бар әле. Үткән тарихта "коммунизм төзү хезмәте фронтыннан" калган хәрабәләр диңгезе ул. Каршыда җимерек ферма, таралган техника, җансыз кардалар. Авылга, туган йортка таба аяклар үзләре йөгерсә дә, бу урыннар үткәннәрне искә төшереп, бәгырьне телгәли. Мин бу "сугышта" дөньямның иң кадерле кешесен—әниемне югалттым. Әлеге хәрби хәрәкәтләрдән исән калып, алган яраларын—саулык-сәламәтлекләрен югалткан авылдашларымның күбесе бүгенгәчә сызлап-сыкранып яшәп яталар әле. Хәзерге буын, аларның балалары, "башка фронтта"—тамак туйдыру, исән калу өчен сугышка керә. Күпме гомерләр, яшәү өметен югалткан яшь җаннарны сорап икән анысы.

Бара торгач төрле күренешләр алышынып, каршыга Тукай искәрткән "гаскәриләр кеби төз нарат урманы" чыга. Шул чорның хыялый җитәкче-җинаятьчеләреннән калган бердәнбер яхшы истәлек. Шулай да мин аларны башка очракка бәйле, авылга кергәндә беренче йортның хуҗасы, урманда эшләп пенсиягә чыккан Фәрхулла абый хөрмәтенә утыртылганнардыр дип саныйм. Фәрхулла абый гомере буе тирә-яктагы йөз яшьлек нарат, имән, каен агачлы урманнарның бердәнбер хуҗасы булып торды. Инде шуңа бәйле сөйләсәң, бүгенгеләр ышанмас: йорты-җире генә түгел, абзар-курасы да авыл кешеләренекеннән аерылып тормады аның. Әти гомер буе урман эшендә булганлыктан, урман хозурында еш очратырга туры килә иде Фәрхулла абыйны. Кайда чыбык кырып балта күтәрсәң, утын әзерләп пычкы сызсаң, озак көттермәс, биш-ун минут арасында килеп чыгар иде. Көндез түгел, төнлә дә урман байлыгына кул сузучыларның каршысына чыкты ул. Еш кабатларга яраткан сүзе "күпкә кызыкма, энем" иде. Шуңа кирәгеннән артык нәфеслеләрне яратмады ул. Андыйларның өнендә дә, төнендә дә төшләренә кереп йөдәтте Фәрхулла абый. Урманны да саклап калды, шул ук вакытта кеше белән судлашып та йөрмәде кебек. Шулай бер вакыт, очрашканда: "Бар, укып кайт, кайтуыңны көтеп торам, аннан урманны сиңа тапшырып, пенсиягә чыгар идем",—дип әйткәне истә калган. Ә безнең әле бар

урманын түгел, бар дөньясын аяк астыңа салабыз дисәләр дә, аз тоелган яшь вакыт. Мин аңа рәхмәтемне әйтеп: "Үземне чебен-черкиләргә талатып, утын сорап килгән авыл әби-бабайларының ялварулы карашларын күрергә теләгем юк",—дигән идем. Ул чакта кем белгән бит авылга газ кереп, соңрак теге йөз яшьлек нарат, имәннәрнең бары олы хуҗаларның коттеджлары өчен генә азык буласын. Фәрхулла абыйдан соң урман хуҗалары еш алышынып, урманнар да бик сирәгәйде шул. Тавыш салсаң, кайтавазлар кире кайтмый хәзер, калын урман да юкарып, бушап калды.

Гөнаһ шомлыгына каршы, "Урман шаулап үсә, Пәрхүш сатып эчә, утырып кала агач төпләре" дип җырлаучылары да без идек. Шаярудан туган хәлләр бу. Киләчәкне күрми, үткәннәрне кадерли белмәгәнбез икән. Бүгенге урман каравылчыларына бер яртыңны бирсәң, үлән кыйган чалгы кебек урманны кыеп, Үрнәк авылы тирәләрен урап, ник хет "Ычтапан болыннарына" хәтле чыкмыйсың.

Безнең авыл халкында бүгенгәчә "Пәрхулла урманнары" дигән әйтем, хезмәткә бирелгән хөрмәт-гыйбарә яшәп килә.

Борчулы уйлардан айнып, карашым авылның уң ягындагы икенче йортка төшә. Бар җире килеш-җитешле тыйнак йорт. Татар авылының, татар хуҗалыгы шундый булырга тиеш ул. Йорт хуҗасы—Әхәт абый. Әхәт—кыскартылган исем булырга тиеш. Исемнәрне кыскарту бездә элеккедән калган, әмма бик үк матур булмаган гадәт. Әлеге очракта бу исемне ата-бабасы кушканча атыйсы килгән иде. Сорап белешергә булыр әле. Исемне тулысынча белү теләге шуңа бәйле: кодрәтемнән килсә, авылның бу урамына Калинин атамасы урынына, Әхәт абый исемен бирер идем мин. Әхәт абый күпләр кебек гомер буе колхоз-совхозларның колына әйләнеп, түрәләрне бушка симертеп яткырмады. Шуңа күрә аларга бик үк табынмады, корган тозакларына абынмады. Үз ягын кайгыртып яшәде һәм алданмады.

Шулай да аның иң зур хезмәтен, авылның да, үз нәселенең дә киләчәгенә өмет биреп, янәшәсендә генә ул-кызына өр яңа йортлар җиткерүдә күрәм мин. Авылны олы юлга таба сузып, тагын бер илле-йөз метрга озайтты ул. Шуңа күрә, аның уллары вә оныклары, читкә очып таралмады, гаилә җылысын саклап, барысы да үз янында кайнашалар. Әхәт абыйның авыл өчен эшләгән якшылык-хезмәтләре моның белән генә тәмамланмый, әлбәттә. Тагын бер искәртеп узасым килгәне—авыл зиратын карап, барлап тора ул. Зират авылның башка очында булса да, аның төзек, күрше авыллар-никыннан ким-хур булмавы—аның изгелеге, саваплы эше.

Юк! Мин хөкүмәт җитәкчесе булсам, һәйкәлләрне чит җирләрдә, төссез, тамырсыз шәһәр-бистәләр, бар дөньясын ыслатып торучы галәмәт зур завод-фабрикалар төзүчеләргә түгел, үз авылының киләчәген саклап калучыларга куяр идем. Үз-ишләремә гыйбрәт итеп, нәкъ менә Әхәт абый кебекләргә, үзләре исән чакта ук салыр идем мин ул һәйкәлләрне!

Татлы хисләргә бирелеп, сизми генә ике-өч йортны узып киткәнмен. Каршымда —салам түбәле Сәгыйть бабай йорты. Безнең өчен әле аның тагын ике исеме бар: Кулсыз бабай, Мулла бабай. Балачакка кайтып кына күз алдымнан аның салам түбәле йорты чагылып киткән икән. Бар бит ул бәхетле кешеләр! XXI гасырга да исе китмичә горур басып чыгачак таш йорт тора бүген бу нигездә. Хуҗасы да чит түгел, Сәгыйть бабайның үз оныгы. Урынның уңайсыз, авышлы булуына карамыйча, күңелен биреп салды аны Фәнис дустым. Инде, әнә, Сәгыйть бабайның торыннары—Ләйлә белән Рәсүл дә чабыша. Бабасы утыртып калдырган алма агачы җимешләреннән дә авыз итә алар. Намазлы нигездә бисмиллалы тормыш дәвам итсен иде. Иң зур теләк шул—барчабызга да картлыкта шундый бәхеткә тиенү насыйп булсын иде ләбаса.

Матур хатирәләр укадай коелып, башым кабат сулга борыла. Авыш нигез, сукмак та салынмаган кыйшайган капка төбе. Монысы икенче Әхәт абый—Габделәхәт абый нигезе. Мәрхүм кешенең "җанын ашап", бу йорт тарихына кагыйлмыйм. Ә хуҗасын, үзенең гөнаһсыз сабыен сагынып, озак ямансулар әле авыл халкы. Бу югалтуны бигрәк тә ялгыз калган авылымның әби-бабайлары авыр кичергәндер дип уйлыйм. Аларның бар өметләре, бердәнбер ярдәмчеләре Габделәхәт абыйда булгандыр. Кыш җитсә, аннан башка абзар-куралтылардан кар көрәлмәде, абзар эчләренә печән дә кермәде кебек. Кышлак утын да киселеп, ярылмады. Хөкүмәт ярдәмендә төзелгән кайбер авыллардагы картлар йорты хезмәткәрләрен берүзе алыштырды Габделәхәт абый. Сүз дә юк—рәхмәт-савабын да күбрәк алгандыр. Ходай урынын җәннәттә кылсын. Аның тагын бер үзенчәлеге, авылымның матурлыгын үлчи алган бердәнбер шагыйрь иде ул. Бу күрше авыл халкы биргән бәя. Барыбыз да беләбез: туган якта пәйгамбәрләр тумый, язучы-шагыйрьләр танылмый ул. «Татарстан яшьләре», «Ватаным Татарстан» газеталарында язмалары чыккач, аһ, шатланган иде. Ә менә бер калын дәфтәр тулы

шигырьләренә тотынып булмады. Яшьлектә безнең каз көтеп, бозау арканлап үскән җирләр, Габделәхәт абыйның язган шигырь юлларына күчеп, һаман ватык пәтифун тәлинкәседәй күңелдә әйләнә—"болакай болыннары, болакай болыннары..."

Авылның күмәкләшү чоры алдындагы бер чиге "кара" Сабир нигезен узып, тагын бер тарихи урынга җитәм. Коммунизмга илтергә тиеш булып, бар өмет хыялларны үзендә саклап калган авылның бер тарихи урыны—сугышка чаклы салына башланган таш юлның бер өлеше ул. Бүгенге көндә бу таш нигезне төбенәчә кырып, яңа юл салып яталар. Хәзер инде безне башка хөкүмәт, башка бай-түрәләр яңа тормыш корырга чакыра. Һәр яңа килгән түрә-патшаның тормышны рәтләячәгенә өметләнеп яшәргә өйрәнгән инде без. Бәлкем, болары ни дә булса майтарыр. Өмет-хыялларыбыз тормышка ашсын иде. Хәер, монысы өчен дә рәхмәт, дөньясында башка болганышлар булса да, юлларын, алар астында калган газ торбаларын үзләре белән алып китмәсләр әле.

Тау башында уйланып, озаккарак туктап калганмын икән. Сул ягымда яңа хатирәләр уяткан, бер-бер артлы калкып ике йорт басып тора. Авылымның мактанычы да күңелемнең үкенече дә алар. Минем өчен Миңнулла белән Зиннур абыйлар туып-үскән бу йортлар татар генералларының нигезе. Генерал булыр өчен бу илдә урыс булып туарга кирәк. Татар халкы—талантлы ул! Шушы Чаллы-Бөкәш төбәгеннән чыккан хәрбиләрне бергә җыйнап, Мәскәү тарафына йодрык күрсәтсәң, анысы гына түгел, Әмерикәсе дә калтырап төшәр иде. Юк шул, төйнәлә белмибез, үзебез эшләп тапканны гына Мәскәү тарафыннан теләнергә өйрәнгән без.

Тау төшкәндә уң якта хуҗасыз бер кечкенә кара йорт кала. Без үскәндә анда ике әби яши иде. Мин аларның кемнәр икәнен дә белмим. Шулай да кечкенә чакта йомырка җыю бәйрәмендә әбиләрнең берсе авылда бала-чага күп булуга шатланып: былтыр күкәйләр артып калган иде, быел йөзне пешерсәм дә җитмәде дип, башларыбызны сыйпап, сөенеп сөйләнгәне истә калган. Хатирәләр йомгагы тау буйлап аска төгәри. Артта аз гына җилдә дә шак-шок тавыш чыгарып, авылга беренче сурәт керткән телевизор антеннасы кала. Беренче чын машинаны да шушы капка төбендә күргән идем.

Алда кече күпер һәм Гыйлемхан абыйның йорты. Гыйлемхан абыйны күргән саен әни искә төшә. Бу хатирәләр он, мичтә пешкән ипи тәменә бәйле. Гыйлемхан абый тегермән тартканда он исе бар авылга таралыр иде. Шул оннан әниләрнең нәрсә пешергәннәрен алдан ук белеп, ис-тәмен дә урамда ук тойдык без. Бүгенге ризыкның тәмен кат-кат чәйнәп тә татып булмый. Әллә җир-туфрак үзгәрде, әллә үзебез тотнаксызландык. Хәер, сәбәбен белмәмешкә салынып, кыланып утыру килешмәс. Туган җир туфрагында үсеп, авыл тегермәнендә бисмилла белән тартылган оннан пешкән ризыклар түгел шул болар. Хәзерге чүпрә-онда Америка суррогатлары, кырык төрле җир ашламалары һәм тагы Шомбыт чүпрә заводында чыккан әллә ничаклы химик катнашмалары бар. Әле дә исән, әле дә яшибез әле без!

Түбән очта яшәүче авылдашлар янында озакка тоткарланып булмый. Бу тирәдән башны аска иеп, гел аяк астына гына карап йөрергә өйрәнелгән инде. Элеккедән калган гадәт. Моннан ары яңа юлларда шак-шок басып йөрелсә дә, барыбер батып-чумып йөргәннәр тиз генә онытылмас, ахрысы. Төшләргә кереп булса да йөдәтер. Алар монда яшәүчеләрнең генә түгел, әллә нигә бер үтеп-сүтеп йөрүчеләрнең дә бәгыренә үткәндер. Бер заман бу урыннар су астында калырга тиеш дип тә сөйләгәннәр иде. Әллә шуңа бәйле, әллә сазлыктан куркып, яңа йорт салганда тау өстенәрәк менеп кунакларга тырышучылар да табылды. Әмма буалары буылса да, балыкларыннан авыз итәргә насыйп булмады, су капкасын ябып, балыгын җибәрәсе генә калган иде, югыйсә. Бу фикер, бәлкем, кайчан да булса бер акыллысының башына җитәр әле.

Түбән очны узып, күпергә җитәрәк, сул якта олы тыкрык. Тимерче, ындыр юлы. Яшь чакларны искә төшереп, гел шунда тартыла күңел. Ындырга кереп чыгасы килә. Безгә бригадир, персидәтел, упраулар кем ул?! Чумар бабай капкасы аша узып булса, ындырында гына аннан качар урын табылыр иде әле. Ындырның төп хуҗасы—каравылчы. Яраткандыр ул безне, яратмаса без бала-чага белән алай булышмас иде. Курка идек, әмма зыяны тимәде. Ындырның икенче хуҗасы Хамәдгали абыйга тап булу алай шәлләтми иде. Анысы йодрыгын селкетсә дә, бала-чаганы түгел, көн-төн ашлык чүпләүче кош-кортларны да рәнҗетмәс. Аннары, без малай-шалайларның барыбызның да әниләре монда эшли. Алар да тел-теш тидертми безгә. Ә менә каравылчы Фәйзрахман абый олы, коры кеше. Аның белән авыррак. Әмма безнең якта бер отыш бар. Без аннан гына түгел, безнең арттан ыргыткан таяк, себеркеләреннән дә тизрәк чабабыз. Ындырдан кусалар, тегермән тирәсендә чуалырга, паркка барып уйнарга була. Ярамаган малай-шалайга. Хыялда чын машина-тракторга әйләнә-ерлек тимер-томыр өеме беткәнмени. Төшке ял вакыты булса, тимерчегә кереп пычак

чүкергә була. Ишеге бикле булса да тәрәзәдәге тимер челтәр тишеген нәкъ безнең баш сыярлык калдырганнар. Ә баш керсә гәүдәсе сыя инде аның. Дөрес, хуҗасы килгәндә качып өлгерәсе дә бар әле. Шунлыктан, керүгә беренче ишекне терәтеп куябыз...

Татлы хыялларны өзеп, дөнья кабат чынбарлыкка кайтара. Тегермән, тимерче дә юк, парк урыны кырга әйләнеп, ындырында да безнең балачак чорыннан бер нәрсә дә сакланмаган инде... Бары ерактан гына ике матур йорт күренә. Аларның берсендә минем алтын куллы күршем Зиннур тора. Кайтып өйдәгеләрнең хәл-әхвәлен белешкәч, төшеп менәм әле. Яшь чакта бар күргән-белгәннәрне без бергә татыдык.

Күпергә дә ерак калмаган. Әмма бу тирәгә бәйле бихисап хатирәләр, адымнарны акрынайтып, чабудан тарта. Элек бу чат иң җанлы урыннарның берсе иде. Бүгенге көндә бар тараф, агачлары сайлап кына киселгән урмандай тишкәләнеп беткән. Сул якта авылымны данларлык тагын бер нигез утыра. Заманында аннан чыккан белем ияләре белән генә дә тулы канлы татар университеты ачып булыр иде. Чын университет бетереп, математик, физик, биолог, юрист... кебек һөнәрләр алган данлыклы Исхак абыйның ул-кызлары алар. Тик татарның укыган берен "чукындырып" бардылар шул. Бүгенгәчә Казан хәтле Казанда татар университеты ачылмавын алмауларын искәртүем. Исхак абый нигезенең бердәнбер хуҗалары, балан белән кура-җиләк куаклары бүген. Җәй җитүгә берсеннән-берсе көнләшкәндәй, кызарып пешә алар. Беренчесенең тәмен бала-чага татыса, икенчесенең ачысы шул килеш кала бирә. Шушы ачы язмышлардан саклыйсы иде туган авылны, туган нигезне. Бу бигрәк тә безгә, төпчек угылларга кагыла. Әнә, артта калган Фәйзрахман абыйның нигезен яңартырга төпчеге Габдулхак абый алынган да инде. Аларның тамырлары нык, изге бурычларын үтәп, ата-баба нигезләрен саклап калырлар. Һәрхәлдә, уңышлар юлдаш булсын.

Күпернең төбендә үк урнашкан Имай (Имаметдин) бабай урыны буш булса да уллары-оныклары авылда аның. Нигезе караусыз түгел. Әниләр өчен олы хөрмәт иясе—ул да тегермәнче иде. Ә безнең күңелгә ул алма бакчасы хуҗасы буларак кереп калган. Шул алма, яшелчә бакчаларын, тегермән буаларын искә алсаң, гаҗәпләнүдән ис-акылың китәрлек. Җәннәт бакчасыдай җирдә, эшчән һәм укымышлы халкы белән беркемгә дә ялынмыйча үзе бер дәүләт буларак яши алган заманалары булган икән лә бит авылның. Әмма бу илдә гомер-бакый халык-милләтләрнең бәйсез булуыннан курыкканнар. Шуңа бәйле ил-авылларын гына түгел, кешеләрен дә бәйлелектә тотканнар. Аларның хуҗалары итеп һәрчак килмешәкләр куелган. Хәер, анысы үзеңнеке утырса да чабатасын түргә элүчесе табылыр иде.

Күпернең уң ягында күңелгә уелып калган соңгы йорт урыны. Бу нигездә бабайның әти-әнисе бер карчыкка вакытлыча йорткa кереп, 12 ел үз авыл-сөргенендә "утырган". Аларның бу тоткынлыктан котылулары Сталинга бәйле. Бер кешенең үлеме миллионнарча кешене иреккә чыгарган. Хәзергеләр әйтсәң дә ышанмас, булган бит заманалары, атасына улы белән торырга ярамаган. Хәзер заманалар үзгәрде, уллары аталары белән торырга теләми. Тиранары шул ук булса да, гореф-гадәтләре башка. Дөньялары болай барса, кая чаклы барып чыгылыр...

Ашыгып күперне чыгам. Каршыда, тау башында күңел ашкынган туган йорт. Хисләнеп ашыгылса да барыбер алдан ук алданасың. Күрәсең, күңел була. Хәл-әхвәл сорашасың—тыныч ланасың. Туган йорт авылның кыл уртасында урнашкан. Авылның икенче ягына сәяхәткә чыксаң да, исән-иминнәрен күреп сөенәсең, бушап калган нигезләрдә яшәп-киткәннәрен искә төшереп, көенәсең. Авылның киләчәген билгеләргә тырышкан өмет-хыялларда барган саен бер киселеп, бер ялгана тора.

Сәяхәтем тәмам. Җырларда җырланганча: "Күргәнче күңел китек иде, күргәч күңел булды инде." Кабат китәргә кирәк. Дөнья ул авылдан читтә дә чаба, дөнья арбасыннан төшеп калмас өчен аны анда да куарга кирәк. Татарның элек авылы да, шәһәре дә булган. Кайчандыр бездән бу шәһәрләрне яулап алганнар. Бүген без аларга акрынлап хуҗа буларак кайтабыз. Авылларны саклап калыр өчен шәһәрләрне дә сакларга кирәк. Шуңа бәйле авылдан китүчеләрдән аны таркатучыларны гына күрергә киракми. Татарның җир эшкәртүчесе, төзүчесе дә, сәяхәтче-сәясәтчесе, язучысы, галим-голәмәсе дә булырга тиеш. Авылны яшәтү, саклап калу өчен без дә җан тартышабыз. Ә авыл буйлап, үткәннәр белән киләчәкне бутап, бүгенгесендә йөрү гайбәт сату түгел. Аллам сакласын! Бар уйлануларым ата бабаларыбыз, үзебез тибрәлгән уртак бишек—авылны яшәтү-яшәртүгә бәйле иде. Ә бу юнәлештәге хыял-гамәлләребезне тормышка ашсын өчен безгә бердәм булу кирәк.

АКЫЛ һӘМ ХИС ДУЛКЫНЫ

РОБЕРТ МИҢНУЛЛИН ПУБЛИЦИСТИКАСЫНА БЕР КАРАШ

Кешенең баш миендә уңдүрт миллиард чамасы күзәнәк бар, диләр. Шуларның яртысы акыл, ә калганы хис белән бәйле икән. Акыл күзәнәкләре эшләгәндә хисләрнеке ял итә, янәсе. Һәм, киресенчә, хисләрнеке хәрәкәткә килсә, акыл-ныкылар тына. Әгәр акыл һәм хис бер үк вакытта "дуласа", ике төр күзәнәкләр аралаша, давыллана, бер-берсенә керешә, нәтиҗәдә акыл һәм хис дулкыны барлыкка килә. Халыкның: "Мисезнең мие күбек, сөйләгән сүзе чүбек",—дигәне дә акылга бәйләнгәндер. "Акыл—ата, хис—ана",—дигәне исә акыл һәм хис дулкыны берлеген аңлатадыр.

Моны тикшерү—психологлар шөгыле. Шулай да аны белү язучы, галим, мөгаллим, табиб...—һәркем өчен лазим. Әслүб-стильләрне дә шуның белән аңлаталар бит. Матур әдәбият өслүбендә (чәчмә әсәр, шигърият, драма) хис өстенлек ала. Чөнки язучы укучының хис-тойгысына, йөрәгенә, күңеленә тәэсир итәргә тырыша. Төрле поэтик бизәкләр, сурәтләү-тасвирлау чараларын мул куллана. Язучының хыял-фантазиясенә тулы ирек бирелә. Публицистик стильдә исә (мәкалә, очерк) хыял-фантазияга чик куела. Фикерләрнең логик дөреслеге саклана. Төрле сәяси-иҗтимагый вакыйга, тормыш-көнкүреш хәлләре, икътисадый мәсьәлә, көн яңалыклары шушы стильдә гамәлгә ашырыла. Кыскача гына болай да диләр: "Матур әдәбият стиле хис-тойгыга, публицистик стиль аң-акылга тәэсир итә". Шулай да моны кырыс хакыйкатькә санамаска кирәктер. Чөнки кешенең баш миендәге акыл һәм хис күзәнәкләре вакыт-вакыт кушылып давылланган кебек, стильләрдәге үзенчәлек хосусияте дә аралашып-кушылып китә.

Стильләрнең бер-берсенә булган тәэсире бик борынгы язмаларда да күзәтелә. Ул әле һаман да дәвам итә. Моның шулай икәнлеген Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, Г. Х. Андерсен исемендәге халыкара әдәби бүләк иясе, күренекле шагыйрь Роберт Миңнуллин публицистикасы да раслап тора. Без аның колакларны назлап, йөрәкләрне җилкендереп торган җыр-моңнарын тыңларга, акылга азык, хискә нур өстәгән шигырьләрен укып ләззәтләнергә гадәтләнгәнбез. Бер үк вакытта безгә шагыйрьнең публицистика белән даими шөгыльләнүе дә мәгълүм. Казанның "Матбугат йорты" нәшриятында басылып чыккан "Шагыйрь генә булып калмадым" исемле китабы без әйткәнне раслый да куя.

Шагыйрьнең публицист булып китүендә, минемчә, серле, сихри, яшерен хосусият бар. Моны Роберт Миңнуллинның элегрәк газиттә эшләве белән дә аңлатып буладыр. Ләкин гади хәбәрчене, журналистны без әле "публицист" дип әйтергә ашыкмыйбыз. Чөнки чын публицистлар бармак белән генә санарлык.

Публицистика—латин сүзе. Чит илләр сүзлеге буенча фикер йөртсәк, иҗтимагый-сәяси хәлләр турында язучы публицист дип атала. Менә ни өчен аң-акылга, фикер йөртү яссылыгының киңлегенә, мантыйкый дөреслеккә бәйле ул. Шулай да нәзариятчы-теоретикларның матур әдәбият өслүбендә хис-тойгыны беренче, аң-акылны икенче итеп куюлары белән тулысынча килешеп тә булмыйдыр. Акыл-белем җитмәсә, халык әйткәнчә, миең күбек булса, кәгазьгә каләм очыннан сүз гәүһәре түгел, сүз чүбеге коелачак. Һәм, киресенчә, акыл очкынына йөрәк ялкыны кушылмаса, фикереңә яфраксыз агачны

хәтерләтәчәк. Гадиләштереп әйтсәк, хистә—акыл, акылда хис булу хәерле. Г. Тукай, Г. Ибраһимов, М. Кәрим, Н. Нәҗми кебек каләм осталары моның гүзәл үрнәкләрен күрсәттеләр. Бу үзенчәлекне без Роберт Миңнуллин публицистикасында да күрәбез. Ул шигъри ялкыннан киләме? Әллә башкачаракмы?

Л. Н. Толстой галиҗәнаплары дөнья куйгач, Г. Тукай "Мөбарәк тәсбих өзелде" дигән шигырь язмакчы була. Күп уйлана торгач, аның шигырь үлчәвенә сыймаячагын аңлый. Моны ул ике строфадан торган шигырь белән аңлата: "Ушбуны яздырды нәсрән вәжданымның көчләве. Мәсьәлә бик зур, сыйдырмый тар шигырьләр үлчәве". Шуннан ул олы талант өчен сызлануын чәчмә итеп яза. Шундый ихтыяҗ хәсияте дә бардыр, бәлки, Роберт әфәнде йөрәгендә. Ул жандай якын күргән, сөйкемлелеге белән язарга дәрт-талант биргән, үзенчә бер шигъри моңга әверелгән Сөне турында һаман җырлап туя алмый бит әле. Аңа булган кайнар мәхәббәтен, күңел илаһилыгын, хис-тойгылар давылын шигырь кысасына гына сыйдырып бетерә алмый, күрәсең. Әле менә публицистика китабын да "Сөнне сагыну" исемле мәкаләсе белән башлый. Сөн—шагыйрь өчен поэтик символ. Сөн, сөйкемле кыздай елмаеп ага-ага, ак күңелле Агыйдел кочагына барып сыена. Агыйдел аны, җәһәт җитәкләп алып, Чулман куенына илтеп йомдыра. Сөн, Агыйдел, Чулман, бер атаның тату балалары шикелле шатлана-шатлана җәһәтләнеп, Идел-Ана йөрәгенә барып сеңә. Күп елгаларны тайчанмыйча кабул иткән бу олы йөрәк, ахыр чиктә, үз язмышын Хазар диңгезе (Каспий) йөрәгенә кушып хозурлана.

«Казан утлары» журналы редакциясе хезмәткәрләре һәм редколлегия әгъзаларыннан бер төркем. Уңнан сулга: Зәки Нури, Роберт Миңнуллин, Рәдиф Гаташ, Гомәр Бәширов, Солтан Шәмси, Марсель Галиев, Ренат Мөхәммәдиев. 1980 ел.

Роберт Миңнуллин шигърияте дә шулай. Сөннән башланып, олы поэзия диңгезенә барып кушылды ул хәзер. Әмма көзен очкан сыерчыклар язын үз оясына кайткан шикелле, аның күңеле һаман әле Сөненә кат-кат әйләнеп кайта. Мәкаләнең "Сөнне сагыну" дип аталуы да шуны раслап тора. Шулай да бу нечкә хисләргә бирелү, йомшау, күңел төшенкелеге түгел, ә, бәлки, олы йөрәклелек, шәүкәтлелек илаһияты. Таш йөрәкләр сагына белми. Бердәнбер газиз анасының күңелен "кош теледәй" генә булса да хат язып та җылытмый. Ә инде Роберт галиҗәнаплары исә Сөнне менә ничек сагына: "Сөн ул — безнең балачак. Сөн ул — безнең кабатланмас хыялый дөньябыз. Әле дә күз алдымда: Сөн иксез-чиксез яшеллеккә күмелеп ага. Ерып та чыга алмаслык әрәмәлекләр. Андагы җиләк-җимеш!.. Ул шомырт, миләш дисеңме, кара һәм кызыл карлыган дисеңме. Каен җиләге, кура җиләге... Гөлҗимешне әйткән дә юк. Ул кыйммәтле җимешне безнең авылда потлап, центнерлап җыеп тапшыралар иде. Хәзер исә дәвага да табуы кыен. Бик күп көмеш сулы күлләрнең урыннары да чокырга әйләнеп калган. Әле мин белгәндә дә биек-биек тирәкләр шаулап утыра иде Сөн буенда. Алар да юк инде. Төпләре генә тырпаеп утыра. Кемдер кисеп алган..." Сөн буеннан башланган шигърият олы поэзия диңгезенә барып кушылган кебек, Сөн турында хисси-публицистик фикерләүләр дә дөньякүләм глобаль мәсьәләләргә барып тоташа. Чыннан да, табигатьне сакламау, рәхимсез рәвештә кыерсыту нәтиҗәсендә, әле тегендә, әле монда озон катламы "ертылып", экологик афәтләр барлыкка килеп тора лабаса. Бу күңелсез күренеш әгәр шулай дәвам итсә, бөтен дөньяны фаҗига сазлыгына батырачак.

Мәкалә шулай тәмамлана: "Табигать—Ана кебек ул. Якын иткәнне, хөрмәт иткәнне, үз иткәнне ярата. Табигать—Бала кебек ул. Кадерләгәнне, назлаганны ярата. Табигать Шомбайның төпсез эшләпәсе түгел ләбаса! Аның һәр каены, һәр талы, һәр торнасы, кыр казы, һәр былбылы исәптә. Аларны саклау безнең намуска бәйләнгән".

Шигърият дулкыны артыннан шагыйрь зур сәяхәткә чыга. Менә ул Каракалпакстанда. "Кунак ашы—кара каршы" дигән мәкалә языла. Аның артыннан минем дә тынгысыз күңел шул якларга сәяхәт итә кебек. Күз алдыма Иртыштан башлап Днепр елгаларынача сузылган очсыз-кырыйсыз дала, анда әле күчмә, әле уртак тормыш кичергән

гаярь кыпчак кабилаләре килеп баса. Бу кабилә ерак ата-бабаларыбызның гәүһәр тамыры бит. Ул тамырдан, алтын баганадай шытып чыгып, татар, башкорт, казах, кыргыз, каракалпак, нугай, кумык кебек данлыклы милләт кәүсаләре чыга. Бер-беребезне жаныбыз да, каныбыз да тартып тора. Йөрәкләрдә кайнар дуслык-туганлык төшенчәсе тантана итә. Шул хакта сүз бара мәкаләдә: "Татарстанда олы бәйрәм. Каракалпакстан әдәбияты һәм сәнгате көннәре. Туган жиребез, туган халкыбыз кунак каршылый. Бу бәйрәм исә бүген генә түгел, инде узган ел ук Каракалпакстанның үз жирендә—Татарстан әдәбияты һәм сәнгате көннәрендә—башланган иде. Димәк, бу бәйрәм—ике халык арасындагы олы бәйрәмнең матур дәвамы. Каракалпакстанның халык язучысы Жолморза Аймурзаевның шушы унайдан язылган бер шигыре дә бар иде. Аның да кайбер юллары Роберт туган күңелендә уелып калган:

Безнең Ватан—иреклеләр
Ватаны,
Кызлар йөзе төсле алсу һәр таңы.
Котлы булсын дусның дуска
Сәфәре...
Сәлам сиңа, кан-кардәшем,
татарым!

Ә инде озатканда шундый сүзләр әйтә калям остасы Жолморза Аймурзаев:

Сез китәсез... Башка нәрсә
Керми бүген уема.
Нәүбәт килде, без барырбыз
Ак Идегнең буена.
Уйнар әле, жырлар әле
Алтын кыллы дутарым
Татар белән каракалпак
Дуслык сабан туенда.

Мәкалә шулай тәмамлана: "Уйна, әйдә, алтын кыллы дутар! Уйна, әйдә, алтын телле гармун! Татарстан жирендә, Идел буйларында— дуслык Сабан туе!

Хуш киләсез, кадерле туганнар!
Хош киләпсез, кадирли
тууысканларымыз!"

Бу юлларда дуслык-туганлык иманына табынуның кайнар дулкыны, йөрәк ялкыны, эстетик идеалы балкый. Бу кунаклашу сиксәненче елларда булган иде. Аңа инде егерме елдан артык вакыт үткән. Аннан соң күпме жилләр исеп, күпме сулар аккан. Әмма дуслык-туганлыкның бу бөек төшенчәсе Каракалпакстан һәм Татарстанның жиренә дә, күгенә дә, халыклары күңеленә дә алтын хәрефләр белән язылып калган. Әлеге изге, кадерле, садә минутлар шагыйрь Роберт Миңнуллин күңелендә дә һаман әле жуелмас энҗе-мәрҗән булып саклана икән. Әмма бу язмада кайнар хис-тойгы, йөрәк ялкыны, күңел давылы очрашуы гына икән дип уйлый күрмәгез (анысы да су һәм һава кебек кадерле), анда шагыйрь-публицист безне Каракалпакстанның зур казанышлары, дөге байлыклары, яшәү рәвеше, мәдәнияте, башка күркәм сыйфатлары белән таныштыра.

Мәгълүм ки, ерак тарихта төрки халыклары бер-берсенә хәзерге кебек дуслык-туганлык байрагы тотып түгел, сөнге белән кан-коеш көрәшенә дә килгәннәр. Үтереш. Талаш. Фажига. Тарих бабай шаһит моңа, галәм шаһит. Шагыйрьнең милләтләр арасында булган бүгенге бөек дуслыкны шигырь үлчәвенә салып та, публицистик язма, очерклларда да чагылдыруы аның гомумкешелек, дөньяви хәлләр өчен борчылып яшәвен, аң-акылы һәм хис-тойгысы ватанпәрвәрлек илаһилыгы белән сугарылганлыкны аңлата. Публицистикада аның фикерләү офыклары гаять киң. Менә без янә туган якларга кайтабыз. Татарстан. Актаныш районы. "Татарстан" колхозы. "Рәхмәт сиңа, игенче!" исемле язма. Без күкрәп үскән иген басуы дулкыннарында хозурланып кына йөрмибез, шул игенне үстерүче алтын куллы, тырыш, батыр йөрәкле, бар авырлыкларны жиңеп яшәүче, ил-халык мәнфәгате өчен көн-төн белән исәпләшмичә эшләүче даһи кыр каһарманнарын күреп шатланабыз. Теге мәкаләдә шагыйрь укучыны бөек дуслык шәүкәтлелеге белән тәрбияләсә, монысында инде яшәү чыганагы икмәккә, фидакарь хезмәткә карата зур мәхәббәт уята.

Сөн елгасы Актаныш (Татарстан) белән Илешне (Башкортстан) нәкъ урталай бүлә. Моны да онытмый шагыйрь. "Сәлам, Башкортостан!" мәкаләсендә гомер-гомергә кан-кардәш булып яшәгән татар, башкорт халкы дуслыгына мәдхия укыла: "Сөн—уртак елгабыз, уртадагы елгабыз. Бәлки шуңадыр да, минем "Әнкәй безне Сөннән алып кайткан" дип башланган җырымны ике республикада да үз итте ләр. Аны Әлфия Авзалова, Зөһрә Сәхәбиева, Миңгол Галиев кебек танылган татар җырчылары да, Флүрә Ногманова, Филүс Гәрәев кебек талантлы башкорт җырчылары да яратып җырлыйлар".

Аш төрләндерү һәрвакыт тансык булган кебек, тема төрләндерү дә бик кирәкле шәйдер ул. Роберт Миңнуллин бу үзенчәлекне публицистик язмаларында да даими искә ала. Безне Татарстан, Башкортстан, Каракалпакстан һаваларын сулатып йөртә-йөртә дә, капылт кына икенче мәүзугка—гаилә темасына күчә дә куя. Хәзер инде без шагыйрь-публицистның "Сүнмиме гаилә учагы?" исемле язмасыннан яшәү фәлсәфәсе алабыз. Зур тема. Искиткеч зур. Яшәү белән үлемне хәл итә торган мәүзут. Тууга караганда үлемнең күбрәк булуы, эчкечелек, наркомания, алдау, алдану, акула чуртанны йоткан кебек, көчленең көчсезне сытарга тырышуы, әхлаксызлык...—шуларга охшаш мең төрле сыйфатлар гаилә учагын сүндерә, изә, челпәрәмә китерә, тарката. Ата—гаилә каны, ана—гаилә җаны. Роберт Миңнуллинның "И аналар!" исемле мәкаләсе шуны күз уңында тотып язылгандыр. Болай ди ул:

"И аналар!

И газиз татар аналары!

Ничә гасырлар дәвамында татар канын саклап калган, карангы, дәвамлы, кырыс еллараша халкыбызны бүгенге көнгә китереп җиткергән асыл затларыбыз сез. Кол Галиләрне, Тукайларны, Туфанларны дөньяга бүлак иткәнсез, Идегәйләрне, Батыршаларны, Колшәрифләрне, Җәлилләрне биргәнсез, мәшһүр ханнарны, каһарманнарны, җырчыларны һәм шагыйрьләрне тудыргансыз. Ни кызганыч, сезнең хакта тарих бөтенләй диярлек белми. Әмма сезгә булган ихтирам хисләре татар күңелендә һәрвакыт сакланыр".

Чыннан да, татар хатын-кызларының каһарманлык табигате бик борынгы заманнардан килә бит. Ире сугышта үлсә, аның өчен көрәшкә китүе... Мәгүбә Сыртлановаңың Бөек Ватан сугышында 782 хәрби очыш ясап каһарманлык яулавы... Хәзерге вакытта мең-мең-мең татар хатын-кызларының авыр, җаваплы, четерекле хезмәттә эшләве... Әдәплелек, шәфкатьлелек, инсафлылык, сабырлык, түземлелекнең матур үрнәкләрен дә күрсәтә ич татар хатын-кызлары! Шагыйрь-публицистның бу мәсьәләгә махсус тукталуы юкка гына түгелдер.

"Стиль—язучының дөньяга карашын чагылдыру системасы", дип тә сөйләшәбез. Чыннан да, язучының дөньяга карашы, эстетик идеалы, ил, халык, милләт мәнфәгатьләре белән яшәве аның хис-акылының йә җәмәгатьчелек алдында сөйләгән, йә каләм очыннан кәгазьгә төшкән сүз гәүһәрләрендә чагылдырыла бит. Мәгәр дөньяга караш, эстетик идеал, акыл-хисләр тирәнлеге күз белән күктән йолдыз чүпләп йөреп кенә барлыкка килми. Роберт Мөгаллим улы Миңнуллин—хәзер Татарстан Дәүләт Советы Рәисе урынбасары. Бу вазыйфаның никадәр җаваплы, җитди, аң-акыл, хис-тойгы синтезы сорый торган хезмәт икәнлеген һәркем яхшы аңлый. Аның җәмәгатьчелек-гавам алдында сөйләгәннәре, шулар хакында язып чыкканнары зур проблемалы, тирән уйланылган, ил-халык язмышына, яшәешкә, киләчәк идеалларга бәйләнешле була. Моны "Телгә дигән акча кая киткән?", "Милли репертуар кирәк!", "Телсез татар кемгә кирәк?!" (Татарстан Дәүләт Советы сессиясендә ясалган чыгышлар), "Тел безне берләштерергә тиеш!" (II Бөтендөнья татар конгрессында ясалган чыгыш), "Аралар якын икән!" (Төркия белән бәйләнеш), "Ташлы Кавал берәү генә!" (Татарстандагы Биектау районының "Юлдаш" күмәк хуҗалыгының үзәге урнашкан гади генә бер авыл турында), "Зәңгәр экран нигә соры?", "Татар барып карамый ышанмый" (Әзербайҗанга сәяхәт) кебек мәкалә-язмалары да раслап тора. Китапның публицистика бүлеге "Өлешемә тигән Илешем!" дигән язма белән тәмамлана: "Бу дөньяның иң матур бер төбәге—Илештер! Иң кайнар кояш, иң якты ай, иң серле йолдызлар Илеш өстендә генә янадыр! Дөньядагы иң сылу кызлар, иң батыр егетләр Илештә генә үсәдер! Җир йөзендәге иң эшчән, уңган, иң сабыр һәм игелекле кешеләр, мөгаен, Илештә генәдер!" Бу сүзләр халыкның: "Һәр сандугач үз оясын мактап сайрый",—дип әйтүе генә түгел. Шигъриятендә дә, публицистикасында да туган җиренә карата кешеләр күңелендә зур мәхәббәт уята каләм остасы. Димәк, аның эстетик идеалы тирән, шәфкатьле, мөбарәкле, шифалы.

Сүз азагында әлеге "Акыл һәм хис дулкыны" дигәнгә янә әйләнеп кайтасы килә.

Шактый еллар элек берәү күренекле шагыйрьләрне публицистика белән шөгыльләнергә өндәп язган иде. Бу юкка гына түгелдер. Артык "коры" мәкаләләр, гәрчә аң-акылга теге яки бу дәрәҗәдә тәэсир итсәләр дә, укучыны дулкынландырмый. Мин үзем, мәсәлән, соңгы вакытта кайберәүләрнең хис-тойгы яки эмоцияне инкарь итүләре белән килешмим. Дөнья бит үзе даими рәвештә дулкын эчендә яши! Акыл белән эш иткәндә дә хис дулкынына киртә тотарга ярамый. Һәм, киресенчә, хис-тойгы дулкыны акылны да талап итә. Моны аңламау күп очракта ил түрендә утырган патшаларны да ялгыштыра. Ф. Достоевскийча әйтсәк: "Зур фикерләр зур акылдан гына түгел, зур хис-тойгыдан да туа". "Акыл һәм хис дулкыны" дигәнем шулдыр инде ул. Публицистның дөнья-галәм дулкынына камил акыл, тирән хис-тойгы дулкыны белән керүе, Тукай әйтмешли, кирәкле шәйдер. Минемчә, талантлы шагыйрь Роберт Миңнуллин бу публицистик язмаларда шуның матур үрнәген күрсәтә. Иншалла! Әлеге изге эшне ул киләчәктә дә дәвам итәр! "Шагыйрь генә булып калмадым..." дигән икән, дәвам итәргә тиеш тә.

Корьән калынлыгы бу китапта "Әдәби тәнкыйть" бүлеге дә бар. Анда да автор җитди проблема белән эш итә. Мәкаләләрнең аталышы ук раслап тора моны: "Киләчәк буын хакына", "Бала да—Кеше!", "Сөендерде дә, көендерде дә", "Нәрсә булды безгә?", "Балачактан башланырга тиеш!", "Балалар дөньясы".

Өченче бүлек "Иҗат портретлары, әдәби эскизлар" дип атала. Кемнәр турында гына юк анда: Муса Җәлил, Сибгат Хәким, Гомәр Бәширов, Илдар Юзеев, Туфан Миңнуллин, Әхмәт Исхак, Мөхәммәт Мәһдиев, Әнгам Атнабаев... Кыскасы, алтмышлап каләм осталарының портретлары!

Дүртенче бүлек—"Рецензияләр, уйланулар, мәкаләләр". Болары да—егермедән артык. Һәрберсендә бер проблема: "Шагыйрьнең офыгы", "Яшьлек урамына чакыру", "Заман сурәтләре" һ. б.

Әйе, сүз нуры көчле Роберт Миңнуллин публицистикасында. Янә кабатлыйк, ул аң-акыл, хис-тойгы нуры белән кәрәзли фикерен. Сүзләрне күңел сандыгыннан гына түгел, йөрәк төпкеленнән дә ала. Гади генә сүзләрдә фикер сөйкемлелеге тантана итә. Фикерләр, әгәр кирәк икән, сурәтләү-тасвирлау чаралары, шигъри бизәкләр белән нәкышлана.

Суфиян ПОВАРИСОВ,
филология фәннәре докторы.

«Казан утлары» елъязмасы

60 ел элек (1943) "Совет әдәбияты" журналында **Мирсәй Әмирнең "Мөстәкыйм карт йокысы"** хикәясе дөнья күргән.

55 ел элек (1948) "Совет әдәбияты" журналында **Кави Нәҗминең "Язгы җилләр"** романының дәвамы чыккан.

50 ел элек (1953) "Совет әдәбияты" журналында **Мирсәй Әмирнең "Ялантау кешеләре"** романы басыла башлаган.

45 ел элек (1958) "Совет әдәбияты" журналында **Әмирхан Еникинең "Йөрәк сере"** повесте укучыларга барып ирешкән.

КАШКА ТӘКӘМЕ, КӘҖӘ ТӘКӘСЕМЕ?

Гаиләбезгә "Казан утлары" журналы күптәннән, үзгә исемле чорыннан бирле килә. Ул шулай озак дәверләр йортыбызга яктылык ташый, хакыйкатькә тугъры булырга өнди, яманлык белән килешмәскә өйрәтә, алдагы көнгә өмет уята. Аның белән киләчәктә дә аерылыр исәбем юк, әмма, укучы буларак, журналга, авторларга кайбер фикерләремне җиткерәсем килә. Ник дисәң, "клиент, кулланучы һәрвакыт хаклы" дигән кагыйдәне сәүдәгәр, җитештерүче, хезмәт күрсәтүче рияданмы-ихластанмы—таный, ә әдәби продукцияне ил табынына куючы санга сукмый гына түгел, матбугатта буза куптара, укучысын шәхси дошманы санап, үтерәм-бетерәм дип, чәч туздырып, күз тондырып арт сабагын укытырга алына. Тәнкыйтьче штатындагылар, үзләре дә язучылар берлеге әгъзасы буларак, корпоратив мәнфәгатьләрне күздә тотып ахры, тәнкыйть исеме астында асылда мактау, яшерен рекламалау белән мәшгуль. Ә укучы тәнкыйтьләсә, аны нинди язмыш көткәнен әзрәк әйттек шикелле. Нәтиҗәдә, алеге ижатчы үзенең укучысын, шул укучысының якыннарын бөтенләйгә югалтып кына калмый, бик күпләр әлеге ижатка мәйдан биргән журналдан яки газетадан җаннары-тәннәре белән баш тарта.

Мәгълүм ки, система эшләсен өчен элемтәнең ике яклы булуы шарт. СССР, КПССлар җимерелүнең төп шарты, кем нәрсә генә димәсен, ике яклы реаль элемтәнең булмавында, төкәнүендә иде. Газета-журналларның тираж югалтулары артында, әлбәттә, сәбәпләр бик күп, әмма иң җитдие—реаль тәнкыйть булмау нәтиҗәсендә сыйфатның начараюы!

Сүзне журналда быел дөнья күргән әсәрләрдән башламакчымын. Әлбәттә, мин ахырына кадәр укып чыгарлык, ягъни чагыштырмача ярыйсы әсәрләр турында гына сүз алып барырга телим.

Әсгать Сәлахнең камил тел белән, мавыктыргыч итеп язылган "Каеннар юлы" повесте укучыны бөтереп алып кереп китә. Әгәр тимерче Сафуан һәм Микулай хатыны Сандра арасындагы мәхәббәт, артык озакка сузылмый, трагик чишелештә төкәнсә, чөнки фронтовик Микулай, тыл күсесе чатан Сафуанны үзен гарипләгән фашист белән бер күргә тиеш иде шикелле, әсәр, минем карашымча, мөкәммәллеккә ирешер иде. Ә автор бәянында Сандра Сафуаннан ике бала алып кайта. Микулай моны белә һәм хатыны сүзен тыңлап, "бажасы" Сафуанга өйлек агач бирә. Урлап бүләк итә торгандыр инде ул аны. Әгәр шушы гамәле өчен Микулай җинаять җаваплылыгына тартылса да, бу повестьта, кешегә санап теләктәшлек итәрлек бер герой булыр иде әле.

Әсәрдә әсәрләндерерлек хәлләр шактый. Сандра—Сафуан башлап җибәргән уйнашны, балигъ булмаган Гөлмәрфуга белән Минзәки, кырга чыгып та, мунчага барып та дәвам ита. Шул Гөлмәрфуга, үскәч, Сафуанга кияүгә чыгып, кыз бала алып кайта. Менә берзаман ерактан Минзәки кайтып төшә һәм Гөлмәрфуга моның белән янә мунча кера, ә берничә көннән, ирен һәм кызын ташлап, Минзәкигә ияреп чыгып китә. Янә килеп автор, пионер лагерьларында өлгергәнрәк малайларның, кызларның "каймагын алуларын" бәян ита. Ә азактарак Сафуаннын, кем кулыннан тотса шуңа ияреп китә торган искиткеч чибәр кызы Даимә сахрага чыгып Микулай һәм Сандра үстергән абыйсы—Данил белән кавыша. Сандра серне, ягъни Данилнең аңа абый булуын Даимәгә чишә. Ахырдан, кызлар мәсьәләсендә тәҗрибәле Данил икенче бер әйбәт кыз табып, бәхетле була, ә Даимә ник болай булдым икән дип уйларга бирелә... Күренә ки, әсәр пикант вакыйгаларга ярлы түгел. Геройлар инстинкт ихтыярында... Әмма кеше дигән җан иясенә интеллект та хас булырга тиеш түгел микән? Әгәр әсәр азагында берәүсе Сафуаннар авылына юл сорап, икенче берәү:

—Нәрсә калган анда сиңа. Анда бит ике кешенең берсе дебил, суында нәрсәдер бар бугай,—дисә, әсәр логик бөтенлеккә әзме-күпме юл сабыр иде... Чөнки, сөяркәсе өчен каравылчы иреннән өйлек агач сораучы Сандраны да, хатыны сүзен тыңлап, "бажасына" агач биргән Микулайны да, аны Сандрам бүләге дип, куанып кабул иткән Сафуанның да гамәлен бүтәнчә ни дип бәяләргә? Ни ислам, ни христиан, ни коммунизм төзүче әхлагыннан тулаем азат, тотнаксыз өлкәннәрнең һәм балаларның кыланмышларын тагын нәрсә дип аклап була? Шаккаткыч хәл, геройларга гадәти көнкүреш әхлагы

да ят... Әллә мин, наданлыгым сәбәпле, заманча әдәби әсәрнең нинди булырга тиешлеген аңлап житкермимме? Бәлки бу әсәр, татар өчен яңа жанр, порнофильмга нигез булырга яраклы беренче карлыгачтыр? Шунысы ярылып ята, авторга Сафуан кадерле, ул аны ярата һәм ничек кирәк алай аклый һәм яклый, әйбәт кеше дип тәкъдим итә. Гәрчә әсәрдәге фактлар моның киресен расласа да...

Мансур Вали-Барҗылының "Идел Яры" (Яшьлеккә сәяхәт)ен укыганда саф сулы чишмәгә юлыккандай буласың. Әдип Маликовның "Тылсымлы хатлар"ыннан соң күңел мондый пакълек-сафлыкны тансыклаган иде. Әмма автобиографик дулкында язылган күпчелек әсәрләргә хас уртак кимчелектән Мансур әфәнде дә котыла алмаган. Ул да төп героен судан ак, сәттән пакъ дип ышандырмакчы. Әмма әсәрдәге фактлар аның дәлилләре белән каршылыкка кера. Әйтик, герой сөйгәне янына дип тулай тораккa икe тапкыр килүендә ярын туры китерә алмый. Һәм бу герой өчен бик зур проблема булып чыга. Ә бит яраткан кешең янына йөз тапкыр бару да күп була алмый!.. Кыз үзе ягыннан мөмкин булган бар адымнарны ясап бетерә, ә егеттән өйләнү хакында сүз чыкмый. Кызның яше бара, һәм үзенә карата шактый битараф егетен кисәтеп тормый гына бүтәнгә үзеннән өлкән кешегә кияүгә чыга. Ә егет булып йөрергә лимиты төкәнмәгән герой, үзен ташладылар дип саный. Егет бер хәл, автор да шул фикерда Бәлкем, әсәрне "Пешмәгән егет" дип исемлиседер? Ярны ятларга бирүне безнең бабайлар да хупламаган бит...

Татар укучысы тарафыннан ифрат жылы кабул ителгән, дөнья күрмәгән дәвамы китапханәләрдән таптырыла башлаган "Бәхетсезләр бәхете" романында да (Фоат Садриев) андый чатаклык бар. Төп герой Сабитовны да яры ташлап, үзеннән өлкән кешегә кияүгә чыга.

Автор Сабитовны ярата, аны аклый. Әмма әсәрдә бәян ителгән фактлар, барысына да Сабитов үзе сәбәпче икәнен бәян итә. Беренчедән, егетнең сөйгәне белән очрашырга вакыт тапмавы. Кыз бит диңгез уртасындагы таш манарада сак астында түгел... Ә эш сылтавы белән, үзенә кунакка килгән сөйгәнен күз уңыннан ычкындырып, беренче секретарының кабахәт малае золымында калдыруы, житмәсә кызы янында, шул адәм актыгына ялагайланып, "Бездә Ришатка карышмыйлар"–диюе генә дә аның кемлеген ачып сала... Боларның аерылышуына Сабитовның булачак хатыны да, башкалар да түгел, егет үзе сәбәпче ләбаса. Шуны ни герой, ни автор танырга теләми...

Марат Әмирхановның "Тояк эзе" романы да мавыктыргыч. Әсәрнең төп герое Кашшаф, шулай ук, автор өчен шактый кадерле. Әмма ул ниндидер буйнсыз шәхес. Хатыны аны исерек хәленнән файдаланып кочагына ала һәм бу аңа өйләнә... Ә хатыны көчле, үз дигәнен итә торганнардан, төп эшен ташлап бизнеска кереп китә һәм гаиләнең бюджетын ул кайгырта. Кашшаф, уңган һәм тугъры хатыны чит илдән сыртына салып товар ташыганда, эше белән бәйле хатын белән мәхәббәт куерта. Автор фикеренчә–ул мәхәббәтнең үзе. Хыянәте фаш булгач, аны хәләле ташлый һәм үзе дә түбәнлеккә төшә.

Янә килеп сөяркәсе дә моны ташлап, Мефодий атлы бомж белән кавыша. Ягъни бу бәндә адым саен ярларын ятларга бирүче. Әсәр азагында ул тоткан фәнни концепция, югары даирәләр хәерхаһлыгы ярдәмендә өскә чыга, хатыны да моңа кайта... Бәлкем, автор һәм герой өчен фәндәге "жиңү" бик тә мөһимдер, әмма укучы күңелендә бу герой бер дә теләктәшлек уятмый... Әгәр әсәр азагында, фәнни эше барып чыгуга шатланып кайтып барышлый кемгәдер килеп бәрелеп, теге бәндә шактый төксе генә:

–Күзеңне ачыбрак йөр, фәләнбаш!–дип артыннан кычкырып калса, бәлкем, әсәр мантыйкый бөтенлеккә якынаер иде.

Роза Хәбибуллинаның "Яшьлегем серләре" әсәре дә кызык һәм анда яңалык та бар. Автор төп герой Гөлчәчәктән бер карыш та ни югары, ни читкә тайпылмый яза. Хатын, законлы ирен тартып алмасыннар өчен, көрәшә һәм житди сынауларны уңышлы кичеп, жиңүгә ирешә... Авторны Ниязның ниләр уйлавы-кичерүе кызыксындырмый һәм төп геройның кылганнарын мәхәббәткә түгел, ә эләктергәнне ычкындырмау инстинктына бәйләп кенә аңлатып була. (Әсәр, ире хыянәтен күтәрә алмый, балаларын язмыш иркенә калдырып үз-үзенә кул салган хатын турында мәгълүматтан башлана һәм Гөлчәчәк ысулы альтернатива буларак тәкъдим ителә. Минемчә, үз-үзенә кул салуны берничек тә аклап булмый, һәм шундыйга саләтле хатыннан вакытында араланган ир, бәлкем, дөрес эшләгәндер...) Әгәр, әсәр азагында, әйтик, Иделдәге ак пароходтагы сәяхәтләре вакытында берәрсе Ниязга килеп.

–Алыгыз, кыйбат сорамыйм, капса–ычкындырмый,–дип бульдог тәкъдим итсә, һәм ир:

–Рәхмәт, миндә андый мал бар инде,–дип көрсенеп җавап күндерсә, минем карашымча, әсәр бөтәер иде.

Тәлгат Галиуллинның "Төнге юллар" һәм Гөлчәчәк Галиеваның "Өзелгән өмет" әсәрләрендәге геройлар арасында да менә бу Кеше дип төртеп күрсәтерлекләре очрамый һәм авторлар андый максат та куймаган. Ирексездән "Казан утлары" элегрәк тәкъдим иткән Рушад, Гата, Хәкимҗан (М. Мәһдиев); Сәйран Сәләхов, Максим Майнагашев, Марсель Ялчинский (Миргазиян Юныс) һәм башка бик күп каһарманнар сагындыра. Хәтта Мәхмүт ага Хәсәновның шөкәтсез Бичура әбие дә шул рәттә чөнки ул куәтле, көчле шәхес.

Әле күптән түгел генә белорус халкының улы, бөек әдип Василь Быков якты дөнья белән хушлашты. Ул үзенең геройларын яратам дип, бер дә аяп тормаган. "Альп балладасы"нда тоткынлыктан качып баручы Иван үзенә иярген Джулиягә башта суга, ә бер мәлне инде үзе биргән тужуркасын да салдыра, икмәкне дә үзе белән алып, кызны ташлап китә. Әмма кире борылып килә чөнки исән калу инстинктын кешелеге җиңә. Ә "Сотников" әсәрендәге Рыбак? Аның сатлыкҗанга әйләнүен автор ничек хәл иткән?

Кем ничектер, укучы буларак, әдәби әсәрләрдән мин иң әүвәле Кеше–Каһарман эзлим, һәм шуны тапмый гажиз калам.

Әлбәттә, журналга, мөхәрририяткә дә үпкәләп булмый, хәзинәдә барын чыгара алар әдәби табынга. Һәм кыйбла жуелмасын диптер, элегрәк дөнья күргән, татарның гүзәл әсәрләрен биргәләп баралар. Әмма андый әдәпле ысул белән генә сыйфат өчен көрәш тиешле нәтиҗәләрне бирмәс шул...

Рөстәм ЗАРИПОВ.

КИЛӘСЕ САНДА УКЫГЫЗ

"Казан капкасын кыш җиле кага...

Мең тугыз йөз утыз жиденче елның егерме тугызынчы ноябре. Ераста уйнаклаган кызгылт таң нурлары офык түренә катлы-катлы өелгән кара-кучкыл тыгыз болытларны көчәнә-көчәнә ермачлап дөньяга яңа көн туып килүен хәбәр иттеләр. Кар сибәләп алды. Казан урамнары суыктан бөрешеп калган, әллә тагын кыш беренче мәртәбә килә бу жиргә–бөтен шәһәр көтелмәгән мөшкел хәлгә тарыгандай пошаманда иде.

Алемасов сәерсенүле карашын машина тәрәзәсеннән алмыйча шактый барды. Аның жанын нидер талкый, изә кебек. Шушы халәтенә жавап тапмый иде ул, югыйсә, әле берничә минут элек кенә барысы да әйбәт, барысы да тәртиптә иде бит. Иртәсе дә башка көннәрдәгедән әллә ни аерылып тормый иде. Көз белән кыш алышынган мәлләргә хас гадәти салкынча иртә. Кәефне исә жен алыштырдымыни–кисәк кенә кара болыт сарды күнел күген. Каты авырудан айный алмый жәфаланучы бетәшкән карт та болай ук яшәү тәмен жуймас".

*Күренекле язучы **Факил Сафинның "Саташып аткан таң"** романының өченче кисәге укучыларны миллионнарча кешеләрнең язмышы өстендә балта уйнаткан дәһшәтле утызынчы елларга алып кереп китә. Унынычы санда шулай ук язучы **Мәдинә Маликованың** кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрне гажәеп җылы буяулар белән тасвирлаган **"Мендем биек тауларга"** исемле лирик повесте дөнья күрәчәк.*

*Шигърият сөючеләрне **Әхсән Баян, Әхмәт Рәшит, Әдхәт Синугыл, Эльмира Шәрифуллина** кебек шагыйрьләребезнең яңа әсәрләре белән очрашулар көтә. Журналның киләсе саны, гадәттәгечә, публицистика, әдәби тәнкыйть, фән, тарих һәм башка тармакларны киң колачлый. Байтак еллар төрле шәрекъ илләрендәге илчелекләрдә хезмәт куйган якташыбыз **Йолдыз Хәлиуллинның "Дипломат язмалары"** дигән күләмле язмасы, мәсәлән, укучыларны алтмышынчы-житмешенче елларда Совет иле алып барган четерекле дипломатик мөнәсәбәтләр белән таныштырыр.*

Киләсе санда шулай ук юмор-сатира сәхифәсе урын алыр, иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздагы яңалыклар киң яктыртылыр дип көтелә.

Фән

ИШӘЛЕ АВЫЛЫ ҖЫРЛАРЫ ТУРЫНДА

Татар халкының үзенчәлекле һәм фәнни яктан караганда бай тарихлы этнографик төркемнәреннән берсе—кераҙшеннәр. Аларның килеп чыгышы, этник формалашуында катнашкан компонентлар турындагы мәсьәләләрне чишелеш тапкан дип әйтеп булмый әле. Бу сорауларга төрле галимнәр бик күптәннән игътибар итеп килгәннәр. Кераҙшеннәрнең тарихы, теле, гореф-гадәтләре, тормыш-көнкүрешләре, авыз иҗаты турында шактый хезмәтләр язылган. Шуна да карамастан, аларның рухи байлыгы, авыз иҗаты жәүһәрләре әле һаман да безне сокландыра.

Кераҙшеннәрнең сөйләшүләрендә, гореф-гадәтләрендә дә үзенчәлекле күренешләр яшәп килә. Алар борынгы кием-салымнарны, бизәнү әйберләрен саклап калганнар. Болар барысы да кераҙшеннәрнең үзләренең генә түгел, ә бөтен татар халкының тарихын ачыкларга ярдәм итәләр. Бу күзлектән караганда, кераҙшеннәрнең рухи культурасы да, һичшиксез, игътибар үзәгендә булырга тиеш.

Безгә үз вакытында Чистай районының Ишәле авылында булырга туры килгән иде. Авылның тарихы, истәлекләре, халыкның килеп чыгышы турында кызыклы риваятьләр язып алдык. Һәм иң әһәмиятлесе, авыл халкының күнелендә бик күп жырлар сакланып килүен күрдек. Язып алынган жырларда жанр төрлелеге аеруча игътибарга лаек.

Сөйләүләреңә караганда, бу авылга башта Ишкенәй исемле бер чуаш кешесе килеп утырган, авыл исеме дә шуннан Ишәле булып калган. Бу тирәдәге авылларның тарихы һәм халыкларның яшәеш-көнкүреше хакында Александр Иванович Васильев исә түбәндәгеләрне сөйләде (кадерле укучым, бу очракта бәянчының тел-лөгать үзенчәлегенә игътибар итсәң иде).

"—Ин алдан ук чуаш бабай килеб утырган Ишкенәй дигән, шуннан калган Ишәле дигән сүз. Татарлар Актау (авыл исеме) төбеннән килгәннәр ахыры исә. Безнең үзебезнең дә туганнар бар ыйы Актауда. Безнең мында терле жактан жыйылган халык, урыслар да бар ийе, алар соңарак килгәннәр. Тимерче бабай килгән (урыс). Чувашлар алар мында килгәч чукынган булырга кирәк, безнең мында чукынмаган чувашлар да бар. Кызыл су авылы, Саугачның йартысы чукынган чуаш, жартысы чукынмаган. Берсен тагын Утлаш дип жертәләр, Атлашкино ул. Тимеразек зур укыган кеше, шул чукынмаган чуаш. Чуаш Жантанда (Чуваш Ялтанында; автор искәрмәсе—Д. Р.) бер бабай бар, метрикәсе бар әле анын, "некрещонный" дип жазылган. Бездән бер пачулкы айрылып чыккан Зирекле дигән, урман төбендә генә ул. Мең тугыз йөз унберенче жыллардук чыккан. Чукынмаган чуашларның дине дә башка, бәйрәмнәре дә башка. Паскылары барыбер бар, бер өч кенә көн алдарак безнең олы көннән. Бездәгечә тегел, чиркәүгә жермиләр. Кайадыр кырга чыгып укыйлар алар бәйрәмнәрен. Аларның исемнәре дә безгә окшамый, дин китабында да жук. Безнеке бит чиркәүдә исемнек бар. Йәләнтәй дигән ирләр исеме бар анда: Мигәдәр, Аиска, Йаку, Силагур. Анын кызы чиркәүгә барган, тырмышка чыккан, утчестывосын әйткән дә, бер нигә дә килми икән, кенәгәдә дә жук икән. Симулла, Миндыбай, Пимулла, Жармук, Иләндүк, Микер, Кычык, Жәнтәй, Ишкенәй, Эрнук. Кыз-катыннары Майраби, Минсылу, Синәслу, Чагак (чагак сайыскан дигән сүз), Миниса, Миннебикә, Әрнәби. Жирне жыл сайын бүлгәннәр. Кайан чыга, шуннан биргәннәр. Чуаш белән кераҙшеннәр жире бергә булган. Иген, терлек, урманны кискәннәр, аннан төпләгәннәр, жир жасаганнар. Безнең жылганың исеме дә Зирекле икән, жылга башында гөл усеб утыра икән. Вәт мона шуннан

калган инде безнең жылганың исеме. Кирәмәт эт урында булган, мынысын Түбән Кирәмәт дибез, аннан бераз китеп Урта Кирәмәт асты, Зирекле авылы йанында эченче Кирәмәт Асты, ансы самай кирәмәт асты инде".

* * *

Авылда изгеләр чишмәсе турындагы риваять бик кызыклы. Ул чишмә изгеләр өсте дип атала. Яңгыр озак яумый торса, яңгыр боткасы пешереп сулар сибешү гадәте бар. Алар турында болайрак сөйлиләр.

Изгеләр өсте

"Изгеләр өсте диләр шул жирне, шул келүчне *(ключ—чишмә)*. Жиде кызны тереләй күмгәннәр. Бер Бүләр байарында жалчыда булганнар алар. Элекедән бит инде ул. Жир селкенеп тырган ди шул төштә аларны күмгәчтен. Тишмәсе (чишмәсе) зур, крус куйган ийе. Шунда күлмәкләр, жаулыклар жаңаларны элә торган ийек, Ларийан дигән кеше шул тишмәнең будкаларын жимерткән ийе. Тәненнән бөтен кешкенни (өзлексез) су агып торды аның. Киредән шул келүчкә барып бетенесен булдырды. Тимер тагараклар куйдырган. Чишмәдән су агып тыра шаулап. Шуннан ул кеше терелгән. Шушы эшен эшли башлагачтын ук сәләмәтләнә башлаган ул. Ычайаклар куйган анда, терлекләр суйалар, учак жагар эчен эчайаклар куйган. Терлек суйгач, тунар эчен тийәкләр жасап куйган. Шунда пешереп ашап, чәйләр эчеп. Мона мин дә дүрт жыл бер уңгайлый бардым, халем жиңелрәккә китте. Шул тишмәнең файдасын күрәм".

* * *

Тормыш-көнкүреш мәшәкатьләре турында сөйләгәндә, әлбәттә, бала үстерү белән бәйле булган һәртөрле ырымнар, ышануларга да игътибар итәргә кирәк. Мәсәлән, М. Я. Васильева безгә түбәндәгеләрне сөйләп күрсәтте.

Бала үстергәндә

"Читкә киттек чикләвек кыймагы ашарга. Без ун симийәйек, умберенчегә Маржа туды. Ул багытта кабык бишек, салам түшәк, кечкенә арбаның кимәсе бар ийе. Авырды. Авырса, бездә им-том итәләр, өшкерәләр. Эч тәрәз күзеннән ала, эч эстәл пычмагын, ишек тыткасын жебетеб аладырийе, пич каршыларын жебетеп, өшкерәләр, шуларны чайкап эчерәләр. Теленә ак төшсә, чыпчык бугын жебетеп эчерәләр, бетәдер ийе. Тел кереше була балаларда, телен алга чыгара алмый. Имәлмәгәч тел керешен кистерәләр, аны кисүчесе бар. Кайсы сакау "р"не әйтә алмый, кайсы дыдык (тотлыга торган) була, минекеләр чатыртап сийләштеләр. Кайсы-берсе айакка йөри алмый, кырсагы күпкән була. Пичтән әпәй чыга. Шул баланы әпәй керәгенә утыртып, бәйләп пичкә тыгыб алалар. Карач баласын тыгыб алдылар шулай, мин әле дә беләм әле, айакланды. Картлар име гел, барыбер килеп барган. Кызамык бар ийе. Кызамыкка бишеккә кызыл жабалар күзе чагылмаска. Мөшкәчле була тагы, аны да карчыклар имләгән. Бүсерле булса, бүсер ташы эчерүче бар ийе, теле булгандыр инде, теле булмаса килешмәс ийе. Әле минем игезәкләрнең сыңары каникулга кайтып кызамык чыгарды. Кызның күзендә кызарып калды. Кызамык анасы шунда булгандыр. Кызыл тавык суйдык, кызамык чыгаргач шулай суйдырталар инде, малай булса кызыл әтәч суйалар, кызга кызыл тавык.

* * *

Авылның тарихы, андагы төрле йолаларның башкарылуы турындагы риваятьләр шушы халыкның тормыш-көнкүрешен, аның үзенчәлекле якларын ачыграк күз алдына китерергә ярдәм итә. Халыкның тормышын, аның күңелен төрле яклап өйрәнгәндә генә без аларның рухын яңартырлык, баетырлык тәкъдимнәр бирә алырбыз.

Әлбәттә, безне аеруча кызыксындырганы Ишәле авылы халкында сакланып килә торган фольклор әсәрләре иде. Жырлар халык күнеленең көзгесе бит алар. Аларда халыкның моңы, сагышы, кайгы-хәсрәте көйгә салына, көчле мәхәббәт хисен кичерә белүләре жырлана, эстетик идеаллары чагылыш таба.

Шунысы характерлы, жыр Ишәле халкының көндәлек юлдашы кебек. Бөтен эшләр, бөтен вакыйгалар жыр белән үрелгән аларда. Көндәлек тормышта башкарыла торган төрле-төрле эшләр барысы да жыр катнашында бара дисәк тә ялгыш булмас.

Безнең тарафтан язып алынган жырларны шартлы рәвештә берничә төркемгә бүләргә мөмкин.

Туй жырлары ин зур төркемне тәшкил итә. Кыз бирү, малай өйләндерү ул кемнең дә булса берәүнең шәхси тормышында ин әһәмиятле, ин жаваплы акт булып тора. Алай гына да түгел, килен төшерү бөтен бер кавем-кабилә өчен зур вакыйга. Үзенең әһәмиятлелеге ягыннан туй ижтимагый акт дәрәҗәсенә күтәрелә. Менә шуна күрә дә туй уздыру гаять мөһим эш. Аның үзенең традицион алымнары формалашкан. Туй белән бәйле гореф-гадәтләргә аеруча зур игътибар бирелә, тормыш агышында аларга бигрәк тә житди карыйлар. Шунлыктан, гореф-гадәтләргә тотрыклылык хас, аларда хәтта безнең бик борынгы бабаларыбызның тормыш итү рәвешенә ишарә ясый торган элементлар да сакланып килергә мөмкин. Кайбер туй ритуалларының жырлы спектакль төсен алуы бәлки шундыйлардан берседер.

Туй жырлары бөтен татар халкына хас. Безгә аларны төрле төбәкләрдән язып алырга туры килде. Әмма Ишәле авылы туе жырлар белән башкарыла торган күренешләр циклын аеруча нык хәтерләтә. Ишәле авылы халкы туй турында менә ничек сөйли.

"Туйлар бит баштан ничек? Кызны пирвый кайсы авылдан алырга диләр. Бәераклар бәеракны эзли. Кызны алырга булсалар, нәселләреңә әйтәләр. Кызны кыяматлыкка апкайталар. Винчайт итәләр. Кыяматлык жортына кыз алырга киләләр. Кызны баш бәйләтә (кызлар баш киемен хатыннар баш киеменә алмаштыру) дә түшәк жәймәсе белән бөркәндерә баш бәйләгәч кыяматлык жортында. Жегет нәселен жыеп, әзерләнеп тора. Жәш киленне төп кодага—жегет жортына апкиләләр. Олы кода жорты санала ул. Кыз жагындагылар жырлап киләләр, түшәк чанасы үзенә, ястыгы-сандыгы үзенә. Кызның энесе була. Утырып килә ул түшәк чанасында. Хәзер киләләр шынгырдап, урам әйләнәләр. Капкасын ачып куйган. Туй кодачалары ат белән ишек алдына керәләр. Йәш киленне, ишек төбенә тун жәйгән, шунда бастыралар, кийаматлык жырлый:

Иртән тордым, кич утырдым,
Фырансус күлмәк бетердем;
Кыдагый, канатым, чык карышы,
Килен канатыңны китердем.

Кыдагый чыкмый. Кийаматлык тагы жырлый:

Кара урманнарны уртасы,
Сары майларның туртасы;
Кыдагый канатым әле дә чыкмый,
Әллә пешмәгәнме буткасы.

Кыдагый ызнай чыкмый:

Сулар-ла ага челтерәп,
Су эсләре жапырак;
Кыдагый канатым әле дә чыкмый,
Туңып та беттег инде калтырап.

Әпәй белә, май белә кыдагый чыга:

Жулның ди буйлары әйлә тал чыбык,
Килгәндер атларыгыз талчыгып;
Без бит сезне генә көтеп тә алдык,
Капка тебенә чыгып, талчыгып.

Яки:

Сызыранның тигермәннәре
Әйләнәдер лә кичке жил белән;
Кыда-кыдагыйлар килергә булгач,
Без кетеб алдык бетен ил белән.

Май бер жомарлык. Чыга да кыйаматлык шул әпәйне башлаб ала да жегеткә дә, киленгә дә каптыра. Кыдагый кереп китә икмәге белә. Кыйаматлык жәш киленне житәкләп алып керә почмакка. Кыз йанына утыручылар бар, икәүме, өчәүме, туганнарының кызлары. Әле кийәү жегете түшәк чанасы сатуларга тотына, бәйә куйа, бу нәстәсе шул бәйә, бу нәстәсе шул бәйә. Бакырны куйа, көмешне куйа. Сыраганын бирә бара. Кажнийыннан акча ала, тунымы, чикмәнеме, батинкасымы, кийез итегесеме, бар да бар. Сандыгын ийгә алып керәләр, малайның үзенә акчасын сатулаша. Берсе сатулады да бер дистә кыз да сорый. Безнең дәдәй кийәү жегете ийе. Дәдәй камчысы белә кызларны куып китерде дебердәттереп, зерә кызыг ул туй. Сандыг эстенә кыз жиңгәсе менеб утыра, тагы акча сорый. Ийнең эчендә кыругум баулар жибәргән әрбирләрне эләргә. Салпитмы, чаршаумы, селгеме. Мендәр тышысы, эскәтерләр, аш йаулыгы диләр аны. Казер кыз жиңгәсе әйбер элә. Ала берсен дә бийи. Чий кирәк, дип. Мона чий, ди, кийәү жегете, камчы белән китереп суга, акча бирә, акча бирмәсә элми тора. Бер әйберсен ала да моңа кемеш чий, кемеш чий, ди, бакыр чий түзми мынарга, ди. Кемеш акча бирә, аннар гына элә. Анарга нәрәтенә үтәдең дип сыра бирәләр ийе, морсала диләр ийе аны. Жырлашалар кыдачалар:

Ай-гай, илдек без, илдек без,
Агиделләр кичеп килдек без.
Иделләрне кичеп, жулда кунып,
Без кыз затыр өчен килдек без.

Капкадан кергәндүк олы кыдага жырлап киләләр:

Биекәй тауның башында
Мыжылдыйдыр байның кортлары;
Алтын гына капка, көмеш кийма,
Шушымыни кыда жыртлары.

Туй кыдачалары чанадан төшәләр дә:

Ач ишекәйеннең келәсен
Без киләселәрне беләсең,
Без киләселәрне беләсең дә,
Күз асыннан карап келәсең.

Бачкычыгыз бийик менәргә,
Ишекләрегез кыйык керергә.
Тырмышыгыз әйләр купис тырмышы,
Эсмит итә алмийм керергә.

Туй кыдачалары, кыз йанына утыручылар түргә кереп утыралар. Аларга жырлыйлар:

Ай-гай атыгыз арыккан,
Кызларыгыз карый жарыктан.
Карамаслар ийе жарыктан,
Кийәү күрер эчен зарыккан.

Кызларга тагын жырлыйлар:

Утыра ди, казлар утыра,
Ойасын мамык белә тутыра.
Озата килгән кызларыгыз,
Сәке башында жырлап утыра.

Ай-гай, ушарбыз, ай, ушарбыз,
Икә жулны бергә кушарбыз.
Кийәүгә китмәгән кызларны
Дунгыз көтүенә кушарбыз.

Болар ыспурлашып жырлый торган жырлар, кайсы жак жинә, тыпырдашып жырлыйлар.

Өстәл артына утыргач, туй мәжлесен мондый жыр белән башлыйлар:

Ишәле сулары, ай, тирәндер,
Тирән жиргенәйләре билдәндер;
Жырны башлаулары, әй, лә бездәндер,
Күтәреб алулары сездәндер.

Эй, ашлыйык, ашлыйык,
Ашламаган жирләрне ашлыйык;
Икә жәш жерәк бергә дә кушылган,
Инде туйларын гына башлыйык.

Аннан соң кода-кодагыйларга багышланган жырлар башкарыла:

Минем алкаларым алты талир,
Аның алтысы да бер манир;
Сезне лә безгә, безне лә сезгә
Сөеп кушкан икән, әй, кадир!

Су ди буйларында жергән нә чакта
Айакайлары таймас булсайы;
Ике балаларны бергә куштык,
Һич айырылмасларга булсайы.

Чаналарны ватып мынча жаксаң,
Йәмне була бит аның кызывы.
Жегетебез алган, кызыбыз барган.
Безгә калган бит аның кызыгы.

Сары майлар куштым мин нә туртага,
Арпа ярмасы куштым бодайга;
Бу кеннәр дей килгәч безләр дә шекер,
Эшләребез дей китте унайга.

Ак ти кайыннарның тузларын салдым
Сизыранский кызыл дегеткәй;
Безди кызыбызны сезгә лә бирдек
Афисәрләр дей кебек жегеткәй.

Сызгыра йылан, әй сызгыра,
Сызламыкта сары бакы чен.
Кыда-кыдагыйлар, сезгә әйтәм
Ташлашмыйык алла хакы чен.

Ишекләрем ачтым көн күрдем,
Тәрәзәләрем ачтым гел күрдем.
Сез кыдаларыма килеп кергәч,
Туй күтәрәлмаслык сый күрдем.

Чалгылардин пычак мин жасаттым
Мәчет башкайларын сырларга,
Сездәй кыдагыйлар килеп кергәч,
Матур жырлар кирәк жырларга.

Туй алып баручы затларның да үз жырлары бар. Аргыш жыры:

Кырларга чыктым, кыргый аттым,
Элгерә микән сабан ашлыгы;
Айагымны тибеп жырлыйым,
Мин бит шушы туйларның башлыгы.

Егет жингәсе:

Ике генә чибәр ураклар ура,
Сул беләкәендә дә жинсәсе.
Айагымны тибеп жырлап та жибәрәм
Мин бит йөгет жингәсе.

Яшь киленнен битен ачу да жырлар белән түбәндәгечә башкарыла.

"Эстәл арасына утыралар бар да. Аш-суларын бирәләр, аннары жәш киленне ачтыралар, шулай бит. Казер жәш килен пычмакта, жәймәсен беркәнгән көйе эстәл каршына чыгарып бастыралар. Жегетнең энесе бар, анарга кулына ике уклау бирәләр, казер шуны ачарга кушалар. Тегендә жәш киленне чыгаргынчы жырлыйлар.

Күк күгәрченнәрнең иләр айагы,
Зәңгәр муллаларның ла тайагы.
Эзләмәдек тә, сырамадык та,
Аксак тегел микән нә айагы.

Менә шулай жырлыйлар. Казер ача ике уклау белә шулайтеп. Күрегез, күрегез, аксак тегелме, сукыр тегелме, ди-ди. Күрсәтми үзе битен. Аннары тагы "аксак тегелме, сукыр тегелме, күрегез, күрегез" дип тагы төшерә, күрсәтми битен. Аннары эченчегә тагы шулай иттереп ача да, башын ук каплап куйа да жәш килен жегереп кереп китә бүлмәгә. Аксак та тегел, сукыр да тегел, күреп калалар. Кызыклар кылындыралар. Ул мына сәхнәгә шул фурмыны куйып күрсәтсән ул бик кызык, бик матур килеп чыга. Безнең керәшен туйлары бик матур булган. Атлар белән кыңгыраулар тагын чыңгыр-чыңгыр ничек кенә килгәннәр әле. Жингине сың безгә шулай алып чыктылар ла. Барук түтийең Санугы ачты, безнең Павал дәдәйнең катыны. Безнең силәшкәннәр дә йазылып барамы сың? Биг әйбәт, йазылсын. Жәш киленне аннары бит әле сийләштерә тагын. Ансы да бар бит әле. Туй узгач"...

"Жәш килен салмасы" дип атала. Кайчан салсаң да жарый инде жәш килен салмасын:

Кызарып та кыйаш чыккан да чакта
Телке кетүләре лә көтәбез;
Безнең әзрәк бүләкләребез бар,
Сездән тәрилкәләр дә көтәбез.

Бадийаннар салдым акмаска,
Каләмперләр дә салдым батмаска;
Бу ди бүләкләрне без салабыз
Жанадан илебезгә кайтмаска.

Хазер тарилка чыгара шуларны салырга жегет анасы. Ит куйалар. Алдан жегет жаклары сала. Аннары сың кыз жаклары, шунда бар да бүләкләрен тәлинкәгә куйалар. Жәш килен салмасы диләр инде аны. Аннан сың кыз анасы жегет жагына бирнә бирә. Бирнәне бит инде алдан кыдаларга бирәләр, ылы кешеләргә. Кийаматлыкка бирәләр. Күлмәк бирәләрме инде, жаулык белән селгеме бирә, кемнең хале ничег инде, парлап бирәләр барына да. Анда жырлап-жырлап алалар бүләк бирүчеләргә.

Аннары кызлар жаклары жырлап жибәрә:

Ачылмаган кибет ачыла,
Башларыгызга бирнә жабыла.
Нишләп жатасың бай улы,
Башларыгызга дәүләт жава ла.

Анда күп салалар, күлмәк, кайсы тавар сала:

Сездән алган бирнәләрне
Машиналарга салып жәйләрбез.
Сездән күргән сый хөрмәтне
Илләребездә кайткач сөйләрбез.

Наратлар да белән чыршыны
Чистай мищщәннәре тарттырсын.
Безне былай зурлавыгыз эчен
Кыдай дәүләтегезне арттырсын.

Аннары жәш килен белән жәш кийәүгә тыттыралар аны.

"Гүчтинәч тураганда жырлый тырган жырлар бар да калды. Айырым гына әйтегез. Кажер чумадан белән гүчтинәчне чыгарасың, кыдалар гүчтинәче. Аргыш турый инде аны гүчтинәчне:

Ике генә кара атыгыз,
Аның берсен безгә сатыгыз,
Бу кадәре күп гүчтинәчне
Ничек тартып килде атыгыз.

Аннары теге жаклар жырлый инде аларга каршы:

Кыр казлары ычкан чакта
Алдан ыча аның аклары.
Ни хәдәре гыруз тейәсән дә,
Шәп тарта бит кыданың атлары.

Аннары тытынасың инде ачарга, сырыйсың ачкыч. Чумадан ачкычы. Ачалмыйбыз дийеп:

Йаңа гына салган гүрничәмнең
Бийек кенә икән баскычы.
Бу чумаданнары без ачалмыйбыз,
Кемдә икән мының ачкычы.

Аннан инде бирә сина, нәрсә дә булса бүләк бирә. Казер үлчәб-үлчәб карыйсын. Мин аргыш булып күп жергән инде:

Аршин гына аршин ука чук
Жиккән аткынайларга житәме дим.

Казер чумаданны ачасың, анда жырлый тырасың. Аннары гүчтинәчне турагачтын инде пычак сабы каты дисең:

Ашагыз, кыдачалар, ашагыз,
Эстәл эсләре тулы кабартма.
Кыдагый канатым, пычак сабы бигрәк каты,
Минем кулларымны кабарта, дисең.

Нәрсә булса да сырыйсың. Кулжаулык гына бирсә, чырмап карыйсың да житми:

Минем пычакларым бер дә кисми,
Кайраклар кирәк пычак кайрарга.
Пычак сабы минем кулымны авырттыра,
Пичәтле кагаз кирәк чырмарга.

Акча сыраб алабыз. Аннары бит инде каз тураргa казыр:

Мин пычак та кайрый алмыйм,
Безнең әти чалгы кайырый.
Шушы каз канатына бер кош кунган,
Бирнә булмас микән дип сайрый.

Анарга бирнә бирәләр. Аннары турыйсың инде:

Ий артындагы алмагачны
Нинди жәннекәйләрдән кимерткән.
Туй буласын алдан белгән,
Казын айрым жавып симерткән.

Кыдагыйларны мактыйсың инде, алар симез каз алып килгән дип жырлыйсын:

Быйыл жыллар бигрәк жавымны,
Сулар жыйылган икән уйларга.
Безнең кыдагый бигрәк унган,
Симез казын суйган туйларга.

Казны урлыйлар да әле аны, аннары түләп аласың, ычып та китә, ул казыңны урлатсаң, үзең акча түләп аласың. Жырлыйлар әле анда:

Тәрәзә төбем табанак,
Узып китте дагал(ы) ат.
Алып килгән казын саклый алмаган,
Сезнең аргышыгыз жабалак.

Кодаларны озатканда "Аргыш катламасы пешерү" йоласы бар. Кодаларны озату да махсус жырлар белән башкарыла.

"Актыктан кыдаларны заткында жырлыйлар. Ашлары уза башлагач, аргышлар зату катламасы диләр, бороп-бороп бармак бийеклеге итеп пешерәләр, туй зата тырган, күчтинәчкә жибәрә тырган. Шул катламаны аргышлар пешерәләр, утын апкергән булалар, керәккә куйып пичкә тыгыб алалар. Аргыш, кыз жаклары-ның, пешмәгән ди. Тагы акча ала пешерүчедән. Өченчегә тагы апкилә. Ашап карый да ала. Туйны зата торган әпәй ул. Кыш-кыш катламасы:

Урманнарда, и, ләр ай таңда
Жир жиләкәйләре лә пешәме.

Мыны бит кыз жаклары жырлый:

Безгә лә китәр багытлар житә,
Аргыш келчәләрегез пешәме?

Керәгенә бәйләп жаулык белән ипи куелган. Шунда куйып эч тапкыр алып чыгып әйләнеп керәләр инде, азактан эченчегә чыкканда кыз жаклары, кыз жагындагы аргыш бу ипине ала, жаулыгы да үзенә була, ипие дә. Әле анда тагын бер кат чыккачтын тотып карый да, пешмәгән, пешмәгән, ди. Пешерүчегә акча салалар бит анарга, аргышка. Жаулыгы да анарга була.

Чынгыр гына чынгыр дугалар.
Китәләр дә бугай кыдалар.
Китмәсләр ийе лә ай кыдалар,
Калдык аракыларын соналар.
Китмәсләр ийе лә ай кыдалар
Кыш-кыш кына диеп кывалар.

Туй башлары—ирле-катынлы аргышлар, зату катламасы пешерүчеләр берсе тыткан ындыр себеркесе, берсе әпәй пешерә тырган калагын, тык-тык бәрәләр, кыша-кыша дип каулыйлар, шайартып жырлыйлар.

Тәрәзәләр ачып бер сызгырдым
Былын печәннәре кипсен дип.
Былын печәннәре кипкәндер,
Сезгә кайтыр вакыт житкәндер.

Кыз жаклары жырлый.

Кызарып та кыйаш чыккан чакта
Жир жиләкләре дә пешмәгән;
Аргышыгыз жатып жыклаган да
Аргыш келчәләре дә пешмәгән.

Аннан сың пешмәгән дип кереп китә, эченчегә чыккач инде аннары ала. Пешкән, пешкән ди дә ала. Аннары аларны куалар шушы керәк белән. Көш-көш, сезгә китәр багыт житте, диләр, себеркеләр белән ындыр себеркесе тытып, сабы белән тыкы-тыкы итеп, жиргә дөбердәтеп куалар шак-шак итеп. Тегеләр жырлыйлар жаваб итеп:

Бийек тауның эй башында
Мәчет манарасында кач тегел;
Кыш-кыш кына дейеп безне кумагыз,
Без бит ийебездә дә ач тегел.

Бийекәй ди тауның иләр башында
Кыршау салалар диләр бер мичкә.
Безнең китәсебез бер дә-дә килми,
Фатир жибәрерсезме бер кичкә.

Тегеләр жырлый инде киткәндә:

Бийекәй ди тауның и ләр башында
Бегәрләнеб үк жата бер тәкә.
Исәннәр дә килдек, саулар да кайтсак,
Кайткач кайыр бирербез бер тәңкә.

Ай-гай да-да салкын, ай-гай буран,
Исәннәр дә микән безнең ил?
Исәннәр дә булса ай безнең ил,
Әлхәмдиллаһи шөкер килгән жир.

Казыр эстәл эсендәге ашка тау итеп (рәхмәт әйтеп) жырлыйлар:

Шыбыр гына шыбыр жаңгыр жава,
Кырылса тепләрендәге ташларга.
Тау итийек тә катып китийек,
Эстәл эсләрендәге ашларга.

Аннары тыралар да, чыгалар да заталар кыдаларны. Жәш килен эшлә, кайнанага булыш. Кайната белән сүләшми. Кайната сынап тыра, тел ачмича сүләшсә саннамау була. Бер көнне "килен, теленне ач инде, сина бер бөтен акча" дип әйтә. Безнең тутабызны, аны шулай бик зурлап туйлар йасап бирделәр, кыда сийләштергән дә тутабыз ыйалган, телен ачмаган. Кыдабыз икенчегә талир тәнкә биргән бер йарым. Безнең тутабыз ике тапкыр сийләштереп кенә сийләшкән".

* * *

Икенче төркем жырлар—календарь йолалар белән бәйле.

Татар халкында яфрак бәйрәме дип йөртелә торган жәйге күңел ачуларның берсе булган "Тыруйчын көне" (Троица) жырларын китерәбез. Ишәледә аны "Кайын башы", "Кайын башы тишә тырган жыр" дип тә атыйлар (тишү—әдәби телдә чишү дигән сүз). Бу жырның көе жырлы-биюле әйлән-бәйлән уены көйләрен хәтерләтә, жинел рухта башкарыла. Сөйләүләренә караганда, "Кайын башы" жырлары махсус шушы бәйрәмдә генә жырлана. Беренче куплет исә төрле башка очракларда да янгыравын күзәттек.

"Тыруйчин кенне кайын апкайтадырыйк чуклап, жегетләр күтәреп кайта. Чуклыйбыз. Әйләнеп биибез, жырлыйбыз. Кайынга бәйләгән чугынны бийегәч кенә бирәләр. Ул кайын чыбыкларыбызны күпердән суга ташлыйдырыйк. Үләсе кешенең агачы суга батып китә. Гумере бар кешенең суга жәйелеп жата.

Жырлагыз, кызлар, сез жырлагыз,
Кылагыгызда алтын най сыргагыз.
Жырлаганда була ай төрлесе,
Кылагыгызны салып тынлагыз.

Тыручин жыры булды инде бу.

Безләр дә барыйк, әй барыйк,
Ак кайыннарга ла житейек.
Ак кайыннарга барып житеп лә,
Кайын башларын ай тишейек.

Ишәле сулары, әй, агым сыу ла,
Акмый микән аның, на, эй, басмасы.
Ишәле кызларын сырасагыз ла,
Чәч ычында зәңгәр лә, ай, тасмасы.

Ай-уйынчыла, ай, уйынчы ла
Утырсана бүлмәләр, ай, буйынчы.
Син уйынчы булсаң, без жырлаучы,
Ташламайык гүмерләр, ай, буйынчы.

Кайын башы тишә тырган жыр бу, тыройцы жыры бу.

* * *

"Урак өмәсе" жыры яңгыраганда кичке энгер-меңгердә басу юлыннан, деңгер-деңгер итеп, жигүле арбаларга төялеп, уракчылар кайтуы күз алдына килә. Степанова Софья Емельяновна бу жырны уректан арып кайтучыларны хәтерләтеп салмак та, арбаларның шыңгыр-шыңгыр баруына ошатып та, кыска тынышлар белән башкара, урак өмәсе турында сөйләп тә бирә. Бу жырның да махсус сүзләре бар. Жырның беренче куплеты башка өмәләрдә дә (мәсәлән, тула басу, киндер тукмаклау һ. б.) жырлана.

"Жәй көне ураг эстендә ишле кешенең урагы сынарак кала. Туганнарын чакыра, барысы да тырышып уралар. Аларга аппарыб ашаталар-эчертәләр. Бетергәчтен атларга утыртып алып кайталар. Урам әйләнәбез ураг эмәсендә булган кешеләр. Атка тейәләбез, кайтабыз жырлашып.

Ай-гай да ла өмәләр, ай өмәләр,
Өмә көйсн кемнәр дә белаләр.
Үзләре дә өмәне итәлмәгәч,
Өмә итүчеләрдән көләләр.

Машиналар дигән нә ай зур нәстә
Кисәк-кисәк мамыкны эрләтә
Безнең хужәйеннәрнең ай бәйрәме,
Монатырак ничек гөрләтә.

Пирвый мыни жырлыйдырыйык:

Сикереп тә менеп утырырга
Безнең арбаларыбыз табанак,
Безнең дий атларыбыз ди ай аргамак,
Замат кайтып житәрбез жургалап.

Жәйге-көзге эшләр тәмамлангач, кыш айларында йон эрләү өмәләре уздыра торган булганнар. Мондый өмәләр халкыбыз яши торган бөтен төбәкләрдә дә билгеле. Кичләрен жеп эрләгәндә, Ишәледә шул жепнең үзе кебек озын һәм моңлы махсус көй белән төрле жырлар жырлана торган булган:

Ай-гай эмәләр ди лә, ай, эмәләр,
Эмә кейен кемнәр дә белаләр.
Эий, эий, эий,
Эмә кейен кемнәр дә белаләр.

Жырлагыз да, кызлар ла, сез жырлагыз,
Кылагыгыздай алтын сыргагыз,
Эий, эий, эий,
Кылагыгыздай алтын сыргагыз.

Үзләре лә эмә лә итәлмәгәч,
Эмә итүчеләрдән келәләр.
Эий, эий, эий,
Эмә итүчеләрдән келәләр.

Жырларның да була ай төрлесе,
Кылагыгызны салып тыңлагыз.
Эий, эий, эий,
Кылагыгызны салып тыңлагыз.

Билгеле булганча, татар халкының игътибарга лаеклы тагын бер гадәте яшәп килгән. Житкән кыз үзенең кул эшләрен алып башка авыллардагы туганына икеөч атнага кунакка бара торган булган. Мондый очракларда, гадәттә, кыз киндер жебе эрли торган булган. Утырмага кунак кыз килү унае белән кызларны ашка алу, жеп эрләү һәм башка шундый өмәләр уздырыла торган булган. Яшьләр исә бу вакытта танышып та киткәннәр, утырма кызны егетләр дә күзли торган булган.

Софья Емельяновна бу турыда болай дип сөйләп күрсәтте.

"Кунак кызы озата торган көй бар. Бара да туганына кыз эшен алып утырмага, ике атна сүс эрләб утыра. Киләп тутырырга тырыша, кабасын-сүсен алып килә. Эй, кунак кызы, сүзеңне бетермәсән сүсенне дугага тагып жибәрербез диләр ийе. Ата-аналары бер киләплек сүс үлчәп жибәрәләр ийе дә. Тутабыз безгә кигән ийе инде, казер мине алып китәләр утырмага. Кунак кызын апкиткәндә кыр капкасынан тәке жырлап аны заталар кызлар.

Кунак кызын озату жыры

Озатырга кушсагыз, озатыйык,
Кыр ди капкаларыннан чыкканчы.
Койяшлар да байыр ла, айлар калкыр.
Без айырылышыб ук киткәнче.
Аклы жаулыкайларның эч парчасы,
Әрбер жаулыкайларда булсачы.
Китәсе кеннәрегез эй булганчы,
Киләсе кеннәрегез булсачы.

Анда жегетләр бармый. Көйе бик салынкы мының, жамансы. Кунак кызы жылый:

Ишәлеләрнең лә и киртәсен
Думбыралар да жасап ла чиртәсе.
Ишәле дә дигән нә асыл илне
Ничег итеп ташлап китәсен.

Шушында ук тагын бер моңлы озын итеп жырлана торган "Солдат озату" жырларын күрсәтеп үтик. Аның да махсус жырлары бар. Шулай ук башка жырлар да жырланырга мөмкин. Мәсәлән, безгә мондый жырларны жырлап күрсәттеләр:

"Салдат ызата тырган кей дә айырым. Китүчегә селгеләр, кулжаулыклар бирәләр, ычтан ычка төйнәп тагып мунена, салдатка заталар:

Без китәбез иләр сез калырсыз,
Камышлардан күпер салырсыз.
Камышлардан күперләр сез салырсыз,
Без киткәнен күрми калырсыз.
Жаңа эйләремне мыржасыннан
Тетеннәре чыгар кыл кебек.
Сез ди туганнарымнан айырылган,
Бер кеннәрем булыр жыл кебек.

Солдат озата торган жыр

Китәсең лә, туганай, син китәсен,
Аткынайга авырлар итәсен.
Аткынайга авыр ла син итмейсең,
Жан гынайга жамансыу эйтәсен.
Кыр ди капкаларыннан чыкканчы,
Эзеп кенә каптым на бер миләш.
Без туганайларыннан айырылгач,
Кемнәр белән итәрсең син кинәш.

Ишәле авылында "Кызлар бәйрәме" уздыру гадәте бар. Аның да махсус жырлары һәм көе бар. Ул турыда болай сөйләп күрсәттеләр.

"Кызлар бәйрәме була. Авылда ничә кыз, кажныйысы чакырып үзене курмәтен бирә. Йегерме йырт бармы, кажныйысында шушы жырны жырлап чыгалар. Жегетләр жан сәкегә тезелешеп утырганнар. Жегетләргә сыра эчерәләр.

Жегетләр дә булсан син жегет бул,
Кемеш кидер кайыш жигәнгә.
Жегетлек гүмерең нә ике килмәс,
Жаучы жибәр жаның сийгәнгә.
Айагына кигән итегеннең
Паттиш икән нә ылтаны.
Ишәле лә дигән асыл илдә
Син икәнсең жегетнең сылтаны

дип чыгалар. Кызлар мына шушы жырны жырлыйлар.

Май (русча масленница) чабу кышның аеруча күңелле һәм күп кеше катнаша торган бәйрәмнәреннән саналган:

"Элгәре бит майда май чабалар ийе. Кызлар, жәш киленнәр чабалар. Атларның жалларына линтылар үреп. Кынгыраулар дугада. Чәч үргән кебек пар кынгыраулар, кемеш кынгыраулар. Кызларны утырталар парлап. Жегетләр үзләренең атларын чаптыралар. Кызлар жырлый. Урам әйләндерә ничә тапкыр Майның кейе үзенә.

Майларны ди сапсаң, син каты чап,
Чана үрәчәләрен жынгыртып,
Жырларны жырласаң каты жырла,
Ишәле урамнарын йангыртып.
Кычкырыб ук жырлап без йебәрик,
Китсен тавышларыбыз тауларга.
Китсә дә лә китсен әй тауларга,
Без сандугач түгел әй сайрарга.

Ишәле урамы киртләч, киртләч,
Киртләчләре бетәр ай кар киткәч.
Ишәле урамнары йәмне йе,
Эйәмнәре бетәр ай май үткәч.
Жырларга диб әйтсән без жырларбыз,
Берне генә тегел, ай икене;
Жырламас та идем ай икене,
Жырла диб әйтүегез сийкемне.

Май атнасы була безнең. Шунда кызлар тау астына төшәләр. Быздан тау йасыйлар ыйы. Жегетләр, кызлар шуалар ый. Бер атна. Татар атнасы[1] кенне май чабу. Урыс атнасына[2] тәкле чабалар".

* * *

Ишәле авылында безнең тарафтан берничә лирик жыр да язып алынды. "Ай, биби" жыры моңлы, сагышлы озын көе белән дә, төзелеше белән дә игътибарны жәлеп итә.

Ай, биби

Жырлап та лай без карыйык, гелкәем,
Ай биби, мыңайма,
Килешерләр микән нә көйебез. (2 кат)
Килешерләр булса ла, ай бу кейебез, гелкәем,
Ай Биби, мыңайма,
Жалан шулай жырлашып жерербез. (2 кат)

Казаннардан Мәскәүләр күренә микән, гелкәйем,
Ай биби, мыңайма,
Баскычларга менеб ий карасак. (2 кат)
Узган гумер кире лә кайтыр микән, гелкәем
Ай Биби, мыңайма,
Сандугачлар булыб ук сайрасак. (2 кат)

Аклы гына ситсыдан күлмәгемә, гелкәйем,
Ай Биби, мыңайма,
Инечләрен салдым на куйныннан. (2 кат)
Унжиде жәшлектә гумерем кайтса, гелкәем,
Ай биби, мыңайма,
Ычкындырмас ыйым ла кулымнан. (2 кат)

Таң алдыннан чыкканна ыспутникның, гелкәйем,
Ай Биби, мыңайма,
Әйләнәсе аның дай түгәрәк. (2 кат)
Шул түгәрәккәйләрнең эчләрендә, гелкәйем,
Ай Биби, мыңайма,
Йәшиг әле, туганнар, бергәләп. (2 кат)

Сандугачлар микәннәй, соклар микән, гелкәйем,
Ай Биби, мыңайма,
Сайырый да микәнней, жук микән? (2 кат)
Жыракай ди жирләрдә туганнарым, гелкәйем.
Ай Биби, мынайма,
Сагына да микәннәй, жук микән? (2 кат).

* * *

Безнең фикеребезчә, югарыда китергән материаллар әйтешләрне жырлардагы кушымталар белән тиңләштереп бетереп булмавын күрсәтә. Әйтешләр күләм ягыннан жыйнаграк була, ә үзенә тирән эчтәлек, фәлсәфи мәгънә салынган.

Ишәле авылында тагын ярым бәйет характерында булган, төрле төбәкләрдәге татарларда да еш ишетелә торган "Булат белән Мәрьямкәй", "Аклар белән кызыллар сугыша" кебек жырлар да шактый еш жырлана.

Гомумән, Ишәле авылында безнең тарафтан язып алынган жырлар жанр ягыннан күп төрле. Аларда да керәшен жырларына хас тирән мәгънәлелек, ритмик көйлелек көчле чагыла.

Дөррия РАМАЗАНОВА,
филология фәннәре докторы.

---

[1]Татар атнасы—жомга.
[2]Якшәмбе.

ӘГЕРҖЕ ТӨБӘГЕ ТАРИХЫ

Әгерже районының географик урнашу урынын карта буенча күзаллап, ана карата еш кына «Удмуртиягә уелып кергән» дигән сүзләрне укырга һәм ишетергә туры килә. Мәсьәләгә тарихи җәһәттән караганда, бу төбәк беркая дә «уелмаган» да, «кермәгән» дә. Ә бәлки элек ничек булган, шул хәлендә сакланган. Ягъни, XVI йөз ахырыннан башлап, XVIII йөз урталарына хәтле рус колонизациясеннән качып, төньяк һәм көнбатыштан бу тарафларга удмуртлар килеп урнашканда, хәзерге чикләрендәге Әгерже төбәге җирләрендә инде татарлар күптәннән яши торган булган. Яңа килгән удмуртлар, әлбәттә, кемнеңдер биләмәсенә урнашмыйча, күрше-тирәдәге буш җирләргә төпләнгәннәр. Нәтиҗәдә, Әгерже төбәге җирләренең географик урнашу урыны удмурт авыллары белән урап алынган һәм берникадәр ярымутрау кыяфәтен алган.

Татарстан картасы. 1933 ел.

Архив документлары, фәнни әдәбият, халык риваятьләре һ.б. төр чыганаклар бу хакта ниләр сөйли? Әйдәгез, тупланган мәгълүматлар белән киңрәк танышыйк.

Әгерже төбәге—Татарстан Республикасының төньяк-көнчыгышында, урманнарга һәм сулыкларга бай үзенчәлекле географик мәйданда урнашкан. Көньяк өлеше Кама елгасы аша Минзәлә районы белән, калган тарафлары Удмуртия Республикасы белән чиктәш.

Район үзәге—Әгерже каласы—төбәкнең иң төньягында, Казан шәһәреннән 304 чакрымда. Төбәкнең көньягында Кама елгасы, төньягыннан көньягына таба Иж елгасы ага. Шулай ук Әгерже, Чәже, Биме, Бәрклят, Кетмәс, Олы Баржы, Кече Баржы, Күмерсу, Җәри, Әҗәү, Бубый кебек елгалар һәм бик күп вак инешләр бар.

Фәнни максатлар белән Россияне гизгән мәшһүр сәяхәтче, географ, Петербург Фәннәр Академиясе әгъзасы П. С. Паллас (1741–1811) 1773 елның җәендәге бер сәяхәте вакытында Әгерже яклары аша узган. Сарапулдан Алабугага сәфәрен тасвирлаган сәяхәтнамәсендә ул Иж һәм Чаж елгаларын, Биектау, Мордывый, Тирсә, Сарсак-Омга, Тәбәрле һәм Сокман авылларын теркәп калдырган. Ул чорда Тирсәдәге Тәфкилевләр утарының мәһабәт вә төзек һәм, гомумән, алпавыт карамагындагы авылларның да чагыштырмача таза тормышлы һәм тәртипле булуына игътибар иткән. Табигатьне өйрәнүче галим буларак, бу якларның табигатенә сокланган. Бигрәк тә, монда яшь наратлыкларның күплеге һәм хисапсыз сандугачлар, куе урманнарда гажәеп күп төрле гөмбәләр үсүе Паллас күңеленә хуш килгән.

Бу якның үзенә генә хас искиткеч бай табигате, калын урманнары, мул сулы һәм балыклы елга-инешләре, көмеш сулы чишмәләре, иркен чәчүлек җирләре, киң болыннары булган кебек үк бай тарихы да бар. Дөрес, ул тарих кырыс та, рәхимсез дә,

кискен борылышлы, гаугалы-давыллы да, шанлы да, сагышлы да... Шул ук вакытта гажәеп кызыклы һәм серле дә. Ә иң мөһиме—ул үз тарихыбыз һәм безгә бик тә газиз, ул кадерле ватаныбыз Татарстан тарихының да бер өлеше. Чөнки Әгерҗе төбәгендә туып-үскән һәркемнең борынгы бабалары тарихи ватаныбыздагы вакыйгаларда катнашканнар, яисә аларның шаһитлары булганнар.

Кызганыч ки, борынгы Мисыр фиргавеннәрен һәм дәһшәтле Рим империясе хөкемдарларын исемләп белсәк тә, чит илләрнең алмисактагы тарихларыннан тирән мәгълүматка ия булсак та, туган төбәгебезнең тарихи вакыйгаларыннан күпләр хәбәрсез. Әлбәттә, моңдый хәбәрсезлек Әгерҗе төбәге өчен генә хас күренеш түгел, бу бөтен ил фажигасе, дисәк тә, ялгыш булмас. Әгерҗе төбәге тарихын фәнни җәһәттән өйрәнү һәм танытуга килгәндә, бу як тарихыннан аерым вакыйгалар галимнәр тарафыннан өйрәнелгән һәм тикшерелгән. Әмма башка күп җәһәтләре алар игътибарыннан читтә кала килде. Кыскасы, Әгерҗе төбәгенең тарихы әлегәчә тулаем, бербөтен буларак тикшерелмәгән хәлдә иде. Моның төп сәбәпләреннән берсе—XVIII йөз ахырыннан 1920 елларга хәтле Әгерҗе ягының Алабуга һәм Сарапул өязләре составында Вятка губернасына кергәнлеге. Чөнки ул дәвергә караган бай архив материаллары, тулысы белән диярлек, Киров (элекке Вятка) шәһәрендә, ягъни Татарстаннан читтә саклана. Ә Казан һәм Татарстан галимнәренең хезмәтләре еш кына Казан губернасы белән чикләнә һәм Әгерҗе төбәге, шул рәвешчә, игътибардан читтә кала.

Фәнни хезмәтләрдә бу төбәккә турыдан-туры бәйле Пьянобор культурасы дәвере турында мәгълүматлар бар. Шулай ук Тирсә волостенә кергән берничә авылның Казан ханлыгы дәверендә булганлыгы тарихи китапларда языла иде. Ә Әгерҗе төбәген тәшкил иткән башка авыллар Казан ханлыгы яулап алынгач, XVI йөздә нигезләнгәннәр һәм бу якларда элек, имеш, удмуртлар яшәгән, дигән караш хөкем сөрде.

Соңгы тикшеренүләр—Казан, Киров, Уфа, Мәскәү, Петербург һәм Ижевск шәһәрләрендәге архивларда һәм китапханәләрдә эзләнүләр, авылларда сакланган риваять һәм истәлекләрне туплап өйрәнү нәтиҗәсендә Әгерҗе төбәгенең тарихын берникадәр тулырак күзаллауга ирештек.

Тарихчы археологларның тикшеренүләре күрсәтүенчә, хәзерге Әгерҗе төбәгенең көньяк һәм көньяк-көнчыгыш өлешендә (Кама, Иж, Биме, Баржы елгалары буйларында) безнең эрага кадәр II гасырларда ук борынгы кешеләр яшәгән. Тарих фәнендә мәгълүм борынгы культура—Пьянобор культурасының атамасы элекке Пьяный Бор (хәзер Красный Бор) авылына нисбәтле. Әгерҗе ягында безнең эрага кадәр II гасырдан безнең эраның III гасырына кадәр яшәгән Пьянобор культурасына нисбәтле борынгы кабиләләрнең торак калдыклары һәм каберлекләре Красный Бор, Олы Баржы, Баржы-Омга, Баржы-Пельга, Иске Балтач, Малиновка, Муново, Зуево, Исәнбай, Бима, Мадык, Ожбуй, Ташлы, Коновалово авылларында һәм бу авылларга якын урыннарда табылганнар. Төгәлрәк әйткәндә, археологлар тарафыннан борынгы кабиләләрнең көнкүреш һәм бизәнү әйберләре табылган. Фәндә борынгы Пьянобор кабиләләре—фин-угор һәм коми-пермяк халыкларының борынгы бабалары дигән караш хөкем сөрә.

Көнбатыш Себернең угор һәм төрки кабиләләре Урал таулары аша үтеп, Кама елгасы ярларына килеп җиткәч, III гасыр башларында борынгы Пьянобор кабиләләре көнбатыш һәм көньяк-көнбатыш тарафларга күчеп киткәннәр. Шул вакытлардан Идел-Кама буйларында борынгы төрки кабиләләр яшәп калган. Тарихи хезмәтләрдә бу төбәктәге халыклар күчеше шул рәвешчә бәян ителгән. Аерым алганда, археологик табышлар Әгерҗе төбәгенә күрше Менделеев районындагы Турай авылы янында III—IV гасырларда төрки кабиләләр яшәгәнлеген раслады. Димәк, шул чордан алып Әгерҗе ягы да төрки кабиләләр карамагында булган дип карарга кирәктер.

Аннан соңгы чорда Әгерҗе төбәге җирләре Идел буе Болгарстаны, Алтын Урда һәм Казан ханлыгы дәүләтләренең биләмәсе булган. Кайбер авылларның риваятьләрендә борынгы Болгар дәүләтенә үк бәйләнеш турында сөйләнә. Мәсәлән, Тирсә, Мордывый, Тоба, Нажар, Чишмә һәм Иж-Бәйки авылларына нигез салынуга 750 еллар бар дигән риваятьләр сакланган. Бу дата болгарларның Чынгыз хан гаскәрләре белән бәрелешенә бәйләп телгә алына.

Баржы-Омга авылы Баржы елгасы буендагы иң борынгы авылларның берсе булуы турында хәбәрләр бар. XIX гасыр галиме А. Спицын Баржы елгасы буендагы удмуртларда бу елга буенда әүвәл заманда нугайлар, ягъни татарлар яшәгәнлеген сөйләүче риваятьләр булуына игътибар иткән. Баржы елгасына коючы бер инеш электән Нугай исемен йөрткәнлеге дә билгеле. Риваятьләрнең никадәр дөреслеккә туры

килүләре мәгълүм түгел. Бу риваятьләрне археологик тикшеренүләр генә раслый яисә кире кага ала. Һәрхәлдә, әлегә бу риваятьләрне кире кагарлык фәнни дәлилләр юклыгын да искәртергә кирәк.

Тарихчы Михаил Худяков Сарапул һәм Алабуга төбәкләре Казан ханлыгының көнчыгыш чикләрен тәшкил иткән дип яза. Ә Альфред Халиков Казан ханлыгының көнчыгыштагы төп чиге—Нократ елгасы дип тәгаенли, шул ук вакытта Иж елгасы буенда да ханлыкка нисбәтле Тирсә, Әгерҗе, Аккужа һ. б. татар авыллары булган дип белдерә. Казан ханлыгы чикләрен күрсәткән карталарда бу җирләр Казан ханлыгы биләмәсендә күрсәтелә.

Алабуга, Сарапул якларында электән үк болгар-татарлар яшәве ныклы дәлилләр белән раслана. Алабуганың болгар шәһәре икәнлеге галимнәр тарафыннан күптән исбатланган, анда байтак архитектура истәлекләре дә исән әле. Сарапул шәһәре хакында исә сирәгрәк языла. 1909 елдагы төзелеш эшләре вакытында анда борынгы зур төрки каберлеге табылган. Галимнәр каберлектә 1351 елгы ваба үләтеннән вафат булган болгар-татарлар жирләнгәнлеген ачыкладылар. Бу—ул заманда үк Сарапул шәһәре урынында болгар-татарлар яшәгәнлеген дәлилләүче кире каккысыз дәлил. Сарапул атамасын галимнәр «сары пул»—сары (ягъни, алтын) акча һәм сары балык (чөгә балыгы) мәгънәләре белән дә аңлаталар.

Бу якларга руслар, удмуртлар һәм чирмешләр (марилар) күчеп килгәнче үк элекке Алабуга һәм Сарапул өязләре жирләрендә татарлар яшәгәнлеген раслый торган башка дәлилләр дә җитәрлек. XIX йөз ахырында Вятка губернасының статистика идарәсе Алабуга һәм Сарапул өязләренә кергән һәр авыл турында мәгълүмат әзерли. Аннан күренгәнчә, руслар, удмуртлар һәм чирмешләр бу якларга, нигездә, XVII—XVIII йөзләрдә генә килеп төпләнгән, авыллар корган. Рус һәм удмурт авылларының аерым бер өлеше элек татарлар яшәгән, татар авыллары булган урыннарга корылган. Бу хакта риваятьләр язып алынган. Ул авылларда борынгы татар зиратлары булуы да күрсәтелгән.

XIX гасыр ахыры статистлары туплаган мәгълүматларда ул чорда Алабуга өязендә—22, Сарапул өязендә 38 рус һәм удмурт авылы булуы, Сарапул шәһәре урынында элек татарлар яшәгәнлеге күрсәтелгән. Хәзерге калалардан Менделеевск, Можга урыннарында элек татарлар көн күргән. Ижевск шәһәре читендәге Пирогово авылы урынында да элек татарлар яшәгән. Бу саннарга бик борынгы, гасырлар дәвамында таркалмыйча, хәзергәчә яшәп килгән татар авылларын да кушып караганда, Алабуга, Сарапул якларында татарларның төп халыкны тәшкил иткәнлеге ачык күренә.

Казан ханлыгы жимерелгәннән соңгы рәхимсез колонизация, көчләп чукындыру сәясәте жирле татарларны читкә, көнчыгышка китәргә мәҗбүр иткән. Ә алардан бушап калган урыннарга акрынлап руслар һәм башка халыклар күчеп килеп, үз авылларын нигезләгәннәр.

Әгерҗе төбәге татарларын тарихчы галимнәр Казан татарларының Алабуга төркеменә кертәләр. 1552 елдан соң күчеп килгән Казан ягы татарлары һәм электән шушы жирлектә яшәгән төрки-татарлар бергә кушылып бу төркемнең нигезен тәшкил иткәннәр. Тарихчы Барис Ижболдин язуынча, нугай морзасы Ишбулды үз гаскәре белән Казан ханлыгын яклап сугышканнан соң, башка аксөяк нәселләр белән берлектә, Кама елгасы буена, Ык тамагының каршы тарафына килеп урнашкан. Рус чыганакларыннан да 1553 елда татар аксөякләреннән дәрәҗәле морзаларның Кама елгасы буенда урнашып, феодаль жирбиләүчеләр булып китүе билгеле. Алар «Арча кенәзләре» исеме белән, формаль рәвештә булса да, 1588 елга хәтле бу төбәктәге халык белән идарә иткәннәр. Ижболдин мәгълүматлары буенча, Ишбулды морза токымнары Иж елгасы тамагы һәм Сарапул елгасы арасындагы жирләрне биләгән. Галимә Зәйнәп Максудованың Ижболдин фикерләрен куәтли торган кызыклы истәлекләре бар. Максудовларның Уразай авылындагы нәселе 1552 елга хәтле Казанда яшәгән затлы нәселдән булган. Галим Дамир Исхаков та XVI гасыр урталарында Иж елгасының түбән агымында төрки-татар авыллары булган һәм алар Казан ханлыгы белән тыгыз бәйле Нугай бәкләренә буйсынганнар дип яза.

Тирсә волосте һәм авылының Казан ханлыгы чорында үк булганлыгы хакында тарихи хезмәтләрдә языла иде. Аерым алганда, Казан өязенең 1603 елгы писцовый кенәгәсендә Тирсә волостенең кенәз Багыш Яуш улы биләмәсенә кергәнлеге мәгълүм һәм анда Тирсәдән башка авыл исеме телгә алынмаган иде. Тарихчы Д. Исхаков Тирсә волостендәге Яушевлар жирләренә нисбәтле 1582 елгы мәгълүматларны язып чыкты, ә безнең соңгы эзләнүләр нәтиҗәсендә аннан да әүвәлгерәк—1562 елгы архив

документлары булганлыгы ачыкланды. Ул документта Яушевлар биләмәсендә Көчек һәм Аккужа авыллары да телгә алынган. Димәк, бу ике авылны Казан ханлыгы дәверендә үк булган диярга нигез бар.

Әгерже төбәгендә, Иж елгасының сул ягында, Биме һәм Кетмәс елгалары буенда урнашкан бер төркем татар авыллары электән үк җыелма бер атама белән Тугызбуй ягы дип йөртелә. Тугызбуй атамасын галим Г. Саттаров башкортларның «тугыз» ыругына бәйләп аңлата. Ләкин бу фикер дөреслеккә туры килми. Архив материалларыннан күренгәнчә, мондагы авылларның иң борынгыларыннан берсе Наратның элекке исеме Тугыз (Тугыз Карагай) булган. Тугызбуй атамасын мондагы татар авылларының исәбе тугыз булуга нисбәт итү, Нарат күршесендәге Девятерня авылының исемен дә рус телендәге «девять» сүзенә бәйләргә тырышу—мәсьәләне, эзләнеп тормыйча, артык жиңел хәл итү очрагы. Русларга хәтле үк нигезләнгән татар авылының исеме һич тә рус теленә бәйле була алмый. Чөнки Девятерня авылы элекке архив документларында Олы Дәфтәр (русча «Улу Дявтирь») дип теркәлгән. Тугызбуй атамасы да шушы Нарат авылына бәйле. Архивларда Тугызбуй авылы искә алынган 1518, 1545 елларга нисбәтле ярлык-грамоталар шул турыда сөйли.

Башка авыллар буенча да кызыклы мәгълүматлар табылды. Архив материаллары арасында Олы Баржы авылы 1598 елда, Салагыш 1600 елда, Нарат һәм Девятерня 1622 елда, Кичкетән 1629 елда, Балтач 1637 елда, Иж-Бәйки, Төрдәле, Сокман, Чишмә (Хороший Ключ), Иж-Бубый (чирмеш авылы буларак) 1640 елда, Рыс 1650 елда беренче мәртәбә телгә алынган документлар табылды. Әгерже төбәгендәге авылларның күпчелеге 1678 елгы халык исәбен алу документларына теркәлгәннәр.

Архив чыганакларыннан күренгәнчә, 1593 елгы бер документта Көчек авылы халкының бер өлешенә Кетмәс елгасы буендагы җирләргә ия булу хокукы бирелгән. Шулай ук Көчек, Иске Аккужа, Девятерня һәм Тугыз авылларының бер өлеш халкы 1622 елның 23 июлендә Шихсуб Шыгасанов исеменә язылган, нигездә, Кетмәс елгасы тирәсендәге җирләргә хокук биргән уртак бер грамотага ишарә иткәннәр. (Бу дата авылларның нигезләнү вакытын белдерми.) Әлеге грамотада аталган исемнәр риваятьләрдә дә чагылыш тапкан. Мәсәлән, Балтач, Тоба, Иске Аккужа, Көчек, Иске Сләк, Девятерня, Үтәгән һәм Баржы авылларының нигезләнү тарихында уртаклык булуга ишарә итүче риваятьләрдә Шихсуб һәм Шыгасанга аваздаш Шыкшыбы һәм Сыгашан исемнәре әйтелә. Девятерня һәм Нарат авыллары телгә алынган 1701 һәм 1702 еллардагы грамоталар Шиһастан Жәббар улы исеменә бирелгәннәр. Бу авыллардан ерак түгел, Кетмәс елгасына коя торган икенче бер елга хәзер дә Шехостан атамасы белән йөртелә. Әлеге атама да шул тарихи шәхескә нисбәтле булса кирәк.

Архив документларыннан күренгәнчә һәм төбәгебез авылларында сакланган риваятьләргә, шәҗәрәләргә караганда, Әгерже яклары электән үк Нократ татарлары белән турыдан-туры бәйле булган. Нократ татарлары дип, нигездә, Нократ елгасына коючы Чүпче (Чепца) елгасы буенда Алтын Урда дәвереннән үк яшәп килгән болгар-татарлар аталган. Нократ татарларының төп нәсел шәҗәрәләре Болгар һәм Алтын Урда дәүләтләре чорына, Кара бик исемле тарихи шәхескә тоташа. Галимнәр Миркасыйм Госманов, Марсель Әхмәтжанов, Дамир Исхаков һ. б. хезмәтләрендә Нократ татарларының хөкемдарлары—биләре һәм морзалары Кара бик нәселеннән булганлыгы язылган. Тарихчылар Кара бик нәселенең Сакмар елгасыннан Нократкача һәм Идел буйларыннан Агыйдел елгасына кадәр арадагы киң мәйданны биләп торганлыкларын язалар. Димәк, безнең Әгерже төбәге җирләре дә (һәрхәлдә, Иж һәм Кама елгалары буйларындагы җирләр) Болгар һәм Алтын Урда дәүләтләре чорында Кара бик нәселе биләмәләрендә булган диярга тулы нигез бар. XIX йөз башы тарихчысы А.Вештомов язганнарга караганда, Вятка губернасында яшәгән татарларның төп өлеше Алтын Урда чорында үк шушы җирләрдә гомер сөргән.

Кара бик нәселенә нисбәтле, Казан ханнарына буйсынган Нократ биләре XIV—XVI йөзләрдә ханлыкның зур бер өлкәсенә—Арча даругасына хаким булып торганнар. Шунлыктан, аларны «Арские князья» дип тә йөрткәннәр. Казан ханлыгы чорында үк «Арча даругасы» дип аталган административ-территориаль өлкә XVIII йөз ахырларына кадәр шул исемдә йөртелгән. Әгерже төбәгенең Иж һәм Биме елгалары буйларында урнашкан күп кенә авылларның тарихы Нократ татарларына бәйле. XIX йөздә төбәкне тикшерүчеләр дә бу тирәдәге авылларның бик әүвәлдә нигезләнгәнлекләрен язып калдырганнар. Бу тирәдәге татар авылларын һәм, гомумән, татарларны якындагы чирмешләр һәм удмуртлар «почорман» (мөселман) дип йөртәләр. Ә Нократ татарлары

арасында «бисермән» дип аталган этник төркем элек тә булган һәм хәзер дә бар. Аларны да Нократ татарлары «почорман» дип йөртәләр. Кайбер тел галимнәре исә моңа нигезләнеп, Кадыбаш авылы һәм бисермәннәр арасында бәйләнеш бар дип язып, ялгышалар. Тарихтан мәгълүм булганча, XIV йөз ахырларыннан башлап, аерым бер дәвердә, рус елъязмаларында болгар-татарларны «бисермән» дип язганнар. Һәм бу атама тулаем мөселман, ягъни татар мәгънәсенә тәнгәлләштерелгән. Әгерже ягындагы башка халыкларда Кадыбаш авылын гына түгел, барлык татарларны «почорман» дип әйтү сакланган икән, бу әле аларны «бисермән» этник төркеме белән турыдан-туры бәйләү өчен дәлил түгел.

Галимнәрдән М.Әхмәтжанов, Д.Исхаков һәм Д.Рамазанова хезмәтләрендә Салагыш, Рыс, Баржы, Уразай авыллары Нократ татарлары (Ильяс авылында яшәгән Кара Бик нәселенең Жанчура би токымнары) тарафыннан нигезләнгәнлеге язылган. Ләкин галимнәрнең бу төбәккә Нократ татарлары 1642 еллардан башлап килгәннәр дип язуларына соңгы табышлар бераз төзәтмә кертә. Чөнки Баржы авылының 1598 елда нигезләнү факты Нократ татарларының Әгерже җирлегенә күпләп күчеп урнашуы XVI йөз ахырларында ук булуын раслый.

Көчек, Иске Аккужа, Олы Баржы, Балтач, Салагыш, Уразай, Ямурза, Исәнбай, Иске Сләк, Кадыбаш авылларында сакланган риваятьләр һәм нәсел шәҗәрәләрендә бу авылларга Нократ татарлары нигез салганлыгы турында сөйләнә. Риваятьләр, үз нәүбәтендә, бу төбәктәге борынгы шәҗәрәләрне раслыйлар. Ә шәҗәрәләр исә Нократ татарлары арасында сакланган Кара бик шәҗәрәсенә тоташалар. Кара бик нәселе шәҗәрәсендә Уразай, Жанморза, Мәдияр, Ырыс, Исәнбай исемнәрендәге шәхесләр телгә алынган. Авылларның нигезләнүен әлеге шәҗәрә белән бәйли торган Әгерже төбәгендә дә шушы ук исемнәрдәге авыллар булуы—очраклылык түгелдер. Сүз уңаеннан шуны да әйтергә кирәк, Әгерже районына күрше Удмуртиянең Камбарка шәһәрен дә тарихчылар Кара бик шәҗәрәсендәге Канбар (Ханбар) бигә нисбәтле дип язалар. Этнограф галимнәр Әгерже һәм Нократ татарларының йола һәм гореф-гадәтләрендә дә уртаклыклар булуын ачыклаганнар. Өстәп шуны да әйтергә кирәк. Безнең тикшеренүләрдән ачыкланганча, Әгерже төбәгендәге кайбер авылларда XVI гасыр ахыры—XVII гасыр башларында Нократ татарлары килеп урнашканчы ук татарлар яшәгән. Мәсәлән, Салагыш, Көчек авылларында электән яшәгән татарлар янына Нократ татарлары яңа бер төркем буларак килеп кушылганнар. Кайбер авылларда сакланган риваятьләр дә моны раслый. Мәсәлән, Салагышта Нократтан килгән Жанчуриннар, Касыймовлар турында хәзер дә сөйлиләр. Шунлыктан бу яклардагы аерым авылларга нигез салынуны тулаем Нократ татарларына нисбәт итү дөрес булып бетмәс.



Стәрлетамакка татарларны күчерү турында Әби патша фәрманы. XVIII гасыр.

М.Әхмәтжанов язуынча, рус хөкүмәте алдындагы хезмәтләре өчен XVI гасыр ахыры—XVII гасыр башларында Нократ морзалары Казан ханлыгыннан калган җирләргә хужа итеп утыртылалар. Шул рәвешчә, Әгерже, Арча, Биектау, Кукмара, Саба, Алабуга, Мамадыш төбәкләрендәге шактый мәйданда Нократ татарлары җирләр алып урнашканнар.

1598 елда Олы Баржы авылына Нократ татарларыннан бертуган Баженовларга рус патшасы фәрманы белән җир биләмәсе беркетелгән булуы ачыкланды. Кайбер мәгълүматларга караганда, Рыс авылы да шул ук елларда Нократ татарлары тарафыннан нигезләнгән. Рыслыларның Кама аръягында да күп кенә җирләре булган. XVII йөз архив

документлары да Баржы һәм Салагыш авыллары тирәсендәге жирләрнең морза Хужасәетовлар биләмәсендә булуын раслый. Кара бик нәселенә нисбәтле Хужасәетовларның Арча ягында һәм Бәләбәй өязендә дә биләмәләре булган. Нократ татарларының моңдый өстенлекләре XVII йөз ахырларынача дәвам иткән. Ә XVIII йөздә төбәгебез татарларының жир биләүче катлам вәкилләре үз жирләренә хужа булу хокукын белдергән «башкорт» сословиесенә язылганнар. Ягъни, жиргә хокуксыз, ясаклы дәүләт крәстияннарыннан аермалы буларак, XVIII йөздән жирле татарларның бер өлеше башкорт сословиесендә йөргән.

Бу очрактагы «башкорт» сүзен һич тә хәзерге башкорт халкы белән бутарга ярамый. Бу катлаулы мәсьәләне тикшергән галимнәр «башкорт» атамасы аерым тарихи чорда ике: этник һәм ижтимагый мәгънәне белдергән дигән нәтиҗәгә килгәннәр. Әгерже төбәге очрагында «башкорт» сүзе этник, ягъни халык мәгънәсен белдермичә, бары тик ижтимагый һәм территориаль берәмлекне аңлата торган термин буларак кулланылган. Территориаль дигәндә, бу жирлектә яшәгән салым түләүче халыкның XVII–XIX йөзләрдә формаль рәвештә Уфа провинциясе (соңрак өязе һәм губернасы) идарәсенә күчүләрен аңлата. Ягъни, Уфа идарәсенә бәйле халыклар (татар, башкорт, чирмеш, удмурт һәм чуашлар) аерым бер дәвердә рәсми документларда башкорт дип язылганнар. Мәсәлән, Баржы, Салагыш һ. б. авыллардагы Нократ татарлары да әүвәлрәк йомышлы (служилый) татарлар булып язып йөртелсәләр, 1750 еллардан башкорт яки типтәр дип теркәлгәннәр. Дөрес, хәзерге кайбер башкорт галимнәре, үз халыкларының исәбен арттыру һәм тарихын киңәйтеп күрсәтү өчен максатчан рәвештә ике мәгънәне бергә кушалар, шул рәвешчә тарихи дөреслекне һәм халык фикерен бутыйлар.

Башкорт булып язылу, заманына күрә, үз жир биләмәләрен саклап калу өчен бер чара булган, шулай ук башка төр өстенлекләр дә биргән. Тарихтан билгеле булганча, XVIII-XIX гасырларда бу төбәктә жиргә ия булган һәр кеше рәсми документларда «башкорт» дип теркәлгән. 1730 елда Казан, Себер һ. б. өязләрдәге (Әгерже ягы ул чорда Казан өязенә кергән) татарларның бик күп өлеше, шулай ук мордва, чуаш, чирмеш һәм удмуртларның, хәтта русларның да авыллары-авыллары белән тулаем башкорт булып язылганлыкларын белдергән мәгълүматлар сакланган. Кыскасы, Әгерже төбәгендәге «башкортлык» хәзерге мәгънәсендәге башкорт халкын, ягъни этник берәмлекне, милләтне белдерми. Ә бәлки үз жир биләмәләре булган «вотчинник» татар сословие-катламын белдерә. Әгерже төбәгенең Исәнбай, Сләк, Үтәген, Иске Аккужа, Яңа Аккужа, Көчек, Олы Баржы, Салагыш, Девятерня һ. б. авылларындагы халыкның бер өлеше элек башкорт сословиесендә булганнар. Бу очракта «башкорт» атамасы, алда әйтелгәнчә, жиргә карата һ. б. мәсьәләләрдәге хокукларның үзенчәлеген белдерүче рәсми социаль термин булганлыгын истән чыгармаска кирәк. Архив документларында да аларның еш кына «башкирцы из татар» дигән гыйбарә белән белдерелүе–мона ачык дәлил. Әгерже төбәгендә «башкорт» булып теркәлгән татарлар һәм чирмешләр күп кенә жир һәм урманнарга ия булганнар. Бу сословиедәге һәр жан башына уртача 30 дисәтинәгә якын (1 дисәтинә 1 гектардан бераз артыграк) чәчүлек һәм урман жире туры килгән. Чәчүлек жирләрне һәм печәнлекләрне хужалары үзләре эшкәртмичә, еш кына рус крәстияннарына арендага биреп торганнар. Шулай ук Салагыш, Исәнбай, Девятерня, Иске Аккужа һ. б. авылларда яшәгән халыкның Кама елгасында һәм үз биләмәләрендәге күлләрдә балык тоту урыннарын XVIII йөздә Пьяный Бор, Каракулино һ. б. авыл русларына, Усаклы һ. б. авыл чирмешләренә 5-25 ел дәвамына файдалануга биреп торганлыкларын дәлилли торган архив материаллары бар. Соңрак ул биләмәләрнең бер өлешен руслар һәм чирмешләр үзләренә сатып та алганнар.

Рәсми кәгазьләрдә «башкорт» сословиесенә караган мондый татарлардан тыш бу төбәктәге авылларның кайберләре икенче бер катлам–«типтәр» сословиесенә нисбәтле. Мондагы «типтәрләр»нең бер өлеше электән жир хокукына ия «вотчинниклар», икенче өлеше соңрак Кама аръягыннан күчкән чирмешләр–«припущенниклар» булган. Мәсәлән, Олы Баржы, Кече Баржы, Девятерня, Кадыбаш, Кичкетаң, Касай, Нарат, Мүшик, Рыс, Салагыш, Уразай авыллары, нигездә, типтәрләр дип язылганнар. Алар 1859 елдан башкорт сословиесенә күчерелгәннәр. Шул ук авылларда яшәгән халыкның бер өлеше дәүләт крәстияннары (ясаклылар) сословиесендә йөртелгәннәр.

XVII йөз ахырында Әгерже төбәгенең Тугызбуй ягына, нигездә, чукындырудан качып, соңрак, 1798-1799 елларда, Минзәлә өязеннән чирмешләр дә килеп урнашканнар. Биме, Күләгәш (Калагыш) һәм Зур Пиләмеш елгалары арасындагы жирләрнең 1691 елда чирмешләргә бирелүе архив документлары белән раслана. Мондагы барлык

чирмеш авылларында, ягъни Бима, Пиләмеш, Байтуган, Кадрәк, Ташлы, Күләгәш, Мандык, Ожбуйда яшәгән халык та элек типтәрләр буларак язылганнар[1]. 1859 елдан алеге чирмеш типтәрләре дә башкорт сословиесенә күчерелгәннәр. 1886 елда Алабуга өязендәге чирмеш авылларында (күпчелеге хәзерге Әгерҗе төбәгенә керә) 2367 чирмеш башкорты булган. Чирмеш авыллары Әгерҗе районының көньяк-көнчыгыш өлешендә, нигездә, Бима елгасы тирәсендә урнашканнар. Шунысы кызыклы, бу төбәктәге 8 чирмеш авылы—һәммәсе дә чукындырылмаган, үз мәҗүси диннәрен саклаганнар. Элек-электән татарлар белән күршедә дустанә һәм мөселман татарлар йогынтысында (изүендә-кыерсытуында түгел!) яшәү сәбәпле, аларның күпчелеге татар телендә яхшы сөйләшкәннәр, хәзер дә беләләр. Шулай ук алардагы кеше исемнәренең дә шактый өлеше борынгы төрки-татарча, хәтта гарәп теленнән кергән исемнәр булуы кызыклы. Мәсәлән, Әгерҗе төбәге чирмешләрендә Акбулат, Алтынай, Ишморза, Байморза, Асылбай, Туктар, Сабит, Иштуган, Максут, Сарманай, Ишбулды, Рамазан һ. б. исемнәр булган һәм бар.

Соңгы дәвер Башкортстан галимнәре арасында, ачыктан-ачык фальсификациягә һәм ялганга барып, Әгерҗе төбәгендә яшәгән һәм тарихның аерым бер чорында башкорт һәм типтәр сословиесендә теркәлгән җирле татар һәм чирмеш халкын хәзерге башкорт халкының бер өлеше дип язучылар бар. Ә кайбер башкорт галимнәренең хезмәтләрендә элек-электән чирмешләр генә яшәгән авылларда, имеш, чирмешләр белән бергә башкорт халкы да яшәгән дигән сафсаталар язалар. Мондый уйдырма әкиятләр, әлбәттә, чын тарихтан бик ерак.

Татар тарихында крепостнойлык—сирәк булган күренеш. Алдарак телгә алынган Тирсә волосте алпавытлары—татар морзалары Яушевлар—XVI йөздән алып XVIII йөз башына кадәр мондагы җирләрнең бер өлешенә (Тирсә, Нажар, Аккужа, Көчек авыллары) ия булганнар. 1720—1730 елларда Яушевларның җирләрен татар морзасы Котлыгмөхәммәд Тәфкилев сатып ала. 1764 елда бу төбәктә алпавыт Тәфкилев карамагындагы Тирсә, Мордывый, Юр (Ишкашар), Нажар һәм Чишмә авылларындагы крепостной крәстияннардан ир-атлар 515 кеше булган. Тәфкилевләр үз биләмәләрен даими низаглар һәм мәхкәмә эшләре аша арттыра барганнар. Шул рәвешчә Тәфкилевләрнең Тирсә волостендәге гомуми җирләре 43 мең дисәтинәгә якын була. Нәтиҗәдә, 9 татар авылының—Тирсә, Нажар, Тоба, Чишмә, Биектау, Мордывый, Балтач, Татар Шаршадысы һәм хәзер Удмуртиягә керә торган Бакыр Заводы (Варзино-Алексеевск) авылының җирләре һәм Иж елгасының ике ягындагы шактый урман-болыннар Тәфкилевләр һәм алар токымыннан булган алпавытлар биләмәсенә кергән. 1858 елда Тәфкилевләр токымының бу төбәктә барлыгы 2850 крепостной крәстияны булган. Бу авылларның кайберләрендә алпавытка бәйле крәстияннар белән бергә бәйсез дәүләт крәстияннары да яшәгән.

Патша Александр II нең крәстияннарны крепостнойлыктан азат итү турында 1861 елгы 19 февраль Манифестына кадәр бу авыллардагы халык аеруча михнәттә яшәгән. 1861 елдан соң крәстияннарга җан башына дүртәр дисәтинә җир бүлеп бирелгәннән калганы һаман да алпавытлар карамагында булган. Шул еллардан башлап элекке Тәфкилевләр җирләренең бер өлешенә руслар күчерелеп урнаштырылган, шулай ук Алабуга һәм Сарапулның Ижболдин, Щерлин, Вешняков кебек рус сәүдәгәрләре һәм Әхмәтшакир Заитов, Латыйп Вахитов кебек җирле татар сәүдәгәрләре сатып алганнар.

Алпавыт Тәфкилевләр уңаеннан алар нәселенең чукынган булу-булмаулары мәсьәләсенә тукталыйк. Чөнки, бу хакта тарихчы Искәндәр Гыйләҗев тәфсилләп язып чыгуга карамастан, һаман да төрлечә уйлаучы-язучылар бар. Тәфкилевләр, чукынмаган татар морзаларының биләмәләрен тартып алу турындагы мәгълүм патша фәрманы булса да, Әгерҗе төбәгенең Тирсә волостендәге крепостной җирләрен саклап калганнар. Бу җирлектә 1720 елдан башлап крепостной татар авылларына ия булган Тәфкилевләрнең әүвәлгесе—генерал-майор дәрәҗәсендәге Котлыгмөхәммәд—1756 елда Тирсә авылындагы мөселман зиратында җирләнгән, каберенә мөселманча таш язып куелган. XIX гасырда Сәлимгәрәй Тәфкилевнең мөфти итеп сайлануы, бу нәселдән Тирсә волостендә киң җир биләмәләренә ия булган башка тармакларының да милек һәм мирасларын мөселман шәригате буенча бүлүне, үзләрен мөселманча җирләүне васыять итүләре—чукынмаган булуларын ачык дәлилли. Ә рус документларында исемнәрен

[1]XVII гасырның беренче яртысында Иж-Бубый авылын нигезләгән чирмешләр, болардан аермалы буларак, «ясаклы» дәүләт крәстияннары булып исәпләнгәннәр.

параллель рәвештә русча да йөртүләре—башка мәсьәлә. Бу—Тәфкилевләр нәселе тулаем чукынган булган дигән нәтиҗә ясарга дәлил түгел. Хәтта мөфти башы белән Сәлимгәрәй Тәфкилев тә рус документларында еш кына «Александр Петрович» буларак язып йөртелгән.

Әгерҗе зираты. 1893 елгы кабер ташы.

Әгерже төбәгендәге татар авылларының янә бер өлешен, 1552 елда Казан дәүләте жимерелгәч, рәхимсез колонизация һәм көчләп чукындыру афәтеннән качып күченүчеләр нигезләгән. Казан арты төбәгеннән (кайбер риваятьләргә караганда, Саба һәм Кукмара якларыннан) килгән татарлар Иске Кызылъяр, Кодаш, Кыдырлы, Сокман, Тәбәрле, Төрдәле авылларын нигезләгәннәр. 1917 елга кадәр аларда яшәгән крәстияннар «ясаклы», ягъни дәүләт крәстияннары булып исәпләнгәннәр.

XVII һәм XVIII йөзләрдә шулай ук Казан якларыннан һәм мондагы авыллардан күчеп чыгучылар Иж-Бубый, Кырынды, Кече Баржы, Куран, Бетсемәс, Мәрдәш, Сәгәлде һ. б. татар авылларын оештырганнар. XIX йөздә шушы төбәк кешеләре һәм күрше төбәкләрдән килүчеләр тарафыннан нигезләнгән Гали, Атнагул, Яңа Бәзәкә, Чокырча һ. б. татар авылларын атарга мөмкин. XX гасыр башында, бигрәк тә 1920 елларда, төбәктәге зур авыллардан аерылып чыгу исәбенә, оешкан татар авыллары да шактый. Саклау, Яңавыл, Бәрләт Авыл, Сәхрә, Мәдъяр, Чәчкә, Тукай һ. б. шундыйлардан.

Тарихның төрле дәверләрендә Әгерже төбәге халкы чит жирләргә дә күчкән. Төбәктәге халык саны даими үзгәреп: кимеп яки артып торган. Хәтта кайбер авыллар кайчак бөтенләй бушап та калганнар. Аларга яңадан кешеләр килеп урнашкан. Мәсәлән, 1678 елда ир-атлар саны 100 кешене тәшкил иткән Көчек авылында 1710 елда 12 кеше генә яшәгән һәм бу авыл 1716 елда бөтенләй бушап калган. 1710 елда 4 хуҗалыгы булган Тансар авылы да, кешеләре күчеп китү сәбәпле, 1716 елда буш булган. XVII-XVIII йөзләрдә хөкүмәтнең колониаль изүе көчәйгән саен төбәк халкы үз нигезләрен калдырып, күпләп көнчыгышка—Кама аръягына һәм Урал буйларына, башкорт далаларына күчкән. Мәсәлән, 1710—1716 елларда Әгерже ягындагы 24 авылдан барлыгы 439 кеше күчеп киткән. 1720-1725 еллар арасында да бу якгагы авыллардан (Әгерже, Чишмә, Тәбәрле, Сокман, Иске Аккужа, Баржы Омга, Баржы Пельга һ. б.) ике йөзләп кешенең башкорт арасына качып киткәнлеге мәгълүм. Бу процесс XVIII йөзнең урталарына хәтле өзлексез дәвам итеп килгән. Әгерже төбәге татарлары XVIII гасырның беренче яртысында Кама аръягындагы Әгерже, Мәллә елгасы буендагы Дәүләтбакты һ. б. авылларга, Урсалы елгасы буендагы Шәрләмә авылына күчкәннәр. Шул ук яклардагы Ахун, Кәтем, Жәүләү, Камыш Тамак һ. б. исемле авылларга да күчеп киткәннәр. 1744 елда Оренбург Каргалысына патша фәрманы белән күчерелгән 200 татар гаиләсенең (ир-атлар саны 996) уникесе (ир-атлар саны 53) Әгерже ягындагы Иске Аккужа, Иж-Бәйки, Биектау һәм Нажар авылларыннан булган.

XVIII һәм XIX гасырларда алпавыт Тәфкилевләрнең Тирсә волостенә кергән крәстияннары еш кына качып киткәннәр. Аларны исә эзләтеп кире кайтартканнар, хөкемгә биргәннәр. Чит-ерак жирләрдә төпләнеп калучылары да булган. Мәсәлән, хәзерге Ютазы районының Акбаш авылын нигезләүчеләр—морза Йосыф Тәфкилевтән качып киткән крәстияннар булуы турындагы риваять сакланган. Риваятькә караганда, бу авылга 1770 елларда Иж буендагы Акбаш авылының (шулай ук Сәет авылы дип тә әйтелгән) 18 гаиләсе күчеп килүе сөйләнә. Ләкин Иж буендагы Тирсә алпавытлары карамагында һәм, гомумән дә, бу якта Акбаш исемендәге авыл булмаган. Бу очракта Иске Аккужа авылы күздә тотылгандыр дип фаразларга мөмкин. Моннан тыш, Тәфкилевләр XVIII һәм XIX йөзләрдә Тирсәдәге үз крәстияннарын Бәләбәй өязенең Килем авылына, Балтачтан Бәләбәй өязендәге Яңа Балтач авылына, Мордывыйдан Уфа өязе Сарыкамыш авылына һәм алардан монда, шулай ук Касыйм өязендәге крәстияннарын

Тирсә авылына күпләп күчергәннәр.

Екатерина II патшабикәнең 1771 елгы 31 декабрь фәрманы нигезендә Алабуга өязенә кергән төрле татар авылларының дәүләт крәстияннарыннан 93 ир-ат гаиләләре белән (200 дән артык кеше) Оренбург губернасындагы яңа нигез салынган Стәрлетамак авылына күчерелгәннәр. Тарихтан мәгълүм булганча, Стәрлетамак Илек яткылыкларыннан олау белән китерелгән аш тозын Агыйдел буйлап җибәрер өчен 1766 елда пристань буларак салынган. Стәрлетамак—1781 елдан өяз каласы, хәзерге вакытта Башкортстанның Уфадан кала икенче зур шәһәре. Димәк, әлеге каланың нигезләнеп, нығып китүенә безнең төбәк татарлары да зур өлеш керткән. 1771 елгы фәрман буенча анда Кыдырлы авылыннан 33, Иске Кызылъярдан 25, Тәбәрледән 8, Сокманнан 7, Кодаштан 6, Тансардан 4 һәм Тобадан 1—барлыгы 84 ир-ат күчерелгән. Хатын-кызларның төгәл исәбе күрсәтелмәгән. Алар да шул ук санда булсалар, якынча 170 кеше күчерелгән дип фаразларга мөмкин.

XVII йөз ахырыннан Әгерже төбәгенә удмуртлар килеп төпләнә башлый. Алар төньяк һәм төньяк-көнбатыш тарафлардан, көчләп чукындыру сәясәтеннән качып, мәселман татарлар арасында үзләренә сыену урыны тапканнар. Удмурт авыллары электән өчәү булган: Баржы-Пельга, Сарсак-Омга һәм Бәрклят-Бодья. Бу авыллар хәзер дә бар. Дини җәһәттән Бәрклят-Бодья халкы электән үк чукынмаган, мәҗүси гадәтләрен саклаган, калган ике авылда мәҗүсилек тә, христианлык та бердәй дәрәҗәдә диярлек яшәп килә. Мәҗүси удмуртларда да Салих, Бикә, Алтынай, Гарифа, Хәдичә, Шәрип, Даут, Вахит һ. б. төрки-татар исемнәре кин кулланыла.

Әгерже төбәгендә руслар XVII йөзнең икенче яртысыннан соң гына яши башлаган. Төбәктәге иң беренче рус авылы—Пьяный (соңрак Красный) Борны Минзәлә өязеннән күчкән крәстияннар нигезләгән. Гомумән, бу төбәккә руслар, нигездә, дүрт дулкын булып килгәннәр:

1) 1660—1670 еллар (Пьяный Бор);
2) 1800—1815 еллар (Зуево, Ильинский, Азево, Иске Чекалда һ. б.);
3) 1850 еллар (Волково, Яңа Чекалда һ. б.);
4) 1860—1880 еллар (Иске Никольск, Сарсак-Әрәмә, Куран, Якшур, Чаж һ. б.).

Беренче һәм икенче дулкын булып бу якларга килгән элекке «удельный» руслар «башкорт» сословиесендә булган татарлардан арендага алып эшкәрткән җирләрен сатып алып төпләнә башлаганнар. Мондагы рус авылларын нигезләүчеләр, Пьяный Бордан башкалары, һәммәсе дә Сарапул өязеннән килгән. Алар, нигездә, Салагыш, Исәнбай һ. б. авылларның уртак милкендә булган җирләргә авыллар корганнар. XIX йөз башларында хөкүмәт ул җирләрне рәсми рәвештә казна карамагына күчергән. Өченче дулкын рус авыллары да шундый жир мәйданнарына килеп урнашканнар. Бу рус авыллары Әгерже төбәгенең көньяк-көнчыгыш өлешендә.

1811—1824 елларда төбәктәге дәүләт крәстияннары—татарлар—карамагында булган җирләрдән бер жан башына 15 дисәтинә нисбәтеннән артык булган мәйданнар казна, ягъни хөкүмәт милкенә күчерелгән. Нәтиҗәдә, Сокман, Тәбәрле, Мукшур, Кыдырлы, Татар Тансары, Кодаш, Иске Кызылъяр һәм Яңа Кызылъяр авылларының шактый мәйданнарны биләгән, нигездә, урманлы җирләре кисеп алынган. Казна карамагына алынган әлеге җирләргә Россиядә 1861 елда үткәрелгән аграр реформадан соң Вятка губернасының төрле өязләреннән рус крәстияннарын күчереп утыртканнар. Әлбәттә, татарлар арасына русларны күпләп күчерүнең, аграр сәбәпләре булу белән бергә, сәяси сәбәпләре дә булмый калмагандыр. Монысы инде Әгерже төбәгенә руслар килүнең дүртенче дулкыны. Бу төркем рус авыллары Әгерже районының үзәгрәк өлешендә, көньяк-көнбатышында урнашканнар.

Жирле татарлар монда русларның күчеп килүләренә каршылыклар да күрсәтеп караганнар. Ләкин баш күтәрүләр кискен бастырылган, гаеплеләр хөкем ителгән. Татарларның каршы килүләренең төп сәбәбе—көчләп христианлаштыру һәм руслаштыру сәясәтеннән курку. Мәсәлән, 1863 елда русларга жир бүлеп биргәндә Төрдәле һәм Кырынды татарлары кискен каршы төшәләр, зур гауга чыгаралар.

Ә XIX йөз ахырыннан 1920 елларга кадәр Әгерже төбәгендә нигезләнгән рус авыллары һәм хуторлары, нигездә, шушы жирлектәге рус авылларыннан аерылып чыкканнар. Болардан тыш 1840—1860 елларда төбәктәге кайбер татар һәм удмурт (Кырынды, Төрдәле, Хороший Ключ, Сарсак-Омга) авылларына да аерым рус гаиләләре килеп төпләнеп яши башлаганнар.

Әгерже төбәгендә XVII—XIX гасырларда иҗтимагый, дини, милли һ. б. мәсьәлә-

ләрдә еш кына баш күтәрүләр, низаглар, ыгы-зыгылар булып торган. Бу төбәкнең татар, чирмеш һәм удмурт халыклары XVII–XVIII йөзләрдә еш булган татар-башкорт күтәрелешләрендә, Пугачев восстаниесендә катнашканнар. Татар-башкорт күтәрелешләре, тарихтан билгеле булганча, патша хөкүмәтенең көчләп чукындыру һәм руслаштыру сәясәтенә каршы башланып киткәннәр һәм утлы сугыш шушы төбәкне дә–ул чаклардагы Алабуга һәм Сарапул өязләрен–биләп алган. Бу восстаниеләр патша хөкүмәте тарафыннан рәхимсез бастырылган. Нәтиҗәдә, крәстияннарның хокуклары тагын да чикләнгән, алар көчлерәк изелүгә дучар ителгәннәр.

Төбәктәге иң зур һәм дәвамлы крәстиян күтәрелешләре–ирекле крәстияннарны көчләп крепостнойлыкка теркәүгә һәм, гомумән, крепостной изүгә каршы баш күтәрүләр булган. Әүвәлрәк алпавыт Яушевлар, соңрак Тәфкилевләр, үз биләмәләрен киңәйтү максатында, даими рәвештә бу төбәктәге башка авылларның җирләрен ачыктан-ачык яки хөкем эшләре йөртеп үзләштерү сәясәтен алып барганнар. XVII йөздә Тирсә, Иске Аккужа, Көчек, Нажар авыллары белән Яушевлар, ә XVIII–XIX йөзләрдә Тәфкилевләр белән Көчек, Иске Аккужа, Иж-Бубый, Салагыш, Баржы, Баржы-Пельга, Иске Чекалда һ. б. авылларның крәстияннары арасында еш кына мәхкәмә эшләре булып торган. Әлеге суд-хөкем карарлары, әлбәттә, еш кына алпавытлар файдасына хәл ителгән.

Алпавытларның җәбер-золымнарына каршы Әгерже якларында беренче зур күтәрелеш 1742-1744 елларда, аннан соң 1764 елда була. Тирсә, Чишмә, Нажар, Балтач, Мордывый авыллары халкына күршедәге бүтән авылларның татарлары һәм удмуртлар да кушылган. Хөкүмәт гаскәрләре йөзләрчә кешенең җанын кыеп баш күтәрүчеләрне бастырганнар.

Ә 1773 елда Тирсә крепостнойлары, пугачевчылар бу тирәләргә килгәнче үк, Тәфкилев утарын туздырганнар, гаскәр оештырып, хакимлекне үз кулларына алганнар. 1774 елның җәендә Е. Пугачев үзенең төп гаскәре белән Әгерже авылына килә, Биектау, Тирсә, Сарсак-Омга, Тәбәрле, Сокман авыллары аша ул чордагы Казан–Пермь юлы белән Алабуга тарафына юнәлә. Пугачевчыларга Әгерже төбәгендәге күп кенә авылларның крәстияннары кушылып, Казанга яуга киткәннәр.

Крәстияннар һәм Тәфкилевләр арасындагы низаглар XIX йөздә дә дәвам итә. Мәсәлән, Шаршады елгасы буена, шул ук исемдәге авылны 1813 елда нигезләп урнашкан рус крәстияннары Тәфкилевләр биләмәсендә рөхсәтсез авыл коруда гаепләнәләр һәм күчеп китәргә мәҗбүр ителәләр. Мондый карар белән килешмәгән крәстияннар каршылыгы 1853 елның язында атлы гаскәр белән бастырыла. Рус крәстияннары башка урыннарга көчләп куыла. Ә Шаршады авылына крепостной татарлар күчерелә. 1905-1906 елларда да Шаршады авылы крәстияннары һәм алпавыт арасында чыккан җир низагы гаскәриләр ярдәме белән хәл ителгән.

Әгерже авылы татарлары элекке дәвердә якын-тирә удмурт һәм рус авылларына, Иж заводында яшәүчеләргә шом салып торганнар. 1830 елларда Әгержегә тәртип-сезлекләрне тыю максатыннан гаскәр китертелгән, авылның 100 дән артык ир-аты хөкем ителгән. Ул елларда халыкны үгетләү максаты белән хәтта Вятка губернаторы үзе дә Әгержегә килгән.

1861 елның җәендә Салагыш, Уразай, Ямурза авылларының уртак милкендәге һәм Азево авылы крәстияннары арасындагы бәхәсле җир мәйданы өчен чыккан гауга да дини һәм милли төсмер ала. Кыскасы, татар авылларыннан җыелган 150 дән артык кеше бәхәсле җирдә печән чабучы русларга һөҗүм итеп, аларны кыйнап, куып җибәрә, атларын, эш коралларын һ. б. кирәк-яракларын тартып ала. Ул гына да түгел, русларны авылларына кадәр куып, Азевоны туздырып-жимереп, Салагышка күп кенә «трофей» һәм берничә әсир алып кайтканнар. Бу вакыйганы тикшерү эше 1869 елга хәтле дәвам итә, гаеплеләр хөкемгә тартыла.

Россия империясенең көчләп христианлаштыру сәясәте Әгерже төбәгенә дә кагылган. Бу афәтне, нигездә, Кырынды, Мукшур, Төрдәле, Ямурза һәм Бетсемәс авыллары кичергән. Бу авылларда яшәүчеләрдән Кырынды татарлары тулаем, ә Мукшур, Ямурза һәм Бетсемәс өлешчә, Төрдәледә исә берничә гаилә XVIII йөзнең соңгы чирегеннән «яңа керәшен» булып исәпләнгән. Ләкин «керәшенлек» кәгазьдә генә булып, татарлар үзләрен һич тә христианнардан исәпләмәгән, ата-бабадан килгән гореф-гадәтләрен саклаган, иманын югалтмаган. Закон белән тыелса да, кача-поса ислам динен, татарча укырга-язарга өйрәнгәннәр, хәтта рәсми кәгазьләргә имза салганда да гарәп хәрефләре белән «Тихон Ибан улы» рәвешендә кул куя торган булганнар. Көчләп тагылган ят дин берегеп кала алмаган.